
# Казан утлары

8.1996





**«Татарстан — минем Ватаным!»**

Авторы — **Бакый УРМАНЧЕ.** *Триптих.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**8**

**(886)**

**1996**

КАЗАН


## *Бу санда*


ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

А. ХӘЛИМ. Кыйбла. *Хикәя* . . . . . . . . 3
Ф. ЯХИН. Ахырзаман пәйгамбәре. *Икенче китап* . . . . . . . . . . . . 32
Г. ГОМӘР. Мөһер. *Маҗаралы повесть* . . 85
Н. ӘМИНЕВА. Дустым буласыгыз килсә. *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . 119
И. СОЛТАН. Көшел-көшел уй. *Шигырьләр* . 126
Ф. ГАТИНА. Хәтер. *Поэма-баллада* . . . . 130

ӘДИП МАЛИКОВКА 75 ЯШЬ

Ә. МАЛИКОВ. Төрле еллардан. *Шигырьләр* 26

ХАРРАС ӘЮПКӘ 50 ЯШЬ

ЗӨЛФӘТ. Тыелгысыз кош сере . . . . . . 78
Х. ӘЮП. Хәтер тауларыннан. *Шигырьләр* . 79

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫННАН

Н. ХАҖИ ӘМИНУГЛЫ. Нишләргә? *Хикәя* 123

ПУБЛИЦИСТИКА

Н. ФӘТХУЛЛИН. Россиядә җинаятьчелекне җиңеп булырмы? *(Социологик уйланулар)* 133

ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫННАН

Бу нинди бәйрәм? *(Күренекле тарихчы, Татарстан Фәннәр академиясе академигы Миркасыйм Госманов белән әңгәмә)* . . . . . . 141
Р. БАТУЛЛА. Әбрар Сәгыйди . . . . . . 161

СӘНГАТЬ

Ш. ХӨСӘЕНОВ. Газап диңгезен әчеп . . . 148

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

А. САЯПОВА. «Кемгә тансык бу замана?» 164
М. ВӘЛИ. Каргышлы еллар . . . . . . . 168
Н. НӘҖМИ. Шагыйрь гомере . . . . . . 175
М. ГАЙНЕТДИН. Татар шәҗәрәләре . . . 178

«Казан утлары» архивыннан . . . . . . . 181

ӨЗ-МӨЗ ГЕНӘ МӘЗӘК

Ш. МАННАП. Мәзәкләр . . . . . . . . . 183

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . 188

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Тәлгат Галиуллин**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Булат Солтанбәков**
**Ренат Харис**
**Розалина Шәһиева**
**Харрас Әюпов**

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: рассказ А. ХАЛИМА «Кыйбла», роман Ф. ЯХИНА «Последний пророк», повесть Г. ГУМЕРА «Печать»; стихи А. МАЛИКОВА, Х. АЮПОВА, Н. АМИНОВОЙ, И. СУЛТАНА, Ф. ГАТИНОЙ.
«Со страниц тюркской литературы»: рассказ Н. ХАДЖИ АМИНУГЛЫ «Что делать?»
«Публицистика»: социологические размышления Н. ФАТХУЛЛИНА «Можно ли победить преступность в России?»
«Из истории народа»: интервью с известным ученым, академиком Академии наук Татарстана М. Усмановым.
«Искусство»: воспоминания Ш. ХУСАИНОВА о выдающемся татарском композиторе Р. Яхине.
«Память»: статья Р. БАТУЛЛЫ «Абрар Сагиди».
«Литературная критика»: статьи А. САЯПОВОЙ «Символизм в творчестве Дардманда»; М. ВАЛИЕВА «Проклятые годы»; Н. НАДЖМИ «Жизнь поэта»; М. ГАЙНУТДИНОВА «Татарские шеджере».
В номере отмечаются 70-летие А. Маликова и 50-летие Х. Аюпова.
Забавные истории Ш. МАННАПОВА.
«Дневник общественно-культурной жизни».
На наших обложках: шамаил Хансавара. Работа неизвестного автора; писатель Лирон Хамидуллин.

## IN OUR ISSUE

«Prose and poetry»: A. Khalim's story «Kibla», Ph. Jakhin's novel «The last Prophet», G. Gumer's narrative «The seal», the verses of A. Malikov,
Kh. Ayupov, N. Aminova, I. Sultan, Ph. Gatina.
«From the pages of the turkic literature»: N. Khadja Aminugla's story «What to do?».
«Publicism»: N. Phatkhullin's socialogical reflection «If one can conquer crime in Russia».
«From the history of nation»: the interview with the academician of Academy of sciences of Tatarstan M. Usmanov.
«Art»: Sh. Khusainov's recollection about the eminent tatar composer R. Jakhin.
«Memory»: R. Batulla's article «Abrar Sagidi».
«Literary gritique»: articles of A. Sayapova «Sombolism in the creative-work of Dardman, M. Valiev «Damned jears», N. Nadjmi «Poet's life», M. Gainutdinov «Tatar shedjer».
The Zoth anniversary of A. Malikov and the 50 th anniversary are celebrated in the issue.
Sh. Mannapov's funny stories.
«The diary of the social and cultural life».
In our covers: shamail «Khansavara». The work of the unknown author; the writer Liron Khamidullin.

- Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.
- Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
- Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шәһинур Мостафин, Тәүфикъ Әйди.**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 2.07.96 ел. Басарга кул куелды 6.08.96 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 $^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 10 459. Заказ Е-349.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1996 ел.

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Айдар Хәлим**

## КЫЙБЛА

хикәя

*Фатих абый Хосни истәлегенә*

I

Июль башлары иде.

Өммегөлсем карчык гомерендә кичермәгән җиңеллек, канатлы тойгы белән уянды. Кичәге ниятләрен хәтерләп, күңеленнән генә кабатлады: «Ходавәндә, хәлиулла, догаларым кабул әйлә...» Күз кабакларын күтәрер-күтәрмәс, тәрәзәләргә сирпелеп алды — йә Раббым, таң аткан. Кадимге көннәрдәгечә, аны кабат-кабат уятып һәм уйларга салмыйча, ничектер песинекедәй йомшак тәпиләрдә, сиздермичә кергән аларның йорт-курасына бүгенге таң. Ул үзе дә карт буыннарын бер учка җыйгандай җыеп, шыгырдатмый-нитми, песиләрчә йомшак басып, шым гына урыныннан күтәрелде, гүяки, мамык табаннары белән идәнгә сарылды һәм тәрәзә пәрдәсен бер читкә шудырды — әйе, таң аткан, аткан гына дисеңме, баеп аткан: гадәттә Юкәле Кул өсләреннән бүселеп чыгып, шактый вакытларга оеп калучан таң сарысы бүген инде сөт өсте булып тәрәзәләрдә агарып та килә; әмма бу беренче карашка гына шулай, күңел күзе белән илтифат итсәң, Өязенең вак таллы үзәнлегенә куе томан ишелеп төшкән; тигезлеккә чыккан, бу тарафка якынайган саен томан кояшның әлегә күренмәгән ерак нурларын күктән тотып алып, сиздерми генә сеңдереп, үзен шактый гына сыеклый һәм шау чәчкәдә утырган бәрәңге бакчасы, гүя, вак җиз иләк аша мөжмелдәп зәңгәрләнә; ә менә якында, ишек алдындагы бәбкә үләне өстендә, томанның әсәре дә юк, анда сәйләнсыман чык тамчылары тәгәрәп ята...

Урын өстен бармак йомшаклары белән генә элләктереп алып җыештырып, кыштырдатмый, иске агач караватсаңакларын шыгырдатмый-нитми, ул үзе яткан алгы якны түргә як белән бүлеп торган канатлы ишек катына килде һәм колагын куйды — Гарифулласы зыянсыз гына гырлап йоклавын дәвам итә иде...

Киез олтыраклы галушларын эләктереп, җәһәт кенә тәһарәт алып керде һәм каз тәпиләре чигелгән намазлыгын җәеп, иртәнге намазына керепте. Шөкер, Ходай саулык-сәламәтлектән аермаганда, биш вакыт намазын да, башка фарызларын да калдырмый. Ә менә Гарифулласы бу фарызларны... Юк, юк, үти алмый, үтәргә теләми дип әйтергә теле бармый Өммегөлсемнең! Әллә ничек инде шунда, бер сүз белән генә әйтүе дә читен. Югыйсә, намаз-тәгъбир мөселман йөзенә нур булып калка да бит. Әмма Гарифулла белән мәсьәлә икенчерәк шул. Инде ничә мәртәбәләр ялынып-инәлепләр дә карады каравын. Гарифулланың теңкәсенә дә тия алмый Өммегөлсем, ни дисәң дә, ир кеше, рәвешләре, холыклары, күргән-кичергәннәре икенче... «Гомереңне иблискә табындырып үткәрсеннәр дә, инде гүр якасына җиткәч кенә намазлык өстенә менү, әллә кемнәр кебек кичә коммунист булып, бүген ишанга әйләнү — моннан да зуррак иблислек бармы?» — дип кырт кисә дә куя ул.

Искене яхшы белә белүен. Аңа, мәзин баласына, ислам догасы ана сөте, бишек җыры белән сеңдерелгән, Иман шарты, Коръән Кәрим сүрәләр, догалыкларны да яхшы хәтерли, Аллага шөкер, тел дә тидертми... Әмма күңеле каткан. Ә кеше бер катса, тиз генә җебеми, йомшармый икән ул. Ярар, нишлисең, Ходай Тәгалә булган гөнаһларын ярлыкасын, урыннарын җәннәтле итә күрсен иде... Кеше уйлый — тәкъдир йөртә, дип юкка гына әйтмәгәннәр бит. Югыйсә, аның Гарифулласында пәйгамбәрләргә хас гыйзмәт, явызлык эшли алмау сыйфаты бар. Шуңа күрә ул үз авылында таныла алмады. Алла алдында акыллы кеше генә җаваплы, акылсыз җаваплы була алмый, ди китап...

Гарифулланың күңелен бала чактан ук сындырганнар шул. Дәһрилек кузгалып кына килгән заманнарда табын артында амин тотып утырган җиде-сигез яшьлек сабыйны актив Өтәләү Зариф наган төеп куркыта, аңа хәттә өянәк тә ябешә — баланы бу авыр хастадан Тәүәтәй мулласының им-томы гына коткарып калды, дип сөйлиләр иде Өммегөлсемнең бианасы белән биатасы. Бахыркаем догасын инде сәке астына качып укый башлый. Монысын да күреп калган комсомоллар сәхнәдән генә түгел, Садретдин мәзиннең өе каршына килеп әйтәләр оятсыз такмакларын:

Ак та була, күк тә була<br>
Шатманнарның туласы.<br>
Сәке астында әппәр итә<br>
Садрый Гарифулласы...

Намазын онытылып, мөкиббән китеп башкарырга тырышса да, карчыкның башында кырыкмаса кырык уй иде. Гыйбадәтенең һәр тәгъбире, һәр авазында Ходай Тәгаләгә бер генә теләк, бер генә үтенеч, бер генә гозер иде: бүген әнә шул Әкчин дигәннәренә барып, ниятне җиренә җиткереп үтәрлек дәрт һәм дәрман гына бирсәң иде, и Тәңре!.. Гарифулласы кире генә уйламасын иде, и Тәңре!.. Иртәнге намазы адәм балалары буй-сынындагы өч йөз алтмыш буыны хакына кояш чыкканда биргән сәдакасы булсын иде!.. Бу якты дөньяда барча адәми затларга күрсәткән ачык чырае, тәмле сүзе, сәламе дә сәдака булып барып ирешсен иде!.. Бу иманның үзе түгелме? Иман булмаса, җавап юк, димәк ки, савап юк, җәннәт юк, җәһәннәм юк. Димәк ки, иман булмагач, адәмзат бер үк куллар белән дога кыла һәм кеше үтерә... Йә, Хода, адәмнәреңне ярлыка! — дииоемне тулысы белән кабул әйлә, ярты мөселман — ярты иблис, ярты шайтан дигән сүз!..

Әкчингә барып кайту соңгы вакытларда аеруча тынгы бирмәде Өммегөлсем карчыкка. Теге вакыйгаларга илле ике ел үтүгә карамастан, аның беркайчан да бу кадәр ярсыганы-йөрәксегәне юк иде. Югыйсә, Әкчин стансасы Шатманнан әллә ни качкан җирдә дә түгел — җитмеш чакрымда гына. Хәзер машинасы тыз-быз килеп торган заманда эһ дигәнче генә барып кайтасы булган да бит...Насыйп итмәгән, тәкъдир дәфтәренә язылмаган булган, күрәсең. Аннан, нигә ди аның афтавызы —

авылда үзләре белән бер канат астында яшәгән дип әйтерлек ике улының, житмәсә кияүләренең дә ялт итеп торган җиңел машиналары бар, әйт кенә! Әмма карчыкның бу изге, сирәк йоланы бер үзе, кеше-кара күзеннән читтәрәк башкарасы килә шул. Сугыш янбалиты Гарифулласын да бу өзлеккән заманнарда юлга ялгыз чыгарга курыкканга күрә генә алырга мәҗбүр үзе белән... Быелгы йөрәксенүен карчык Мәскәү хөкүмәтенең ырадиусыннан да, тилевизорыннан да бер туктаусыз: «Бөек җиңүгә илле ел! Бөек җиңүгә илле ел!» дип кычкыруы белән бәйли. Бу кадәр кан коеп, бу кадәр үгиселеп җиңүне карчык үзенә бирелгән табигый акылдан чыгып, һич кенә дә бүгенге телсезлек-денсезлек белән бер бизмәнгә сала алмый аптырый һәм җәфалана иде. Кем җиңде соң монда? Урысмы, нимесме? Ватан сугышы аның өчен бары тик сугыш, рәнҗеш, мәгънәсез канкоеш кына иде югыйсә. Әгәр Әкчингә быел да бара алмаса, ул анда беркайчан да бара алмаячак кебек тоела иде Өммегөлсемгә...

Намазын тәмамлап, дөньяның дүрт тарафы, барча тереклек, барча милләт-кабилә, балалары һәм балаларының балалары хакына дога кылды. Аннан, гадәтенчә, картын уятмас өчен, моңлы тавышын үзеннән әллә кая җибәрми, тыелып кына мөнәҗәт әйтте. Сайланылган җәүһәр сүзләр белән кабатланмас мәкамнең кушылуыннан бар булган бу әсәр, кызганыч ки, әлегә кадәр Өммегөлсемнең һәм бары тик Өммегөлсемнең генә байлыгы иде. Әнисеннән отып алган бу җыруны ул инде менә ничәмә еллар башкара — иртәсен һәм кичен; яңгырда һәм кар-буранлы көннәрдә; күңеле күтәренке һәм бик тә төшенке чакларында; әмма мөнәҗәт аның күңелен туйдырмый да, маемлатмый да иде...

Ходавәндә, хәлиулла, догаларны кабул әйлә,
Өметем күп, рәхим Аллаһ, гөнаһым күп — гафу әйлә!
Әкерен алсаң җанымны иманымның нуры берлән,
Кыямәт көнем мөшәрраф кыйл сигез оҗмах нуры берлән!
Ля иляһа, кыйл гыйнаять барча эшкә сәйкәфил,
Әнтә раббым, әнтә хәсби, әнтә нигъмәти вәкил...

Тыкрык очыннан мал тавышлары ишетеп, тышка чыкты һәм абзарын ачып, ике сарыгын, ике кәҗәсен көтүгә куып керде дә чәен куйды. Вак күзле онга йомырка сытып, камыр туглады һәм карты яраткан кәгазь сыман юка битле коймаклар пешереп алды. Чәе кайнап, коймакларын таба төбендәге майда йөздергәч, сак кына, иркәләп һәм ярым пышылдап, картын уятты:

— Гарифулла... Гарифулла, дим... Чәй әзер...

Әчкелтем арыш ипие кебек гади игенче гаиләсендә «Хәерле кич! Хәерле иртә!» диган теләкләр кулланышта булмаган һәм ул төчеләнү, кәнфитләнү саналганлыктан, күрәсең, Гарифулла абзый сүзсез генә урыныннан күтәрелде, сүзсез генә тышка чыгып керде һәм сүзсез генә мич аралыгында электр утын «чек!» итеп кабызып, юынгычның телен шалдыр-болдыр китерә-китерә ач яңакларын, ияк асларын сабынлый башлады...

Бөркет танаулы, үткен карашлы, кар кебек ак башлы, бар тирә-якта килеш-килбәте, хәтта какчалыгы белән дә бер пәйгамбәргә охшаган мәһабәт, үзенчә ифрат дәрәҗәдә укымышлы, зыялы бу кешенең һәр иртәдә ничек кырынып азапланганын күрсәгез иде! Их, шул көндәлек кырынулар!.. Тагын да канга тузып, ертылып бетәр микән? Тәүлек дигәндә камыт энәсе шикелле эре, кыл кебек шыртлап торган сакал-мыек баса да китә бит, шайтан алгыры! Тирән буразналар, сай ерыклар белән ермакланып беткән яңакларны, шундый ук өзлеккән, муртайган тиреле ияк асларын, бугаз тирәләрен, бигрәк тә берсе өстенә берсе менеп беткән җыерчыклы бугаз төере тәңгәлендәге каты кылны кыру аның өчен, гүяки, үз тәнеңне кайрак белән кайрау, телеңне аркылы тешләп, таучарлактагы җиз үлән, кылган кыру кебек авыр мәшгулиятләрнең берсе иде. Менә ул әле дә кемнеңдер җиткән тырнаклар белән тупас киндер тукымасын

тырнаган авазлар чыгарып, кырына башлады. Кайчагында ул эченнән генә, көн саен болай газапланганчы, елына бер тапкыр бәби табып карауны җиңелрәк түгел микән дип уйлап, көлемсерәп тә куя...

Шулай ук сүзсез генә чәй эчтеләр алар — өйдә иреннәрнең чынаяк читендәге чәпелдәүләре генә ишетелә иде. Күп сүзне гомумән җене сөймәгән Гарифулласына Өммегөлсем карчык чынаягын яңарткан арада сирпеп кенә карап ала алуын — бу караштa һаман да шул бер өмет, бер теләк, бер гозер яшеренгән: хәтереннән чыгармаганмы кичәге вәгъдәиманын аның карткае?!

Белә, Гарифулла сүзне үзе башламаячак. Чәйне тәмамлап, тирән табакта шылтырдатып чынаяклар чайкаштырган Өммегөлсем карчык күкрәк төбеннән чыккан нәзберек, газаплы аһәң белән сорап куйды:

— Йә, карт, әйт соңгы сүзеңне... Кузгалабызмы?

Гарифулланың кырынганнан соң ике урынына гәзит кисәге ябештерелгән йөзе буйлап бугалак төеннәр йөгереште, күзләре яшәреп китеп очкынланды.

— Сөйләшкән идек бит инде, Гөлсем,— диде кырыс кына. «Өмме»ләрен кыскартып ташлап, ул аны шулай Гөлсем дип кенә йөртә. Карчыкның эченә җылы йөгерде.

— Әзерләник, алайса...

— Әзерлән, бәй.

Мәсьәләнең болай җиңел хәл ителүеннән Өммегөлсемнең куллары үзләрен тыңламас булып бәлҗерәп төште. Ул мич арасына керде, калтырана-калтырана кичә үк әзерләп куйган төенчеген яңадан актара, казына башлады — аңа кирәк булачак берәр нәмәстәкәен онытмаганмы, илаһым? Ул аның өчен бары тик зур хәрефтән әйтелә һәм языла торган Ул, Аңа, Аны, Аның иде. Аһ, дисбесе онытыла язган түгелме?

— Җилгә җиленләп, бозга бозаулап йөрергә вакыт юк,— диде киенеп тә беткән карт.— Кичкә әйләнеп кайтырга кирәк. Йорт-җир күз-колаксыз кала. Юлныкын белмәссең, бер-бер хәл булса, балаларга да әйтеп куймадык аны, югыйсә...

— Булмас, карт, булмас... Дөбер-шатыр әйләнеп кайтырбыз, Ходай кушса...

Озак та үтми, өстенә маршал Брежнев заманнарында ук тегелгән, якасына тимер әчесе чыгып күгәргән ике Бөек Ватан сугышы ордены беркетелгән, сирәк кулланудан бераз накыслана төшкән куе зәңгәрсу пинжәк, башына эчтән түбәтәйле ак салам эшләпә кигән, сары путаллы таякка таянып адым берәмтекләгән җитмеш сигез яшьлек Гарифулла карт, аның артыннан эре чәчәкле яшелле-зәңгәр кәшемир яулыгы, яшькелт озын күлмәге, шундый ук яшькелт бәйләм жимпере белән әллә кайлардан күренеп, кулындагы төенчеген җилли-җилли атлаган җитмеш биш яшьлек Өммегөлсем карчык тәүдә ике чакматаш бөртеге тыкрыктан яктырып, аннан, үзәк урамнан, яшелле-зәңгәр ике йолдыз сыман зурайганнан-зурая барып, Шатман очындагы автобус тукталышына якынлашып киләләр иде...

## II

Бәләбәй-Бөгелмә калкулыклары...

Җир асты сулары урталай бүленеп, чишмә-елгалар калкулыкларның иң биек таңгәлләрендә ярылып, бары тик көньяктан төньякка, төньяктан көньякка гына ага бу тирәләрдә. Автобус тәрәзәләрендә койрыкка койрык, яурынга яурын тәңгәл килеп, Европаның кысан тигезлекләреннән Азиянең иркен далаларына, Азиянең иркен далаларыннан Европаның кысан тигезлекләренә таба ялларында ут ташыган аргамаклар ташкыны сыман, тау-калкулыкларның өзлексез чылбыры чаба... Җир шарының ниндидер меридианнары, экваторы, калалары һәм салалары

өчен Вакыт төшенчәсе төрле булган кебек, бу калкулыклар чылбыры өчен дә Вакыт бүленеше бердәм һәм котылгысыз бердәм иде...

Атлар чаба: үткәннән — киләчәккә, киләчәктән — үткәнгә...
Аһ, бу төбәк һавасының татлылыгы, суларының салкынлыгы!..

Кайчандыр кешелек таңында Алты Ай һәм Урхан-Йәнәсәй киңлекләреннән һау-һаулап чыгып, бормаланып аккан Иртеш һәм Уралтаулар тезмәсе аша Европага ашкан, үзара ызгышта халыкларның бөек күченешен барлыкка китергән һуннар, шул ук Алты Ай, Урхан-Йәнәсәй кыяларында «Туган йирим — мәңгү бар!» дип ташны уеп, кешелеккә бөек ядкарь калдырган түрекләр, гасырлар аша шул ук Алты Ай, Урхан-Йәнәсәй бишегеннән ур-ра-а-лап чыгып, ярты дөньяны уратып, биләп алып, тарихы яңа гына борынлап килгән мәҗүси милләтләр һәм шивәләргә иман һәм дәүләтчелек бүләк иткән түрек-мангуллар, Идел дәрьясы һәм Хәзәр, Урта диңгез буйларындагы шәһәрләр, Атлантидалары, фәст дисбеләрс белән су астына киткән түрекләр, Эгей ярларына, кыйтгаларның бөек чукындыручылары — Рум башкисәрләре каршына басып, «Әһә-һә-һәй!» кычкырып, мондый көчләү, асу-кисүләргә чик куйган, кайчандыр шул ук Алты Ай, Урхан-Йәнәсәй тундраларыннан Чукыт ярымагавы аша Америка лабылыкларына үтеп, әстәк, әнкә һәм мая мәдәниятләрен тудырган Ату-алып — Ата Алып варислары түрек-татарлар, кайдадыр Океания утрауларында тәтенләп утырган Крәкәтау янартауларында яңа дәүләтләр барлыкка китереп, үзләре дәүләтсез калса да, юкка чыкмаган түрек-татар кавеменең ике гөнаһсыз баласы, ике чакматаш йолдызы — Гарифулла карт һәм Өммегөлсем карчык, һәркайсы үз уеп уйлап, Әкчин станциясына китеп бара... Аларның фикер алышыр нәрсәләре күп булса да, бәхәсләшер нәрсәләре юк. Гарифулла белә һәм беркайчан да онытмый: аты булса — дилбегәсе кулда; түбәтәй ничек кенә күркәм һәм түгәрәк булмасын, аның астына шулай ук күркәм һәм түгәрәк баш кирәк. Өммегөлсем карчык та белә һәм беркайчан да исеннән чыгармый: һәр киемнең ата һәм инә каптырмасы була; ал тәгәрмәч кая тәгәрәсә, арт тәгәрмәч тә шуннан тәгәри...

## III

ССР да таркалды. Нибары өч кеше тарката алгач, димәк, аның үзен дә өч кенә кеше оештырган булмады микән?

Тукта, бу ел ничәнче ел соң әле? Мең тугыз йөз дә туксан бишенче диләр шикелле. Булмас ла... Ә ничек исән калган ул? Бәлки ул үзе теге, чын Гарифулла түгелдер? Бәлки чын Гарифулла инде әллә кайчан козгыннарга азык булгандыр? Бәлки бүгенге Гарифулла ул ниндидер икенче, җен алыштырган Гарифулладыр?

Карт ирексездән көлемсерәп куйды.

Бигрәк тә өзек, төсе-яме качкан, эче-карыны киселгән заманнарга туры килде шул аның гомер башы һәм, гомумән, язмышы! Октябрь түнтәрелеше еннәрендә дөньяга килеп, тәүдә авыл мәдрәсәсендә этисе Садретдин мәзиннән өч сыйныф сабак алганнан соң, яңа мәктәп ачабыз дип, мәдрәсәне яптылар. Гарәп имлясы — искелек калдыгы, имеш. Шул мәктәпне көтеп, буразнага төшкән Гарифулла латинга күчкәндә ундүрт яшендә иде инде. Күмәк хуҗалыклашу дигән убыр утының Өязе буйларына шактый соңлап тәгәрәп килеп җитүе нәтиҗәсендә микән, утызынчы еллар башы Гарифулла күңелендә чагыштырмача тыныч еллар булып калган. Гарәп имлясыннан латинга сикереп, яңа язманы үз укучылары — шул ук Гарифуллалар белән бергә сөргән-тырмалаган кичәге мөгаллимнәр кулында тагын өч сыйныфны ордым-бәрдем тәмамлагач, авылда инде ак карачкыга әверелә башлаган этисенең киңәшен тотып, ул мыштым гына Бәләбәй укытучылар техникумына керә алды. Таныклыгының

хәлиткеч бүлемтегенә шул ук әтисе хәстәре белән, күрәсең, «дин әһеле баласы» диеп түгел, ә ярлы керәстиән диеп язылган иде. Ул укырга кергән 1934 елны Садретдин мәзинне шул «халхуз дигәннәре»нә аеруча көчли, кул-аякларын бәйләп диярлек өстери башладылар. Ай саен салына башлаган салымны түләп өлгерә алмагач, аларның өенә кулындагы шомполын талчыбык сыман итек кунычына шапылдатып, Өтәләү Зариф, Ак Керфек Сөнгатуллалар килеп керде. Авылда гына түгел, бар тирә-якта бердәнбер булып идәнгә беркетелгән «Зингер» тегү машинасын сайгагы-ние белән куптарып алып чыгып киттеләр. Авылның яңа хакимияте күптән түгел генә бөтен халыкны үз авызына каратып торган, гаять дәрәҗәдә абруйлы Садретдин мәзин белән сүз көрәштерүдән качып, аның гаиләсенә, бигрәк тә хатыны Мәүлидә абыстайга каныктылар. Әйе, техникумга урнашып кайткач төнгә каршы кичтә әнисе өйдә юк иде.«Кәнсәләргә мине түгел, һаман да шул әниеңне һәм Зәбих энекәшеңне алып киттеләр. Миңа күзгә чалынмаска куштылар»,— диеп, әтисе балтасы суга төшкән кеше затында аптырап утыра иде. Гарифулла кәнсәләр ягына китте. Әнисе белән энесен утсыз-нисез бүлмәгә шартлатып бикләгәннәр һәм сак куйганнар иде. «Бар, юньле чакта югал, югыйсә үзеңне ябарга да күп сорамабыз». Төне буе шул кәнсәләр тирәсендә йөреп, ай янындагы якты йолдыз кебек таң аттырды Гарифулла. «Ай янында якты йолдыз минем йолдызым гына, таң алдыннан ул да сүнә, калам ялгызым гына», дип җырланган халык сүзләренең мәгънәсен шактый аңлады ул төндә яшүсмер. Иртән көтү куганда чыгардылар аларны. Толымнары көмеш чулпылары белән бергә кисеп алынган, курашын җирдән күтәрергә оялган әнисе елап шешенгән һәм дистә елга картайган иде. Ул чакта авыл һавасы шартлар чиккә җитеп кызды, анда төнге мунчаларда яндырылган изге китапларның әче сөреме йөзде, мең ел эчендә тупланган рухи байлык көн эчендә хәерче кулына калудан куркып, черү һәм юкка чыгу өчен каберлекләргә, базларга, алмагач төпләренә күмелде һәм еш кына ачык авызлы чормаларга менде...

Үзе җырчы, үзе шигырьче Гарифулла техникумның җан шифасына әверелде. Алар куйган тамашаларның исәбе-хисабы булды микән? «Зәңгәр шәл», «Галиябану», «Беренче театр», «Асылъяр», аннан тагын ниндидер бер билгесез язучы Кадермәтнең «Дөрес алдакчы» дигән әсәре дә истә калган. Бәләбәй төрмәсендә Туктаров атлы Казан артисты утыра икән дигән хәбәрне ишеткәч, житәкчелеккә махсус хат язып, Туктаровны сак астында булса да репитиция һәм тамашаларга китертә алуга ирештеләр. Менә шул тамашалардан соң винтовка астында залдан чыкканда режиссер күзләрендәге моңны күрсәгез иде! Исән түгел микән Туктаров абзый? Их, бер Казанга барып чыгып, балаларын булса да эзләп табарга иде... Кая ди инде ул?

Булачак җәмәгате Өммегөлсем белән дә шул сәхнәдә табышты ул. Көлгән чакта бит алмаларында мәхәббәт чокырлары ярала торган ифрат та матур тавышлы, житез Шаран кызы Гарифулла укуын тәмамлыйсы елда кыска вакытлы курсларга килгән иде. «Галиябану»да алар Хәлил белән Галиябануны башкардылар. Тамаша алдыннан егет бик тә мәгънәле төш күрде: имеш, ул куенында карчыга баласын йөртә икән. Томшыгында хаты да бар житмәсә. Өйләнүгә юрады. Һәм ике яшь йөрәк, озын-озак уйлап тормыйча, уч төбендә генә яткан Шаранга кайтып, никах укыттылар да куйдылар. 1937 елның җәендә ике яшь укытучы Шатманга кайтып төште. Бер генә ел укытып өлгерделәр алар. Күк йөзендә болытлар куерганнан-куера бара иде. Менә авылда алтын-көмеш алка, чулпы, беләзек, хәтта җиз комган җыю, аларны ярыша-ярыша дәүләткә — Кызыл Гаскәр исәбенә тапшыру галәмәте башланды. Ике йөз йортлык авылдан сиксән биш җиз комган тапшырган Шатман тирәякта беренче урынны яулады. Һаман колхозга кермәгән мәзин килене, өстәвенә комганын да тапшырмаган укытучы Өммегөлсемне педсоветта

тикшерделәр. Районәктән килгән мәгариф бүлеге вәкиле аңа эштән куылу белән дә янап куйды.

Урак өсте иде. Садретдин мәзиннең Җилдәр авыл советында эшләгән чыбык оч туганы, кичке караңгыда атын ак күбеккә батырып, килеп керде һәм әтиләренең колагына нидер пышылдап, шундук юк булды. Гарифулла сизенде: күк йөзендә исән калган йолдызлар чатный иде. Әтисе гаиләне бер йодрыкка җыйды һәм куркыныч хәбәр җиткерде. Көтелмәгән чапкынчы аңа әйткән икән: «Садретдин абзый, бүген төнлә күзгегез кая карый, шунда чыгып олагыгыз. Иртәгә барыгызны да кулга алачаклар».

Соңыннан сөйләвенчә, әтиләре бу хәлне көтеп йөргән булган икән. Мәчет манарасын кисеп төшерткән Өтәләү Зарифның йөзенә төкергән икән. Ул бер ай чамасы элек, киткән баш киткән, дип хатынының чулпылы толымнарын, авылның җиз комганнары өчен шулай үч алган булган икән.

Аларның йорты авыл очында — нәкъ ай янында якты йолдыз калка торган төштә иде. Әтисе әнисенә юлга төйнәлү өчен дүрт сәгать вакыт бирде. Ут сүндерелде. Унсигез яшьлек сеңлесе Рабига белән әнисе кулга нәрсә эләгә, зиһенгә ни килә, шуны җыештырына башлады; әтисе исә кулына икс үткен чалгы пычак, утсыз фонарь алып, Гарифулланы, киленс Өммегөлсемне, унбиш яшьлек Зәбих энесен ияртеп, абзарга чыкты. Сукыр тычкан күзе сыман гына кабызылган фонарь, ниһаять, абзарның эчке почмагына эленде. Әтисе мөгезле эре терлек, кәҗә малы һәм бәрәннәргә кагылмады. Дүрт баш сарыкның авызларын бисмилла тастымаллары белән уратып, мекердәтмичә генә тыннары каткан алмагачлар арасыннан мунча артына сөйрәттерсп, берсе арты берсен чала, Гарифулла исә туный торды. Үткен пычак йөзләрен ай нурында ялтыратып хәләл малын чалган әтисенең «Аллаһы әкбәр, Аллаһы әкбәр!» дип пышылдаганы һәм анардан да кочлерәк тыелып, ничектер пышылдап һәм сызгырып үләнгә шыбырдаган кан тавышы гына ишетелде. Иманлы тормышта гел көн яктысында, кондез чалынган корбан малының да хәтта үз сиземләве бар, күрәсең: төнлә, вакытсыз, кемнәндер качып суелган сарыкларның күзләре якут ташы кебек зәңгәрләнеп сүнкләнгән иде. Әзер итнең юыласы өлеше Өммегөлсем белән мунчада юылды, Зәбих куллары белән тозланып, чиста чүпрәк капчыкларга салынды. Тире-койкаларга әтиләре үзе тоз сипте һәм чыптага төреп, арбага салды. «Кирәкләре чыгар». Эш тәмамланды дигәндә генә ул тагын бер йола башкарды. Гарифулла моны беркайчан да онытмас: алмагач төбенә кечкенә чокыр казыды да, суелган мал тоякларын, эчәк-карынын, йөрәк-бавырларын укына-укына чокырчыкның бер кырына төшерде, ә менә сарык башларының һәркайсын әле суынып та бетмәгән сөтле иреннәреннән үпкәндәй чупылдатып алып һәм кыйблага каратып, чокырчыкның икенче кырына ипләштерде һәм укына-укына күмде...

Абзарга кергән әниләре сөтле сыерын һәм башмагын калдырып китәсе килмәде:

— Мин бит аларга быел күпме алма ашаттым! Ярылып яткан алмалар! — дип пышылдады ул. — Алыйк, сиңа әйтәм... Үзе сөтле, үзе буаз да!..

— Тамакларына кадалсын, бәдбәхетләрнең! — Садретдин мәзин хатынын утлы караш белән көйдереп алды. — Мондый хәтәр юлга мөгезле эре терлек белән чыгарга башыма тай типмәгән ләбаса!.. Чегән табырына бармыйбыздыр бит? Качып китсәң дә, чәчеп кит дигән борынгылар!..

Сыерның саран яктыда тәгәрәп торган күзләре урнын кебек төпсез иде. Мәңгегә аерылуны сизеп, елый иде, мескенкәй. Алъяпкыч чите белән сыер яшьләрен сөрткән әниләрен күреп, әтиләренең дә күңеле йомшарды булса кирәк, әмма аның сүзе сүз иде:

— Үзебез шырпы кабына кереп ятар мәлдә... Шул шырпы кабына сыер кадәр сыерны ничек сыйдырыйм мин?! Исәп белән баемаган халхуз урак җылысы белән генә баемас!..

Әйе, шулай диде әтиләре. Гарифулланың үз гомерендә беренче һәм соңгы тапкыр әтисе авызыннан ишеткән тупас сүгенү сүзе шул булды.

Ниһаять, бурлы ат фурманга җигелде. Җылы, ямьле, җиһаз тулы өйләрен ташлап китәргә мәҗбүр булган хуҗалар инде өшегән, күшеккән хәерчеләр, мөһаҗирләрне хәтерләтеп һәм бер-берсенә ельшып, хәерле юл догасы кылды. Таң алдыннан, дөресрәге, сәгать өчтә, ала алган кадәр китапларын, мал-мөлкәтен, казанын-таганын төяп, арба артыннан абыстаен, өч баласын һәм киленен ияртеп, Садретдин мәзин кайчандыр үзе укыган Ырымбур тарафларына юлга чыкты. Ишеккә дә, капкага да, абзарга да бик салмадылар. Хәер, аларда йозак дигән нәрсә юк та иде.

Бүгенгедәй хәтерендә Гарифулланың, алар авылдан чыкканда ай янында шул ук якты йолдыз иде.

— Атасы, атыңны беразга гына туктат әле,— диде әниләре Ташлытауга күтәрелгәч.— Авыл, туган җир белән хушлашыйк. Без булмасак, балаларга, кайтып үз нигезләребездә яшәргә насыйп итсен...

Таң сарысы белән чорналган алты җан иясе кыйблага тезләнеп, юл догасын укыды. Дога укый белмәгән бурлы атның шомрайган колаклары ай божрасын тишеп кергән иде. Алар көндез туктап ял иткәндә казан-казан ит пешереп, атналык, коюшлы һәм җиләс тартә-дугада җилләтеп һәм киптереп, учакта ыслатып, тагы да ике атналык азык әзерләп, салкын чыклы төннәрдә сарык койкасы белән ябынып йоклап (соңыннан аңлавымча, урысның «койка» дигән сүзе көне-төне далада чабып арыганнан соң, ябынып йоклый торган татарның тире-койкасыннан чыккан икән), алар Илкүлмин, Илек, Каргалылар аша Ырымбурга, аннан казакъ далаларына юл тотты. Сәфәрнең егерменче көнендә купкан ком гарасаты гаиләне Чалкар дигән стансада туктатты...

Юк, аларны ком бураны түгел, ә аяусыз, кансыз язмыш туктаткан булып чыкты. Әгәр белгән булса, моннан ничек кенә булса да котылу — юлны дәвам итү өчен Гарифулла барлык чараларны күргән булыр иде. Әле төзелеп кенә яткан тимер юлдан атнасына нибары бер тапкыр үткән поездны көтеп акылдан шашкан мөһаҗирләр даирәсе — чегәннәр, тегеннән-моннан җыелган качкалаклар, бохар ялкаулары, бушка килгән мал исен сизеп ябырылган әтрәгәләмнәр һәм алыпсатарлар, атасыз-анасыз калган ташландык балалар, бала-чагасыз кемсәләр, тагын да әллә нинди, әллә нинди кавем һәм кабиләләр белән тулган Чалкар стансасы үзенә күрә яңа хакимият алып килгән нәҗәсәтлекнең, яшерен алыш-бирешнең һәм җинаятьчелекнең бер кабатланмас оясы иде. Атларын, сатарга мөмкин булган бар нәрсәләрен күпме бирсәләр, шул бәягә сатып өлгергән Гарифуллаларга,— Ходай үзе сакласын!— үзләрен генә сатасы калды... Мондый куркыныч юк та түгел иде — әнә, аларга дүртенче арба булып ияреп Ырымбурга кергән татар Гәрәй, мәсәлән, көннәрдән бер көнне үзенең уникс яшьлек кызын бер казакъ баена егерме кадак арпа оньна алыштырып кайткач, Садретдин мәзиннең, йөрәге ярсып, Гәрәйне каеш чыбыркы белән ярганы хәтердә:

— Йөзең кара! Оятсыз! Тәүбәгә кил! Нишләп без дә бала сатмыйбыз?!

Казакъ далаларында ак чебеннәр очып, кыш та якыная башлагач һәм башка чара калмагач, муллалыгын яшергән әтиләре үзләре көн күргән зимләнке һәм тамак ялы хакына Чалкардагы казакъ баена, Гарифулла белән Өммегөлсем исә йөз егерме чакрымда яткан Җандыктагы Сәендек байга елына ун пот арпа һәм ике куй исәбенә куй көтәргә ялландылар. Көтүдәге куй — мең баш. Бүреләр — дала тулы. Син ялгыз. И-их, андагы йокысыз төннәр һәм тынгысыз көннәр!..

Алар әйләнеп кайтканда Чалкарда башка сыймас мәхшәр иде: урамнарда корсаклары күпкән, йөзләре шешенгән, күз чокырларын бет һәм эрен баскан үле һәм тере гәүдәләр аунап ята; тирәләрендә өер-өер комыклар кайнаша; һавада пиндидер сасы куыклар, селәгәй тамчылары очып йөри; шундый ук шешенгән һәм күзләре акаеп бетләгән, билгә

кадәр шәрә калган бәндәләр, бер-берсен авызларыннан очкан мөһмәләт белән агулап, корсаклары гөптәй, аяклары җептәй ниндидер шәүләләр, тимер чылбырлар белән коралланып алып, үзләрен үзләре кыйный, кара канга батырып җәзалый һәм әллә нинди авазлар чыгарып, җир тырнап, мәйдан тирәли гү килә... Инде менә ничәнче ай котырган гөбән чиренең җенен менә шулар куалар, имеш. Бу кадәр караңгылыкны һәм наданлыкны аңлатырга бер укымышлысы, бу чирдән дәваланырга бер табибы булмаган даирәнең үләсе кешесе үлгән, үлмәгәннәре, ярдан очарга әзерләнә иде...

Чалкар читендәге җир белән тигез зимләнкене чак-чак таптылар Гарифуллалар. Эзләп тә таптылар, мәңге җуелмас кара кайгыларга да баттылар: сөекле энесе Зәбих һәм сеңлесе Рабига гөбән чиреннән дөнья куеп, җирләр кешеләре булмагач, гәүдәләре «туганнар каберлеге» дигән чокырга ыргытылган; әти белән әниләре дә үлем хәлендә, әтиләре, җитмәсә, телсез иде...

Урам дисәң урам, мәйдан дисәң мәйдан булмаган чарлак җирдә очраган бер табак битле төрекмән кардәш,— рәхмәт төшкере!— шешәсеннән голт-голт китереп, ниндидер саргылт сыекча салып бирде:

— Ич! Ичсан, ишин гайдар![1]

Гарифулла аны ике дә уйламый эчеп җибәрде. Соңыннан белүенчә, спирт булган ул.

— Аялыңа да ичир! Мәне унытмасан![2]

Эчерде аны Гарифулла Гөлсемгә дә. Ат сыман авызын шакарып эчерде.

Әтиләре аңына килә алмыйча җан тәслим кылды. Бераздан әниләре дә якты дөньяны ташлап китте. Шулай итеп, бер атна эчендә бер зимләнкедән ике мәет чыкты. Хәтерендә, үлем белән якалашкан телсез әтисе, нәрсәдер аңлатырга тырышып, биш бармагын күрсәтте — ни әйтергә теләде ул? Биш баласы кала дип аңлатырга тырышса — аның балалары өчәү генә, аларның да икесе кабердә иде... Нәрсә, нәселебезне ишәйтегез, бишне иш итегез диярgә ымсындымы, мәрхүмкәй? Әниләре үз аңы белән үлсә дә, сөйләшә алмады. Телен чак әйләндереп, ул бер генә сүзне кабатлый иде:

— Кайтырга... тырышыгыз... Кайтырга ты... ры... шы...гыз...

Шулай итеп, Чалкарда өч кабердә дүрт мәет калдырып, кырыгынчы елның башында ачык платформада Урта Азиягә чыгып сыза алдылар. Соңыннан, аеруча сугышта, Гарифулла үлемне күп күрде, әмма бер генә үлем дә аның күңелендә әти-әнисе үлеме кебек аңлашылмас дәрәҗәдә шыксыз тойгы калдырмады: ул бу үлемгә ышанмый, аның хакында уйлый алмый, уйлый алган хәлдә акылдан язар кебек иде. Вагыйгаларга илле җиденче ел китеп барса да, Гарифулла һаман да шул халәттә — ата-ана үлеменә ышанмау, башына сыймау сәерлеген ул бары тик чиксез ярату белән аңлатырга тырыша. «Без чынлап да исәнме ул?» дигәндәй, ул тагын да карчыгына карап алды. Гөлсеме исә күзләрен йомган да ике кулы белән дисбесен берәмтекләп, авыз эченнән нәрсәдер укына...

Сәмаркандта көткән кешеләре юк иде. Бер рәхимле үзбәккә тап килеп, ул яшьләрне үзенә сыендырды. Өстәвенә үзбәк мәктәбенә мөгаллимнәр итеп тә урнаштырды. Ләкин бу бәхет озакка бармады, Гарифулланы хәрби хезмәткә алдылар һәм, укыган кеше буларак, Томскидагы хәрби училищега курсант итеп җибәрделәр...

Автобус Дим елгасын кичеп, юл зур татар авылы Никифардан соң кисәк кенә уңга борылгач, Гарифулла уйларыннан арынып, басулардагы өлгереп килгән игеннәргә, өркәч-өркәч тауларга, Дим ярларына сипләнеп йөгергән әрәмәләргә сокланып барды. Барысы тере, барысы үзенеке... Игеннәргә аеруча куанды Гарифулла. Кызык, әкәмәт җәй булды быел:

---

[1] Эч! Эчмәсәң, бетәсең!
[2] Хатыныңа да эчер! Мине онытмассың!

кәккүк кычкыра да яңгыр ява, кәккүк кычкыра да яңгыр ява. Менә соңгы көннәрдә генә бераз корытты һава. Әйтерсең, кояш тастагы сабый кебек чәптер-чәптер килеп коена да, йөгереп чыгып, тымызык һавада кәккүкләрен кычкырта-кычкырта тагын да кыздыра башлый...

— Игеннәр саргая,— диде Гарифулласыннан күреп, тирә-якны күздән кичереп барган Өммегөлсем.— Саргаялар...

— Саргаялар...— диде Гарифулла.— Әле агарасылары бар...

Бу аларның җитмеш чакрымлык Шатман-Әкчин юлында сөйләшкән бердәнбер сүзе булды.

...Укулар ни сәбәпледер бик кыскартылып, курсантлардан ашыкпошык кече офицер әвәләп, Гарифулланы Алматадагы яңа хәрби училищега укытучы-тылмач итеп җибәрделәр.

— Сез әле һаман коммунист түгелмени?— диде аны үзенә чакыртып алган политбүлек башлыгы Бема.— Сез нигә партиягә кермисез?— Бүлмәдә авыр тынлык урнашты. Комиссар күзләрен чекерәйтеп, кичә генә офицер таныклыгы алган курсантка төбәлде.

— Бу хакта уйланганым юк иде әле,— диде Гарифулла тыйнак кына.

— Эрәзве бу хакта уйланмаска мөмкин?! Үсәсегез, чиннан чинга күтәреләсегез килмимени?..— Бема алдында яткан исемлектән Гарифулланың фамилиясен эзләп тапты.—...Гарифулла Садретдинович?!— Әтисенең исемен шундый зур хәрби авызыннан ишетеп, ул кара тиргә тоште.— Юк, артык хафаланмагыз, барысы да тәртиптә. Мин болай гына, сыйнфый иминлек дигән нәрсәдән чыгып кына... Әйе, сезнең әле һаман коммунист булмавыгыз безне бераз сагайта төшсә дә, ышаныч күрсәтеп, сезне Алматага җибәрергә булдык. Көнчыгыш халыкларыннан — беренче чиратта казакълар, үзбәкләр, төрекмәннәр, кыргызлар... эээ, тагын кемнәр бар әле анда... каракалпаклардан хәрби кадрлар аз. Алардан совет властенә лояль булган катлам тудыру — стратегик бурыч. Сез, татарлар гомер буе урыс идеясен көнчыгышка илткән укымышлы, ышанычлы, тылмач халык... Ә болар, наданнар, урыс боерыкларын һич кенә дә аңламый һәм аңларга да теләми. Саламны сенодан аермый!— Ул авыз читен чалшайтып көлемсерәде.— Сезнең бурыч: хәрби фәнне, урыс командаларын үз телләрендә аңлатып, совет офицерлары үстерү...

Алматада эшкә башлап, хатынын үз янына алдырам дип йөргән көннәрдә генә сугыш башланып китте. Август азагында Гарифулланы хәрәкәттәге гаскәргә озатырга дип Өммегөлсем үзе дә килә алды. Фронтка ул панфиловчылар белән бер эшелонда барды. Гарифуллалар дивизиясе Воронежга чигенеп, шәһәрне дошманга сугышсыз бирде. Беленькая дигән авыл янында яраланып, Мичуринскида өч ай госпитальдә ятып чыкты. Бот битендәге сумитне кәтәлүк сыярлык итеп умырып алса да, ярчык сөякне зарарламаган иде. Икенче кат яралануында дошман тырнагына капты. 1943 елның февралендә, Гродно янындагы концлагерьда, Талип дигән Буа татары белән ит комбинатыннан ташланырга әзерләнгән мал эчәгесе, карын тизәге эченә башларына капчык киеп кереп ятып, боз булып туңдылар һәм, ниһаять, чокырга бушатылдылар. Хәтерли Гарифулла, алар әсирлектән котыласы төндә дә ай янында якты йолдыз иде.Әйе, якты йолдыз аларны ташламады: өч көн буе кышкы урман эчендә, эзсез-сукмаксыз, азыксыз-сусыз куырылганнан соң, бер авылга таң булып, урам очындагы йорт тәрәзәсен шакыды алар. Ышансаң — ышан, ышанмасаң — ышанма: соңыннан беленүенчә, Гродно тирәсендә таралып яткан дистәләгән татар авылларының берсе Якубович булып чыкты ул. Анда яшәгән кешеләрнең барысының да фамилиясе Якубович иде. Урысча, белорусча, хәтта ләхчә яхшы сөйләшкән, әмма татарча бер сүз белмәгән, шулай да биш вакыт намазларын калдырмаган Сәлмән һәм Мәрьям Якубовичлар соңгы чиккә җитеп хәлсезләнгән милләттәшләрен аякка бастыру өчен барысын да эшләделәр. Их, барып чыгарга иде шул якларга... Кая инде ул. Соңыннан татар авылларын Гарифулла Вильнюс тирәсендә дә, ләх, румыйн, болгар җирләрендә дә очратты.

Әмма аларның берсенә дә Гродно өлкәсендәге татар авылына аптыраган кебек аптырамады.

Аерылганда Якубовичлар елап калды. Аларның кылган догалары ярдәм иткәндер, күрәсең, юлсыз калын урманнар, ялан-кырлар аша бер ай чамасы җик күргәннән соң, Гарифулла белән Талип фронт сызыгын исән-имин үтеп, үзебезнекеләргә кушыла алды. Ике сәгать үттеме-юкмы, аларны монда армия контрразведкасы капитаны Енушкевич кулга алды һәм ике атна буе фашистлар да сава алмаган эчәгеләрен сауды: «Кем сез? Документларыгыз кайда?» Исән түгел микән аның михнәттәше Талип Сибгатуллин? Их, барып кайтырга иде Буа якларына... Кая ди инде ул?

Лейтенанттан рядовойга төшкән һәм рядовойдан өлкән сержантка күтәрелгән Гарифулла Аппаков сугышны Мекленбургта тәмамлады. Җиңүдән соң да ике ел ярым буе солдат сукасын тарткан фронтовик туган Шатманына 1947 елның ноябрендә генә кайтып керә алды. Аның бик тә укытасы килә иде. Мәгариф бүлегендә барысын да искә төшерделәр. Сугышта кан кою, әлбәттә изге нәрсә... тик менә... тс-с!.. авылдан качып киткән мәзин малаена, кичәге хәрби әсиргә ничек итеп балалар тәрбияләү эшен йөкләргә мөмкин? Аның чәчләре сугышта түгел, унбиш минут эчендә мәгариф бүлегендә агарды. Әйе, нишлисең, балаларга һуннар турында да, су астына киткән торки Атлантида, фәст дисбесе турында да, Америка түрекләре әнкә, әстәк һәм маялар турында да мәгълүмат бирергә насыйп итмәде...

Тәмам җен ачуы чыккан Гарифулла уңга-сулга карамый, иң авыр эшкә алынды — ун ел буе Җилдәр белән Шатман арасындагы Актаудан акбур ташы чыгаручы, аннан яшелчәчеләр бригадиры булып эшләде. Олауларда, соңрак машиналарда ул озаткан акбур коммунизмның ничәмә-ничә бөек төзелешен агартты икән? Агартты микән? Болай да акбаш Гарифулла эшеннән тегермәнче кебек бөтенләй агарып кайта иде. Авыл башына килеп керү белән бала-чага уратып ала һәм озата бара:

— Ак бабай килә! Ак бабай килә!..

Менә егерме елга якын инде ул лаеклы, үзе әйтмешли, таяклы ялда.

Ул кайтканда авылда икенче кампания — татар авылын сарыкчылык, атчылык һәм кошчылыктан коткарып, дуңгызчылыкка күчерү бара иде. Аларның алты почмаклы иркен өйләрен бар тирәне сасытып, мыркылдатып яга торган дуңгыз фермасына күчерткәннәр. Гарифулла иске урынга Җилдәр ак ташын шакмаклап кисеп, авылда беренче таш йорт җиткезде. Үләме алдыннан әтисе ишарәләгән биш бармакны васыять дип кабул итеп, Гөлсем белән шул нигездә биш бала үстерделәр. Өчесе үзләре белән авылда, икесе Уфада. Барысы да гаиләлеләр. Әле яңа гына шәһәрдәге улының кызы, кызының улы аларда кунак булып киттеләр. Татарча белмиләр, дуңгызлар. Әти-әниләрен әйтер идең... Әмма үз балаларың бит, димәк, төшендереп, сеңдереп җитмәгән. «Мәктәп, балалар бакчасы гаепле,» имеш. Сәбәп эзлиләр. Урыстан күреп, татар да сәбәп эзләргә өйрәнде. Үз балаңа туган телеңне дә бүләк итә алмау җинаятен нинди сәбәпләр белән аңлатырга мөмкин? Ул шәһәр сабыйлары белән кызык та, кызганыч та. Гөлсемгә алар «абика» диләр. «Мин сезгә әбикә түгел, картәни!» дигән була да бит тегесе, әмма сорау әзер: «А что это такое картина[1]?» Шулай бер көнне кызчыкка картәнисенең утызынчы еллардан сакланып калган алка-беләзекләре бик ошаган икән. «Дай мне!» дә «Дай мне[2]!» ди бу. «Мин үлгәч алырсың»,— ди картәнисе. Гарифулла исә — тәрҗемәче. «А когда она умрет[3]?» ди бит, дуңгыз, күзен дә йоммый! Нәүбәте җиткәч, бер көнне оныгын иярте, котүгә чыкты Гарифулла. Күрә, Әхмәтгалинең азгын сыеры басуга кереп бара. «Бар әле,— ди

[1] Нәрсә соң ул «картина»?
[2] Миңа бир.
[3] Кайчан үлә ул?

Гарифулла.— Анауы сыерны борып кил!» «Который[1] сыер?»— ди бу. Сыер инде башкаларын да ияртеп, басуга кереп тә китте. «Анаусын,— ди Гарифулла.— Койрыксызын.» «А что такое койрык?» Менә сиңа, мә! Аптырагач, кулындагы чыбыркы сабыннан артына койрык ясап, сикереп күрсәтте Гарифулла: «Вот так, сикерт-сикерт!»

Алла дигән, иман дигән инануны җаннан гына түгел, агу җибәреп, каннан да кысрыклап чыгарырга тырышсалар да, гыйфритләр аны тынычта һәм сугышта намазсыз итсә дә, имансыз итә алмадылар. Әйе, көне-төне гыйбадәттә булып та кеше үтерергә мөмкин. Һәм үтерәләр дә. Син соңгы вакыйгалар — бүшнә һәм чәчән мөселманнарының хәлен генә кара. «Йә, хода, нинди яшерен көчләр кырдыра бөтен дөнья күз алдында бу мөселман өммәтен?— дип газапланды бик күп китаплар, Рум империясе тарихларына кадәр укыган Гарифулла.— Кем кулы уйный монда? Нсраниларны мөселманга католик Америка, католик Ватикан котыртамы? Румның яһүдиләргә каршы башлаган урта гасырлар инквизициясен беләбез. Инде яһүдиләрнең үз катнашлыгы белән уйлап чыгарылмадымы икән бу ниндидер мөселман фундаментализмы?..»

Автобус урман эченнән үргә күтәрелеп, яңадан ачыклыкка чыккач, еракта электровоз кычкыртты. Өммегөлсем карчык дертләп куйды. Менә алар әле генә җәелеп, агарырга да өлгермәгән кап-кара, яшь асфальт мәйданга, нәкъ вокзал каршына килеп туктадылар. Алда, ишек катында утырсалар да, урыннарыннан дәррәү кубарылган яшьләрне алар алдан үткәрделәр һәм иләп, сакланып, чирканып кына чиста асфальтка бастылар.

— Сәгать ничә, Гарифулла?

— Ун,— диде Гарифулла, җиңүнең илле еллыгы уңаеннан бирелгән бүләк сәгатен карап.

— Әйбәт. Бик әйбәт. Теге чакта да җомга һәм нәкъ иртәнге ун иде...

Өммегөлсем карчык белә иде: бүген чынлап та җомга һәм ул әллә кайчан билгеләп куелган.

Башка мәшәкатьләре, керер кешеләре булмагач, алар перронга күтәрелделәр. Барыр юллары шунда тәмамланып, шып туктадылар. Гарифулла карчыгын ашыктырмаска, юк-бар, кыбырсу сораулар белән борчымаска карар итте. Үзе монда алып килде, үзе йөретсен.

— Сиңа әйтәм,— диде һаман һушына килә алмый басып торган Өммегөлсем.— Бакзалы шул ук иске күренә... Аешмыйчарак торам — Уфа кайсы тарафта да, Кинәле кайсы тарафта?

— Һы,— диде Гарифулла илле ике ел зур юлларга чыкмаган карчыгының зиһенсезлегенә чын-чынлап аптыраган булып. Аннан куллары белән ишарәләде.— Монда — Уфа, тегендә — Кинәле!..

— Әйдә, менә шушыннанрак чыгып карыйк әле...

Алар составлар үтми-сүтми торган арада чуен юллар аша аргы якка үттеләр. Сукмак аларны чуен юлыннан илле-алтмыш адымнарда башланып киткән авыл урамына алып чыкты.

— Монда элек буш җирләр иде...— Үзенең уңны-сулны аера башлавына чиксез куанган Өммегөлсем карчык сүзгә юмартланып китте.— Ничек кенәләр бөтәеп киткән Әкчин, ә? Буш урында авыл дигән, ә?

— Без эзләгән урынны табу шикле инде болай булгач,— диде Гарифулла адымга җаны ярсый барган Гөлсемен тынычландырырга тырышып.— Шул тирәне чамалый алсаң да ярар...

— Бәй, син тагы... Үз алтынымны күмгән төшне дә тапмагач, адәм тәганәсе булам түгелме соң мин?— диде карчык кыбырсып. Тараф төшенчәсен югалтса да, саф акылындагы Өммегөлсем нәкъ шул төшне, нәкъ шул урынны, нәкъ шул аршын җирне табарына ышана иде булса кирәк.— Урман сыман нәмәстә бар иде дә бит... Каеннар, пар каеннар бар иде...

---

[1] Кайсы?

Әллә күзләрем күрми, әллә тупләгәннәр... Анавында тыкрык сыман ара шәйләнә түгелме?

Карчык Гарифулласын җилтерәтә салып шул тарафка алып китте.

— Агачлык бар иде... Пар каеннар бар иде...

Аларга сипкелле битле яшь кенә, бер чуар хатынкай очрады.

— Сеңлем,— диде карчык аны туктатып.— Бу авыл... күптән корылганмы?

— Күптәнме, дип... Мин монда туып үстем инде. Бер утыз-кырык ел булыр...

— И-и-и, рәхмәт төшкере... Син, сеңлем, үзебезнең татар кызы да икәнсең...— Өммегөлсемнең күңеле күтәрелеп китте.— Соң, монда кемнәр яши — татарлармы, урысლармы?

— Татарлар!— диде чуар хатын, атлый башлап.— Арабызда урыслар да бар үзе.

— Мөселман зираты бармы соң?— дип кычкырып өлгерде карчык.

— Белмим, әби!— Хатынкайның җавабын инде җилләр генә алып килде.— Бар шикелле!..

Ничек кенә булмасын, куанычы чиксез иде Өммегөлсемнең. Аның Тансыгы — йөрәк алтыны мөселман җирендә, мөселман куенында — иманлы төбәктә йоклый икән...

## IV

...Өч ел бала таба алмады Өммегөлсем. Түземсезлек белән бала көткән ирен бәхетсез итәрмен микән ни, дип эчтән сызып, үзе уйлавынча, каралардан коелып йөргәндә ул, ниһаять, көмәнле булды. Гарифулла бу шатлыклы хәбәрне белеп китте. Сөенече аңлатырлык идеме — әгәр сугыш яланнарында ятып калса, аның нәселе дәвам итәчәк. Садретдиннең бердәнбер оныгы булачак бит ул. Әгәр ул ир бала да булып куйса? Гарифулласы, яраланып, Мичурин каласы госпиталендә ятканда Өммегөлсем 1942 елның 19 апрелендә дөньяга исән-имин, бар әгъзалары да сау-сәламәт ир бала табуы, корбан ашы үткәреп, алдан сөйләшкәненчә, Тансык исеме кушуы турында хәбәр итеп өлгергән иде аңа. «Тансыкны сакла, Гөлсем,— дип язган иде җавап хатында Гарифулла.— Сугыш хәлен белеп булмый, әгәр һәлак булып куйсам, Тансык улыма васыятем шул: авылыбыздагы туган нигезебезне ничек кенә булса да сүндермәсен, яңадан тергезсен иде. Мөмкинлек туу белән авылга кайтыгыз. Илдә чыпчык та үлми. Анда туган-тумача да җитәрлек әле, ярдәмләреннән ташламаслар...

Тансык улымның туу хәбәре мине бик тә әсәрләндерде. Шигырьгә һәвәслегем булса да, Бәләбәйдән соң кулыма каләм алганым юк иде. Менә монда бер бәет ише нәрсә күңелемнән кәгазьгә түгелде...

Укыгыз бәнем яуда язган сүзебезне,
Күргән кебек булырсыгыз үзебезне.
Менгән атым җирән түгел, шомырт кара,
Яурынында мылтык-кылыч ялтырап бара.
Килеп җиттек Донец дигән су буена,
Гаҗизләндем сугышның нык булуына.
Дошманнарның туплары бик ерак ала,
Ерак ала, төшкән җирдә чокыр кала.
Сайрый былбыл, сайрый аккош бу җирләрдә,
Җөмлә агач яфрак яра тугайларда.
Кайтыр көнем булса икән туган илгә,
Хәсрәтләрем барчасы да бетәр, имди...»

Кая ди ул заманда хатын-кызга хәзерге кебек еллар буе өйдә утырып, бала үстерү бәхете? Ике атна үттеме-юкмы, Тансыкны үзе фатирда

яшәгән үзбәк хатыны карамагына калдырып, эшкә дә чыкты. 1942 елның декабрендә Гарифулласының хәбәрсез югалуы турында хәбәр килде. Өммегөлсем өчен кояш сүнде. Елгалар корыды. Үләннәр кара көйде. Аның бердәнбер өмете, юанычы булып әтисенең йөзен дә күрмәгән Тансыгы калды. Үләннәр кебек үзе дә кипте-корыды Өммегөлсем. Төннәрен елый-елый шешенеп бетә дә, иртәгесен йөзе һәм маңгаендагы җыерчыкларын җылымса су белән тигезләп, эшенә йөгерә. Шулай очны очка ялгап яшәп ятканда, бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, хатын-кызны гына эзәрлекли торган бер афәт килеп чыкты — яшь, эшчән, көче-дәрте ташып, чибәрлеге әллә кайлардан күзгә бәрелеп торган һәм, хәзер инде, күпләр уйлавынча, тол калган хатынга үзбәк ирләре тәмам юл бирми башлады. Алар бит Рәсәй тарафларыннан килгән хатын-кызга аеруча каныгалар, күзләрен тожырайталар да, кайда мөмкин, шунда тозак куеп, эзәрлекләргә тотыналар һәм еш кына үзләренең түбән ләззәтләренә ирешмичә туктамыйлар. Авыр кабул итсәләр итәрләр, инде дистә еллар аша шунысын да әйтми калдыралмый Өммегөлсем: үзбәк өчен хатын-кыз чүпрәктән дә ваграк мәсьәлә. Җитмәсә, мәктәп директоры, сөйләүләре буенча, ришвәт тәртеп, фронттан котылып калган Абдулла әкә аңа тәмам тынгы бирми башлады. Үзбәк өчен түрә хакы — тәңре хакы. Бер яклаучысыз калып, намусын күз карасыдай саклаган хатынны үзенеке итү өчен нинди генә түбәнлекләргә бармады ул кабәхәт җан. Эшеннән куу белән яный башлады явыз. Фатирыннан сөреп чыгару белән куркытты мөртәт. Кая, кемгә барып егылырга? Эч серләреңне кемгә бушатырга? Чит җирнең кичке шәфаге, иртәнге таңы биздерә башлады. Совет иле киң дә бит ул, әмма басып торыр, яшәп торыр урынны гына күрсәтми иде ул Өммегөлсемгә. Гарифулласының васыятен үтәү ниятендә ул ничек кенә булса да Шатманга кайтып егылырга кирәк дигән фикергә килде. «Җәйгә кадәр түз бала, Рәсәйдә әле бик тә салкын»,— дип фатир хуҗабикәсе еландай телен чыгарып ялынса да, бернәрсә дә тота алмады хатынны. Ул туган ягын сагынып ярсыган һәм үзен эзәрлекләгән адәмчекләргә карата нәфрәттә кайнаган иде. Әгәр Гарифулласының Шатманында кабул итмәсәләр, Ташлыма кайтырмын, дип тә юанды ул.

Февраль урталары иде. Сатыласы әйбер ашык-пошык һәм ярты хакка сатылды. Моннан бер ай чамасы элек кенә кызамыктан көч-хәл белән котылган, инде хәзер тәненә ит утыртып, Гарифулласына охшап, бит алмалары, иреннәре алланып-балланып үсә башлаган ун айлык Тансыгын һәм авылдан чыккан мәһәр савыты — фанир сандыкка чүпрәк-чапрагын, бер сүз белән әйткәндә, таланудан калган кирәк-ярагын алып, ерак юлга чыкты. Кая ди ул вагонда утырып, йоклап бару — мичкәдәге тозлы балык кебек шыплап тулган иде ул мосафирлар белән. Һавасы да ифрат тынчу, сасы һәм тозлы-тирле иде. Җитмәсә, юлга дип алган азыгын берсенче көнне үк төенчеге-ние белән урладылар. Түзсә дә түзә икән адәм баласы: ун көн буе ач килде, Өммегөлсем. Станса саен төшеп-менеп, яңарып торган юлчылар синең хәстәреңне аңлый аламы? Дөрес, юлдашлары аны ике мәртәбә ризыкландырдылар. Сатып алырга дисәң, нә бакзалларында, нә вагонында бернәрсә дә юк. Ун көн эчте ул кайнаган суны һәм аңлады: су туклыклы икән. Инде Тансыгы да азыксыз кала күрмәсен дип куркәгенең сөт бизләрен корытмас өчен дә мул эчте ул суны...

Әмма төп фаҗига азыксыз калуда түгел, бөтенләй икенче нәрсәдә иде. Сәфәрнең өченче көнендә үк кайнары күтәрелеп, эч киту белән чирләгән һәм мондый уңайсыз шартларда ананы чиксез җәфаларга, газаплы мәшәкатьләргә дучар иткән, бәлигъсыз һәм бер гаепсез булып, шул гаепсезлеге белән әнисенә мең мәртәбә җаваплылык өстәгән Тансык күкрәк сөтен дә сорап бармады: мич кебек кызган, табадагы орлыктай куырылган, төсе качкан сабыйны һәр имезү үзе бер вөҗдан газабына әйләнде. Аның иреннәреннән, гүяки, ялкын ургыла һәм бу ялкын Өммегөлсемне вакытсыз юлга чыкканы өчен үкендереп, аяк табаннарыннан

баш түбәсенә кадәр көйдереп ала иде. Дарулар һәм табиб эзләп, ана вагонның бер башыннан икенче башына чапты, әмма табибы да, кирәкле даруы да табылмады. Соңгылары күп җыелды җыелуын, ләкин эч китүдән, кайнар хастадан гына юк иде. Машинист киңәшен тыңлап, берәр стансада төшеп калмаганына соңыннан бик тә үкенде Өммегөлсем, нишләптер төшеп калмады шул — күрәчәкләре шул булган, ахрысы. Тәнен кызгылт тимгелләр биләп алган сабый күз алдында сула, сүнә бара иде... Мәскәү-Ташкент поездыннан Уфа тарафына китә торганына күчеп утыргач, Кинәле стансасына җитәрәк... кочагында тәмам хәрәкәтсез калган биләүне чишсә... инәкәйгенәм!.. Аның Тансыгы, аның йөрәк парәсе, аның бөек һәм бердәнбер әсәре күзләре ачык килеш якты дөнья белән хушлашкан иде... Бөтен тәне аша үткән кара шаукым йөрәккә китереп сукты, акылыннан язар... аһ!.. үзбәк, марҗа хатыннары шикелле, фаҗигасен яшермичә, ачыктан-ачык, җир тырнап җылар, поезд кадәр поездны туктатыр хәлдә дә һушын җыеп, авызын томалый алды Өммегөлсем. Ул корама юрганга капланып, тавышсыз-тынсыз гына үкереп-үксеп елады. Һәркемдә үз кайгысы гына булган юлчылар янәшәләрендә секунд эчендәге фаҗигане сизмәделәр дә шикелле. Өммегөлсем аны сүрәтли алмаслык түзем белән сиздермәде. Аптыраган, тәмам канатлары сынган ана, яшь каен чаукасы кебек сыгылып, үле баласын вагон бәдрәфенә алып кереп бикләнде һәм шашкан күзләр белән сабыйның кара көйгән иреннәренә авызын куеп тын өрә башлады:

— Китмә, Тансыгым... Китмә, Тансыгым!.. Китмә, алтыным!..

Әмма Тансык кайтмас җиргә киткән иде шул инде. Шул мизгелдә ана күкрәге сөтсез калды. Үзе тамактан язды. Бер тәүлеккә якын барды ул үле баласын кочаклаган һәм аны имезгән булып кыланып. Менә Кинәлегә дә төштеләр. Тәүлекләр буе поезд көтеп, бакзал идәнендә аунаган юлчылар арасыннан үзенә сукмак хәстәрләп, туктаусыз йөренеп торды һәм бары тик унсигез сәгатьтән соң гына утырып китә алды. Аһ, андагы үле сабыйны күтәргән килеш кәмпәстиргә чират торулар!.. Шулай да юлның иң читен өлеше Кинәле белән Әкчин арасында булган икән: кышкы эшсезлектә Куйбышев каласыннан чуен казаннар, әлүмин савыт-саба ташып көн күргән алыпсатар татар хатыннары — өйдә ятимнәре көткән солдаткалар һәм нәселсез калган киленчәкләр, кыз-кыркын матур корама юрганга төрелгән сабыйны күреп һәм хатын-кызга бигрәк тә якын бала исен сизеп, тәмам котырдылар: «Балаңны күрсәт тә балаңны күрсәт!», «Бер генә сөйдер!», имеш. Аннан «Балаңны нигә имезмисең?» дип теңкәгә тия, җәзалый башладылар. Монда да бер тәүлек буе диярлек вагонның бер башыннан икенче башына йөренеп торды. Хатын-кызлар үзара пышын-пышын килә башлады. Берсенең икенчесенең колагына әйткәнен ачыктан-ачык ишетте Өммегөлсем: «Бимазаламагыз инде, акылга бер рәвешлерәк күренә...»

Әкчиннән җитмеш чакрымда яткан Шатманга кышкы зәмһәрир суыкта үле бала күтәреп, ничек кенәләр кайтып керергә мөмкин? Туганнары нәрсә әйтер? Кайткан-киткән кеше анда бит болай да тәүлекләр буе олау көтеп ята! Үз гомерендә бер генә тапкыр да булмаган, күзе күрмәгән Әкчиннән олавы туры килгән хәлдә дә, ат адымы белән, юл уртасында кемгәдер куналар төшеп кайту өчен генә дә тагын ике тәүлек вакыт кирәк түгелме? Юрганга төрелгән сабый гәүдәсе дүрт тәүлек эчендә нишләр? Исләнеп, муртаеп бетмәсме? Бу әрвахлар рухын рәнҗетми, үз сәгатендә, хәтта ки ашыгып ләхеткә кертүне фарыз күргән мөселман кануны өстеннән, фәрештә килеш теге дөньяга китеп барган сабый хәтереннән көлү, адәм баласын гүр җылысыннан мәхрүм итү түгелме?

Өммегөлсем Тансыкны ничек кенә булса да Әкчиндә җирләргә карар итте. Иртәнге сәгать унда поезддан чыкканда тирә-юнь буран гарасатында йөзә иде. Бер кулы белән үле баласын, икенче кулы белән агач сандыгын күтәргән, күз ачкысыз буран караңгысына уралган һәм күзенә болай да ак-кара күренмәгән Өммегөлсем кая барырга белмичә, тегендә-

монда сугылды да, каршы очраган бер ападан зиратның кайда икәнлеген сорады. Ул марҗа булып чыкты. Барлы-юклы тел белән аңлата торгач, шунысы ачыкланды: Әкчин — урыс авылы икән, мөселман каберлеге юк икән, булган мөселманнар мәетләрне ун-унбиш чакрымда яткан Слак, Айдагол авыллары зиратларына җирли икән. Бу исә Өммегөлсемнең хәлен тагын да кискенләштерә иде. Һәм бу мөмкин дә түгел иде. Сабыйны кичке шәфәкъ сүнеп, кояш баеганчы җиргә тапшырып өлгерергә кирәк. Кәтмәгәндә генә башына гаярь фикер килде. Тукта, Өммегөлсем башы түнүдән уйлап та өлгермәгән түгелме: Әкчин мөселман авылы булмагач, теләсә кайсы төштә ул каберне кем казыр да, кем ясин чыгар?

Минутлар сәгатьләрдән озын һәм газаплы тоелды. Ул шулчак кочагында боз булып суынып барган Тансыгының тавышын ишеткәндәй булды. «Әни җаным, җәфалама үзеңне,— диде аңа бу өзлеккән аваз.— Минем җаныя тән-шәрифләремне дә җәфалама. Син үзең ясин чыгып, җылы кабергә куйсаң, миңа җир йөзендә һәркайда да мөселман зираты булыр. Тик урынымны япа-ялаңнан сайлама. Якындарак урман, баш очымда агач булсын. Җәен, шуның күләгәсендә син миңа Коръән чыгарсың...»

Өммегөлсемдә ниндидер зур сыналыш булды. Гүя, ул шушы мизгелдән баласы өчен ана да, ата да иде. Аңа иңнәренә кәйлә-көрәк күтәргән бер төркем хатын-кыз очрады. Ул җан ачуы, әллә нинди кыргый көч белән алга тартылды, бар булмышы белән хәзер, менә хәзер шартлаячак шартлаткычны хәтерләтеп, ашык-пошык сөйли, үз хәлен аңлата башлады.

— Кая ди ул монда кешегә кабер казу?— диде араларыннан күмеләчәк мәетнең яшь ана кочагында икәнлеген башына да китермәгән бер татар хатыны.— Үзебезне чак йөртәбез, сеңелкәем! Эшебезне кара!— Ул иңендәге кәйләне чак кузгатып куйды.— Өйдә балаларыбыз ач утыра! Син ир-атка мөрәҗәгать ит...

Буран исә һәр такта киртәгә, һәр тимер очы, һәр агач башында сыбызгы табып, сызгыра, гүли һәм үкерә иде. Ике адымнан кешене малдан, малны кешедән аерып булмаслык бу гарасатта кулларындагы биләү баласы, такта сандыгы белән бер сәер сынны хәтерләткән Өммегөлсем авыл буйлап түбәнгә төшеп китте. Буранда йөзеп, алдына кемдер калкып чыкты.

— Татарлар кайсы йортта яши монда?— диде хатынкай инәлеп, гүя, ул хәер сорый иде.— Татарлар кайсы йортта яши?

Пәйгамбәребез Мөхәммәт хәзрәтләре һәм аның беренче хәләл җефете Зөләйха исемнәрен ишеткән Өммегөлсемнең эченә җылы йөгерде. Ул кочагындагы сабыйның үле икәнлеген онытып, сөеп куйды:

— Оештырырлар, алла боерса... Безнең халык — оешкан халык... Бердәм халык... Ярдәм итми калмаслар...

Ул өйгә хуҗаларча ышаныч белән шакымый-нитми генә килеп керде. Алгы якта кырык яшьләр чамасындагы хатынкай көтелмәгән мосафирга бер аптыраса, ашыгып-ашыгып, аңлашылыр-аңлашылмас рәвештә, өстәвенә кеше ышанмас нәрсә турында сөйләгән хикәятенә ике тапкыр аптырады. Ул сүзсез генә түр якка үтте, кемгәдер пышын-пышын тәфсилли башлады...

— Берәр телем икмәк бир дә, куып чыгар син аны,— диде эчке бүлмәдән ир тавышы.— Акылдан язгандыр ул. Татарча аңламаса, урысча аңлат. Сугыш заманы... Кем генә йөрмәс. Бәлки ул нимес шпиунидыр?

— Мы не знай,— диде хатын кире чыгып. Һәм икмәк савытында актарына башлады.— Берни белмибез.

Икмәк савытында әле һаман кечкенәрәк телем эзләп маташкан хатынга кырт борылып, урамга чыкканда Өммегөлсем күзеннән сыгылып чыккан ачы яшь тамчысы тупса сайгагын көйдереп алды.

— Болар оешмаганнар, сабыем...— Ул Тансыгын туктаусыз сөя һәм аның белән сөйләшә иде.— Болар безнең халык түгел... Татарлар мондый булмас...

Ул кирегә борылды һәм сул рәттә мөселман санагычы буенча изге сан — җиденче йортка керергә булды. Иншалла, ярдәм итәрләр. Ярдәм иттермичә, ул шуннан чыкмаячак.

Капкасыз-нисез ихатага үтү белән тәбәш кенә абзар эченнән ап-ак сакалы биленә кадәр төшкән бер карт күренде. Тырышып-тырмашып аңлата торгач, Никодим карт,— исеме шулай икән,— аны өенә алып керде. Мәсьәләне үзе төшенгән микъдарда әбисенә җиткергәч, тегесе кулларын җәеп, үксеп елап җибәрде:

— И, ходаем! Шушындый гарасатта да бәла-каза чыга...

— Елар чак түгел, Марфа,— диде карт чишенеп.— Бәлагә тарыганнарга булышырга кирәк...

Өстәлдән әйберләр җыештырылды. Өммегөлсем өстен салып ташлап, юрганны сүтте, аннан өшегән куллары белән биләүне чишеп, сабыйның туңа башлаган шәрә гәүдәсен күрү белән әллә нишләде. Чир һәм җан бирү газапларыннан котылган Тансык исә берни булмагандай елмаеп ята иде... Үзен-үзе кулга алып, ул сандыгыннан ак җәймә суырып чыгарды һәм җәяр өчен өстәлгә кире килгәндә почмак түрендәге изге Мәрьям ана кирәмәтен күреп, буынсыз калды, йомгак булып төенләнде һәм газиз баласының өстенә капланып, бу газаплы ун көн эчендә беренче тапкыр аналарча ләззәт белән елый, үкси башлады.

— Тынычлан, кизим,— диде Никодим карт үзе дә яшьләрен эчкә йотып.— Бог един... Ходай бир...

Марфа түти мич арасына кереп китеп, мышык-мышык елый иде.

Кар белән катнашып авырайган, җепшегән җил ташкыны күтәреп алып китәрдәй булып өйгә китереп сукты, ул хәтта селкенеп куйды.

Өммегөлсем гүзәлләрдән гүзәл сабыеның зәңгәр тамчы гөлне хәтерләткән күзләрен ачып һәм ябып, күз кабакларын, колак бөгәлләрен, суыкта алсуланган бит алмаларын, иреннәрен йомшак куллары белән сыйпады, үпте, тагын үпте, алсу гөлдәй кечкенә иреннәрен кузгата биреп, үсеп өлгергән җәүгәрләрен — нәкъ унбер сөт тешен санап карагандай барлады, инде хәзер үзләреннән үзләре кайнарланган бармак чуклары белән бөтен тәнен, барлык буыннары исәннәр микән дигәндәй капшап чыкты, сөйде, үпте, тагын да сөйде, тагын да үпте һәм, аңына килеп, сорады:

— Сезнең монда кыйбла кайда икән?

Кыйбла дигәнне аңлаучы-белүче юк иде.

Өммегөлсем Ходайга тапшырып, сабый гәүдәсен башы белән үзе фараз иткән кыйбла тарафына борды һәм өстенә ак җәймә япты. Марфа түтигә су җылытырга кушып, ана белән Никодим кулларына кәйлә, көрәк алып ихатадан чыкты.

— Эздис...

Хатынкай картны бакзал ягына тартты. Аның исәбенчә, санда ялдашмас, яланда адашмас өчен, Тансык бакзал тирәсендәрәк җирләнергә тиеш. Бая, акылыннан шашып, перронда йөргәндә ул,— әгәр буран күзне бумаган булса,— чуен юлы аша, нәкъ бакзал каршында, ниндидер агачлыкларны хәтерләткән шәүләләрне дә шәйләп калган иде шикелле...

— Шушында. Эздис...

Өстенә Марфа түтинең инде буран акшарлап та өлгергән сырмасын кигән Өммегөлсем, коньякның җиңел бутыйлары белән калын көрттә бата-чума, картны шул агачлык янына алып керде. Менә бит, Тансыгының колакка ишетелгән теләге тормышка аша түгелме — куш каен ләбаса! Әйе, каеннар шул. Өммегөлсем өчен маяк, Тансыгы өчен сәхра. Җитмәсә, ике-өч йөз адымда урман сыман нәрсә дә куерып торган кебек. Бәлки ул чынлап та урмандыр? Хатын кар ерып, кушкаен һәм бер төптә үскән өч каен арасын исәпләде — егерме биш адым иде. Кушкаеннан биш адым алга атлады һәм туктап калды.

— Эздис...— Өммегөлсем үксергә җитешеп, икенче тапкыр сорады.— Кыйбла эгде, кыйбла?

Карт аңламый иде.

Кыйбла сүзенең урысчасын белмәгән, Шатманда һәм Сәмаркандта кыйбла тарафын яхшы аерган Өммегөлсем, туган җиренең котелмәгән хуҗабикәсе, Әкчиндә, гүелдәп һәм ажгырып котырган буран эчендә иртәдән бирле кыйбласын табалмый газаплана иде.

— Нәрсә соң ул «кибла»? — дип сорады көрәгенә таянган карт.

— Кояш кайда?

— Кош, говоришь?[1] — Никодим аңларга тырышып, күзләрен челт-челт йомгалады. — Птица, что-ли?[2]

Бәхетсезлегенә, ул кояш сүзенең урысчасын белеп тә оныткан иде. Күк йөзендә кояш булмау, аны кара буран ятьмәләре каплаганлыктан көнчыгышны һәм көнбатышны аныклый алмаган хатын тилергән күзләре белән ак өермә аша күккә инәлде:

— Кояш... кояш... Син кайда?

— Луна что ли?[3]

— Юк... юк...! — Өммегөлсем үрсәләнеп кычкыра иде. — Дин дилает! Нуч дилает![4]

— Солнце?[5]

— Әйс, әйе!

— Ул әнә тегеннән чыга. — Никодим кулы белән төртеп күрсәтте.

Өммегөлсем җиде кат күк гөмбәзен тишеп чыгардай караш белән күккә төбәлде. Димәк, көнчыгыш — бу тарафта, көнбатыш — теге тарафта, ә көньяк... Көньяк тарафтан бер карыш уңга борылсаң — кыйбла! Мәккәи Мәдинә!

Ул кыйблага аркылы казылырга тиешле кабер урынын билгеләде.

— Эздис... Әссаләмә галәйкем я әхләл кубур...[6]

Алар карны көрәп ыргыттылар. Өммегөлсем телен аркылы тешләп, ач ана бүреләргә хас җан ачуы белән җирнең өстәге туң катламын кимерә башлады. Йөрәкне телеп паровоз кычкыртты. Кыш салкын булса да, җир җылы, туфрак ике илледән дә тирәнрәк туңмаган булып чыкты. Кабер авызына актарылып төшкән буранда тирләп һәм пешеп, ике яктан җәһәтләгәч, эш тиз, ырамлы барды — ике сәгать үттеме-юкмы, кабер әзер иде диярлек. Никодим да, Өммегөлсем дә үз гомерләрендә ләхет алган кешеләр түгел иде.

Сырмасын салып ташлап, Өммегөлсем кабергә сикереп төште. Сабые гәүдәсе өчен иң җылы, иң иманлы уемның — ләхетнең нинди булырга тиешлеген үзенчә чамалап, үзенчә билгеләде. Аннан ләхетне алмаш-тилмәш уйдылар. Стансада тагын да паровоз кычкыртты. Кабер әзер иде.

Марфа түти аларны җылытылган сулары белән каршылады. Өммегөлсем сандыгыннан сабыйның авыз-борынын чистарту өчен актан-ак чүпрәк кисәкләре, исле сабын, Гарифулласының бүләге булган хушбуй, инә-җеп алды. Кан җылысы итеп кенә җылытылган суга һәм Никодим алып кергән сабый юылачак тактага хушбуй да бөркелгәч, моңа кадәр бүрәнәләренә арпа, чөгендер исе сеңгән өй эче затлы хуш ис белән тулды. Ул хәзер еламый, хәтта сәер дәрәҗәдә тыныч иде. Яше, гүяки, каядыр тирәнгә, кеше-кара күрми торган җиргә киткән егерме өч яшьлек хатынкай түти ярдәмендә үз гомерендә беренче тапкыр мәет юа башлады.

— Иляһи ният кыйлдым әхирәт госелен коендырмакка... Тәннәрен пакьламакка! — дип пышылдады ул. — Әшһәдәнлә иләлләһа әннә мөхәммәдән гөбедөһү вә рәсулүһү...

---

[1] «Кош» дисеңме?

[2] Кошмы әллә?

[3] Аймы әллә?

[4] Көн ясый, төн ясый?

[5] Кояш?

[6] Сәлам сезгә, әй, кабер әһеле. *(гарәп.)*.

Марфа түти кәфенлеккә ак тукыма әзләп урамга чыгарга дигәндә, Өммегөлсем аны туктатты:

— Нит, нит... Сбоя... Сбоя...[1]

Үзенчә бөтен шартына китереп, ул сабыеның гәүдәсен кат-кат юды. Ак җаймәне кәфенлек итеп ике кат аска салды. Гарифулласы һәм үзе хакына. Сандыгындагы вак борчаклы чиста күлмәген сабыйга ахирәт күлмәге итеп киендерде. Җылыда яктырып, тәмам алсуланып киткән кадерле ит кисәге — йөрәк парәсен аста җәеп калдырган кәфенлеккә кат-кат төрде. Бөркет күзе белән инәсенә җеп саплап, җеназага барганда сүтелеп, таралып китмәсен өчен кәфенне берничә урыннан типчеп чыкты. Никодим карт каяндыр табып керткән юкә кабыкны исле май белән хушландырды. Кабык өстенә корама юрган, корама юрган өстенә мәетне аягы белән ишеккә таба каратып салды һәм җил-буран керерлек җөй калдырмыйча, илтифат белән төрде; болай да тын өйгә гүр тынлыгы урнашты; тешләрен кысып, бер омтылыш белән Марфа түтинең сырмасын киде һәм, мәет янына килеп, тагын да дога кылды:

— Баламның гүр эчләре җылы, ләхет эчләре иманлы, урыны оҗмахта булсын! Ходай Тәгаләм, фәрештәңне кабул ит! Тәүбә, Ходай Тәгаләм! Үзең ярлыка!..

Кабыкка салынган гәүдәне күтәреп, алар култык астына кыска такталар да кыстырган Никодим карт белән икәүләп яңадан буранның күгелҗем дөньясына чумды. Бакзал тирәсенә җитәрәк давыл айкаган телеграф һәм электр чыбыклары бер-берсенә чорналып, җиргә тубалтубал очкыннар чәчрәп төште. Кабер авызын, ике яклап өелгән кызыллы-кара балчыкны кар каплап өлгергән иде.

Өммегөлсем мәетне кабер белән янәшә, башы белән көнбатышка каратып урнаштырды. Баскан килеш кенә үзе белгән Фатыйха һәм Ясин сүрәләрен укырга керешге...

Җил-давыл кабер төбенә үк төшеп айкала, ләхет авызларына кереп, курайларда уйный, йөзләгән тальяннарда сыздыра, иңри, оркестр булып гүли, улый, ниндидер чатлы йолдыз сыман эре кар бөртекләре бөтерелә, уйнаклый, шунда ук давыл тагын үзенең җепшегән җилкәне белән аяктан егардай булып арттан китереп суга һәм бер мизгелгә ышыкка кергән кебек тынып кала; көрәгенә таянып, күзен йомган Никодим карт кайчандыр мең ел элек гарәп аргамаклары канатында Идел-Урал буйларына килеп, Евразия чикләрендә беренче булып караңгы, тупас, кыргый мәҗүси тормышны яктылык белән сугарган изге канун, мәңгелек рухият һәм кешелек моңын сугышта йөреп яткан ике улы хакына багышлап тыңлый иде шикелле; туңган җир өсте, парланып яткан кызыл балчык, инде яңадан суынып барган сабый гәүдәсе, бураннарда чәбәләнгән күк гөмбәзе, якында гына үксегән паровозлар, кабер катында калган шушы ике адәм шәүләсе — бар тирә-як далада яңгыраган азан авазы белән төйнәлеп бәйләнде:

— Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!.. Әшһәдү әнлә илаһә иләлләһү! Аллаһы әкбәр!..

Өммегөлсем кабергә үзе төште. Кесәсенә кыстырып килгән «Һәфтияк» китабын бисмилла әйтеп улының башы ятачак күтәренке төшкә куйды, гәүдәне Никодим кулларыннан кабул итеп, ләхеткә урнаштырды, сул кырыена балчык түшәп, башын бераз гына кыйблага янтайтты һәм инде хәзер кәфенне яңадан ачып, улының нурлы йөзе, гаҗәеп сыны белән тагын бер генә тапкыр — соңгы тапкыр хушлашырга хокукы булмаганлыгын аңлап, ләхет авызыннан авырлык белән башын үткәрде һәм кара җир куенында ак башак булып яткан Тансыгы өстенә капланды... Юк, ул еламый да, беркемгә, бернәрсәгә ялвармый да иде. Инде аның йөрәге җир өстеннән җир астына күчеп һәм колак пәрдәләрен ярырдай булып

[1] Юк, юк, үземнеке.

суга, дөпелдәп катламнарны яңгырата иде. Аның башыннан куркыныч уй үтте: «Әллә үземә дә шушында гына калыргамы?»

— Син анда артык озак, кизим,— диде югарыдан Никодим.— Чык инде.

Кабер төбенә лапылдап такта кисәкләре төшеп ләпәште. Аларны ләхет авызын каплау өчен Никодим ташлый иде...

Кыл өзәрлек тә хәле калмаган Өммегөлсемне кабердән Никодим күтәреп диярлек чыгарды. Калганнарын ул юньле-рәтле хәтерләми. Кабер ничек итеп күмелде? Өйгә кайчан һәм ничек кайттылар? Өммегөлсем алты төн һәм алты көн эссе табада кайнаган май шикелле куырылды, саташуыннан өн белән төш бергә буталды. Мең рәхмәтләр, Никодим абзый белән Марфа түти тәрбиясендә ул ун көн дигәндә аякка баса алды. Улының каберлегенә кабат-кабат барып, күңелен бушатты. Белгән догаларын, Коръән аятьләрен укыды, кабернең өстен рәтләп, язлар житкәч килгәндә табуы җиңел булсын диеп, туң җиргә хәле барынча казык та төртеп куйды... Ниһаять, изгеләрдән изге күңелле хуҗаларына рәхмәтләр әйтеп, ул авылдан килгән бер олау белән Шатманга — Садретдин мәзиннең бертуган энесе Гайнетдиннәргә кайтып төште. Кире Шаранга китү уена алар якын да килмәде. «Кем белә, килен,— диделәр туганнары. Бәлки Гарифулла да кайтып төшәр. Соңыннан күз күрер. Өйдә үзебездә яшәп тор — урын житәрлек!»

Аны мәктәпкә эшкә алмадылар. Ул башта сарыкчылыкта, аннан дуңгызчылыкта, аннан Гарифулласы белән яшелчәлектә эшләде. Гарифулласы исән-сау әйләнеп кайтмаган булса, аның җаны һәм тәне шул хәсис дуңгыз фермасында черячәк иде. Мәктәпкә эш сорап барган яшь мөгаллимәнең иске «гөнаһларын» онытмаганнар иде шул. Киресенчә, моңа кадәр ясалма күренгән каршылыклар хәзер табигыйләшеп кискенләшкәннәр иде. Шулай итеп, заманы өчен шактый белемле мөгаллимә, авыл зыялысыннан алдынгы колхозчыга әйләндерелде. Мәдәният-мәгърифәт, сәясәттән шактый артта калганлыгын сизә Өммегөлсем, кайбер яңа сүз-атамаларны әйткәндә дөрес әйтәм микән дип борчылып үзе өчен оялып та куя...

Һәр җәйдә сабыйны зиярат кылу, иң зур хыялы — гәүдәсен Шатманга күчереп күмү уе беркайчан да тынгы бирмәде Өммегөлсемгә. Күмәк хуҗалыкның ул чактагы рәисе Сабира апа хатынның кайгысын тирәннән аңласа да, мондый җаваплылыкны үз өстенә ала алмады. Авыл советына барырга кушты. Каберлек, күмү-җирләү алар карамагында, диде.

— Сез нәрсә?! — дип җикерделәр инде хакимияткә үрләп алган Өтәләү Зарифларның уллары.— Әле сине, качкалакны, үз-үзен атып үтерминчә әсир төшкән сатлык җан хатынын авылдан кумаганга рәхмәт әйт! Күчереп җирләү, мөселман йоласы, имеш!..

Соңгы тапкыр 1947 елның җәендә барды ул авыл советына. Анда ач балалар өчен аерым приют оештыру белән шөгыльләнәләр иде.

— Чит-ят җирләрдә яткан бер гаепсез фәрештәгезне кайтарып күмү турында кеше мәшәкатьләп йөргәнче, менә берәр баланы алып тәрбияләгез! — диделәр үзе дә ачтан шешенгән хатынның үз сүзләрен үзенә кабатлап.— Бездә чит-ят җир юк. Барысы да совет җире. Кеше кадәр кешене күчереп җирләү өчен НКВДның махсус рөхсәте кирәк! Ә анда пәйгамбәрләргә дә, фәрештәләргә дә исемлек тутырылган...

Курыкмас җиреннән курыкты ялгыз, яклаучысыз хатын. Алла сакласын, тыныч яткан җиреннән куптарырсың, ә монда күмдермәсләр дә. Ничә мәртәбәләр кырык ясин һәм ничә мәртәбәләр Коръән чыкты икән ул сабые рухына? Ярлы булса да, Өммегөлсем әти-әнисенең, бианабиатасының дини кешеләр булып, аңа ислам рухын — бердәнбер табыну һәм көч алу кыйбласын сеңдерүләренә куанып бетә алмый иде.

Гарифулласына да әйтеп-әйтеп карады. Фронттан шактый басылып, сынып кайткан, бу хәтәр заманнарда үзе дә як-ягына каранып яшәргә мәҗбүр булган ир мәсьәләне нишләптер куертмады. Ачлык-ялангачлык

дәвам итте, аннан берсе артыннан берсе балалар туа башлады. Болар бәлки сәбәп кенәдер? Әллә тормышка битарафлык, имансызлык бастымы? Шулай гомер үтә торды. Яраларны еллар томаны япты. Һәм менә...

## V

Өммегөлсем Гарифулланы эре сабаклы әрекмәннәр, зәңгәр кыр җитене баскан тыкрыктан алып керде. Бәрәңге бакчалары очына барып чыккач, алар туктап калды. Өммегөлсем көткән агачлар юк иде. Илле ике ел дәвер эчендә кешеләр генә түгел, җир кыяфәте дә танымаслык булып үзгәрә икән. Аннан, кышын, буран эчендә үткән ике-өч сәгать вакыт эчендә нәрсәләрне генә хәтерләп өлгерәсең? Өммегөлсем кечкенә чөйләргә бәйләнеп, чиста, ямь-яшел үлән кырган бозауларны күреп куанды. Аның улы яткан җирләр мөселманча пөхтә, яшел, мал-мөлкәтле һәм җыештырулы иде. Әнә бит, Ходай Тәгалә рәхмәте белән бәрәңгеләре дә зәңгәр чәчкәле көлмәктә утыра!..

Җил тегермәнедәй җилкенеп һәм дәртләнеп, шуның нәтиҗәсендә Гарифулласын шактый артта калдырып, Өммегөлсем карчык үзе чамалаган кишәрлекне берничә тапкыр әйләнеп чыкты. Моннан бер өч-дүрт йөз адым чамасында урман бар икән барлыкка, тик менә каеннар юк. Кая ди ул каеннар — төпсәләре дә эзсез югалган. Бар тирә-якны, җирнең катламнарын берьюлы күрә торган күз нурлары белән үтәли тишеп, шул төшне, шул урынны, шул өлешне, шул ноктаны табасы килә иде... Аның бердәнбер кыйбласы булып вокзал туры калды. Бакча башларындагы читән-каертма, киртәләр буйлап ул шул тарафка китте.

— Нәкъ паравызлар каршында иде... Нәкъ паравызлар кычкырта торган җирдә иде...

— Хәзер паровозлар түгел, карчык,— диде артыннан килгән Гарифулла.— Хәзер электровозлар. Алар безнең яшьлектәге шикелле җанны илертеп кычкыртмый.

Моңсызлар...

Әйе, моннан нәкъ кырык ел элек корымлы, йөрәк ярып кычкырта торган паровозларның пөхтә, ыспай һәм ялкау гына сызгыртучы электровозларга алыштырылганлыгын белми һәм белә дә алмый иде.

— Вокзал турысында гына... Менә шушы чамадарак...— Атлыйатлый карчык үзе белән сөйләште.— Каеннарын түгел, төпсәләрен дә калдырмаганнар, ичмасам... Менә — мондарак... биредәрәк булырга кирәк...

Һәм Өммегөлсем карчык кисәк кенә туктап калды. Гүяки, аңа Тансыгы җир астыннан «Тукта, әни, син бит мине нәкъ менә шушында калдырып киттең...» диеп эндәште. Буыннары таралган ана дерелдидерелди төенчегеннән намазлыгын эзли башлады...

— Ярар, Ходайга тапшырдык алайса...— Ул күк йөзендә ярсып янган кояшка карап, җиңел генә кыйбласын тапты, нәкъ вокзал турысына һәм нәкъ вокзалга каратып намазлыгын җәйде. Киез олтыраклы галушларын бер читкәрәк салып, намазлык өстенә менеп басты да сорап куйды:

— Тәһарәтең бардыр бит, Гарифулла? Миңа кирәкми...

Дистә еллар буе ишетелмәгән мондый сорау Гарифулланы дәррәү какшатты.

— Бисмиллаһир рахман ир-рәхим! Әра әйттәлләди йүнәзибү биддин...

Әкчин стансасының яшел хәтфәсендә, Тансыгының сөякләре җәйрәп яткан яланда Тансыгына багышлап, шау чәчкәдә утырган бакчалар аша меңләгән төп бәрәңге куакларына, җир-ихаталарга, урман-тауларга, барча кешелеккә иминлек теләп, Өммегөлсем карчык Кәүсәр сүрәсеннән Мәгавен сүрәсенә күчте.

Өммегөлсемнең бик ерактан, тирәннән, Ташлысының, Шатманының Юкәлетау, Ташлытау, Кырынтау буйларыннан шарлап аккан мәшһүр чишмәләрен хәтерләткән көмешле, бәрхет кылганлы мәкаме күптәнге хуҗасы булып бар тирә-якка сарылды. Гарифулла нәрсә эшләргә белми катып калды. Гаепле һәм оятлы тойды ул үзен. Аның бәгырендә нәрсәдер айкалды-чайкалды, ташып түгелде һәм аның иреннәре үз-үзен тыңламыйча, ниндидер сихри көчкә буйсынып, моңа кадәр уйламаган-нитмәгән тәгъбирләрне пышылдый башлады:

— Җанымның каны... Канымның җаны... Минсез һәлак булган бирдәнбер Тансык улым... Тәүбә!.. Гафу ит...

Кайчандыр сабый чакта ятланып, күңелгә сеңдерелеп тә, алтмыш-җитмеш ел буе таш астында тотылган борынгы, бер рәвешендә бик тә аңлашылган, икенче рәвешендә бигүк аңлашылып та җитмәгән сәер, серле, беркатлы һәм катлаулы мәгънәләр һәм авазлар аның телендә тегермән ташы шикелле авыр әйләнеп һәм бөтерелеп яңара башлады... Эссе кояш астында җылы яңгыр яугандай тоелды Гарифуллага. Гүя, таушалган тән, каткан буыннар шул җылы яңгырда җеби һәм йомшара иде. Ул битенә, муеннарына кадәр тамчылап шыткан тирләрен сөртеп алды. Юк, яңгыр-фәлән яумый икән. Бу мәгънәләр, бу мәгънәләрнең һәр буыны бүген аның өчен күптән онытылган гарәп телендә түгел, ә ни өчендер туган телендә яңгырый иде кебек. Нәрсәдер урталай ярылды: сабый чак — алдан колын, ә колын маңгаенда Ярымай үзе чаба!

— Аллаһы Тәгалә бар! Галәмдә бер Алладан башка Алла юктыр! — дип кычкырып җибәргәнен ул сизми дә калды. — Аллаһы Тәгалә, барлык гөнаһларымны ярлыка! Мине рәнҗеткәннәргә дә якты вә ачык юл күрсәт, ялгышларыннан арындыр! Мине рәнҗеткәннәргә мин рәнҗемим, әгәр алар, шайтаннан котыртылып, ни сәбәпледер миңа рәнҗи икән, Ходай Тәгалә, сиңа ялварсыннар!..

Аңа рәхәт иде. Кайчандыр кеше булып туып һәм тәрбияләнеп, партиягә кермичә, шул ук партия тарафыннан котылгысыз рәвештә сугышчыга, «азат итәм» дип басып алучыга әвереледерелгән, базларында да җанын издермичә тәрбияле ташчы булып кала алган Гарифулла, гүяки, бүген яңадан үзенең төп сыйфатына — кешелегенә кайта иде...

— Аллаһы Тәгалә! Җирдәге кошларыңа-киекләреңә, барлык милләтләреңә, диннәреңә карамастан, канат һәм куәт, саулык һәм сәламәтлек, күңелемнең җаный сәдакасын җибәр! Кеше җанын коллыктан азат ит, җир йөзендә коллык челпәрәмә килсен!..

Өммегөлсем намазының дүртенче рәкагәтендә бәрәңге бакчасына карап сәҗдәгә киткән иде. «Кыйбланы дөрес сайладык микән без? — Картның миеннән яшен тизлеге белән шул фикер үтте. — Кыйбланы дөрес сайладык микән?!»

— Йөзен күрмәгән сабыемның урыннары оҗмахта булсын! Аның өч йөз алтмыш буыны җир куеннарында миңа рәнҗемәсен һәм пәйгамбәр тырнаклары булып чәчкә атсын!..

Шул ук сихри көч аны Гөлсеме артыннан сәҗдәгә тезләндерде. Җитмеш ел буе диярлек бер рәкагать намаз укымый каткан буыннары кораб колгасы шикелле шыгырдады. Ике рәкагать сөннәт һәм ике рәкагать фарыздан соң алар бер-бер артлы очкан аккошлар кебек парлап сәҗдә кылды һәм тәкбир әйтте:

— Аллаһу әкбәр ля илаһә иллалаһә вәхдекү ля шәрикә ләһ. Ләһелмөлкү вә ләһе...

Өйлә намазларын барча әрвахларга, шул исәптән, күптән инде мәрхүм булган чит кавем Никодим абзый һәм Марфа түтигә багышлап, Өммегөлсем карчык белән Гарифулла карт озак итеп дога кылдылар.

Башларын күтәрсәләр — аларга, ихаталарга менеп атланып, балачага карап тора.

— Сез ишеттегезме, алар ничек матур җырлады! — диде салам чәчле кызчык башкаларына.

— Карчык, без кыйбланы дөрес сайлаган булганбыз микән? — диде Гарифулла галушларын киеп, каз тәпиле намазлыгын җыештырып маташкан Өммегөлсемгә.

— Дөрес, нишләп дөрес булмасын ди? — Иңеннән тау төшкәндәй иркенәеп, җиңеләеп һәм яшәреп калган Өммегөлсем намазлыгын төенчегенә салган арада зур ышаныч белән кулларын болгаштырды. — Менә — көнчыгыш, әнә — көнбатыш, теге якта — кыйбла, Мәккәи Мәдинә! — Ул кулларына кәнфит учлап, эре генә кыяфәт белән сабыйларга таба юнәлде. — И-и, сабыйларым... Татар балалары бит сез...

Өммегөлсем балаларга кәнфит тарата башлады.

— Татарча беләсезме соң?

— Алар юк, — диде чая кыз. — А мин татарча билям. Татарлар татар урогыннан кача. Мин — русская. Мин татар урогына калам. Миним мама «уйрянерга киряк», ди. Шулай дурыс ведь?

— И, бәбекәйләрем... — Карчык аларның иңнәреннән сөеп хәер тарата башлады. — И-и-и, йөрәк парәләрем...

— Кирякми! Не надо! — дип шаулашты сабыйлар. — Кирәкми!..

— Хәердән баш тартмыйлар, алыгыз, — дип өстәде Гарифулла. — Һәм менә шулай итеп әппәр итегез! — Ул дога кылгандагыдай итеп, битеннән сыпырды.

Хәер алган балаларга бу ифрат та кызык иде. Алар кат-кат әппәр итте.

Карт белән карчык үзләренә генә билгеле зиратта һәм Әкчиндә күпме йөргәннәрдер, монысы билгесез. Кичен исә, шәфәкъ ялкынына төренеп, алар автобус тукталышына якынлашып килә иде...

*февраль-март, 1996.*
*Переделкино—Чаллы.*





# ТОРМЫШТАН УТ АЛЫП

**Әйе, еллар аяусыз... Татар әдәбиятында исән-сау яшәп иҗат итүче фронтовик язучылар хәзер җиде-сигез бөртек кенә калып бара. Шуларның берсе — Әдип Маликов.**

Быелның 16 августында 75 яшен тутырган язучы Әдип Маликовның солдат хезмәте 1939 елда ук Ерак Көнчыгышта башланып китә һәм, Көньяк Сахалинны япон самурайларыннан азат иткәннән соң да, разведчиклар отделениесе командиры — өлкән сержант сыйфатында 1946 елның маена кадәр дәвам итә.

Үсмер чагыннан ук беренче шигырь-хикәяләрен «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын»), «Чаян» журналларында бастыру бәхетенә ирешкән Әдип Маликов, фронт шартларында булса да, каләмен ташламый — фронт газеталарына язышып тора. Беренче күләмле әсәрен — «Атаудагы хисләр» поэмасын да шул елларда яза һәм аны Казанга юллый. Поэма Фатих Хөснинең хәерфатихасы белән «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналының 1945 елгы июль санында басылып чыга. Шулай итеп, яшь шагыйрь өчен олы әдәбият мәйданына юл ачыла.

Орден-медальләрен чыңлатып Казанга кайткан фронтовик язучылар арасында Әдип Маликов та була. 1946—1949 елларда ул Татарстан радиосында мөхәррир булып эшли. Сәләтле егет 1949 елда Татарстан Язучылар союзы тәкъдиме белән Мәскәүгә — М. Горький исемендәге Әдәбият институтына укырга җибәрелә. Әмма, сугыштан соңгы авыр тормыш шартлары аркасында, Әдип Маликов тиздән укуын читтән торып дәвам итәргә мәҗбүр була. Республика яшьләр газетасы «Яшь сталинчы»ның (хәзерге «Татарстан яшьләре») үз хәбәрчесе буларак, 1951—1955 елларда хатыны Саҗидә Сөләйманова белән Минзәлә шәһәрендә яши. Татарстанда нефть ятмалары ачылып, бөтен ил шаулый башлагач, Ә. Маликовны 1955 елда Әлмәт шәһәренә күчерәләр. Анда ул шәһәрнең әдәбият-иҗат түгәрәген оештыра. Шул җирлектә 1963 елда Татарстан язучыларының Әлмәт бүлеге ачыла. Әдип Маликов 12 ел (1965—1966 һәм 1972—1982 е. е.) шул бүлекнең җитәкчесе вазифаларын башкара. Киң җәмәгать эшләре алып бара.

Әдип Маликов иҗатының беренче чоры Бөек Ватан сугышына — аерым алганда, Ерак Көнчыгыш, Сахалин атавы, шундагы сугышчы-солдатларга багышлана. Ул үзе бер повесть-истәлегендә «Яшьлек утравым» дип атаган якларга җитмешенче елларда янадан сәяхәт кыла, шул рәвешле күңеле өчен изге-мөкатдәс елларына иҗатында әледән-әле әйләнеп кайта тора.

Әйткәнебезчә, аннары инде — Әлмәт! Язучының бөтен гомере шунда эшләп, шунда иҗат итеп үтә. Нефть төбәге булган бу якларның нефтьчеләре, төзүчеләре — кыскасы, олы җанлы гади кешеләр — Әдип Маликовның икенче чор иҗатындагы төп геройлар әнә шулар. Ул аларга дан җырлап, «Ташчы», «Фәрдәнә», «Гайшә апа», «Таңбатыр», «Сал-

кын Алан», «Чигүле кульяулык», «Бергә яккан учаклар» һ. б. күп кенә кызыклы поэмалар язды. Ә инде журналист Әдип Маликов каләме укучыларга «Кайнар эзләр» («956), «Без кояшны юлда каршылыйбыз» (1964), «Кембригә юл салучылар» (1965), «Яшьлек утравым» (1974), «Гашыйклар юлы» (1978) кебек очерк һәм истәлек китаплары бүләк итте. Әдип Маликов — өч дистәгә якын китап авторы.

Яу кырында алган «Батырлык өчен» медале һәм икенче дәрәҗә «Ватан сугышы» ордены янына, әдәбият өлкәсендәге хезмәтләрен олылап, Әдип Маликовның күкрәгенә «Почет билгесе» ордены да өстәлде. Ул шулай ук Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дә.

1959 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы булган Әдип Маликов әле дә иҗат дәрте белән янып яши, янадан-яңа әсәрләр иҗат итә.

Янып булмый шигырьдә,
Ут алмыйча тормыштан,—

дип яза ул үзенең бер әсәрендә.

«Казан утлары» редакциясе журналы Әдип Маликовны 75 еллык юбилее белән кайнар котлый һәм иҗатында алга таба да тормыштан ут алып яшәвен тели. Озын гомер Сезгә, Әдип ага!

# Әдип Маликов

## ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДАН

* * *

Гашыйк булырга да өлгермәдек,
Сафка дәшеп, быргы уйнады.
Кырыс еллар,
                    күзгә туры карап,
Чигерделәр кызыл туйларны.

Сау булыгыз таныш болыннарым,
Без киттек тә бугай кузгалып.
Агыйделкәй ага тынгы белми,
Ак пароход бара су ярып.

Керфекләрен суза таң нурлары,
Алсуланган өсте елганың.
Ярлар түгел,
                    ярдан кулын болгап,
Калды гүя яшьлек елларым.

*1946*

### Яшен суы

Кырык эшем тора кулга сорап,
Ник бирсен дә булмый күтәреп?
Читлектәге усал җәнлек кебек,
Үз-үземә йөрим үртәлеп.

Чыгып китәм кинәт тар бүлмәдән,
Кулым селтәп китәм барсына.
Йөргәнмени көтеп якын дустын,—
Кояш баса көлеп каршыма.

Явып киткән йомшак, җылы яңгыр,
Күл җыелган яшел болында.
Түгә-түгә дымсу чәчәкләргә,
Битем юам яшен суында.

Җиңеләеп кала сулышларым,
Җиләс җилләр үтә кагылып...
Җитә кайчак тере бер чаткы да,
Китсен өчен йөрәк кабынып.

*1960*

## Җыр туганда

*(Хикәят)*

Көннәр кояшлы,
Һавалар җилсез.
Тынса да җилләр,
Тын түгел диңгез.

Килә дулкыннар
Нидер сөйләнеп.
Ярга вак ташлар
Чыга ияреп.

Диңгез буеннан
Керми Сажидә[1].
Таш җыя көн дә
Диңгез сай җирдә.

Таба ташларның
Төрле-төрлесен,—
Кылыч сыманын,
Конверт төслесен...

Кичен Сажидә
Барлый табышын,
Тыңлый-тыңлый ул
Диңгез тавышын.

Тезә ташларын
Төрлечә итеп...
— Боларны, диңгез,
Эшкәрттең ничек!

Шома ал ташны
Ала сокланып,—
Эчендә гүя
Калган ут янып.

---

[1] Шагыйрә Сажидә Сөләйманова.

Бу ташның берәр
Сере юк микән?!
Башка дөньядан
Килгән ут микән?!

Утыра озак
Карап ул аңа:
«Йә, сиңа нинди
Исем табарга?»

Мохтаҗ исемгә
Һәр яңа күренеш.
Аны син генә
Табарга тиеш!

Били күңелен
Тынгысыз уйлар.
Чыңлый җыр булып,
Тартылган кыллар.

...Чума диңгезгә
Иртүк кузгалып.
Улый сирена,
«Чикне узма!» — дип.

Елмая кояш.
Һавалар җилсез.
Таш тәгәрәтеп,
Уйный чал диңгез.

*Гагра, 1968*

## Бусагамнан узды Туфан

Сихерләде мине шигырьләре
Сабый чактан.
Күңел сизенгән...
«Урал эскизлары» хыялымны
Алып китте шагыйрь эзеннән.

Урал, Урал,
Шаулы митинглар...
Станоклар җыры колакта.
Үзем күргән гүя барсын, барсын,
Үзем булган шунда чынлап та.

Яшел тышлы ул китапны
сонра
Кемдер җыйды, кемдер яшерде.
Ә җырлары, затлы орлык сыман,
Ил кырлары буйлап чәчелде.

Эзләдем мин «Урал эскизларын»,
Уралда да булдым — тапмадым;
Айкап йөрдем Себер тайгаларын,
Сахалин һәм Курил якларын...

Буып булмый җырны ялган белән,
Хаклык өстен чыга ничек тә.
...Бусагамнан узды бер мәл Туфан,
Гүя аллам керде ишектән.

Күреп алды нәни улыбызны,
Маңгаеннан үпте күтәреп.
Һәм чал башын иеп,
Сәҗидәгә
Карап куйды никтер текәлеп.

Йомшак кына басып, түргә узды.
Борылды да кинәт,
сорады:
— Тату яшисезме, матурларым?
Һәм... җавап та көтеп тормады,
Аркабыздан сөйде аталарча,
Күрешкәнгә гүя сөенеп.
Улы-кызы, ни туганы түгел...
Аның өчен без, йә, кем идек?

Кеше өчен сөенү
Бөекләргә
Килә торгандыр ул тумыштан.
Үлем көткәндә дә сүрелмәгән
Мәхәббәте аның тормышка.

Туган итте Әлмәт кешеләрен,
Девон ягын кертте җырына.
Яңа җыентыгын бүләк итте,—
Әйтер сүзен дәвер-чорына.

«Бу очрашулар безгә бик кадерле,
Матур эзләр бизәр араны.
Киләчәктә тагын ни кадәрле
Бергә яшисебез бар әле,
Бергә яшисебез бар әле!»

* * *

Җыры яши балкып күңелләрдә,
Һәр буынга тансык,
замандаш.
Җырчыларын халык үзе сайлый,
Күңеленә булса аваздаш!

*1979—1987*

## Алда шигъри язлар

Бер юлдан барабыз,
Бер йөкне күтәреп,
Төшмәсен сиңа, дим, авыры.
Юлларда сикәлтә,

Ташулар кичәсе,
Каршылый бураны, янгыры.

Каршылый томаны...
Син куе томанда
Югалып торгандай итәсең.
Томаннар тарала,
Син читкә борылып,
Яшьләнгән күзеңне сөртәсең.

Бер юлдан барабыз,
Көне бар, төне бар...
Йолдызлар кул изи еректан.
Фәрештә шикелле,
Син күккә ашасың,
Мин сине табам да...
Югалам.

Табам да югалтам...
Табам да югалтам...
Ә йөкнең авыры
Сиңа да, миңа да бер төшкән.
Югалту бик авыр...
Син шунда яңадан
Елмаеп чыгасың бер төштән.

Бер баксаң — син гади,
Гәрәбә шикелле,
Балкыйсың үтәдән-үтәгә.
Ә кайчак нур булып
Гөлләргә кунасың,
Табалмам шикелле иртәгә.

Бер юлдан барабыз...
Елмая чәчәкләр.
Алар бит төрлеләр, серләләр.
Җыр булып әйлән дә
миңа кун.
Ә алда —
Яңа яз,
өр-яңа бөреләр.

*1965*





**Фәрит Яхин**

# АХЫРЗАМАН ПӘЙГАМБӘРЕ

ИКЕНЧЕ КИТАП*

## Мәдинә тормышы. Һиҗрәт

Хәзрәте Мөхәммәд галәйһис-сәлам яраннары белән догада булдылар, кайчан ки аларның сөхбәтләре тәмам origin итеп, мөселманнар үз йортларына таралыша башладылар. Барчасының йөзләрендә иман нуры балкый вә хәсрәтләре бермә-бер кимегән төсле иде. Аллаһы тәгалә хөрмәтеннән кадер тапкан бу адәмнәр Ахирәт көне өчен мәңгелек ризыклы һәм хөрмәтле иделәр, без дә аларның итәгенә ябышып, иманыбызны камил кылыйк, күңелләребезне хакыйкый риваятьләреннән алынган хәбәрләр белән ныгытыйк.

Әйе, кайчан мөселманнар намаз вә пәйгамбәр белән сөхбәттән куптылар, Мөхәммәд галәйһис-сәлам янына Җәбраил белән Микяил фәрештәләр килде вә Аллаһы тәгаләдән хәбәр китерделәр. Бу вакытта олуг хәзрәтебез яраннары Әбу-Бәкер һәм Гали дә янәшәсендә иде. Күңел түрендә иманы камил вә ныклылык сәбәпле, һәм дошманнардан йөрәге куркусыз булганлыктан, Гали сәхабәне хөрмәт вә дан өчен Гали Әл-Мортаза, ягъни Гали Арыслан дип, дуслык вә иптәшлеге белән һәрдаим тугрылык мәшәкатен тарткан Әбу-Бәкер сәхабәне мәртәбә җәһәтеннән Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйк, ягъни Әбу-Бәкер Тугры-Дус исемендә атап йөртә иделәр.

Алар өчесе бергә: Мөхәммәд пәйгамбәр, янәшәсендә — Гали Әл-Мортаза, уң ягында — Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйк — үзара мөгамәлә өчен калган иделәр, Җәбраил галәйһис-сәлам хәбәр белән килде һәм Аллаһы тәгаләнең рәсүленә Мәдинә шәһәрен һиҗрәт йорты итеп сайлавын белдерде. Мөхәммәд пәйгамбәр Мәккәне калдырырга һәм Ясрип каласына юл тотарга тиеш иде.

Мөселманнарга каршы кяферләр һаман да күтәрелә бирделәр. Иртәгәсе көндә Мөхәммәд пәйгамбәрне үтерергә ниятләделәр. Әбу-Җәһил һәм Әбу-Ләһәп эшне тизләтер өчен коткы утын көчәйтә төштеләр, халыкны котыртуда яңадан-яңа хәйләләргә бардылар, шәһәр эчендә нинди генә башбаштаклык яки җәбер-золым, яисә яман хәл килеп чыкса, — боларның барсында да рәсүлуллаһны гаепләделәр. Бу, әлбәттә,

* Ошбу әсәрнең беренче өлеше журналыбызның 1993 елгы 7—8 саннарында нәшер ителде.

куркак җаннарның наданлыгын көчәйтә, күзләрен сукырайта, күңелләрен томалый иде. Мөнафикъләр үзләрен дөреслек юлында дип ышандылар. Эшнең ахырыннан карашлары киселгән бәндәләр менә шулар төсле ахмак булдылар.

Аллаһы тәгаләдән сөекле пәйгамбәренә һиҗрәт кылу әмере ирешү белән Мөхәммәд галәйһис-сәлам яраннарыннан Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйк һәм Гали Әл-Мортазага хәлне сөйләп бирде. Моны алар көткән иделәр, хәтта тормышларында иң авыр вакытлар килгән очракларда да бер-бер илгә яки кабиләгә күчеп китү, яшеренү теләкләрен белдереп киңәш тә бирә иделәр. Әмма элегрәк Мөхәммәд пәйгамбәр ул теләкләргә күнми килде. Бу юлысы үзе хәлдән хәбәр бирде һәм һиҗрәтнең Аллаһы тәгаләдән әмер рәвешендә ирешүен белдерде. Мөселманнарга Мәккәне ташлап чыгудан бүтән бер юл калмаганлыгын ачык аңлашылды. Яки алар кяферләр кул астында һәлакәт табачаклар, яки инде Аллаһы тәгаләгә буйсынып, теләкләренә ирешәләр.

Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйк төш күргән. Имештер, олуг якты ай Мәккә шәһәре өстендә барлык галәмнәрне нурландырып торды. Аның артыннан меңнәрчә йолдызлар уянды. Бу гаҗәеп манзарадан бөтен тарафлар илаһи тойгыга күмелде. Әмма ай Ясрип тарафына күченде. Мәккә өстендә сүнеп беткән йолдызлар тагын да ишәеп вә хозур рәвештә Ясрип күгендә балкый башладылар. Ул да түгел, ай вә йолдызлар Мәккә өстенә кайтты. Шәһәрне яңадан нурга күмделәр, караңгы кичәләре якты көн кебек балкыды. Тагын да көтелмәгәнрәк күренештән Әбу-Бәкернең акылы шаша калды. Мәккә күгендәге ай балкышыннан бөтен тараф вә тирә-юнь йолдызлар җемелдәве белән күмелсә дә, ни хикмәт, ай урыныннан күченде, йолдызларын калдырып, Ясрип тарафына йөрде. Әбу-Бәкернең кызы Гайшә хәзрәтләренең куенына керде, йортының капкасыннан узды. Шунда җир ярылды һәм ап-ак йөзле нурланган ай, анда барып, җир авызында юкка чыкты.

Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйк бу төшеннән куркынып уянды. Маңгае тирләп чыккан, җаны урыныннан кузгалган иде. Ничек тә юрарга белмәде. Мөхәммәд пәйгамбәр Ясрип тарафына һиҗрәт кылса, һәлак булачак, дип уйлады ул. Шунлыктан анда күченүгә, һичшиксез, каршы чыгарга кирәк иде. Әмма дә Мәккә мөселманнары арасында Аллаһы тәгаләнең рәхмәте белән серләрне ачуда галимлек дәрәҗәсен алган кемсәнәләрдән берәү бар иде. Әбу-Бәкер аңа үзенең кайгысын сөйләп бирде һәм төшен юрауны үтенде.

Вакыйгалардан хәбәр бирүче борынгы риваятьләр ул галим кемсәнәнең исемен тарих битләреннән югалтсалар да, хәбәрен саклап калдырганнар.

Ул төш юраучы әйтте:

— И Аллаһы тәгаләнең сөеклесе вә пәйгамбәребезнең уң кулы, хөрмәтлебез Әбу-Бәкер, Сезгәме инде бу төштән хәвеф-хәтәр җыярга, Сезгәме инде хәлнең ахырыннан хәбәрсез калырга. Пәйгамбәребез безгә Аллаһы тәгаләнең гыйлемен өйрәтмәде мени? Җир йөзенә килгән бәндә раббының каршына китми кала ала мени? Мөхәммәд галәйһис-сәлам дә көннәрнең берендә мөэминнәрдән аерылыр, ул тулган ай да галәм күгеннән китәр, әмма кабызып калдырган учаклар шикелле йолдызлар сүнмәс,— диде.

— Пәйгамбәребезгә хәбәр ирешер һәм ул Мәккәдән Ясрип тарафына һиҗрәт кылар, йөзләр вә меңнәр исламга күчәр, иман китерерләр. Туган шәһәренең күгә караңгыда калыр, әмма көннәрнең берендә Мөхәммәд галәйһис-сәлам Мәккәне наданнардан азат итәр, бозыклыктан коткарыр. Яңадан да Ясрипкә күченеп, кызың Гайшә белән бәхет табар. Гүре дә шул шәһәрдә булыр. Аллаһы тәгаләнең аңа вә барча колларына рәхмәте чиксездер,— дип сүзен бетерде. Әбу-Бәкернең акылы котланып, хәтере кайтты. Серне арадан чыгармаска сүз ныгытып, базарга юнәлде

һәм ике дөя сатып алды. Ул малларны тиешле урынга китереп, кичләрен яшерен җирдә тоттылар, көндезләрен алар сулы үзәннәрдә утлар иделәр.

Мөхәммәд пәйгамбәр Мәккә шәһәрендә калмаска тиешлеген ачык аңлады, кайчан Әбу-Бәкер һәм Гали белән булды, аларга Хак тәгаләдән ирешкән аятьне әйтеп бирде. Дусты Әбу-Бәкернең каршына килеп, аннан сәфәр өчен дөя сорады. Алар икесе бергә юлга чыгарга тиеш иделәр.

Хәбәрләрдән шулай килә ки, Мөхәммәд пәйгамбәр аннан соң Галигә үзенең тиздән шәһәрне ташлап чыгасын белдерде һәм әйтте:

— Мин сиңа үземнең яшел бөркәнчегемне калдырам. Бу кичәдә Ясрип тарафына юлга чыгармын. Минем белән бары тик Әбу-Бәкер генә булыр. Син монда хәбәр күтәрсең һәм соңрак безгә килеп кушылырсың,— диде.— Әмма әйткәннәремне җиренә җиткереп үтә. Бу кичәдә минем яшел бөркәнчегемне ябынып урыныма ятарсың, минем түшәктә йокларсың!

Гали Әл-Мортаза боларны ишетте вә ризалыгын белдерде. Пәйгамбәребезгә хезмәткә һәрвакыт әзер иде ул.

Бу вакытта Мәккә кяферләреннән Әбу-Җәһил, Әбу-Ләһәп һәм дә шулай ук Әбийә бине Халәф һәм Хиҗаҗ балаларыннан Мийәссәр вә Мөнибәһ, Насретдин бине Әл-Харис, Гукбәт бине Әбийә-Мөгыйт һәм тагын да берничә мөнафик бергә җыелып, Мөхәммәд пәйгамбәрне үтерергә киңәш тоттылар. Тупсасына килеп, аны саклап торырга, Мәккәдән чыгармаска дип фикер иттеләр. Ишек төбенә барып, сакка утырдылар.

Әбу-Бәкернең дөяләрен Гамер бине Фәһр һәм дә Габдулла бине Аркат исемле кешеләр көтүлектә йөртә иделәр. Аларга алдан хәбәр бирелде һәм кайда килергә икәнлеген тагын берничә көннән хәбәр белдерәчәкләрен әйттеләр.

Юлга чыгарга мөмкин иде. Әмма Мәккә кяферләре юлга аркылы төшәчәкләр. Алардан качып котылу алай ук җиңел булмаячак. Моны Мөхәммәд пәйгамбәр дә, Әбу-Бәкер дә яхшы белә иделәр. Кемне кемне, әмма расүлне шәһәрдән чыгармаска диделәр, Ясрипкә китә калса, хәлләре яманга калачак иде мәшрикләрнең. Эшнең үзләренә бәла белән бетәчәген Әбу-Җәһил һәм Әбу-Ләһәп дөрес төшенделәр. Һәр тарафка үз кешеләреннән сак билгеләп, хәбәрдар кемсәләрен куйдылар. Бар нәрсәне хәтерләп-күзәтеп кенә торырга кирәк иде. Пәйгамбәрнең ишеге төбенә утыртылган саклары да уяулык күрсәтергә, шымчылыгын ахырына кадәр камил дәрәҗәдә үтәргә тиеш иде.

Әбу-Бәкер белән сәгате-минуты алдан сөйләшенеп куелган, Гали сәхабәгә бурычлар йөкләтелгән, шәһәрдән читтә дөяләр көтә. Юлга чыгарга кирәк.

Мөхәммәд пәйгамбәр Аллаһы тәгаләдән ярдәм вә хәерле сәфәр теләп догага утырды. Җәбраил галәйһис-сәлам вә Микяил фәрештә Мәккә өстенә йокы сөреме иңдерделәр. Расүл Әкрам, йортын калдырып, тупсасыннан атлап кына чыкты, нигезләргә сеңеп йоклаган кяфер шымчыларны күрде. Иелеп туфрак алды. Бисмилласын әйтеп аны мөнафикләр өстенә сипте. Адәм балалары көннәрнең берендә ничек кабер йокысына талалар, бу бәндәләр дә шул рәвешле аңсыз-хәбәрсез калдылар. Гүр туфрагы ничек тәнне дөнья күзеннән яшереп тотса, бер уч тузан бөртеге дә пәйгамбәр кулыннан төшүгә, аларның игътибарын томалады. Таңга кадәр изрәп йокладылар. Бары тик үз ишләре килгәч кенә, күзләрен ачтылар.

Расүл Әкрамны эзләнеп ары карадылар, бире сугылдылар. Аның кайдалыгы белән кызыксындылар. Җавап бирүче табылмады.

— Сез төне буе йоклагансыз, юкса өстегезгә-башыгызга бу кадәр туфрак өелмәс иде! — дип ачуланды Әбу-Җәһил үзенең яраннарын.

— Ул өеннән чыкмады. Моннан төн эчендә узган бер генә адәм заты да күренмәде,— диде сакчылар.

— Халкыбызны таркаткан, аллаларыбыздан аерган, арабызга дошманлык утын салган үзбелдек Мөхәммәдкә үлем! — диде Әбу-Ләһәп.

— Үлем! Үлем! — дип күтәреп алды аның сүзен ахмаклар.

Ишекне каерып, тупсаларын ватып, кяферләр Мөхәммәд пәйгамбәр йоклаган урынга ташландылар. Моңа кадәр бу эшне кылудан куркып яшәгән, әмма ул көннең киләсен сабырсызланып көткән мөнафиклар, ачу вә нәфрәт белән ярсып, гөнаһсыз пәйгамбәрнең канын түгәчәкләр иде. Алар бары тик шуны гына тели иделәр.

Җилкенеп килгән җирләреннән артка чигенәрәк төштеләр, бүлделәр, үзара берсен-берсе таптап та киткәләделәр. Әмма Мөхәммәд пәйгамбәр йорт эчендә юк иде. Ятак урынындагы яшел бөркәнчеген ачып, Рәсүл Әкрам түгел, бәлки Гали сәхабә күтәрелде. Әгәр дә кяферләр урын өстендә йоклаган кешене үтерергә ярамаганлыкны белмәгән булсалар, Галинең канын түгәчәк иделәр. Ата-бабадан килгән изге канун аларның якасыннан алды, күтәрелгән кылычларын тотып калды.

— Пәйгамбәрең кайда? — диделәр алар, җикереп, үз ачуларына тыгылып. — Пәйгамбәрең, сихерчең кайда? Бозучыңны кая яшердең? Чыгар! Юкса үзеңне үтерәчәкбез!

Гали сәхабә артка чигенде. Бу төндә Рәсүл Әкрамның Мәккәдән чыкканын, аның урынында үзенең йоклаганлыгын сөйләде. Калганын ул белми һәм белгән очракта да әйтергә хакы юк иде.

— Әшнәсе Әбу-Бәкердә булырга кирәк! — диделәр кяферләр.

— Яшь хатынының хәлен белергә киткәндер!

Сүз Гайшә хакында бара иде. Кяферләр ни бар яман сүздән чирканмадылар. Үзләренең телгә оста булуларына куанып, теләсә нәрсә сөйләнеп, Әбу-Бәкернең капкасыннан уздылар һәм пәйгамбәрне таләп иттеләр.

Мөхәммәд галәйһис-сәлам биредә дә юк иде.

— Ул вакытта Әбу-Бәкер үзе чыксын! Алар бит аерылмас дуслар, анысының башына җитсәк, тегесе дә качкан җиреннән күренми калмас. Кайда Әбу-Бәкер? — диде Әбу-Җәһил, Гайшәне куркытып.

Алдан ниятләнгән эшләрен җиренә җиткерер өчен ашкынган кяферләрнең күзләрен кан баскан, томаналыклары тәннәренә көч, сукыр күңелләренә гайрәт уты салган иде. Бары тик үзләрен генә дөрес һәм кирәкле эшне башкаручылар кебек хис иттеләр, эшнең ахыры нәрсә белән бетәсен уйларлык түгел иделәр.

— Әтием өйдә юк, төнен дә йортыбызда кунмады, — дип җавап бирде Гайшә. Ул да ялганларга теләмәде. Бик ниятләнеп эзләсәләр дә, ни Мөхәммәд галәйһис-сәлам, ни Әбу-Бәкер шушы кяферләр кулына Мәккә эчендә эләкмәде. Чөнки алар бу вакытта шәһәрдән чыккан һәм ераклашып бара иделәр.

Кояш күтәрелгәннән күтәрелә бирде. Төне буе килгән юлчыларның тәннәре йончыган, аяклары арыган, тамаклары ач иде. Ял таләп итеде.

Мөхәммәд галәйһис-сәлам юл буе гаҗизләнде. Аяк киемнәре кысан булу сәбәпле үкчәләрен кырдылар, тиресе суелып, каный, әрни вә әчетә иде. Аның бара алмаслыгын аңлагач, Әбу-Бәкер шунда пәйгамбәрне үз җилкәләренә алды, шактый гына араны күтәреп килде. Алар хәзер икесе тәмам хәлсез иделәр.

Ул вакытта кяферләр эшнең ничек икәнлеген тулысынча диярлек төшенгән һәм куа чыгып бара иделәр. Үзләреннән алда эзбасар сунарчыларны вә бу өлкәдә хәбәрдарракларны җибәрделәр. Көннең эсселәнгәннән эсселәнүе дә аларны ашыктыра иде. Кайсылары ат өстендә, кайсылар дөягә атланып, Мөхәммәд пәйгамбәр вә Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйкның эзенә төшүгә, тузаннар кубарып чаптырдылар. Аллаһы тәгаләнең сөекле бәндәләрен ахмакларның гаскәре бастырып ук диярлек җитешеп килә иде.

Шунда тарихлардан тарихларга, китаплардан китапларга, риваятьләрдән риваятьләргә кереп калырлык могҗиза пәйда булды. Моңа ышанмаган бәндәләр бар икән, аларның акылы тар күңелләре җитмәсендә

богаулануында гаебебез юк, ишетеп калсыннар һәм хәтерләренә яза бирсеннәр: ул хәлләр болайрак мәйданга чыкты...

Мөхәммәд пәйгамбәрнең кысан аяк киемнәре үкчәсен суккач, ярасы ачытып әрни башлады, кан күренде, ул баралмас булды. Моңлы күзләреннән энҗедәй яшь бөртекләре йөгерде. Хәле китте. Юл аның өчен авыр газапка әйләнде. Шушы кадәр изаланулары аның дәртен сүндерде. Тукталып каласы килде. Дошманнарының җәбере тән газабыннан авыр булмас төсле иде. Әмма дусты Әбу-Бәкер аны ташламады, юлны дәвам иттерергә дәртләндерде. Пәйгамбәрнең Хак тәгалә каршында бурычы олуг иде. Ул аның әмерен үтәргә, Мәккәдән чыгарга тиеш! Дошманнары кулына калса, бурыч йөге авачак, хөрмәте бетәчәк. Боларын гына Әбу-Бәкер сүзсез дә аңлады һәм:

— Мин синең ишәгең булыйм, йә Мөхәммәд! — диде.

Кадерле кешесеннән шушындый сүзне ишетү Рәсүл Әкрамны авыр хәлгә куйды. Дусты иркле бәндәләрдән иде. Ничек итеп аны ишәгең урынына күрергә мөмкин? Пәйгамбәр баш тартты.

— И Әбу-Бәкер, син минем колым түгелсең! Син — Аллаһы тәгалә бәндәсе! Ничек итеп ишәгем булырсың? Бу мөмкин эш түгел. Кирәкмәс, үтенмәсәңче! — диде.

Әмма Әбу-Бәкернең сүзе туры, теләге камил иде. Тик Рәсүл Әкрамга каршы әйтә алмады. Күнде. Юлларын дәвам иттеләр.

Мондый да олуг җанлы адәмне, Мөхәммәд галәйһис-сәлам төсле итагать вә вөҗдан иясен дөнья йөзе Ибраһим пәйгамбәрдән соң хәтерләми иде.

Рәсүл Әкрамның хәлләреннән хәбәрдар булып торган мәләк һәм фәрештәләр аһ ордылар. Ярдәмгә буйлары җитмәде. Кяферләрнең юлына таулар аркылы егылырдай кебек кузгалырга кымшанып, сулар ярларыннан чыгып, кяферләрне гарык итәргә әзер иделәр. Теләкләре тыелды. Бар нәрсәләрне күреп вә белеп торучы Аллаһы тәгаләдән әмер ирешмәде. Олуг дәрьялар урыннарында калды, таулар авып түнүдән тыелды. Бу — хөкем билгесе түгел, бәлки сынау һәм пәйгамбәренең кемлеген белергә теләү генә иде.

Соңгы араларда көн вә төннәрнең артыгы белән эссе торуы сәбәпле һавалар да өскә эленеп, тән һәм хәрәкәтләрне авырайта иделәр. Мөхәммәд галәйһис-сәлам артыгын бара алмады. Аягындагы җәрәхәте әрнеде, күзләреннән энҗе яшьләре кипмәде. Көн яктылыгы белән бергә дошманнарының да куркынычы арта бара иде. Пәйгамбәрнең авыр хәлен күреп, Әбу-Бәкернең йөрәк бәгырьләре әрнеде.

— Йә, Мөхәммәд, кабул итә күр сүземне. Син минем юлдашым. Ә юлдашны чын дус ташлап китәрме? Хезмәт итим үзеңә. Алыйм җилкәмә, ирешим Аллаһы тәгаләнең рәхмәтенә! — дип тагын да үтенде ул.

Башкача чара юк иде. Рәсүл Әкрамга күнәргә мәҗбүр булды. Артларыннан куып килүче кяферләр аларның эзләренә басып, менә-менә килеп җитәчәк иделәр.

Әбу-Бәкернең дә хәле бетеп бара иде. Әмма Мөхәммәд галәйһис-сәламне ташламады. Киресенчә, аны йөк итеп түгел, бәлки мамык шикелле җиңелдән тойды.

Саур тавына ирештеләр. Мондагы мәгарәнең барлыгын алар белә, әмма анда елан көтеп торганын күз алларына да китерми иделәр.

Кайбер хәбәрләрдән шулай киләдер, сөйләрләр, бу елан Гайсә Мәсихи заманнарыннан бирле яши һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең дөньяга киләчәген күрү теләгендә гомер кичерә иде. Көннәрнең берендә ул, үз язмышын уйлап хәерсез булды. Иблис ярдәмчесеннән саналуы сәбәпле, урыны тәмуг утында икәнлекне бер дә өнәмәде. Гайсә пәйгамбәргә килде һәм сорады:

— Йә Алланың илчесе, бар нәрсәне хәбәр итәсең, Саур тавы мәгарәсе кайда булыр? — диде.

— Ул тау куышы сиңа ни өчен кирәк? — дип белеште пәйгамбәр, аптыраулы караш ташлап.

— Мөхәммәдне каршы алырга барам,— диде елан.

— Әле ул вакыйгаларга кадәр алты йөз еллар бардыр,— диде Гайсә, тагын да исе китеп.

— Хәзердән барып ирешмәсәм, аннан соңга калырмын. Тәмам тәкатем бетте,— дигәч, Гайсә галәйһис-сәлам аңа Саур тавы кайсы тарафта икәнлекне күрсәтеп бирде. Әмма дә ләкин еланның максатын тәмам житәрлек дәрәҗәдә төшенмичә калды. Белеп алса, кире якны күрсәтер иде.

Ә елан яманлык белән юл алды. Аның теләге Мөхәммәд пәйгамбәрнең теләгенә каршы төшеп, язмышын кяферләр кулына тапшыру иде. Ничек тә аягына чолганырга, тешләргә, һәлак итәргә дигән уе башыннан чыкмады. «Мөхәммәднең юлын кис-сәрмен!» — дип ысылдый-ысылдый шуышты ул.

Әбу-Бәкер исә юлдашы Мөхәммәд галәйһис-сәламне җилкәсендә нәкъ менә шушы мәгарәгә китерде. Әмма тау куышына алдан үзе үтте, пәйгамбәрне бераз сабыр итәргә өндәде. Күңелендә еланнан шикләнү билгесе пәйда булган иде.

Әбу-Бәкер, мәгарәгә үтеп, өстендәге җиләнен салды, аны җәйде, урын җайлады. Әмма еланнардан шикләнүе бетмәде, шунлыктан бу хәшәрәтләр килмәслек рәвештә хәстәрләнде.

Оста аучыларны яллаган кяферләр эз югалтмыйча бастырып килә бирделәр. Инде аларның максатлары тәмам ачык, Мөхәммәд пәйгамбәрне үтереп ташлау иде.

Бар әзерлекне кылганнан соң гына, Мөхәммәд галәйһис-сәламне Әбу-Бәкер мәгарә эченә дәште. Елан тешли алмаслык итеп ябындылар. Пәйгамбәр шунда, Әбу-Бәкернең тезләренә башын куеп, йоклап та китте. Дусты исә утырган хәлендә күзләрен йомарга гына уйлаган иде, җилән тишегеп шәйләп алды. Моннан елан керерлек икән. Аягы белән каплады. «Үземне чаксалар да ярар, Мөхәммәдкә генә зыян итә күрмәсеннәр!» — дип уйлады ул.

Пәйгамбәр шушы мәгарә эченә үзенең дусты Әбу-Бәкер артыннан керү белән үк үрмәкүч кузгалды һәм тау тишегенең авызына пәрәвез оясы кора башлады. Ул да түгел, ике күгәрчен очып килделәр һәм шунда үзләренә оя кордылар.

Кяферләр килеп житте. Кайсылары ат өстендә, кемнәре дөядә иделәр. Эзбасар сунарчылар Саур тавы мәгарәсенә кадәр килсәләр дә, монда пәрәвезне һәм ояда йомырка өстендә утырган күгәрченнәрне күреп, гаҗәпкә калдылар һәм:

— Алар һичничек монда керә алмаганнар, юкса урыннарын ташлап, күгәрченнәр качар иде, пәрәвез дә эленеп тормас, оя-җәтмәсе бозылып бетәр иде,— диделәр.

Аларга шушылар җитә калды, эчкә керергә теләкләре табылмады, Мөхәммәд белән Әбу-Бәкерне башка бер җиргә качканнар дип исәпләп, кабат эзләренә төшәргә ашыктылар.

Мәгарә эче тыныч вә салкынча иде. Алҗыган качакларның тәннәре ял теләде. Мөхәммәд пәйгамбәр аяк ярасының әрнүеннән тешен кысып, иминлеген Аллаһы тәгаләгә тапшырганнан соң, Әбу-Бәкернең тезләренә башын куйган хәлендә, әйткәнебезчә, йокыга китте. Дустының да күзләре эленде. Кайдадыр ысылдап куйган елан тавышына игътибар юнәлтеп тормадылар.

Гайсә галәйһис-сәламнән мәгарә тарафын белешкән елан максат сәгатенә ирешүне көтеп алган иде. Ул шуышып кына килде. Әмма Мөхәммәд пәйгамбәрне тешләргә теләп тә, Әбу-Бәкер корган урынга үтеп керә алмады. Ысылдап, шушы тирәдә йөрештерә башлады. Уң вә сулга чыкты. Алты йөз ел буена хыялында тоткан максатына ирешмәячәгенә хафаланды. Шулвакыт ябма тишеген каплап торган Әбу-Бәкернең аягын күреп алды.

Елан бөтерелде һәм сукты. Максаты тишек авызын азат итү һәм шуннан эчкә узу иде. Әбу-Бәкернең йокысы ачылды, әмма аягын алмады.

Күзләреннә утлар күренүгә карамастан, еланны пәйгамбәр янына кертергә исәбе юк иде. Елан икенче тапкыр сукты, тишекнең ачылмавын күргәч, өченче мәртәбәсендә Әбу-Бәкернең аягына тешләрен батырды. Ул инде саташып өлгергән иде. Агуы чыккач, пәйгамбәр өчен аның зәһәре калмады. Артка чигенде. Әбу-Бәкер авыртудан калтыранып куйды. Күзләренә кайнар яшь бөртекләре җыелды. Алдына башын куеп йоклаган Мөхәммәд галәйһис-сәламне уятмаска иде исәбе. Түзде.

Әйтерләр ки, дин иясе бәндәләр бу вакыйганы исләренә алган вакытта күңелләренең сыкравын тоярлар һәм дуслыкның никадәр күркәм тугрылык таләп итүенә мәдхия җырларлар. Нинди генә олуг юлга чыксаң да, Әбу-Бәкер кебек дустың булсын! Ул синең өчен җанын фида кылырга әзер торсын, әмма үзең дә аны ташлама, юкса гомерең буе бәгырь түреңдә авыр таш йөртерсең...

Елан чагудан Әбу-Бәкернең күзләренә җыелган кайнар яшь бөртекләреннән берсе Мөхәммәд галәйһис-сәламнең маңгаена тамды. Пәйгамбәр уянып китте һәм дустының хәвеф эчендә икәнлеген тиз аңлап алды.

— И сөекле дустым, ни булды?

— Елан чакты,— дип җавап бирерлек хәл тапты Әбу-Бәкер.

— Нигә үземне шунда ук уятмадың?— дип хафага төште Рәсүл Әкрам һәм юлдашының яраланган аягына үрелде, шифалы иреннәрен шунда терәде, еланның агуын суыра башлады...

Мөхәммәд галәйһис-сәлам Әбу-Бәкернең ярасын кат-кат суырды, агуның тәмам чыгып беткәненә кадәр тырышты һәм максатына иреште. Шушы рәвешле бәладән котылдылар.

Риваятьләрдә тагын да шулай сөйләнелә ки, кяферләр бераз юл үтүгә, тау тишегенә кабат әйләнеп килделәр һәм, ниятләнеп, мәгарәгә керергә теләделәр. Әмма күгәрчен оясындагы йомырка һәм чигелгән пәрәвез аларны икенче мәртәбә туктарга мәҗбүр итте. Шулай да эчкә узарга теләделәр. Шунда күңелләренә шик төште. Елан ысылдаган тавыш аларга өркү салды.

Алты йөз ел буе агу йөрткән һәм Мөхәммәд пәйгамбәргә зыян салырга ниятләнгән елан Әбу-Бәкерне чагуыннан соң хафага төшкән һәм үз алдына ачу белән зәһәр тавышлар чыгара иде. Бер дошманның яман гамәле икенче дошманнарга курку салды. Шулай да кяферләр Саур мәгарәсенә кереп карарга теләделәр, юкса тынычлана алмас иделәр.

Аларның үзсүзле булуларын Җәбраил галәйһис-сәлам белеп торды һәм Аллаһы тәгаләнең рөхсәтенә таянып, кеше сурәтендә алар арасына төште һәм:

— Монда сез эзләгән кемсәләрнең яшеренүләре мөмкин эш түгел. Күрмисезме? Күтәрелеп, күгәрчен очты. Әмма йомыркасы калды. Аның өстенә басмыйча үтәргә мөмкинме соң? Тагын да арырак карагыз. Пәрәвез ятмәсе тау тишеген тулысы белән каплап бетергән. Моннан үткән кеше аны ертмыйча уза алыр идеме? Инде дә колак куегыз. Мәгарә эчендә усал еланнарның ыжгырганнары ишетелә. Кем үз теләге белән язмышын үлем авызына салыр иде икән?— дип белдерде.

Бу сүзләрне ишетүгә, кяферләр мәгарә эченә керү теләгеннән баш тарттылар һәм, тагын да күтәрелеп, пәйгамбәр вә аның дусты Әбу-Бәкерне артларыннан бастыру өчен кузгалдылар. Аларның юлы бүтәнчә шушы Саур тавы мәгарәсенә төшмәде.

Мөхәммәд галәйһис-сәлам һәм Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйк бу тау куышында тагын да өч көн һәм өч төн тордылар. Аларга ял гына түгел, бәлки тән яраларының савыгуы һәм дошманнарының чарасызлыктан бераз тынычлана төшүе дә кирәк иде.

Мәккә кешеләреннән Габдулла бине Әбу-Бәкердән бүтән һичкем серне белми иде. Ул Саур тавы мәгарәсенә килеп йөрде, кирәкле азык-төлекне китерде, вакыйгаларны бәйнә-бәйнә сөйләп, әткәсен һәм аның дусты пәйгамбәрне мәгълүматлы итеп торды. Кичләрен алар янына җитешер, таңда корәиш арасына кереп, бар кирәкле сүзне белешер иде.

Бу тирәләрдән ерак түгел җәйләүләрдә Әбу-Бәкернең колы Гамер бине Фәһр үз җае белән генә хуҗасының көтүләрен көтә иде. Ул да мөэминнәр сафына басып, Аллаһы тәгаләнең камил дәрәҗәле колларыннан исәпләнер икән. Шулай ук пәйгамбәргә мәхәббәте зур булып, сердән хәбәр алды. Ил өстенә кич иңеп, бер сәгать узар-узмастан көтүләрен шушы мәгарә янына куар иде дә, тук вә көр малларыннан сөтне савып, яраннарына китерер иде. Аның шушы рәвештәге олуг хезмәтләре Рәсүл Әкрамга карата гына түгел, хуҗасы Әбу-Бәкергә кешелеклелеге өчен рәхмәте дә иде. Яхшы хуҗада яман хезмәтче тормый дигән сүз Гамер бине Фәһрнең күрсәткән гамәлләреннән соң калды һәм телләрдән телләргә күчте.

Рабигыль-әүвәл аеның дүшәмбе көнендә, яңа туган айның бишенче кичәсендә Гамер бине Фәһр һәм Габдулла Аркат, ике дөягә атланып, пәйгамбәр һәм Әбу-Бәкер яшеренгән тау куышы янына килделәр. Ерак юлга кузгалырга вакыт җиткән иде инде. Рәсүл Әкрамны тотып биргән кешегә йөз баш мал вәгъдә ителү сәбәпле, Мәккә ахмаклары Ясрип белән ике арадагы сахра вә далаларда таралып, көн вә төн шымчылык итсәләр дә, хәбәрсез калдылар. Гамер бине Фәһр көтүләрне башка бер колга тапшырып, хуҗасын озата йөрергә, яшерен юл вә сукмакларны яхшы белгән бәдәви гарәп Габдулла бине Аркат аларны Ясрипкә хәвеф-хәтәрсез китерергә тиеш иде. Сөйләшенү шулай булды.

Мәгарәдә соңгы тапкыр тәгам җыйдылар, дога кылдылар. Мөхәммәд галәйһис-сәлам элеккечә тыныч һәм бар эшендә Аллаһы тәгаләгә таянганлыгын белдереп эш итте. Һиҗрәткә төшкән көннәреннән бирле Әбу-Бәкернең җаны тынычлык тапмаса да, Рәсүл Әкрам һичнинди шик төенен күңел түрендә сакламады. Аның шушы рәвешле булуы дустын да ныклыкка этәрә иде. Гамер һәм Габдулла дөя өстендә килүгә Әбу-Бәкер ашыга башлады. Аның бу хәвеф-хәтәрле урынны тизрәк ташлап китәргә теләге зур иде.

Гамер бине Фәһр белән Габдулла бине Аркат икесе бер дөягә утырдылар. Икенче дөягә Мөхәммәд галәйһис-сәлам һәм дусты Әбу-Бәкер урнаштылар. Йөгәнне Әбу-Бәкер үз кулына тотты. Аллаһы тәгаләгә тапшырып һәм аның амин дигән сәгатенә атап, сәфәр башладылар.

Мөһаҗирләр Сәвәһил юлына керделәр. Мәккә вә Ясрип арасында кяферләр тырышып-тырышып пәйгамбәр эзен барлаулары сәбәпле, махсус рәвештә алар шушы юлны сайлады. Ул Ясрипнең капма-каршы ягына, Бәхрел-Кылзум, ягъни Кызыл диңгезгә таба, көньяк-көнбатышка илтә иде. Үлем тырнагыннан котылган бәндә шикелле ашкынган Әбу-Бәкергә тотынып утырган Мөхәммәд галәйһис-сәлам, киресенчә, сагыш вә моң эченә чумды. Аның күркәм авызыннан бәгырь төбен айкап аһ авазы ишетелде.

Кич иңеп бара иде. Төн буе киләселәре бар. Мәккә арттa калды. Мөхәммәд пәйгамбәрнең авызыннан чыккан аһ авазыннан якынтараф уянып киткәндәй булды.

— Йа Аллаһы тәгаләнең колы, Мөхәммәд галәйһис-сәлам, аһыңны орма! Юкса безнең барчабыз да утка төренербез. Болай да адәмиләрнең мәрхәмәтсезлекләрен күреп, бәгырьләребез киселә. Без сине юксынырбыз! Без сине көтәрбез! Син төн булып кит, таң аттырып кайт! — дип теләк теләде таулар.

Аларның сүзен һәр тараф күтәреп алды. Барчасы пәйгамбәргә хәерле сәфәр теләде. Илдән яман бәндә китсә, дөньялар яктырып калган кебек була, мәгәрем ки, яхшы кеше илдән китсә, кояшлы көн дә сүнгән кебек тоела, бар тарафлар сагыш-моңга чума, бәгырьләр телгәләнә.

Мөхәммәд галәйһис-сәлам туган иленнән аерылуны авыр кичереп аһ оруга, аның хәлен белешергә дип Җәбраил фәрештә житеште һәм үтенде:

— И Аллаһы тәгаләнең сөеклесе, хәлең ничектер?

Рәсүл Әкрамның күңеле тулы моң-сагыш иде. Дәшәргә кодрәте житмәде. Һәр адәм баласына хас хис вә кичерешләрдән ул ничек итеп азат булсын ди?

— И Аллаһы тәгаләнең сөеклесе, илдән аерылу сагышында хәлең ничектер? — дип кабатлады фәрештә, җавап ишетмәүдән хәвефләнеп.

Пәйгамбәрнең күзләрендә яшь бөртекләре иде. Әмма ул икенче кабат Аллаһы тәгаләнең хәбәрчесе Җәбраил фәрештәне борчуга салып аһ ормады, бәгыренең өзгәләнүләренә түзәр булды. Үзен бу рәвешле тотуына сокланырлык иде. Шунда Җәбраил галәйһис-сәлам әйтте:

— Йә, Мөхәммәд, илдән аерылып киткән гарибләр хәлен күр: бәгырьләрендә нинди авыр таш йөртерләр. Алар түгелме Аллаһы тәгаләнең сөеклеләре? Алар түгелме адәм балалары арасында һәр яклардан хөрмәт казанырга тиешле кемсәләр? Илдән китәргә мәҗбүр ителгән бәндәләрнең һәр аһы туган йортында кәеф-сафа корып ятканнарның хәвефедер. Әгәрем дә көннәре тыныч тормыш белән үтсен дип теләсәләр, гарибләргә мәрхәмәт йөзе күрсәтсеннәр, юкса бәхетләре булмас! — дип белдерде.

Пәйгамбәр яраннары белән кичтән юлга чыгар, таң беленүгә ялга туктар иде. Алар олуг сәүдә юлларына төшмәделәр, азлар гына белә торган сукмакларны сайладылар. Мөхәммәд галәйһис-сәлам һәрдаим үзен тыныч тотты. Ясрипкә якынайган саен Әбу-Бәкернең дә күңеле урынына утыра башлады. Габдулла бине Аркат юлны яхшы белә, адаштырып аптыратмады. Хәвеф-хәтәргә төшерерлек кешеләргә дә очрамадылар. Әмма ризыклары гына җитәрлек түгел иде.

Юлда килгән вакытларында төнге ялга туктаган көтүгә очрадылар. Аларның каршысында, угрылар дип белеп, малларны саклаучы чыкты. Төндә кемнәр йөрмәс. Бер-бер хәвеф яки көтелмәгән хәл килеп чыкмасын өчен үзара аңлашырга тиешле иделәр. Бу сөйләшүне үз өстенә Әбу-Бәкер алды һәм инде шактый ерак юл узуларын, ризыклары да азаеп китүне, тамаклары ач икәнлекне шунда көтүче кемсәгә бәйнә-бәйнә сөйләп бирде һәм эчәрлек вә авызга тидерерлек сөт бирүен үтенде. Әңгәмә вакытында дөядәгеләр дә шикле хәрәкәт ясамадылар, хөрмәт вә ихтирам белән олуг кыяфәтләрендә кала бирделәр. Әбу-Бәкернең затлы телдән сөйләүләре, юлдашларының тыныч вә күндәм торулары көтүче вә сакчыларның күңелләренә хуш килде һәм ярдәм кулыннан коры калдырмадылар, сөт тулы савыт суздылар. Хәтта алар янында булса да, Әбу-Бәкер нигъмәткә авызын тидермәде, иң элек изге зат Мөхәммәд галәйһис-сәлам каршысына китерде һәм аңа тәкъдим итте.

Барысының да ризыкланасы һәм сусауларын басасы килә иде. Рәсүл Әкрам Аллаһы тәгалә исеме белән сөт тулы савытны мөбарәк кулларына алды, күтәрде, авыз итте, әмма тиз арада тәкатен табып, үзенә тиярдәй өлешне генә йотты да башка юлдашларына суздьı. Шул рәвешле һәммәсе сыйландылар. Һәр эчкән йотымнары аларга көч һәм дәрт өстәде, тулы бер савыттан тәмамына кадәр ризыклангандай тәэсир калдырды. Шул кадәр дә тату вә бер-берсенә карата күрсәткән кадер-хөрмәтләренә игътибар итеп торган көтүчеләр хикмәт вә мәгънә эчендә хушландылар һәм бу вакыйганы чынбарлыктан битәр, бер могҗиза рәвешендә хәтерләрендә калдырдылар.

Рәхмәтләре белән болар яныннан китеп, икенче юлы пәйгамбәр һәм аның юлдашлары Мәгъбәд йортына килеп чыктылар. Болар күчмә гарәп кабиләләреннән булып, араларында зәнкиләр* дә бар иде. Үзләре бик тә арык тәнле икән. Шушындый кыяфәтләре тормышларының мохтаҗлык белән авырлыкта үткәнлегенә дәлил иде. Ул гына да түгел, хәтта маллары да арык булып, хуҗаларын өметтән өзәләр икән.

Мөхәммәд галәйһис-сәлам ризыктан бераз тартынып торырга вә сабыр итәргә риза иде дә, әмма юлдашлары талчыккан һәм азыкка мохтаҗлыкларын сиздерер дәрәҗәдә кыландылар. Шунлыктан бу көн юлларында беренче очраган кемсәдән — Хәмид кызы Хузагыйдан кабымлык хөрмә җимеше вә ит кисәге үтенделәр, хәтта акча да тәкъдим

---

* Зәнки — негр.

иттеләр. Бары тик теләкләреннән генә коры калдылар һәм ачлыкка дучар ителделәр.

Хәмид кызы Хузагыя үзе Мәгъбәд кабиләсеннән иде. Аның эше көн дә ишек төбендә утыру һәм үткән-сүткәннән хәбәрдар булып торудан кала, шундый юлчыларга мөмкин кадәр ярдәм итү, сораганга — су, теләнгәнгә азык каптырып җибәрү иде. Әмма соңгы вакытларда көннәрнең эссе торуы аркасында көтүлекләрдә маллары зәгыйфьләнде, ризыкларында тарлык хасил ителде. Юлдашлары белән килеп ирешкән пәйгамбәрнең өмет белдереп үтенүләренә бу өлкән яшьтәге хатын ярдәм итә алмасын әйтте:

— Әгәр дә йортыбызда ризык бар икән, мин аны бушка да бирәм. Акча да кирәкмәс. Тик бүген үзегезне коры калдырам. Кичәге көндә сездән дә олуграк затлар килделәр, хәтта аларга да табын ясар өчен мөмкинчелегем булмады. Зур кунаклар иделәр. Шулай килеп чыкты. Малларыбыз зәгыйфьләнде. Йортыбызга эсселек җәбер вә җәфа салды,— диде.

Гамер бине Фәһр һәм Габдулла бине Аркат бер-берсенә карашып куйдылар. Аларның өметсезлектән күңелләре сулган, йөзләре тартылган иде. Гүяки: «Никләр өчен генә бу олуг юлга чыктык?» — дип уйлый төсле иделәр. Әбу-Бәкер дә сәфәрдән талчыккан, соңгы вакытларда бөтенләй олыгаеп киткәндәй күренә, аның да ышанычы кимегән иде булса кирәк.

Юлдашларының авыр хәле пәйгамбәрнең күзендә яшь бөртекләренең хасил кылынуына бер сәбәп иде. Алар яки шушында тукталырга, дошманнарының кулына төшәргә, яисә ризыкланып, юлларын дәвам итәргә тиешләр. Икесенең берсе. Әмма ни чара, ярдәм кулын сузарлык кем бар?

Мөхәммәд галәйһис-сәламнең күзләре чатыр артында бәйле торган сарыкка төште. Аның кыяфәте бик тә арык һәм өметсез иде. Әмма Рәсүл Әкрам Хак тәгаләнең ярдәмен теләде вә:

— Ул сарыгыгызны савып, сөтен эчсәк ни булыр? — дип үтенде, малны әйләнеп, як-яктан карады.

— Булмас,— дип белдерде хатын.— Булмас. Ул сарыгыбыз бик тә зәгыйфь, шул сәбәпле көтүдән дә кала. Аның нинди сөте булсын ди? Тәнендә җаны гына калган бит,— диде.

— Савып карарга рөхсәтегез юкмыдыр? — диде пәйгамбәр.

— Рөхсәтен рөхсәт тә, тик теләгегез уңыш тапмас дип беләм.

Рәсүл Әкрам шушы сүзләрне ишетүгә сарык-куйны ике тез арасына алды, бисмилла әйтеп, эшкә керешге. Тәпи араларына тустаган куеп, сарыкны сава башлады. Аллаһы тәгаләнең хикмәтедер, Мөхәммәд галәйһис-сәламнең мөбарәк куллары тию белән бу хайванның имчәкләре тәмамын сөткә тулды вә сибелеп ага башлады. Бу нигъмәттән барчасының да кәефләре күтәрелде. Пәйгамбәр иң элек юлдашларын сыйлады. Аннан соң тагын сауды. Бу юлысы да тустаган мөлдерәмә тулды. Икенче кат сыйландылар. Инде һәммәсе шатлана иделәр. Рәсүл Әкрам тагын куйны ике тезе арасына алды.

— Зуррак савытыгыз булмасмы? — дип үтенде.

Хатын көнде. Сарыктан бу рәвешле мул итеп сөт акканын аның үз гомеренә беренче тапкыр күрүе иде. Күзләре күргәнгә күңеле ышанмады. Шулай да дәүрәк савыт китерде һәм аптыраган хәлендә калды.

Мөхәммәд пәйгамбәр куйның имчәкләренә өченче кат мөбарәк кулларын тидерде. Сөт чишмәсе ага башлады. Бу савыт та тулды. Әмма монысын Рәсүл Әкрам үзенең юлдашларына бирмәде, бәлки малның хуҗасы Хәмид кызы Хузагыягә калдырды. Риваять итеп сөйләрләр ки, шушы вакыйгадан соң бу сарык алты көн буена хуҗаларын сөте белән сыйлады һәм, ни гаҗәп, унсигез яшенә кадәр бәрәкәтле имчәкләреннән мәртәбә табып, ияләрен куандырды.

Пәйгамбәр юлдашлары шушы Мәгъбәд йортыннан чыккач, озак та тормый Хәмид кызы Хузагыянең ире көтүлектән эшен бетереп кайтты. Табында савыт тулы сөтне күргәч, берара аптырап калды, аннан соң:

— Бу сөт кайдан килде? — дип сорады.

Хатыны вакыйганы бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Ире ул юлчыларның кем икәнлеген авырлыксыз аңлап алды һәм, Мөхәммәд белән Әбу-Бәкер вә иптәшләре икәнлеген төшенүгә, аларны тотып биргән яки кайдалыгын хәбәр иткән кешегә йөз баш дөя бүләк кылыначак дигән сүзне хәтеренә алып, бу кадәр байлыкларга кызыгудан тыела алмыйча, Мәккә кяферләренә ничек тә хәбәр бирергә ашыкты. Моңа кадәр пәйгамбәрне кайдан эзләргә дә белмәгән дошманнарына бу бәндә аваз белән тапшыручылар аша серне белдерде. Мәккә ахмаклары Рәсүл Әкрамның кайсы юл белән һиҗрәт кылганлыгын төшенеп алдылар, әмма серне чишкән ирне бүләксез калдырдылар. Тарихлардан шул билгеле: берничә елдан бу хатын вә ир Мәдинәгә барып, Мөхәммәд пәйгамбәрдән гафу сорадылар.

Һиҗрәт вакытында булган кызыклы вакыйгалардан тагын берсе шул иде ки, хәбәр китапларына ул «Сирака хәле» дигән исем белән кереп калды һәм ахмаклар өчен сабакның ничек бирелүе мисалларыннан иде.

Мөхәммәд пәйгамбәр, аның юлдашлары Әбу-Бәкер, Гамер бине Фәһр һәм Габдулла бине Аркат, Мәгъбәд йортыннан чыгып, юлларын дәвам иттеләр. Инде максатларына да әллә ни ерак калмаган кебек иде. Шунда аларны сәфәрдә Сирака кешеләреннән берәү күрде һәм кемнәр икәнлеген чамалап алды да, хуҗасы каршысына җитешеп, баш орды, әйтте:

— Юл арасында дүрт адәмне шәйләдем, хәбәрләргә караганда, алар Мәккәдән качып килүчеләр булырга кирәк!

Сүзендә ялган юк иде. Берничә көннәр генә элгәредер, Мәккәдән хат күндерелеп, кем дә кем пәйгамбәр вә аның юлдашын тотып бирсә, яисә үтерсә, бу хезмәтләренә бәрабәр йөзәр баш дөядән бүләк ирешәчәк, ул гына да түгел, моны башкаручы бәндә корәишләр арасында иң олуг кылынып, дуслары да ителәчәк, имеш. Беренче тапкыр моңа әлләни игътибар бирүче күренмәсә дә, хат икенче тапкырында да шундый ук эчтәлек белән килеп ирешкәч, байлыкка җанын фида кылыр өчен әзер торган һәр кеше күзен юлдан алмады. Сираканы да юктан өскә ишелергә торган мал кызыктыра иде.

Пәйгамбәрне юлдашлары белән бергә күреп калган кемсәдән хәбәр алуга, Сирака күңел түрендә кайнаган уй-фикерен төенләп, теләк-омтылышын канәгатьләндерергә ашыкты. Исәбе ничек тә серне яшерергә, байлыкны уртактан бүлешмичә, үзенә генә учларга иде аның. Шунлыктан бер дә исе китмәгән кыяфәттә:

— Әйе, минем яннан да уздылар алар,— дигән булды.— Әмма Мәккәдән качып килүче затлар түгел, башкалар болар. Төс-кыяфәтләре дә охшамаган. Юк-юк! Ялгышмыйк. Алар түгел!

Шушы рәвешле сөйләвен сөйләде, бары тик теле такылдаганны зиһене җыймады. Башында башка уйлар иде: ничек тә үзенә генә алырга биреләчәк бүләкне!

Сирака эшне тиз тотты. Хезмәтчесеннән яшертен генә ат иярләтте. Һичкемгә сиздермичә юлга төште. Кулында угы-җәясе, сугыш була калса дип алынган кирәк-ярагы иде. Атын да һичбер кызганусыз куалады. Уңлы-суллы селтәнеп камчылады. Күз алдында гүяки бүләк итеп куыла килүче йөз баш дөя көтүе, хыялында байлык вә мәртәбә иде.

Аның дәһшәт белән ашкынып ат чаптырганын иң алдан Әбу-Бәкер күрде һәм күңеленә курку йөгерде. Тыя алмады, күзләренә яшь килде.

— Бу безнең гомерләребезне кисәргә дәртләнгән кешегә охшый, харап кына булырбыз! — дип йөрәк әрнүен пәйгамбәргә җиткерде.— Бетерер башларыбызны!..

Бу хәлдән Рәсүл Әкрамның да күңеле кузгалды, Сираканың дәһшәте үзеннән алда йөри иде. Мөхәммәд пәйгамбәр, Аллаһы тәгаләдән ярдәм үтенеп, догага кулын күтәрде.

Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйк чарасыздан һаман да күзләреннән яшь агызды. Мөхәммәд галәйһис-сәлам аны тынычландырырга теләп, юату сүзе буларак:

— Нигә бу кадәр хафага төштең? — дип сорады.

— И Аллаһы тәгаләнең колы вә сөеклесе Мөхәммәд, үзем өчен борчылудан түгел, сине харап итәр дә мөэминнәрне ятим калдырыр дип борчылудан күңелем бүселде,— диде Әбу-Бәкер.

Шунда Рәсүл Әкрам:

— Без ялгыз түгел, безнең ярдәмчебез бар,— дип сакал сыпырды.

Ул да булмады, Сираканың аты кешнәде һәм хуҗасын баш аша алга ыргытты. Мәтәлеп төшкән Сирака чактан гына кадалып калмады. Тиз ара аягына басып, атын тезгененнән эләктерде. Җәһәтлек белән генә иярenә атланды һәм саллы итеп камчысын орды. Ат сузылып алга томырылды. Хуҗасының дәһшәте тагын да арткан, ачуы кабарган иде. Аллаһы тәгаләнең кисәтүен санга сукмыйча, кирелек вә нәфселектә күңелен адаштырды. Җитмәсә:

— Туктагыз, туктыйсы булмасагыз, үтерәм! — дип яный үзе.

Мөхәммәд саллалаһу галәйһи вә сәлләм тагын да догага кулын күтәрде һәм:

— Йа Ходаем, син безне дошманнар үченнән имин ит, ярдәмеңнән ташлама! — диде.

Ул да булмады, Сираканың аты чабудан тыелды, киреләнеп кешнәде. Сыртын камчы белән каезлаудан файда юк иде. Атның дүрт аягы да тездән югары җиргә чумган иде. Сирака чарасыз калды. Өченче тапкырында үзен оятлы итәсе килмәде, кодрәте шиңде, көче кайтты һәм:

— Мин синең чыннан да пәйгамбәр булуыңны таныйм. Ике тапкыр кисәттең, өченчесенә җөрьәт итмим. Теләсәң, кунагым бул, теләсәң, ни бар байлыгымны сора, җаның теләгәне — үзеңнеке! — дип баш иде.

Пәйгамбәр аның тәкъдимнәрен кире какты һәм аңа иманнамә төзеп бирергә теләге барлыгын белдерде. Әмма Сирака моның асыл мәгънәсен аңлап җитмәде. Бу кадәр җайсыз хәлдә калганы юклыктан акылы саегыбрак киткән иде. Шунлыктан теле дә сөйләнүдән туктамады:

— Минем юлларда кәрваннарым йөреп торыр. Сез килгән якка каршы тарафтан да кәрваным кайтыр. Менә сезгә минем кынымдагы угым. Алыгыз. Аны күрсәтегез, билге булыр, кәрваннарымнан кирәк кадәре байлык вә малларымны үз теләгегез белән алырсыз,— дип, күп нәрсәләрне әйтеп ташлады. Әмма пәйгамбәр итагатьле генә итеп баш тартты. Аңа байлык кирәк түгел иде, чөнки Аллаһы тәгалә биргән гыйлемнән дә олуграк вә өстенрәк нәрсә бармы бу дөнья йөзендә?

Рәсүл Әкрам, иманнамә язып, Сиракага тоттырды. Ул бу язуны ук кынына салды һәм үз ахмаклыгына хәйраннар калып, юлчылар китеп баргач та, шактый озак вакытлар кузгалмый торды. Икенче көнне Мәккәгә хат күндерде һәм үзе тап булган могҗизадан хәбәрен биреп, Мөхәммәдкә ышанычын белдерде.

Һиҗрәттә пәйда булган вакыйгалардан тагын да берсе шул иде, Бәни-Әслам кабиләсеннән Бәридәтел-Хасип, пәйгамбәр вә юлдашы Әбу-Бәкернең җанын кыйган өчен Мәккә дошманнары йөзәр дөя бирәчәкләрен ишетүгә, мал вә байлык хафасында калды. Үзенең җитмеш кешесен иртәләп, көн вә төндә уң һәм сулны айкады. Ахырда, кайсы юл белән киләчәкләрe ачыклангач, шунда барып, көтеп алдылар, һәрбер сәфәр чыккан затны сораштырып кына уздыра иделәр. Менә көннәрнең берендә пәйгамбәрне дә күрергә насыйп булып, мәгънәле әңгәмәдән соң, Мөхәммәд галәйһис-сәламнең сүзләренә вә Аллаһы тәгаләнең кадир кодрәт иясе икәнлегенә тәмам камил рәвештә инанып, иман китерде. Үзе белән килгән җитмеш кешесе дә аңа ияреп иман китерделәр. Шулай итеп, Ясрипка барып җиткәнчегә кадәр пәйгамбәрнең иминлеген саклауны Бәридәтел-Хасип үз өстенә алды.

Шушы рәвешле Рәсүл Әкрам үзенең иптәшләре белән һиҗрәт юлын авырлык белән булса да, хәвеф-хәтәрсез генә үтә бирде һәм һәрдаим юлдашлыкта Хак тәгаләнең барлыгын тойды.

Мөхәммәд галәйһис-сәламне Ясрип шәһәрендә көтә иделәр. Бу Ясрип дигәннәре пәйгамбәрнең бабасы Габделмотталип хәзрәтләренең туган җире иде һәм шунда сәфәр кылганда Рәсүл Әкрамның газиз әткәсе Габдулла вә берничә елдан сөекле әнкәсе Әминә дә шушы тарафларда кабер туфрагын тапкан иделәр. Гүяки, Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлламнең монда һиҗрәт кыласын хак тәгалә алдан ук белеп торган һәм аны кендеге белән бу мәнзәл-төбәккә бәйләп топкан иде. Шул сәбәпледер, башкача булмас, Ясрипне гарәпләр асылда Мәдинә, ягъни Шәһәркала дип кенә йөртә иделәр һәм тора-бара, Мөхәммәд галәйһис-сәлам шушында төпләнеп калгач, горурлык вә мәртәбә белән үзләрен олуглар хисабында санаган Ясрип халкы калаларын Мәдинәтер-Рәсүл, Пәйгамбәр шәһәре, диделәр. Шунлыктан Ясрип урынына Мәдинә дип язганнан тарих вә хакыйкатькә һичбер хилафлык булмастыр!

Шулай итеп, Мөхәммәд галәйһис-сәламнең яраннары белән Мәккә кяферләре арасыннан чыкканлыгы вә Мәдинәгә таба юнәлгәнлеге хәбәре Ясрип халкына килеп ирешүгә, шәһәр эчендә бер-бер хәрәкәтләр күренә вә гаҗәеп хәлләр мәйданга чыга башладылар. Бәхет өметендә яшәгән кавем олуг хис вә тойгы тәэсирендә калды. Инде менә пәйгамбәр килеп җитәр дә сәгадәт диңгезендә гарык булырлар һәм камиллек-бәрәкәт аларны шатландырыр төсле иде. Әмма Рәсүл Әкрам һаман да күренмәде. Мәккә вә сахра тарафларыннан килеп ирешкән хәбәрләр Мәдинә халкын шашындыра иде.

— Кара әле бу ахмакларны, пәйгамбәрнең вә яраннарының башына бихисап күп мал, көтү белән дөя атаганнар бит!

— Пәйгамбәрнең китерәчәк сәгадәтен шулкадәр ким бәһагә куйгач, ахмаклардыр шул!

— И мескеннәр, и наданнар! Дөнья малын Хак тәгалә гыйлеменә кем алыштыра инде?

— Юньле булсалар, пәйгамбәрдән баш чөерер иделәрме?

Шушы рәвешле сөйләнелгән сүзләр аңсызларны да аңлы, фикерсезләрне дә фикерле итә иде. Тәкате тәмам өзелгән мөселманнар Мәдинәдән чыгып, Мәккә вә сахра ягын белештерергә юл алганны күрүгә, аларга башкалар да иярде. Иртәдән килеп кичкә кадәр, кулларын маңгай өстенә куеп, кәрван юлларын күзәткән өлкән вә кече яшьтәге затлар пәйгамбәрдән иминлек хәбәрен генә булса да көттеләр.

— Менә бүген дә килмәде!

— Менә бүген дә насыйп итмәде! — дип, кичке йокы вә ял өчен өйләренә кайтыр һәм иртән кояш күренгәнче диярлек тагын юлга чыгып көтәр иделәр. Әмма чарасыз иделәр.

Көннәрнең берендә шулай Мәдинәдә ни бар өлкән вә сабый, инде гадәтләренә кергән хәлдә, шәһәр читенә агылдылар. Монда яшәүче яһүдиләр ара-тирә аларның артыннан карап кала бирделәр. Ике кеше бер чатта очрашып мөгамәлә кыла башласа, мөселманнарның бу эшләрен яки мактадылар, яисә:

— Бу китапсыз кавем дә пәйгамбәрле булып, Аллаһы тәгаләнең теләге белән яши башласа, Тәүратның хилафлыгы ачылыр, безнең якты көнебез каралыр, кояшыбыз баер, — дип фараз итә вә үзара бәхәскә төшә бирделәр.

Бу көндә дә мөселманнар Мәдинәне ташлап, юл башына чыктылар. Кайсы ялгыз, кайсысы бала күтәргән, кулындагы таякка терәүләнгән халәттә сахра тарафын күзәткәндә, аларның араларына кушылган яһүдиләрдән берәү бинихая балкыш белән еракта нур күрде. Үз диненә камил дәрәҗәдә ышанган, Хак тәгаләнең барча могҗизаларында хикмәт вә сәгадәт барлыгын төшенгән бу зат беразга телсез калды. Пәйгамбәрнең нурыннан сахра вә таулар сихри балкыш белән күмелеп, гүяки кояш чыга

вә акрын гына күтәрелеп киләдер төсле иде. Асылда актан киенгән Мөхәммәд галәйһис-сәлам вә аның юлдашы Әбу-Бәкер, ул шулай ук актан иде, бу вакытта Мәдинә шәһәренә житеп килә һәм тукталып калган иделәр. Рәсүл Әкрамның сәгадәт нуры яһүдине тәкатьсез калдырды һәм ул шул минутта хакыйкатьне теленә алды вә әйтте:

— И гарәп таифәсе, сез таләп иткән бәхет-дәүләтегез чыннан да шушыдыр, башка булмас! — диде.

Мәдинәдән чыгып, пәйгамбәрне каршы алырга ашкынган һәммәсе дә Рәсүл Әкрамның сәгадәт хәбәре буларак яктырткан кальбе нурыннан күңелләренең асыл түрендә шатлык вә куаныч таптылар. Ничәмә гасырлар гомер кичергән вә мохтаҗлык һәм шатлыклы вакыйгаларны ишетеп тә, күреп тә белгән халык бу вакытта олуг бәйрәм вә бәхет хисен кичерде. Ул да түгел, Хак тәгаләнең рәхмәте белән Мәдинә шәһәрендә балкыш хасыл ителеп, һәммә гарәп вә яһүди таифәсенең йөзләре көчле шатлык вә иминлек төсенә буялган иде.

Халык сөенде. Мәдинәдә нур хасыл булды. Нәжари кабиләсеннән шәех Гомәр бине Гауфнең шигырь вә җырга гаҗәеп дәрәҗәдә маһирә бер кол-җариясе бар иде. Пәйгамбәрне мактап вә зурлап, һәркемнең уй-кичерешләрен тасвир кылып, бу зат касыйдә вә шигырь чыгарды. Моны ишетеп, барчалар куандылар вә сөенечләрен яшерә алмастан, берсен-берсе котладылар.

Бу көн рабигыль-әүвәл аеның дүшәмбесе, уникенче кичәсе иде. Мәдинә тупсасына килеп баскан Мөхәммәд галәйһис-сәламнән дусты Әбу-Бәкер сорады:

— Хәзрәт, кемгә тукталырбыз?

Рәсүл Әкрам һичбер шиккә төшмәстән хәбәрен бирде:

— Бу кичәдә туганнарымнан Бәни-Нәҗар кабиләсендә булырбыз!

Гарәпләрнең бу кабиләсе Мөхәммәд галәйһис-сәламгә туган вә карендәш тиеш иделәр. Чөнки Рәсүл Әкрамның бабасы Габделмотталип хәзрәтләренең газиз әнкәсе Сәлимә шушында туды. Аны кияүгә пәйгамбәрнең олуг бабасы Габдемәннаф алды. Габделмотталип үзе дә шушы кабиләдә кунакта чакларында яралды һәм дә шушында туды. Бу сәбәптән Мөхәммәд галәйһис-сәламне алар кадер вә хөрмәт белән каршыладылар, куанычлары шулкадәр көчле иде ки, бәйрәм вә бәхет хисе йөрәкләренә сары май булып ятты.

Ул кичәдә пәйгамбәр үзенең иптәшләре белән шушы кабиләгә кунак булып төште. Алар Гөлсем бине Әл-һәдим исемле мөслимәдән сый-хөрмәт таптылар, аларның йортында кундылар. Олуг хөрмәтләрен үз өйләрендә Хәбиб бине Асаф, Хариҗа бине Зәйд һәм башкалар да күрсәтте.

Мәдинә халкы тәкатьсез калып, Рәсүл Әкрамның шәһәргә дә керүен көтә иде. Әмма Мөхәммәд пәйгамбәр кузгалмады. Хак тәгаләнең рөхсәтеннән башка Мәдинәгә керү хилаф эшләрдән булырга мөмкин иде дә, Әбу-Бәкер сабырсызлык галәмәтләрен дә күрсәткәләде. Пәйгамбәр ашыкмады. Мәдинә көтә бирде.

Арадан мөселманнар Әбу-Бәкергә килделәр һәм Рәсүл Әкрамны шәһәргә чакырдылар, халыкның зар булып, бәйрәм хисе эчендә көткәнлекләрен сөйләделәр.

Бу вакытта Мөхәммәд галәйһис-сәлам агач күләгәсендә затына күрә олуглык серләрендә чумып утыра иде. Әбу-Бәкер аның каршысына килде вә пәрдә корды. Халык, төркем-төркем булып, монда агыла вә пәйгамбәр белән әңгәмә тотарга вә аны шәһәргә күтәреп кертергә әзер иде. Аларның якты күңелләре нурланды һәм Рәсүл Әкрамга мактау вә данлау сүзләрен китерделәр. Әмма пәйгамбәр тагын да Мәдинәгә керми кала бирде.

Үндүрт көн буена Бәни Гомәр һәм Бине Гауф кабиләләрендә Мөхәммәд пәйгамбәр вә яраннары кунак булдылар. Хак тәгаләнең олуг хөрмәтләренә рәхмәт йөзеннән Куба җирлегендә бер мәсҗед төзетеп,

аны җомга көнендә җыелышып, бәйрәм ясап ачтылар. Куаныч вә шатлыклардан мөселманнар тантана итте.

Мөхәммәд галәйһис-сәлам вә Әбу-Бәкер Мәккәне ташлап чыкканнан соң дүрт көн узуга, кичен, кеше аягы өзелгәч, ягъни бәндәләр өйләренә бикләнеп йокларга яткач, пәйгамбәрнең арысланы саналган Гали хәзрәтләре дә, Ясрип тарафына күңелен юнәлтеп, юлга чыкты. Көндезләрне ялга туктап, кичләрен, дошманнарга юлыгырга теләмичә, яшеренеп кенә килә иде...

## Әнсарлар арасында тәүге еллары

Мөхәммәд галәйһис-сәлам Куба мәхәлләсендә мәсҗедне төзетеп тәмам иткән чагында хәзрәте Гали сәхабә Мәдинә тарафына килеп иреште. Аның аяклары парә-парә булып суелган, битләре тартылган, тәне арыган вә йончыган иде. Пәйгамбәрнең кайдалыгын бик җиңел белде. Һәркемнең телендә иде ул. Һәммәсе ниндидер олуг тантана белән күңелләрен сөенеч хисенә тутырганнар. Бигрәк тә гарәпләр вә мөселманнар үз шатлыкларын яшерә алмыйча куана иделәр. Куба мәхәлләсендә мәсҗед төзелешен ишетүгә, Гали сәхабә дә моны исламның җиңүе дип кабул итте, шунда юнәлде.

Гали Арыслан белән Мөхәммәд пәйгамбәр очраштылар. Суелган вә канап беткән аяк табаннарына саклык белән басып атлаган сәхабә, Рәсүл Әкрамны күрүгә, аның кочагына ташланды. Күзләрендә шатлык вә куаныч очкыннары уйнап, бәгыре аяк табаннарының әрнүеннән сыкраганын пәйгамбәр шунда ук сизеп алды. Аякларыннан сыпырды. Гали Арысланның батырлыгын данлады һәм дога укыды. Аллаһы тәгаләнең рәхмәте белән аның бәгырь әрнүе, Мөхәммәд пәйгамбәрнең кулы тиюгә, җан рәхәте белән алышынды, яралары савыга башлады.

Мәсҗед төзүне тәмамладылар. Бу кичәдә хәзрәте Гомәр үз кабиләсен ташлап, Куба мәхәлләсенә килеп иреште. Ислам тарихында беренче буларак, җомга намазы шушы Куба мәсҗедендә укылды. Пәйгамбәр белән бергә йөз мөселман бар иде. Алар барчасы шушы мәсҗедкә җыелдылар. Шушында икенче могҗиза хасил кылынды вә хөтбә уку фарыз ителде. Шушы көннән башлап һәр җомга мөэминнәрнең мәсҗедкә җыелып намаз укулары вә имам-хатиптан хөтбә тыңларга тиешлеге савап булып төзелде вә фарыз рәвешендә һәркемгә төште, моны һәр мөселман күтәрергә разый кылынды. Беренче җомганы намазын вә хөтбәне Мөхәммәд галәйһис-сәлам күтәрде. Һәрбер мөселманның күңелен айкарлык итеп сүз сөйләде, шуның белән аларны бәхет вә сәгадәт нурына күмде.

Куба мәхәлләсе мәсҗеде төзелеп беткәч һәм беренче җомга намазы вә хөтбә укылуга Мөхәммәд пәйгамбәр Мәдинә шәһәренә күченде. Барча халык аны каршы алырга дип чыктылар. Мәдинә килеп керүгә, һәммәсе аңа тартылды, кайсы аның дөясенең сул ягына, кайсылар — уңына, артына вә алдына төштеләр. Кемнәрдер Мөхәммәд пәйгамбәр утырган дөянең нуктасыннан тоткан булса, Рәсүл Әкрамны үзләренә дәшә башладылар вә йортларына чакырып, шунда кунак итәргә һәм яшәргә калдырырга теләделәр. Шунда Мөхәммәд галәйһис-сәлам:

— Мин сезнең барыгызга да рәхмәтлемен,— диде.— Әмма дөям кайда килеп тез чүксә, шунда тукталырмын! Барыгыз да читкәрәк китсәгез иде. Нуктасыннан тартмагыз, кайда барырга, кайсы урынга тукталырга ул үзе белер!

Әнсариләр читкә тартылды. Һәммәсе пәйгамбәр артыннан ияrделәр.

Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәдинәдә кабере булачак урынга килеп җитүгә, дөя ике тезенә чүкте. Аз вакыт кына торганнан соң, ул кабат

күтәрелде, алга таба китте. Һәм икенче кат тез чүкте, кабат күтәрелмәде. Пәйгамбәр, Мәдинәгә кергәч, тукталачак беренче йорты шушында икәнлеген һәркем төшенде.

— Бу безнең торыр урыныбыз булыр! — диде Рәсүл Әкрам.

Монда бер йорт бар иде. Аның иясе Әбу-Әйүп әнсари икән. Әнкәсе Шәрифә Халид исемен йөртеп, атасының аталышы Зәйд иде. Алар Бәни-Нәҗҗар кабиләсе гарәпләре иделәр.

Әбу-Әйүп әнсари ярлы тормышлы булганлыктан, башка гарәпләр бераз аптырабрак калдылар. Үзара:

— Пәйгамбәр монда яшәсә, мәдинәлеләрнең тормышлары начар икән дип уйлар, бездән күңеле кайтыр, — дип борчыла башлап, сүз йөрттеләр. Кайсылары:

— Безнең йортыбызга төшеп, нурландырсагыз иде?! — диделәр.

Әмма Җәбраил галәйһис-сәлам шулвакыт пәйгамбәрнең колагына хәбәр китерде. Аллаһы тәгалә теләге белән Мөхәммәд пәйгамбәр шушында калырга тиеш күрелеп, бу нигезнең хикмәтле икәнлеге вә пәйгамбәрләрнең монда тукталып үткәнлекләре аңлашылды. Шул сәбәпле Рәсүл Әкрам үзенә Әбу-Әйүп йортын тору өчен иң яхшы урын дип тапты.

Шатлык вә сөенеч белән тулган Әбу-Әйүпнең күңеле җиденче кат күктә исә дә акыллы йөзенә оят йөгертте. Үзе пәйгамбәрне йортына илтте, үзе уйлады: «Мөхәммәд галәйһис-сәлам миндә яшәмәс, тормышымны күргәч, йөз чөерер!» — дип борчылды. Әмма Рәсүл Әкрам гаҗәеп дәрәҗәдә итагать вә сабыр иясе иде ки, ул хәтта бер генә тапкыр да кимсетеп вә кимсенеп сүз әйтмәде, Әбу-Әйүп йортын яхшы сарайга тиңләде.

Бу хәлләр барча Мәдинә халкын хәйранга калдырды.

Әбу-Әйүп үзенең гаиләсе белән йортның өске катына урнаштылар һәм кичне дә шунда уздырдылар. Мөхәммәд пәйгамбәр аскы катта урын алды. Иртәгәсе көн Әбу-Әйүп тиз ара Рәсүл Әкрам каршысына житешкән иде.

— И халкыбызның сөеклесе, Аллаһы тәгаләнең без гасыйларына җибәрелгән илчесе! Без бу кичәдә бер генә минутка да оеп китә вә йоклый алмадык, — диде ул борчулы йөз белән.

— Ни булды? Ни өчен? — дип сорады Мөхәммәд саллаллаһу галәйһис-сәлам.

— Атам-анам синең каршыңда фида булсыннар, чөнки уйладык, әгәр дә берәребез яткан җиреннән йокы аралаш кузгала калса, өстегезгә тузан коелыр вә якты йөзегезне сулдырыр һәм керләндерер дип белдек. Өске катта кем кузгалса, аскы катка тузан вә туфрак коеладыр. Өскә менсәгез иде?! Сез өстә яшәрсез, без аскы катта гомер кичерербез.

Әмма пәйгамбәр аның белән килешмәде. Үзенең барлыгы белән хуҗаларны кыен хәлгә куярга вә кысрыкларга теләми иде ул, шуңлыктан:

— Безгә аста булу кирәк, чөнки халык-җәмәгать килеп-китеп йөрер, кыенлык күренмәсен, — диде.

Бу сүзләре Әбу-Әйүпне тагын да авыррак хәлгә куйды. Пәйгамбәргә аның каршы әйтәсе килми иде, шулай да намусы һаман да сүзгә этәрде:

— Мин сезнең белән килешермен. Ярар! Әмма без югарыда, сез аста тору һичнинди әдәп кагыйдәләренә сыймас, — диде.

Әгәрен ки Әбу-Әйүпнең бу сүзләре белән килешмәсә, чыннан да, хуҗаны кыен хәлгә куячагын ачык төшенгән пәйгамбәр бары тик әдәп кагыйдәсенә хилафлык кылмасенгә генә өске катка күтәрелде һәм анда бер ай дәвамында яшәде. Һичкемгә җайсызлык вә авырлыклар тудырырга исәбе юк иде. Бер ай тәмам булды дигәндә Җәбраил галәйһис-сәлам ирешеп, Мәдинәдә мәсҗед бинасы корырга һәм пәйгамбәргә шунда күчү кирәклекне төшендереп китте. Бу белдерү әнсарилар арсына көне-сәгате белән таралып өлгерде. Шулай итеп, Пәйгамбәр мәсҗеден төзетү мәсьәләсе көн тәртибенә куелды.

Мәдинәдә әнсарилар җыелышып намаз укый торган бер йорт бар иде. Рәсүл Әкрам килгәнче дә алар шунда җыелыша иделәр. Үзе инде иске вә кайсыбер диварлары җимерелә үк башласалар да, туфрагы изге вә Нух пәйгамбәр белән бәйле иде.

Йортка Рафигъ бине Гамрунең ятим калган уллары Сәһил белән Сөһәйл хуҗа икән. Бу ике бала Әсгад бине Зирарә тәрбиясендә яшәп, шәһәрдә өрек җимеше белән сәүдә итәләр һәм монда шуларны саклый иделәр. Бинаның әйләнәсендә өрек агачлары үсеп, күркәм генә бакчасы да бар иде.

Бу урында әнсарилар намаз укыйлар, ә Әсгад бине Зирарә монда имамлык итә иде.

— Бу кемнең йорты?—дип сорады пәйгамбәр.

— Аны сиңа Сәһил белән Сөһәйл ятимнәр бүләк итәләр,—дип белдерде Әсгад бине Зирарә.

Әмма Рәсүл Әкрам кабул итмәде. Ун алтын акча бәрабәренә сатып алды, акчасын Әбу-Бәкер хәзрәтләре бирде. Бу урында шулай ук каберлекләр булып, пәйгамбәрнең теләге белән аларны ачтылар һәм мәхәллә белән бергә күчерешеп, башка бер урынга җирләделәр. Кирпеч вә таш ташып, бинаны тәртипкә салдылар. Бу эшләрдә пәйгамбәр үзе дә катнашты.

Бу хәлне күреп торган халык җан-тән белән Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи-сәламгә тартылдылар һәм бу эштә катнашуны олуг мәртәбә вә дәрәҗә санадылар.

Шушы рәвешле өмә белән төзү күңелле һәм дуслыкны ныгыта торган вакыйгалардан иде. Гали сәхабә үзенә күрә бер такмак чыгарып әйтте, аның ул сүзләрен Гомәр күтәреп алды вә артыннан кабатлап йөрде. Бу вакытта ни сәбәптәндер читкә килеп утырган бер мөэмин Гомәргә ачуланып:

— Җитте, тынычлан, юкса кулымдагы бу таягым берлән сине кыйнап ташлармын,—дип орыша башлады.

Аның бу мәгънәсез сүзләрен Мөхәммәд ишетеп алды һәм, эшнең нәрсәдә икәнлеген тиз ара төшенеп, ул сәхабәне тынычландырырга кирәк тапты:

— Гомәр минем ике күзем, һичкемнең аны рәнҗетергә хакы юк!— дип белдерде.

Әйтерләр ки, шушы сүздән соң хәдис пәйда ителеп, Гомәр сәхабә— Ислам Күзе дигән исем белән атала башлады. Бу кушамат пәйгамбәрнең аны олылавы гына түгел, барча мөэмин-мөселманның да Гомәргә рәхмәт билгесе иде.

Гомәр сәхабә арада көч-кодрәт иясе генә түгел, хәтта намус билгесе дә иде. Шунлыктан ул пәйгамбәргә ике күзе аталды. Берәүләр кулларына ялгыз кирпеч яки таш күтәреп килсәләр, Гомәр сәхабә икене китерә иде. Аның берсе үзе өчен булса, икенчесе пәйгамбәр исеменә аталды.

Мәдинә эчендәге тәүге мәсҗед төзелеп беткәндә кыйбла ягы Бәйтел-Мөкатдәс тарафында кала бирде. Намаз вакыты ирешеп, барча мөэминнәр шатлык вә рухи күтәрелеш белән рухани гамәлләрен башкару өчен шушында җыелдылар. Мәсҗедтә өч капка-ишек эшләнелде. Аның берсен «Рәхмәт капкасы» дип атадылар, икенчесе «Пәйгамбәр ишеге» кылынды, өченчесе халык керү өчен аргы башка ясалды. Тарихлардан билгеле булганча, бу мәсҗед Гомәр сәхабә вакытларына кадәр үзгәрешсез калды, аннан соң, ислам таифәсенең шактый ишәюе аркасында зурайтылды. Госман бине Гаффан хәзрәтләре аны асыл ташлар белән бизәтеп кабат төзетте. Тагын да заманалар эчендә ничәләр кат җимерелде вә кабат төзекләндерелде.

Мәдинәдән күченүгә бер ай узды дигәндә пәйгамбәрнең кызлары Өмме-Гөлсем вә Фатыйма һәм йорт халкы, гаиләсе Мәккәдән чыктылар һәм монда һиҗрәт иттеләр. Аларны каршыларга вә китерергә Мәдинәдән кешеләр күндерелде. Әбу-Бәкернең гаиләсе дә күченде. Шулай итеп,

Мәдинәдә мөһаҗир гаилә башлыкларыннан кырык биш кеше җыелды. Мөхәммәд пәйгамбәрнең теләге белән алар, ягъни кырык биш мөһаҗир, шулай ук кырык биш әнсарилар белән карендәш вә туган кылынды. Моннан шул ачыкланды: кемнәр карендәш булдылар, аларның мираслары бер-берсенә күчәргә вә васыять кылынырга тиеш иде. Шушы рәвешле мең ятлар да якын карендәшләр булып киттеләр вә шатлык-сөенеч, кадер-хөрмәт таптылар. Бары тик Гали Әл-Мортаза гына бу эштән читтә калды һәм ул, тәкатен югалтып, көннәрнең берендә Рәсүл Әкрамга үзенең үпкәсен белдерде:

— И Мөхәммәд пәйгамбәр, син барчаларны туган вә карендәш ясадың, әмма мине ялгыз калдырдың,— диде.

— Син минем карендәш һәм туганым, башкаларда мондый мәртәбә күренмәде. Моның өчен шатланырга тиешсең,— дип белдерде Мөхәммәд галәйһис-сәлам, аны тынычландырып вә хакыйкать күзен ачтырып.

Мәдинәдәге мәсҗед янына бер хөҗрә-йорт төзеделәр. Шуннан соң гына Рәсүл Әкрам һәм аның якыннары Әбу-Әйүп өеннән анда күчеделәр. Мөһаҗирләрнең тәүге йорты шушы булды һәм пәйгамбәр урыны дип атала башлады.

Һиҗрәтнең беренче елында мәйданга чыккан вакыйгалардан иң әһәмиятлеләренең берсе яһүдиләр белән төзелгән солых булды.

Бәни-Кариза вә Надир һәм Кыйнкаг яһүдиләре, көннәрнең берендә җыелышып, үзара бәхәс кылдылар. Бу вакытларда гына арадан берничәсе пәйгамбәр каршысына килеп, Ахирәт көненнән хәбәрләр бирүен сораганнар иде. Рәсүл Әкрам аларның үтенечен канәгатьләндерә алмады, чөнки ул бу турыда әлегә хәбәрсез иде. Бары тик Җәбраил галәйһис-сәлам белдерүеннән соң гына, ул аларга җавап бирә алды. Әйтте:

— Тәүрат китабының гыйлемнәрен төшенгән галимнәрегезнең сүзләре белән чагыштырырсыз. Мин Аллаһы тәгаләнең пәйгамбәре. Иман китерегез,— дип таләп куйды. Арадан берничә Рәсүл Әкрам ягына авышты. Әмма бу Китаплы халык үзен горур тотты. Беренчеләрдән булып ислам диненә күчкән яһүдигә Габдулла дигән исем бирделәр. Башкаларның да күңелләренә изге юлга керү теләге оя корып, аларны мөселманнарга якынлаштыра, эш-гамәлләренә карата хөрмәт хисләрен уята иде.

Бу хәл яһүдиләрне борчуга салды. Җыелышып бәхәс тотканнан соң, бер киңәшкә килделәр һәм Мөхәммәд пәйгамбәр белән килешенеп солых төзергә, шуның белән үзләрен һәртөрле хәсрәттән азат итәргә булдылар. Шушы фикерне йомарлап, Рәсүл Әкрам каршысына күнделәр һәм сүзне моңардан башладылар:

— Халыкны ни-нәрсәгә чакырасың, нигә дәгъвәт кыласың?

— Мин аларны бары тик Аллаһы тәгаләгә инанырга өндим. Чөнки мин — Аллаһы тәгаләнең пәйгамбәре, Мәккә шәһәрендә тудым, Мәдинәгә һиҗрәт кылдым. Барлык сыйфатларым Тәүрат китабыгызда бәян ителеп, галимнәрегез тарафыннан тәкрарлангандыр. Сез алардан ишеткән булсагыз кирәк! — дип җавап бирде Рәсүл Әкрам.

Яһүдиләр барысын да башыннан ахырына кадәр тәгәл вә дөреслек белән сөйләшергә килгән иделәр, шунлыктан сүзләре дә тугрылык вә хакыйкать илә булды.

— Без бу хакта ишеттек,— диделәр алар.— Килүебезнең сәбәбе башка бер мәсьәләдер. Үзара солых теләге белән куандырмак иде. Шартыбыз: без сиңа вә өммәтеңә дошманлык кылмабыз, юлларыгызга чыгып, комачаулык ясамабыз һәм дә шулай ук дошманнарыгыз белән дуслашмабыз, алар ягына чыкмабыз, аларга ярдәм итмәбез!

Мөхәммәд саллаллаһу тәгалә галәйһис-сәлам аларның шушы сүзләрен күңеле аша кичерде һәм, үтенечләрен кабул итеп, шартларын хуп күрде. Сүз куештылар. Кәгазьгә язып теркәделәр. Ике як та антлар эчеп, кабиләләргә хәбәрләрен салдылар һәм һәркемгә боларны үтәүне бурыч итеп йөкләделәр. Әмма араларында булган олуг голамәләре әйтте:

— Мөхәммәд пәйгамбәр шиксез Ибраһим Нәбиуллаһның улларыннан Исмәгыйль галәйһис-сәламнең кавеменнәндер. Без исә шул ук Ибраһим Нәбиуллаһның Исхак галәйһис-сәлам халкыдыр. Тәүрат сүзләрен төшенгәннәргә билгеле: Исмәгыйль кавеме ахырда Исхак халкын үзенә буйсындырыр!

Бу сүзләрдән күңелләренә коткы уты төште.

Мәдинәдә пәйгамбәр мәсҗеде төзелү сәбәпле дин эшләре шактый тәртипкә килеп, әнсарилар вә мөһаҗирләр гамәлләрен җиренә җиткереп үтәргә тырыштылар. Әмма дә ләкин намазга җыелу вакытын төгәл белдерү кирәк иде. Шулай бер җомга алдыннан өммәтләр Рәсүл Әкрам каршына килделәр һәм үзләренең зарларын сөйләп бирделәр, әйттеләр:

— Фарыз гамәлләрдән җомга намазына вакытында җыелудан чарасыз калырбыз. Бәлки, арадан беребез быргы кычкыртыр, шуның белән намаз вакыты җиткәнлеген төшенербез вә мәсҗедкә җыелырбыз, мөмкин эштер?

Әмма пәйгамбәр аларның бу киңәшенә каршы төште һәм быргы кычкыртуны яһүдиләр гадәте икәнлеген аңлатып, алар белән охшашлык ярамаслыгын белдерде:

— Быргы авазына яһүдиләр җыелырлар, үзебез дә буталырбыз.

Хәерле җәмәгать арасыннан тагын да киңәш иреште:

— Бәлки, чаң кагарбыз? Аның тавышы еракларга ишетелеп, барчабыз да белеп торыр.

— Юк,— дип тагын каршы төште Мөхәммәд галәйһис-сәлам.— Мөмкин вә кирәкле нәрсә түгел, носарилар шул рәвешле кәлисәләрендә чаң кагарлар. Алар белән буталырга һәм үзебезне бутарга ярамас.

Шунда әсхаптан берәү ут ягарга вә аның төтенен күреп җыелышу мөмкинлеге барлыгын әйтте. Әмма бу гадәт мәҗүсиләрдән калганлык сәбәпле, пәйгамбәр моңа да каршы чыкты. Шунда Гомәр разиллаһы ганһының йөзе нурланып китте һәм ул:

— Арадан беребез аваз белән кычкырсын: «Намаз вакыты килде!» — дип чакырсын, моннан да уңайлысы булмас,— диде.

Рәсүл Әкрам аның бу киңәшен кабул итте һәм тавышы назлы вә көчле саналган Билалга әмерен тапшырды, намазга җыелырга чакырып аваз салырга кушты.

Тиз ара Билал да Мөхәммәд пәйгамбәр сүзенә буйсынды һәм, мәсҗедкә килеп:

— Әссалату җәмига! — дип кычкырды.

Шуның белән барча мөселман намаз вакыты җиткәнлеген төшенде һәм җыелыша башладылар. Көннәрнең берендә Габдулла бине Зәйд әнсари Мәккә тарафына карап, шушы сүзләрне кычкыра иде, сәхабәләр аны күреп сорадылар:

— Нәрсә эшлисең?

— Мәккә халкын намазга дәгъвәт итәм! — дип җавап бирде ул, башын горур тотып.

Аның бу тырышлыгы рәхмәтсез калмады. Йокыда вакытында колагына Җәбраил галәйһис-сәлам намазга чакыру рәвешен өйрәтеп китте. Габдулла бине Зәйд әнсари, уянып, ул сүзләрне кабатлады, күңеленә уелып калган иделәр.

Пәйгамбәр каршысына килеп, намаз хәбәрен ни рәвешле кычкырганда дөрес буласын белдерде. Рәсүл Әкрам аның теләген кабул итте һәм, Билалны үзенә чакыртып, Габдулла бине Зәйд әнсаридан азанны өйрәнүне боерды. Шул рәвешле намаз алдыннан азан әйтү тиешлеге билгеле булды.

Моңа бәйле рәвештә тагын да бер вакыйга мәйданга чыкты.

Гомәр сәхабә Мөхәммәд галәйһис-сәлам каршысына килеп, сүз алды һәм бер хикмәтле төш күреп, анда азан тавышын ишеткәнлеген бәйнә-бәйнә сөйләде. Рәсүл Әкрам аның да хәбәренә гаҗәпләнмәде.

— Сөбханалла! Синнән әүвәл Җәбраил галәйһис-сәлам килде һәм шушы рәвешле белдерде! — дип төшендерде.

Риваятьләрдә сөйләнеләдер ки, Мөхәммәд саллаллаһу галәйһис-сәлам төнге мигъраҗ вакытында күкләргә ирешеп, анда да намаз авазына колак тоткан иде. Әмма ул вакытта бу эшне сөннәт итеп кабул кылмаган вә бу хакта уйланмаган иде. Инде хәзер моның да тәртип белән мәйданга чыгуына шатланып, Аллаһы тәгаләнең кодрәтенә хәйраннар калды.

Бу елда Мәккә халкы хәвеф утында иде. Мөнафикларның арасында үзенең ахмаклыклары белән дан тоткан Вәлид бине Мөгайрә авырып егылды. Кайчан ул үзенең үлемен аңлады, күзләренә яшь килде һәм елый башлады. Саубуллашырга Әбу-Җәһил килгән иде, аның елаганын күргәч:

— Нигә сыктыйсың? — дип сорады. — Үлем хәвефе алдында бер-бер уй-ниятең пәйда булдымы әллә? Һәлакәттән куркасыңмы?

— Юк, үлемнән куркып еламыйм, әмма дә хәвефем дә юк түгел. Сәбәбе шул: Мөхәммәднең дине Мәккәдә таралыр дип фикер кылдым, бу уемнан үзем үк курка калдым, — дип зар кылды Вәлид бине Мөгайрә. Бу аның соңгы теләге иде.

— Һич борчылма, кирәкми! Борчылырлык урын юк, минем заманда, әгәрем ки тәнемдә җаным бар икән, аның өммәте безнең шәһәрдә күренмәс! Һичберсе аяк баса алмас! — дип сүз бирде Әбу-Суфийан.

Вәлид бине Мөгайрәнең бу җәһәттән әйтер башка сүзе бар идеме, әллә башка сәбәп беләнме, йөзе җыерылган иде вә куркыныч хәлендә дөньядан китеп барды. Аның бу кыяфәтен күргән бәндәләрнең күңелен шулай ук хәвеф уты биләп алды. Мәккә халкы мөнафиклар белән тулып, Мөхәммәд каршында чарасызлыклары аркасында һәм үз ахмаклыклары сәбәпле җан тынычлыгы таба алмыйча яши бирделәр.

Һиҗрәтнең беренче елында күпләрне хәйранга калдырган вакыйгалардан олугларының берсен «Сәлман Фарсиның иманы» дигән исем белән риваятьләрне тәфсилләп сөйләүчеләр тарихларга кертеп калдырдылар. Ул әһәмиятле вә кызыклы булганы өчен бу урында бәйнә-бәйнә бәян ителергә кирәкле табылды. Бу хәлләрне Сәлман үз авызыннан Ибне-Габбас хәзрәтләренә сөйләп калдырган иде.

Сәлман фарсы үз эшен бик оста белеп башкара торган вә шуның белән дәрәҗәләр алган бакчачының сөекле бер улы иде. Ул Исбаһан якларындагы Хәй исемле бер авылда мал иясе әткәсенең йортында һичбер авырлык вә кыенлыклар күрмичә тәрбияләнеп үсте. Атасы утка табынучылардан булып, бу гыйбадәтенә бөтен күңелен вә барлыгын бирә торган иде. Сөекле малаен да һәрдаим үз янында тотып иркәләр, аңа кадер вә нигъмәтләрен кызганмас, шул рәвешле сабый вакытыннан бирле күңеленә мәхәббәт орлыкларын чәчеп, буй җиткәндә улының гүзәл тәрбия иясе күркәм кемсәнә рәвешендә халык арасына чыгачагына ышана, бу максатында һичбер вакыт вә малын кызганмас иде. Кичә-көндезләрен Сәлман төсле малай-шалай урамда уйнар, әти-әниләре аларны өйдә ятмасыннар өчен куып чыгарырлар иде. Әмма шулар кебек үк булган Сәлман фарсыны әткәсе үз янында гына тотып, хәтта ут каршында гыйбадәт вакытларында да улын гадәтләнергә, табыну фигыленә тартырга тырышты. Кайчан өйләрендә ут яксалар, малай, өлкәннәрне кабатлап, гыйбадәтләренә җан-тән белән бирелеп иярә башлады. Моның белән тагын да өстенрәк мәхәббәт вә ышаныч казанды. Әтисе гаҗәеп дәрәҗәдә үз диненә бирелгәнлеге сәбәпле, башка төрле гыйбадәтләрнең ахмак вә ялган фигыль икәнлеген тәкрарлап, улын бик тә ихлас күңелле вә камил җанлы итеп тәрбияләргә тырышты.

Бервакыт шулай утка табыныр алдыннан бөркелә торган майларының беткәнлеген белеп, әтисе Сәлман фарсыны йомыш белән җибәрде һәм тиз ара китерергә әмер бирде. Малай йөгереп урамга чыкты. Максат

юлына эз салды. Тик ни хикмәт, бу вакытта носари-христианнарның кәлисәсендә гыйбадәт башланып, бар күңелләрне адаштырырлык дәрәҗәдә йолаларын үтәүгә керешкән иделәр. Сәлманның сукмагы шунда төште. Ул үзенең кызыксынуын суыта алмады. Әтисе кушкан йомышын да онытып, кәлисәнең эченә үтте вә таң-гаҗәепкә калды. Бер носари кычкырып Инҗил укый, башкалары гыйбадәт рәвешен тота иделәр. Йөзләрендә вә тирән күзләрендә күз яшьләре катыш уйнаган теләк вә үтенеч, күкрәкләреннән саркып чыккан җыр вә үксү баланы әсир итми калмадылар. Бу инде малай күреп үскән һәм ияреп гыйбадәт итә торган көйдергеч ут кына түгел, акыл вә җаннарны ашкындырып, күкләргә илтә торган дини йола иде. Сәлман фарсы тыела алмады, арадан бер носари кемсәгә килде һәм, кызыксынып, сорау бирде:

— Бу нинди дин?

Ул кеше малайның күзләреннән җаны ни теләгәнне бик тиз төшенеп алды һәм:

— Бу дин — Гайсә динедер! — дип җавап бирде.

Ни-нәрсә икәнлеген тәгаен генә аңлап җиткермәсә дә, Сәлман фарсының күңеле әсирлектән азат була алмады һәм ул әсәрләнгәннән әсәрләнде. Әтисен вә үзенең утка табынучы икәнлеген дә онытты, йомышны да исеннән чыгарды. Ул арада дөнья бетереп аны эзләп йөри иделәр. Малай моны да белмәде. Гайсә диненә мәхәббәте артып, утка табынудан тәмам гайрәте чикте, күңеле суынды һәм шушы кичергән хисләрен вә үз хәлен носариларга сөйләп бирде дә:

— Сезнең динне алырга телим, олуг кемсәнәгез кем була? Шунда барыр идем,— дип белдерде.

— Берничә көн кичүгә, Шамнан кәрван төшәр, кире киткән вакытларында аларга ияртербез, олугыбыз белән очрашырсың, динебезне кабул итәрсең,— дип сөенде носарилар.

Шушы вәгъдә белән канәгатьләнеп вә киңәшләрен кабул кылып, Сәлман фарсы канатлы кош кебек очып кына өйләренә кайтты, әмма сөекле әткәсе аны гомерендә беренче тапкыр ачуланып каршы алды вә утлы сүзләрен яудыра башлады:

— Бу кадәр вакыт кайда йөрдең? Тиз арада кайт дип әйткән идем бит! Нигә сүземне тыңламадың? Кешеләремне җибәреп эзләттем, һичбер җирдә юк идең!

Малайның күңеле әлегә суынып җитмәгән иде, әтисенең сүзе арасына кысылып, вакыйгаларны бәйнә-бәйнә сөйләп тә бирде һәм үзен аңлар дип уйлады, әмма ялгышты. Аның бу хәбәре әткәсен тагын да ярсытты вә рәнҗетте ки, әгәр дә йөрәк түрендә улына карата мәхәббәт чәчәге бөре койган булса, Сәлманне баш-аяк ботарлап ташлар иде. Ягылмады. Кайнарлыгы да суынмады. Ачулануын дәвам итте һәм носариларның динен тәмам хурлап ташлады, утка табынуны иң дөрес гыйбадәт рәвеше итеп танытырга маташты. Әмма улының күңеле әткәсенең диненнән суынган вә башка хыяллар белән күкләрнең җиденче капусында йөзәр иде.

Сүзләренә улының колак салмаганын күреп, әтисе Сәлман фарсының аякларын богаулады вә аны, ирегеннән мәхрүм итеп, тоткын ясады. Аның бүтән чарасы калмаган иде. Кәлисәгә аягын да бастырасы килмәде. Әмма улы җаен тапты, носариларга үз хәленнән хәбәр бирде вә, Шам тарафыннан кәрван килеп ирешүгә, аларга ияреп китте. Моны белгән атасының бәгыре урталай ярылырдай булды, әмма соңарды, инде хәзер, үрелим дисә, буе җитмәс, суктырыйм дисә, кулы кыска иде. Шул кадәр сөеп вә тәрбия күрсәтеп үстергән татлы улы канат чыгармастан элек оядан егылып төште. Һай тормыш дигәннәре, шушы кадәр дә мәрхәмәтсез булыр икән. Ата теләген узып бала кадер табармын дип уйладымы, әллә инде үз кадерен үзе белмәдеме? Ачулану гынамы соң, рәнҗерсең дә, еларсың да шул.

Кәрван әһеле белән уртак сүзгә килеп, Сәлман фарсы алардан:

— Минем тәрбиямне бер-бер олуг зат заһид вә диндар кемсәгә тапшырсагыз иде,— дип үтенде.

Аны тирә-юньдә дан-шөһрәт тоткан, һәрьяклап мактауга лаек саналган монахка калдырып киттеләр. Сәлман фарсы үз хәленнән хәбәрләрне сөйләп, моның күңелен яулады. Тырышлык вә күндәмлек өлгеләрен күрсәтте. Остазына лаеклы шәкерт булырга тырышты. Дин һәм йолаларын мәкаммәл рәвештә күңеленә сеңдерер өчен дәресләрен дикъкать белән тыңлады. Шул рәвешле үзе дә мактауга лаек күрелде, барча эшләрдән гыйбрәт ала башлады, эш йөртү серләренә төшенде һәм ышаныч казанды. Әмма акыл чүлмәге гыйлем белән тулган саен, әйләнә-тирәсендәге заһидларның эшләре гамәлләренә туры килмәвен дә күрде. Бигрәк тә остазына үпкәсе зурайды. Бу кемсә, телендә Ходай исемен тибрәтеп тә, кулында акча шылтыратырга яратарак төшә икән. Тирә-юньнән җыелган хәер-садакаларны шәригате кушканча дин эшләренә куймыйча, үз мәнфәгатенә тотып, һичкемгә бирми. Янында җиде капчык алтын тупланып, җәмәгать моннан хәбәрсез кала килә иде. Бу хакта Сәлман фарсы белеп алды, носари диненә күңеле суынмады, мәгәр остазына ачуы килде.

Моннан шул аңлашылды, Аллаһы тәгалә исеменнән сөйләүчеләр һәм дин таләбендә йөрүчеләр, муллалар вә ишаннар, мөфтиләр һәм казыйлар, имамнар һәм мөридләр, кайда гына булмасыннар, нинди хәлдә генә калмасыннар, иң беренче чиратта, хәер вә садаканың урынын белсеннәр, йомарлап үз кесәләренә тыгар алдыннан уйласыннар: кылган гамәлләре сөйләгән сүзләре белән хактан да туры киләме? Юкса ялганчылар вә ахмаклар агына чыгарлар. Диннең башына өч нәрсә җитәр. Сугыш та түгел, дөнья бетү дә түгел, үлем дә түгел. Бәлки ялган сүз, ягъни сүзнең гамәлгә туры килмәве, гайбәт, ягъни белмәгәнне белгән кебек сөйләп күпертү, һәм наданлык, Аллаһы тәгаләнең каһәреннән курыкмау, ягъни Аллаһы тәгалә гыйлеме өчен бирелгән хәер-садаканы үз кесәңә салу, җәмәгать файдасын үзеңнекеннән түбән күрү. Әйтерләр: Хак тәгалә бер-бер бәндәләренә зиһен бирде, Коръән аятьләрен өйрәнергә юллар ачты. Әмма алар Сәлман фарсының остазы төсле җәһәт-җәһәт кесәләренә алтын җыю белән мәшгуль булдылар. Ахирәт көнен исләреннән чыгардылар, үлем фәрештәсе аяк очына килгәндә, акча биреп, аннан котылып булмасын аңламадылар. Носариларның олуг күргән ул заһидлары да үлем түшәгенә ятты. Әле озын вә озак еллар буена яшәр төсле иде, әмма ул да әҗәлен тапты.

Заһидлар җыелышып килделәр. Аны хөрмәт белән җирләү өчен әзерлек күрделәр, изге китап сүзләрен укыдылар вә моңланып җырладылар. Әмма Сәлман фарсы аларга серне ачып бирде һәм мәрхүм җыйган җиде капчык алтынның кайда яшерелгәнлеген күрсәтте. Килделәр, таптылар, үз күзләренә ышанмыйчарак тордылар. Ачулары кабарды, зиһеннәре таралды һәм, кәлисәгә кереп, әле яңа гына олылап данлаган монахны табутыннан чыгардылар, тау-таш арасына сөйрәп китерделәр һәм болгап аттылар. Ул гына да түгел, моның белән генә күңелләре тынычланмыйча, мәетенә ташлар ыргытып мәсхәрәләделәр һәм каргаларга азык итеп ташлап калдырдылар. Носари диндарларына ышанычы кимегән Сәлман фарсы бу хәлләрне күреп шаклар катты, күңеле кабат урынына утырды, диннәренә мәхәббәт чәчәге яңадан ачылды, җанын сөенеч вә шатлык биләп алды һәм ул шушы сумгада яшәп калды.

Хәрәкәтләнгән мәрхүм заһид урынына икенче бәрәүне чакырдылар. Бу кеше гаҗәеп дәрәҗәдә намуслы, олуг галим һәм диндар иде ки, Сәлман фарсының аңа карата хөрмәте вә мәхәббәте көннән-көн артты, аңа тугры хезмәтен күрсәтте. Шушындый булганлыгы өчен үзе дә кадер-хөрмәт казанды. Дин эшләре көннән-көн алга барды. Яшерен вә ачык серләрне аңлау дәрәҗәсе Сәлман фарсыны һәрдаим тәрәккыять итмәктә иде.

Ул да булмады, күтәрелеп килгән кояш кечкә якка авышты, бик тиз тәгәрәп төшеп, баер вакыты якынлашты. Тормыш һәм табигатьнең Аллаһы тәгаләдән алган кануны иде бу. Олуг заһид үлем түшәгенә егылды. Моны ишеткән Сәлман фарсы тиз ара аның каршысына килеп тез чүкте һәм үтенде:

— И олуг остаз, шушы кадәр дә хезмәтләремне күрсәттем, мине кемгә калдырып китәсез? Сезнең кебек камил сыйфатлар иясен моңа кадәр очратмаган идем. Рәхмәтем зур. Бер-бер кемсәнәгә дәлаләт итсәгез иде?!

Шәкертенең сүзләре бәгырен айкап узды, ягымлы тавышыннан һәм чын йөрәктән чыккан сүзләреннән җаны эреде. Хәтерен айкап, бер-бер заһидны исенә төшерергә тырышты. Тереләр арасыннан андый лаеклы бәндәне белми иде. Әмма шәкертен теләсә кем кулына калдырып китәргә ярамаганлыгын да аңлады. Бу аның соңгы бурычы иде. Һәм ул тапты.

— И сөекле шәкертем, валлаһи дип әйтәм,— диде, күзләре вә йөзе нур белән тулды.— Һичкем белми, әмма мин беләм. Бар андый кеше! Дөньядан йөз чөереп, гыйбадәт белән генә яшәүче, Ахирәт тормышын күрүче диндар кеше берәү генә бар бөтен җир йөзендә!

Аның төс-кыяфәтен, кайда яшәгәнлеген бәйнә-бәйнә сөйләп-аңлатып бирде. Бу табышына үзе дә сабый балалар кебек сөенде һәм елмаеп җан тәслим кылды. Аны кадер вә хөрмәт белән җирләгәннән соң, Сәлман фарсы остазы дәлаләт иткән заһидны эзләп китте һәм юлы максатына китереп җиткерде.

— Мине остазым Сезнең каршыгызга җибәргән иде,— дип, ул барча хәлләрне сөйләп бирде, кайдан килгәнлеген, кем күндергәнлеген, исемен белдерде.

Шулай итеп, Сәлман фарсы шушы заһидның тәрбиясенә күчте вә аңа хезмәтләрен күрсәтте. Әмма бу бәндә дә өлкән яшьтә булганлыктан, озакламый авырый башлады. Бу—үлем хәбәре иде. Сәлман фарсы аннан да бүтән бер остазга җибәрүен үтенде. Ул әйтте:

— Якын-тирә кала вә авылда андый бәндәнең барлыгын белмим, шулай да син шул кешене тап,— дип аңа нәсихәт кылды.

Бу остазын да дәфен кылгач, Сәлман фарсы кабат өч заһид тәрбиясен күрде һәм аларга да тырыш хезмәтләрен күрсәтте. Бу вакытта буй җиткән егет иде инде. Шушы өч заһидның соңгысы аңа әйтте:

— Һичкемне белмим, әмма ләкин син барчабыздан бәхетлерәк, чөнки Ахырзаман пәйгамбәре мәйданга чыгар вакыт җитте. Ул сүз һәм гамәлдә Ибраһим галәйһис-сәлам динен күтәрер, гарәпләрдән булыр, туып-үскән ватаныннан һиҗрәт итәр, аны ташлап чыгар, ташлык эчендә, хөрмәсе күп бер шәһәргә күченеп яшәр. Билгеләре шулардан гыйбарәт: садака алмас, әмма бүләк кабул итәр, тагын да белеп тор, ике иңе арасында миңе-мөһере булыр!

Бу заһид исә Сәлман фарсының гомерендә очраган носарилардан Тәүрат гыйлемен иң камил рәвештә үзләштергән, ачык вә яшерен серләрен белгән олуг галим кемсә иде. Туры юл күрсәтте. Егетне адашып йөрүдән саклап калды. Сәлман фарсы, аны җирләгәч, Ахырзаман пәйгамбәрен эзләп китәргә карар кылды.

Егетнең милкендә берничә сыер вә сарыклар бар иде. Боларны сатып, сәфәр чыгарга әзерләнде. Бәхетенә, бер сәүдә кәрванына тап булып, аларга бәһасен бирде һәм үзләренә ияртүләрен үтенде. Әмма гарәп иленә ирешүе җиңел эшләрдән түгел икән. Күпме юллар йөреп, гаҗизләнеп беттеләр, җитмәсә, Сәлман фарсыны кәрван хуҗасы колга әверелдереп, Госман Әл-Ашил исемле яһүдигә сатып җибәрде. Бу кемсәнең яшәгән урыны хөрмә бакчасы булганлыктан, егет: «Пәйгамбәр һиҗрәт итәчәк урын шушыдыр!» — дип, уй-фикер кылды һәм моны күңеленә ныгытып, җанын тынычландырды, язмышына ризалашты. Тик бара-бара акылы ачылып, бәгыре киселгәнен тоя башлады. Пәйгамбәр

килергә тиешле ил гарәпләр ягында иде. Шушы исенә төште. Җаны кабат бәргәләнде, күңеле тынычлыгын җуйган иде.

Көннәрнең берендә яһүди туганының улы кунакка килде һәм Сәлман фарсыны үзенә кол итеп сатып алды. Ул Мәдинә шәһәрендә яши иде, үзе белән егетне шунда алып китте. Бу вакытларда Мөхәммәд галәйһис-сәлам дә Мәккәне ташлап чыккан һәм аның менә-менә килеп җитүе көтелә иде. Сәлман фарсы Мәдинәгә килеп ирешкән көннәрендә үк бу хакта ишетеп алды. Моңа дәлил буларак, хуҗасы янына килгән берәүнең теленнән дә шул хакта хәбәрләр ишетте. Ул вакыйга болайрак мәйданга чыкты.

Сәлман фарсыны һаман да, хөрмә агачларына менеп, җимешләрен җыю эшенә куа иделәр. Шулай бервакыт ул, ботакта утырып, шул эш белән мәшгуль чагында колагына аермачык сүзләр ишетелде. Агач төбенә генә аның хуҗасы һәм янына килгән кунагы тукталып, урын алдылар. Сөйләшә башладылар. Телләрендә әллә зар, әллә сөенеч иде, монысы ук сизелмәде. Колак тоткан егетнең күңелен кузгатырлык мәсьәләне уртага куеп гәпләшә иделәр.

— Мәккәдән бер адәм килде, пәйгамбәрлек кыла икән. Барча гарәпләр аның янына киттеләр,— дип, ачык әйтте кунак.

Боларны ишетүгә, Сәлман фарсы тиз ара агачтан түбән сикерде һәм әңгәмә тоткан хуҗасыннан һичбер тарсынусыз:

— Ни дисең? Чынмы?

Колының бу рәвештә әдәпсезлек кылуы хуҗасына ошамады һәм ул, аяк киемен салып, егет йөзенә ыргытты вә куа башлап:

— Сорау бирергә синең ни хакың бар! Кит моннан, эшеңдә бул!— дип җикеренде, тагын да икенче башмагын салып, Сәлман фарсыга орды.

Егет кичкә кадәр тырышып эшләде, әмма күңеле пәйгамбәр белән очрашу хакындагы уйлар белән айкалган вә чайкалган иде. Ахшам җитүгә, кулына хөрмә алды да Куба авылына карап юл тотты. Мәҗлескә туры килеп, Мөхәммәд галәйһис-сәламне мөселманнар арасында сөхбәт җәбен тоткан хәлендә күрде. Пәйгамбәрнең каршысына берникадәр хөрмә китереп:

— Син бер салих вә серләрне белеп торучы затсың, яныңда фәкыйрьләр бар, садака бирдем!—дип белдерде. Үзенчә сынавы вә белешүе иде.

Мөхәммәд галәйһис-сәлам:

— Килегез, авыз итегез!—диде, сәхабәләрен сыйлап, үзе дә бер хөрмәне кулына алды.

Бу хәлдән Сәлман фарсы канәгатьлек кылып, кире шәһәргә кайтып китте. Икенче көнне дә ахшам вакыты ирешүгә кулына хөрмә җимешләре алып, Куба мәхәлләсенә юнәлде. Пәйгамбәрнең каршысына килеп:

— Бүләгем булсын!—диде.

Мөхәммәд галәйһис-сәлам рәхмәте белән кабул итте һәм тагын да яраннарын сый-хөрмәткә дәшеп, ашарга боерды. Бу хәлдән Сәлман фарсы тагын да канәгатьлек табып: «Икенче билгесе шушы!»—дип куанды. Ул вакытта сәхабәләр егерме биш кеше булып, егет тиз ара санарга кереште, җирдә хөрмә төшләреннән мең кадәрен санады, моңа хәйран калды.

Бүтән бер вакытта тагын Кубага юнәлде. Бу көнне хәзрәте Мөхәммәд кайгы вә хәсрәткә чумган иде. Сәхабәләрдән берсе вафат булып, шуның җәсәден юа иделәр. Шунда Сәлман фарсы Мөхәммәд галәйһис-сәламнең мөһеренә игътибар итте, ике калак сөяге арасында кабарып торган миңе бар иде. Шунда егетнең күңеле тәмам ачылып, башыннан һәртөрле шик-шөбһәсе китте, сәлам бирде һәм, күзләреннән яшьләрен агыза-агыза, тыела алмыйча шатланып елады, иман китерде. Аның шушы рәвешле кылынышына барчасы да гаҗәпкә калдылар. Бу бер дивана яки тиле түгелме дип шикләнә иделәр. Аларның йөзләрендәге сәерсенү билгеләренә игътибар итеп, Сәлман фарсы үз хәлен төшенеп

алды һәм башыннан ахырына кадәр бөтен тормыш юлын сөйләп бирде. Аның тарихы һәммәсе өчен дә кызыклы вә гыйбрәтле тоелды. Шунлыктан: «Әгәр күңелең иман теләсә, җиде яттан да эзләп табарсың»,— дигән сүз мәйданга чыкты.

Сәлман фарсының коллыгы Мөхәммәд галәйһис-сәламне борчыды. Егет догасын да онытмады, хуҗасына да хезмәт итте, әмма хак мөселман дәрәҗәсенә ирешүе өчен ирекле шәхес булуы зарур иде.

— Коллыктан котыл,— дигәч, Сәлман фарсы моның чарасын эзли башлады. Хуҗасына гозерен тотып килде. Уңай җавап тапмады. Тагын барды. Аны азат итмәсә, эшләрнең начарга китәргә мөмкинлеген аңлап, яһүди көннән-көн остарак итеп хәйлә җәтмәсен үрә торды һәм егеткә үти алмаслык бурыч йөкләп, аны мәңге кол итү чарасын тапты. Моны елмаеп кына Сәлман фарсыга җиткерде:

— Ирек алырсың, әмма минем шартым бар,— диде.— Иң беренче итеп, өч йөз төп хөрмә агачы утырт, алар чәчәк атып, җимеш бирә башласыннар. Икенчедән, кырык вакыйә алтын бирерсең!

Боларны башкарып чыгу мөмкин эш түгел иде. Хәленең яман икәнлеген бер очрашуда егет җай белән генә пәйгамбәргә сөйләп бирде. Боларны ишеткәч, Мөхәммәд бераз борчылып алды һәм янындагы сәхабәләренә боерды:

— Карендәшегезгә ярдәм итегез. Мөселманны коллыкка калдыру яхшы түгел, Ахирәт савабы булыр,— диде.

Моны кабул итеп, һәммәсе дә мөмкин кадәр ярдәм күрсәтергә булдылар, җыелышып, өч йөз хөрмә үсентесе китерделәр.

— Чокырларын казып, миңа хәбәр бирерсең,— дип боерды бу юлысы Сәлман фарсының үзенә пәйгамбәр.

Егет кушылганны күңел күтәренкелеге белән башкарды һәм Мөхәммәд галәйһис-сәламгә эшнең тәмам икәнлеген әйтте. Пәйгамбәр үз куллары белән үсентеләрне утыртып чыкты, әмма берсен Гомәр бине Әл-Хаттап утыртты. Аллаһы тәгаләнең кодрәте белән агачлар шул ук елда җимеш тә бирделәр. Аларны карап йөргән вакытында Мөхәммәд пәйгамбәр арадан берсенең корыганлыгын күрде һәм сорады:

— Моны кем утыртты? Ул агач ни өчен җимеш бирмәде?

Янәшәсендә хәзрәте Гомәр бар иде. Яшермәде, әйтеп бирде:

— Бу агачны мин утырткан идем. Өммәт эше пәйгамбәрнең гамәле кебек булырга тиеш дип белдем!

Мөхәммәд галәйһис-сәлам ачуланмады, кисәтүне дә кирәк тапмады, ул үсентене кире тартып чыгарды һәм урынына кабат үз куллары белән утыртып куйды. Могҗиза : озакламый ул агач та, башкаларын куып җитеп чәчәк атты һәм җимеш бирде.

Сәлман фарсы шушы бакчасына хуҗасын алып килде вә беренче шартының үтәлгәнлеген әйтте. Әмма коллыктан әлегә азат ителмәде. Кырык үлчәм, ягъни кырык вакыйә алтын белән түлисе бар иде әле. Һичбер өмете вә чарасы юк иде. Әмма Аллаһы тәгалә иманлы бәндәсен ярдәменнән ташламады. Мал чалганда, Сәлман фарсының бәхетенә, берсенең корсагыннан кош йомыркасы кадәр алтын чыкты. Мөхәммәд галәйһис-сәлам аны егетнең коллыктан азат ителүе өчен багышлады һәм әйтте:

— Бу алтынны ал, хуҗаңа илтеп бир!

Сәлман фарсы башта пәйгамбәрнең бу сүзеннән аптырабрак калды, аннан соң:

— И Рәсүлуллаһ, бу җитмәс, миннән бит кырык үлчәм алтын таләп итәләр,— дип белдерергә җөрьәт итте.

Бу сүзен ишеткәч, алтынны пәйгамбәр кире үз кулына алды. Ул шактый кечкенә һәм җиңел иде шул. Мөбарәк кулында әйләндереп карагач, Рәсүл Әкрам аңа дога кылды һәм кире Сәлман фарсыга сузды:

— Ал моны!

Алды. Үлчәп карадылар. Тәмам кырык үлчәм, ягъни кырык вакыйә авырлыгында килде. Моны хуҗасына китереп, Сәлман фарсы зат рәхмәт ителде һәм пәйгамбәргә олуг хезмәтләрен күрсәтте.

Һиҗрәтнең икенче елында Мәдинә халкы сахрага чыгып, бәйрәм уздырды. Мөселманнарның бер-берсенә хөрмәт вә сый күрсәтүләре күпләрне хәйранга калдырды. Бу рәвешле дуслык мөнәсәбәтләре насари һәм мәҗүсиләрдә дә күренмәгән иде. Бигрәк тә яһүдиләр курка калдылар, мәгәрем ки ислам дине куәт алып, саннары ишәя төшсә һәм дә шушы рәвешле бер-берсенә хөрмәтле булып калсалар, ул вакытта алар дөньяны тетрәтәчәк дип курыктылар.

Бу дәвердә мөселманнар Бәйтел-Мөкатдәсне кыйбла итеп таный, шул якка сәҗдә итеп, намаз укый, дога кыла торган иделәр. Сахрадагы олуг бәйрәмдә дә Коръән аятьләрен уку шул рәвешле барды. Аллаһы тәгаләдән ата-бабаларына, угыл-кызларына бәхет вә сәгадәт өметендә догалар кылып, иминлек вә исламның куәт алуын үтенделәр.

Мөхәммәд галәйһис-сәлам һиҗрәтнең уналтынчы аена кадәр, (кайбер хәбәрләрдә унҗиде аена чаклы диләр) Бәйтел-Мөкатдәс тарафын кыйбла тотты, әмма өйлә намазы вакытында Җәбраил фәрештә иреште һәм икенче рәкәгать рөкугында пәйгамбәрне борылырга мәҗбүр итте. Бу хәлне мәхәллә халкы бер-бер ялгышу түгелме дип кабул кылуга карамастан, ул борылган тарафыннан кире кайтмады, намазын дәвам иттерде. Аңа иярган әһеле-мөэмин дә тарафын үзгәртергә мәҗбүр иде.

Моңа кадәр дә уртага алынып сөйләнелә торган сүзләрнең берсе булган кыйбла мәсьәләсе өйләдән соң тагын да телгә кысыла торган бәхәскә әверелеп китте. Ара-тирә яһүдиләрдән:

— Гаҗәп, бик гаҗәп хәл, Мөхәммәд үз диненә хилафлык кыла, кыйбласында безгә тарта,— дигән сүзләрне ишетеп, мөэмин-мөселман аптырашта калгалый иделәр. Шулай бервакыт Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең үзенә дә ирештергәннәр иде. Әмма ул чакта пәйгамбәр электән ният ителгән кыйбла тарафын бозмый калдырды. Аллаһы тәгаләдән бер-бер хәбәр-вәхи көтте. Вакыйгалар үз чиратлары белән барып, хәзрәт вәхи таләбеннән өзелмәде, хәл дә үзгәрмәде.

Һәм менә Мөхәммәд галәйһис-сәлам өйлә намазында кыйбланы үзгәртеп, Кәгъбә тарафына түнгәч, яһүдиләр тагын сүз тараттылар һәм, әһле-мөэминне үртәгәндәй итеп:

— Көнчелектән кыйбласын үзгәртте! — диделәр.

Әнсарилар эшнең асылын аңларга тырыштылар. Тик Мөхәммәд галәйһис-сәлам мәсьәләгә ачыклык кертергә ашыкмады, намазга бөкләнгән саен Кәгъбә тарафын тота торган булып китте. Шуннан сүзләр тагын да куердылар. Мәдинәнекеләр:

— Хәзрәтебез ватанын сагынды, үскән илен кыйбла итте, Кәгъбәне Бәйтел-Мөкатдәстән өстен күрде,— дия башладылар. Шулай да намазга аңа иярделәр, кыйбланы аныңча тоттылар.

Мөселманнар арасына тавыш-гауга вә коткы уты салырга хисаплаган яһүдиләр, бу хәлдән үзләренә файда эзләп, ничек тә болгатып калырга ашыктылар. Мөселманнарның җыелышып мөгамәлә кылуларын күрсәләр, уртага кереп, сафсатага таянган хәлдә сүз ташлар булдылар:

— Әүвәлге кыйблагыз дөрес идеме, әллә хәзергесеме?

— Әгәр дә элеккечә ният ителгән икән һәм ул дөрес булса, аннан баш тарту — Хак тәгалә әмерен бозу түгелме?

— Әгәр дә ялгышлык белән әүвәлге кыйблагызга баш органсыз икән, нигә бу кадәр вакытлар наданлык болыты астында кала бирдегез? Ни өчен моңа чаклы кыйблагыз билгеле булмаган?

Сәхабәләр бу рәвешле бирелгән сораулардан аптырабрак кала, кыенлык тоя иделәр. Әмма мөэмин арасында да зиһенле бәндәләр булып, алар җавапны тиз таба һәм тавыш-гаугага сусаган яһүдиләрнең авызларын капларлык итеп:

— Дөрес эш шул — әгәр дә Аллаһы тәгалә әмер итсә! — дия иделәр. Бу сүз аларга пәйгамбәрдән күчкән иде.

Монда да үзләренә файда итә алмагач, яһүдиләр баш катыруның бүтән җайларын уйлый вә тапкалыйлар иде. Шундый вәсвәсәнең берсе шулай ук шактый сүзләр тудырды һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең үзенә ирешге:

— Моңа кадәр вафат булган кешеләр ничек һәм ни рәвешле булырлар? Ахирәт көнендә кайда хөкем ителерләр?

Яһүдиләр теленнән алып, бу сүзне китергән мөэминнәргә Мөхәммәд пәйгамбәр:

— Аллаһы тәгалә иманлы бәндәләрне сөя! — дип җавап бирде. Бу хәдистән бик күп мәгънәләр чыгып, күп галим вә әдипләрнең фикер төеренә әверелеп киткәне тарихлардан билгеледер.

Кыйбла тарафы беленгәч, икенче көнне Мөхәммәд пәйгамбәр сәхабәләре белән бергә төзегән Куба мәхәлләсе мәсҗеденә килде һәм бер ел эчендә бозылып киткән диварларының ташларын үз куллары белән күтәрде, төзекләндерде. Якшәмбе көнендә кабаттан монда килеп намаз кылды һәм шунда әһеле-мөэмингә белдерде:

— Кем Кубага килеп намаз укый, ул кеше гомерен савап белән уздырыр!

Шушы рәвешле ул Кәгъбәдән соң Куба мәсҗеден олылады, артык сүз сөйләшүче вә бәхәс кылып баш катыручы кешеләрнең телен кисте. Бу хәбәрне ишеткән яһүдиләр дә тынарак төштеләр. Сафсата белән генә мөэминнең иманын бозу мөмкин түгел иде шул. Әлегә башка чарасын тапмадылар.

Мөхәммәд пәйгамбәр шушы рәвешле Мәдинәдә, дан-шөһрәтенә игътибарын юнәлтеп тә тормастан, аз белән канәгать табып яшәвен дәвам итте. Кызы Фатыйма да аның янында иде. Кыйбла тарафы билгеләнелгән мәсаҗедне Зөл-Кыйблатыйн дип атап йөртә башладылар. Халык тынычланырга өлгермәде, сүзләр хәзрәте Фатыйма тирәсендә куерып киттеләр. Әнсарилар вә сәхабәләр аның гүзәллеген белеп, күңелләре аңа тартылганын тоя иделәр. Шул сәбәпле кызны хөрмәтләү йөзеннән хәтта Зөһрәи Фатыйма дип тә атадылар, ә кайберәүләр, бигрәк тә шагыйрь җанлы егетләр аны таң йолдызы белән тиңләп, бары тик Зөһрә исеме белән генә телгә ала башладылар. Шулай итеп Фатыйманың исеме җырларда Зөһрә рәвешендә яңгырый торган иде. Болай үзгәртү хәзрәте Мөхәммәдкә сиздермәс өчен дә уңай булганлыктан, егет-җиләнгә үз хисләрен яшерми әйтергә дә мөмкинлек бирде. Әмма серне Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйк ялгышлык белән әйтеп ташлады. Аның максаты Фатыйманы хатынлыкка сорау иде дә бит, югыйсә, әмма ни эшлисең инде.

— Зөһрәне миңа насыйп кылсаң иде? — дип үтенде пәйгамбәрдән Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйк.

— Минем ул исемдәге кызым юк, — дип Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең дустына шикле караш ташлады. Хәтере чуалмаганмы, янәсе.

Шунда Әбу-Бәкер барысын да аңлатып бирде һәм кабаттан Фатыйманы хатынлыкка сорады. Аңа каршы пәйгамбәр:

— Ышаныч тотыйк, — дип кенә җавап бирде.

Әмма Фатыйманың язмышы сәхабәләрне чыннан да дулкынландыра иде. Әбу-Бәкер шулай сабыр итәргә мәҗбүр кылынгач, Гомәр бине Хаттат тиз ара кызның кулын сорарга ашыкты, әмма ул да:

— Ышаныч тотыйк, — дигән җавантан башканы ишетмәде.

Көннәрнең берендә Әбу-Бәкер, Гомәр, Сәгад бине Мөгаз мәсҗедтә сәхбәт кылып утырганда, Фатыйма хакындагы сүзне уртага алып сөйләшә башладылар. Шактый озын вә озак барган сүзнең ахырында күңелләренә акыл нуры иңеп:

— Безнең арада хәзрәте Фатыймага имам Галидән дә лаеклырак һичкем юктыр, башка беребезгә дә илтифат ителмәде, — диделәр.

Шунда Гомәр бине Хаттат бераз сабыр итә калды һәм ул да:

— Фатыйма, шигем юк, имам Галигә насыйп булыр, әмма сорап, белешеп куймыйча ярамас,— диде. Моңа каршы Әбу-Бәкер:

— Галигә мәсьәләнең асылын үзем чишәрмен, Мөхәммәд галәйһис-сәламнән дә үтенермен! — дип, урыныннан кузгала башлады.

Сәгад бине Мөгаз, уртак фикергә килүләренә шатланып, аңа ияреpгә ашыкты.

— Йа Әбу-Бәкер, син һәрвакыт сүзне акыл белән йөртәсең, сөйләшә беләсең. Без дә сиңа кушылабыз,— диде.

Алар өчесе бергә мәсҗедтән чыктылар һәм имам Галине эзләп киттеләр. Әмма соңга калдылар. Гали инде күптән, хөҗрәсен калдырып, дөясенә утырган да Нихалистанга юл тоткан икән. Ул авылда аның дусларыннан бер әнсариның хөрмә бакчасы булып, аны сугарырга ярдәмен күрсәтә, шул рәвешле хезмәт куя икән. Эшне кичектермәс өчен Әбу-Бәкер, Гомәр, Сәгыйть шунда юнәлүне мәслихәт күрделәр.

Гали аларның килгәннәрен еpактан ук шәйләп алды һәм, бер-бер хәл булмаганмы дип, шиккә дә төште, каршы барып, хәлләрен сорашты, ни сәбәпле җаннары тынгысызлык чоңгылына төшкәнлеген белеште, хәерле көн теләде. Әмма Әбу-Бәкер:

— Йа Гали, син безгә хәерле көн теләрсең, тик әлегә безгә һичбер хәер юк. Үзеңне шул сәбәпле эзләп килдек. Мөхәммәд пәйгамбәребезгә кардәшлектә синнән якын һичкемне белмибез. Кызы Фатыйманы корәиш вә Мәдинә халкыннан күпләр сорадылар, әмма берсен дә илтифат итмәде. Арадан бер син калдың. Ни өчен сакланасың, ни өчен сорап бармыйсың? — дигәч, имам Галинең күзләренә кайнар яшьләр тулды һәм әйтте:

— И Әбу-Бәкер, йөрәк түрендә очкынланган утым көчле. Ул ут — Фатыймага мәхәббәтемнең дәлиле. Аны минем кебек яратучы һичкем юк. Шулай да сабыр итәм, чөнки каршылык бар,— дип башын аска иде. Аның хәленнән Әбу-Бәкернең күңеле кузгалды һәм ул шунда ук егетне юатырга ашыкты, тыныч кына сөйли бирде:

— И Гали, алай димә әле. Аллаһы тәгалә вә аның рәсүле Мөхәммәд пәйгамбәребез каршында дөнья малы тузан бөртеге кадәр генә. Фәкыйрьлегең хилафлык түгел...

Имам Галине дөясенә утыртып озаттылар. Егет, яшәгән ханәсенә кайтып, өстенә кияр өчен пакъланган киемнәрен чыгарды, юынды һәм башы очлаеп өскә калыккан артсыз башмакларын киеп алды. Шушы рәвешле чиста кием вә саф күңел белән пәйгамбәр каршына килергә вә тез чүгәргә ниятләде.

Мөхәммәд галәйһис-сәлам ул көнне Өмме-Сәлимәнең өендә иде. Ишекләренә Гали килеп какты. Яки ул көлкегә калып, куылып чыгарылачак, яисә Фатыйма хәзрәтләре аның бәхетенә насыйп булачак. Икенең берсе, өченчесе юк. Шунлыктан Гали, ни булса — шул, дип язмышын Аллаһы тәгаләгә тапшырды. Аның ишек кагуына каршы Өмме-Сәлимә:

— Кем бар анда? — дип кычкырып сорады. Бүлмәдә утырган Мөхәммәд пәйгамбәр:

— Ишекне барып ачу кирәктер,— диде.— Ул һич тә куркыныч вә дошман түгел, Аллаһы тәгалә вә аның рәсүле хезмәтен башкаручы хөрмәт иясе! — дип белдерде.

Өмме-Сәлимә бераз аптырады да:

— Йа Рәсүлуллаh, кем хакында болай әйтәсең? — дип сорады. Гали һаман да ишек төбендә ачканнарын көтеп кала бирде. Пәйгамбәр исә, әле ашыгырга исәп тотмаган Өмме-Сәлимәгә:

— Карендәшем һәм агамның улы Гали хакында әйтәм,— диде.

Боларны ишетүдән хәйран калган хуҗабикә ишеккә йөгерде, абынып китеп, чак кына йөзе белән җир сөртмәде. Ишек артында, чыннан да, Галинең басып торганын күргәч, бөтенләй капланып китә язды. Пәйгамбәрнең бу кадәр барча серләрне белеп торганлыгын аңлагач, исе-акыллары китте. Галине түргә чакырды, әмма егет баскан урынында кала бирде. Итагать белән генә:

— Әссәламегаләйкем, йа Рәсүлуллаһи, вә бәракәтүһи! — диде, эчкә һаман да кермәде. Шунда пәйгамбәрнең җавап сәламе ишетелде:

— Вәгаләйкем әссәлам вә рәхмәтуллаһи вә бәракәтүһи!

Шуннан соң гына Гали сәхабә йортка узды һәм Рәсүл әкрам каршысына килде. Мөхәммәд саллаллаһу тәгалә галәйһи вә сәлләм аңа үз янынннан урын күрсәтте. Гали башын иеп кенә килеп утырды, сүз башларга кодрәтеннән килмәде. Моны сизенеп торган пәйгамбәр:

— Йа Гали, бер морад-теләгең бар кебек, сөйләргә телисең, күрәм, тарсынма. Нәрсә дисәң дә, хасил кылыныр! — диде. Тел яшереп торуның мәгънәсе юк иде.

Бу вакытта Өмме-Сәлимә үз бүлмәсенә кереп китәр җирдән туктальш калган һәм ике ирнең сүзләренә шаһитлык кылып тора иде. Гали сәхабә күңелендә вә уенда ни бар, шуларны ачып салган хәлендә сөйләде дә сөйләде, пәйгамбәр аны тыярга кирәк тапмады.

— И Рәсүлуллаһ, — дип сүз башлаган иде егет. — Атам һәм анам сиңа фида булсыннар. Үзегезгә мәгълүмдер ки, атам — Әбу-Талип, анам — Фатыйма, бу урында аларны исемә алырга кирәкле таптым, урыннары күркәм кылынсын, Аллаһы тәгалә аларны газаплардан арала-сын, синең тоткан эшләрегезне уңышлы кылсын! Син мине ачык күзле вә якты күңелле итеп тәрбияләдең, үзеңнән күргән яхшылыкларны атам вә анамнан күрмәдем. Тәүгеләрдән булып кадерле вә хакыйкый дин юлына күндем, ата-бабамның бозык динennән котылдым, мине хак дингә китерүче булдың. Минем тормышыма терәк син булдың, и Рәсүлуллаһ, һичбер хаҗәт вә сагышым юк, әмма дә ләкин күңелем түрендә кызыгыз, һәркемнең телендә вә җырындагы гүзәл кызыгыз Фатыймадыр. Күңелем башкага күз салмас, җаным аны тели. Үземә хатынлыкка сорар идем, моңа мөмкинлек бирсәгез иде? Бармыдыр рөхсәт, йа Рәсүлуллаһ?

Мөхәммәд галәйһис-сәлам каршы килеп бер сүз әйтмәде, бары тик сабыр гына:

— Бирнә өчен тиешле саналган вә кирәкле нәрсәң бармы? — диде.

Моннан шул билгеле булды: пәйгамбәр кызы Фатыйманы карендәше Галигә хатынлыкка тапшыруга риза иде. Бу сүзләрне ишетүгә, егет балкып китте, әмма үзенең тормыш хәле исенә төште, йөзе кабат сулды.

— Йа Рәсүл, — диде ул. — Минем хәлемне синнән башка беркем дә белми һәм белмәс. Бары тик бер кылычым, бер җөбәм-чапаным, ялгыз дөям генә бар. Болардан башка һичнәрсәм юк!

— Кылычың сугыш өчен кирәк, дөяң — йөрү өчен. Синең белән җөбеңә солых итәм, килешәм, сиңа бәхет телим, Хак тәгалә күкләрдә Фатыйма белән үзеңә никах кылды, — дип белдерде Мөхәммәд саллалаһу тәгалә галәйһи вә сәлләм һәм бераз сабыр итеп торганнан соң дәвам сүзне кирәк тапты, эшне аңлатып биреп әйтте: — Син монда килердән алда каршыма бер фәрештә иңде, алдыма татлы эчемлек китерде. Йөзе-бите күп иде. Нәсел сафлыгы хакында миңа гозерләнеп сөйләде. Сорадым: «Син миңа ни өчен нәсел сафлыгы хакында искәртәсең?» — дидем. Ул исә: «Мин гарше каимәдә яшәүче фәрештәләрнең берсе булам, аталган исемем Сәтаилдыр. Хак тәгалә бу көн каршыңа шушы асыл сурәтемдә килергә әмер итте. Кушылганны башкардым. Артымнан Җәбраил галәйһис-сәлам иңәр, үтенечең бар икән, аннан сорарсың», — дип кенә җавап бирде. Бу вакытта күктә Җәбраил фәрештә пәйда булды, кулындагы ефәк тасмага бер җөмлә язылган иде. Аны үземә күрсәтте. Сорадым: «Монда ни-нәрсә язылган?» Җәбраил фәрештә аңлатып бирде, әйтте: «Аллаһы тәгалә кызың Фатыйманы абзаңның улы Галигә никях итте һәм күкләрдәге барлык җан иляренә боерды, җәннәтләрне бизәделәр. Хур кызларына вәхи бирелде, Туба агачы төбенә чатырлар кордылар. Барча фәрештәләргә дүртенче күктәге Мәгъмур сараена җыелырга әмер ирешде. Алар каршында мөнбәр Кирамәттә атагыз Адәм пәйгамбәр хөтбә укыды, икенче яктан Бәйтел-Мәгъмурда Рахаил фәрештә хөтбә укыды. Шуннан соң күкләр хәрәкәткә килеп, барча фәрештәләр

җәннәткә юнәлде. Аллаһы тәгаләдән вәхи иреште: «И Җәбраил, колым Фатыйма — Мөхәммәд пәйгамбәрем кызын бәндәм Гали бине Әбу-Талипка насыйп иттем, син дә бу эшне фәрештәләргә җиткер!» — диде. Тиз ара үтәдем, барча җанияләрен шаһит иттем һәм менә шушы язуны теркәп куйдым да, сиңа китердем»,— диде. Мин исә: «Күрдем, Аллаһы тәгаләнең әмеренә буйсындым!» — дидем. Шуннан соң Җәбраил галәйһис-сәлам ул язуны, мөһерләп, Ризван кулына тапшырды, аннан аны Туба агачына эленгән алтын сандыкка салдылар, төндә янган фонарь төсле нурлар чәчә башлады. Моны күреп, барча мәләк вә фәрештәләр сөенештеләр, шатланып, бер-берсен тәбрикләделәр һәм бүләкләр бирештеләр. Ул язу Кыямәткәчә шунда торыр!..

Бу сүзләрне ишеткәч, Гали сәхабәнең күзләре вә йөзе нурланып китте һәм ул, шатлыгын яшерә алмыйча, әсәрләнеп аһ орды. Бу аның өчен олуг сөенеч көне иде.

Әйттеләр ки, Аллаһы тәгаләнең рәхмәте белән ярлар бер-берсенә мәхәббәт тотарлар, күңелләренә салынган гыйшык уты аларны исәрләндерер, акылларын адаштырыр, әмма бу мәгъшуклар үзара алдаш кылмасыннар һәм берсе икенчесен алдамасын гына, ул вакытта мәңге бәхетле вә рәхәт тормышта гомерләрен кичерерләр. Ахирәт көнендә алар өчен шатлыклы сәгадәт минутлары хәзер кылыныр. Һәркемнең үзе яратканы белән уртак бәхеткә күмелеп яшәү хокукы бар, шуның өчен җан атсыннар һәм хезмәт куйсыннар, бары тик мәхәббәтләрен йөк итемәсеннәр, Аллаһы тәгаләне онытмасыннар!

— Кальбең-күкрәгеңдә ышаныч нуры хасил булсын! Мин сезнең никахыгызга ризамын! — диде пәйгамбәребез.

Ул сөхбәт келәмендә утырып калды, Гали сәхабә сөенечтән нурланып, бәхет-сәгадәт рәхәтенә күмелгән хәлендә ишектән килеп чыкты һәм туп-туры мәсҗедкә юнәлде. Теләге Аллаһы тәгаләгә рәхмәте йөзеннән догага тезләнү иде. Мәсҗед капкасыннан килеп керүгә, анда Әбу-Бәкер һәм Гомәр сәхабәләргә туры килде. Алар сабырсызланып, аннан хәбәр көтеп торалар икән...

— Ни булды? Сүзебезне һич ишетмисең! — диде алар.

Гали сәхабә аларның эндәшкәнен ишетте, әмма ни теләгәннәрен төшенмичә калды. Әбу-Бәкер һәм Гомәр аның аптыраулы карашыннан беразга сәерсенеп калдылар, тагын да сорауны кабатларга мәҗбүр булдылар:

— Йә, хәл ничек? Боердымы?

Бу юлысы Гали бине Әбу-Талип аларның соравын аңлап алды һәм иптәшләрен шатландыру йөзеннән, тиз-тиз җавап бирергә ашыкты:

— Пәйгамбәр үтенечемне кабул итте!

Боларны ишеткәч, барчасы бердәй шатланып, сөенечләрен яшерә алмыйча бер-берсенең җилкәләренә кактылар һәм егетне беренчеләр буларак котларга ашыктылар. Шул рәвешле, кызу-кызу атлап, мәсҗед эченә уздылар. Ул арада Мөхәммәд саллалаһу тәгалә галәйһи вә сәлләм үзе дә күренде. Аның да йөзе кояш кебек балкый иде.

Мәсҗедкә керүгә, пәйгамбәр тиз ара хәзрәте Билалны дәштерде һәм аңа:

— Мәдинә шәһәрендә яшәгән барча мөһаҗир вә әнсаридан булган мөселманнарны дәшең,— дип боерды.

Билал азанга күтәрелде. Мөселманнар, бу чакыруны ишетүгә, бердәй мәсҗедкә җыелдылар. Пәйгамбәр намаз вә догадан соң, мөнбәргә күтәрелде һәм боерды:

— Белегез, и мөселманнар, бүген Җәбраил карендәшем килеп хәбәр бирде, Хак тәгалә барча фәрештәләрне Бәйтел-Мәгъмурга дәшкән һәм: «Колым Фатыйма бине Мөхәммәдне бәндәм Гали бине Әбу-Талипка насыйп кылдым!» — дип белдергән. Тагын да шуны ишетегез, миңа әмер итте, бу сүзләрен халыкка белдерергә һәм ике бәхетле затның никахларын укырга!

«Фатыйма кемнең бәхетенә насыйп булыр икән?» — дип төн йокыларын югалткан егетләр вә язмышы хакында уйланган мөһаҗир һәм әнсарилар пәйгамбәрнең шушы сүзләреннән соң, тынсыз калдылар, йөзләре моңсу да, сөенечле дә иде. Мөхәммәд галәйһис-сәлам әйтте:

— Йа Гали, күтәрел, калкып бире кил, никах хөтбәсенә колак тотарсың! — диде.

Гали сәхабә алгы тезмәдән күтәрелде һәм башын итагать сыйфаты буларак аска игән хәлендә пәйгамбәрнең уң ягына килеп тезләнде вә Аллаһы тәгаләгә рәхмәтләрен җиткерде. Шунда пәйгамбәр болай диде:

— Йа Гали бине Әбу-Талип, әйт: «Рәсүлуллаһ Мөхәммәд бине Габдулла кызы Фатыйманы миңа насыйп итте, аның мәһәр-калымы — минем җөббәм булыр. Мин моңа ризалык бирдем, сез аңа шаһитлык кылыгыз!

Гали сәхабә пәйгамбәрнең шушы сүзләрен кабатлады. Әмма сәхабәләр:

— И Рәсүлуллаһ, бу рәвешле ризалык бирдеңме? Без шаһит була алабызмы? — диделәр.

Пәйгамбәр аларга:

— Шаһит булыгыз! — диде.

Мәсҗед эченә җыелган барча мөһаҗир вә әнсар:

— Аллаһы тәгалә бәхетле итсен үзләрен! — диделәр.

Шуның белән никах хөтбәсе тәмам ителде, мәсҗедтән чыгып, өйләренә таралыштылар. Пәйгамбәр, һичкем белән әңгәмәгә тукталмыйча, торагына килде һәм туйга әзерләнергә боерды. Артыннан ияреп кайткан Галигә:

— Бар, җөббәңне сат, акчасын миңа китерерсең,— диде.

Туйга әзерләнергә кушылса да, Мөхәммәд галәйһис-сәлам эшне ашыктырмады. Бәйрәм кичегә бирде.

Гали сәхабә мәһәр хисабына салынган җөббәсен 480 дирһәм акчага Госманга китереп сатты һәм, алыш-биреш тәмам ителгәч:

— И кадерле дустым вә карендәшем, мин бу киемеңә хуҗа булдыммы? — дип сорады.

Гали сәхабә аның бу сүзләрен ишетте, бераз аптырабрак калды, сүзендә берәр хикмәт юкмы дип, шикләнә төште, шулай да:

— Әйе,— дип җавап бирә алды.

— Димәк бу җөббә минеке булды, 480 дирһәм — синеке, шулай бит! — диде Госман һәм шиккә калган Гали бине Әбу-Талипка эшнең ахырын белдерергә ашыкты.— Бәс, шулай булгач, мин аны сиңа бүләк итәм!

Көтелмәгән бу хәлдән Гали тагын да аптырабрак калды, ни әйтергә дә белмәде. Бераздан гына вакыйганың асылын аңлап, дирһәмнәрне һәм җөббәне кулына алып, пәйгамбәр янына кабат килде, аларны каршысына куйды, ни сәбәпле шулай килеп чыкканын аңлатып бирде, хәлне сөйләп күрсәтте. Рәсүлуллаһ шунда, мөбарәк кулларын күтәреп, хәзрәте Госманның бәхетен үтенеп вә хәерләр теләп дога укыды. Акчадан беразын Әбу-Бәкергә бирде һәм туй кирәк-яраклары алырга боерды. Сәлман фарсы һәм Билалны дәштереп, аларга хәбәр салырга кушты:

— Бүләк итеп туйга кем нәрсә китерә ала, рәхим итсеннәр! — диде.

Шулай итеп, туйга бүләк китерү сөннәт вә гадәт икәнлеге халыкка билгеле булды.

Пәйгамбәрнең бу сүзләрен ишеткәч, барча мөселманнар үзләренең хөрмәтләрен күрсәтергә ашыктылар. Фатыйма өчен урын-җир җиһазларын Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйк китерде, Хәбәш Мысридан эче йон белән тулы бер түшәк сатып алды, сәхтийаннан эшләнелгән бер җәймә бүләк итте һәм башка төрле кирәк-яракларны тапты. Аларны пәйгамбәр каршысына куйды һәм:

— Йа Рәсүлуллаһ, бу синең кызың өчен вә туй кирәгенә өммәтләреңнән бүләктер,— дип белдерде.

Кадер-хөрмәттән Мөхәммәд галәйһис-сәламнең күзләрендә яшь күренде вә ул аларны тыеп тора алмады, ихлас күңеленнән:

— Йа Аллаһ, кавемемә бәрәкәт бир! — дип, дога кылды.

Ул да түгел, башкалар да булачак яшь гаиләнең туй ярарына һәртөрле кирәкләрне китерә башладылар. Болардан күңеле тагын да йомшара төшкән пәйгамбәр, кияве Галигә:

— Синең хатыныңолуг бер хатын, ул барча галәмдәге хатыннарның хуҗасының хуҗасы! — диде.

Бу сүзләреннән соң Фатыйманы никадәр яратканлыгы вә аңа хөрмәте генә түгел, бәлки аны барча хатын-кызлар өчен дә үрнәк итеп күтәргәнлеге аңлашылып тора иде.

Никахтан соң, бер ай вакыт кичте, әмма Гали бине Әбу-Талип вә Фатыймаи-Зәһрә әлегә кавышмыйча калдылар. Көннәрнең берендә Галинең туганы тиешле Гакыйль сәхабә:

— Йа Гали, бу никахың белән мактаулы булдык, ләкин морадым бар: бу ике энҗе бер-берсенә кушылсыннар иде, шул тиешле! — дигәч, имам дәрәҗәсен алган Гали күңеле түрендәге серләрен яшерә алмыйча, җавап бирде:

— Минем дә теләгем шул, әмма сабыр итәрмен вә тыелып торырмын! Бу — Рәсүлуллаһ теләгендәдер! — диде.

Гакыйль сәхабә, шушы сүзләрен ишетүгә, башта беразга аптырабрак калды, аннан соң аны кулыннан җитәкләп алды да: «Әйдә әле!» — дип Мөхәммәд галәйһис-сәламнең каршына китерде вә тезләнделәр. Әмма пәйгамбәрнең урыны буш иде. Алар янына Рәсүлуллаһның җариясе Өмме-Имин туры килде һәм нинди борчулар аларны монда йөрткәнен сорады. Хәлне сөйләп бирделәр.

— Бу эш белән сезнең йөрүегез бер дә килешә торган гамәлләрдән түгел,— диде Өмме-Имин.— Моны килешенеп үтенергә кирәкле. Аның өчен хатыннары белән бергә уртак сүзгә килү кирәк, аларның татлы телләре вә үтенечләре тиешледер. Шулай күркәмрәк булыр.

Гали белән Гакыйль аның сүзләре белән килештеләр.

Өмме-Имингә эшне хәл итү йөкләнелгән булганлыктан, ул иң элек Өмме-Сәлимәгә барды һәм асыл сүзне аңлатып бирде. Бу яктан да ярдәм кулы сузылырга әзер икән. Бергә-бергә алар пәйгамбәрнең яшь хәләше хәзрәте Гайшә бүлмәсенә керделәр. Өмме-Сәлимә йомышны төкми-чәчми сөйләп бирде. Пәйгамбәр үзе дә монда булганлыктан, Өмме-Сәлимә күркәм тел белән бәян итте, ахырында:

— Әгәр дә бу вакытта順ныбызда аның әнкәсе булса, безгә Фатыйманың язмышы өчен бер генә борчулы уй кереп карамас иде,— диде һәм Рәсүл Әкрамның күңелен мәрхүмә хатыны — Хәдичәне искә алуы белән кузгатуга сәбәп итте. Пәйгамбәрнең күзләрендә яшь бөртекләре күренде.

— Дөнья йөзендә Хәдичә кебек бер хатын бар идеме? — диде ул, бераз вакыттан соң.— Бөтен халык миннән йөз чөергәндә дә ул минем сердәшем булды, ул минем иптәшем иде һәм кулында җыелган барлык малын минем юлымда сарыф итте, вә ислам диненең бөреләнүе вә куәт алуы өчен һәммә төрле ярдәмнәрен күрсәтте, тормышын да кызганмады. Хәдичә кебек хатын ислам вә минем өчен дөньяда берәү вә бердәнбер генә булды! — диде.

Аның сүзләреннән соң Өмме-Сәлимә борчуга төште һәм:

— Йа Рәсүлуллаһ, Хәдичәне һәрдаим исебездә тотарбыз, Аллаһы тәгалә урынын җәннәт әйләсен. Ходай агайның улын да кызың белән бер җепкә куйды. Син дә аларны бер җиргә куйсаң, шушы ике гәүһәр-энҗене бер-беренә кавыштырсаң иде? — дип үтенде.

Боларны ишетеп торган пәйгамбәр:

— Гали үзе миңа бу сүзләрне белдермәде, и Өмме-Сәлимә, юкка борчыласың,— дип кенә җавап бирде. Әмма хатыны эшен ахырына кадәр хәл итәргә теләде һәм каршы чыгып:

— Гали бу көннәрдә үзен гаять тә оялучан итеп тота. Күңелендәге гыйшык уты йөзен сулдыра. Шул җәһәттән белдермәс! — диде.

Шуннан соң гына Мөхәммәд пәйгамбәр, җариясе Өмме-Имингә әмер итеп, Гали бине Әбу-Талипны чакырырга боерды.

Мәдинә эчендә кияү егетен таба алмадылар. Ул юл башында иде. Хәленнән көенгән рәвешендә, күңелен кая куя алмыйча, ерак сахра вә киң сәйран җирләргә карап, Мәҗнүн дивана хәленә җитәрәк, сөекле Фатыйма хәсрәтеннән боегып утыра иде. Бәлки шушы кичәдә шәһәрне ташлап чыгар, бәгыре төбендәге иң изге серләрен болыннарда чәчәкләргә сөйләр, кәрван вә кабиләләрдән читләшеп, бер илдән икенчесенә күчәр? Кем икәнлеген һәм нинди хәсрәт белән янып йөргәнен дә белмәсләр...

Гали үз исемен атап дәшкән хатын ягына таба борылды. Өмме-Иминне яхшы белә, таный иде. Ни кирәк аңа? Рәсүлуллаһтан хәбәр китергәндер, агамның улына кызымны бирмәмен, дигәндер. Мөмкин эш түгел шул. Күкләрдә җаннар җаннарга бәйләнсә дә, җир йөзендә башкачарак ул... Җитмәсә, тән вә җисемнәр дә бер каннан. Туганнарга хатын вә ирлек зилаф эштер...

— Йа Гали, Рәсүлуллаһ үзеңне эзләтә, каршына дәшә! — диде Өмме-Имин, ашыгып. — Хәзер үк килергә боерды.

Алар пәйгамбәр каршына килделәр. Гали керүгә, мәҗлестәге хатыннар чыгып китте, алар монда артык иде. Ир белән ир, укытучы үзенең укучысы белән сөйләшә. Бер-берсен аңларлар!

Хәзрәте Гали башын иеп кенә утырды, күзләрен Рәсүл Әкрам йөзенә таба күтәрергә оялды. Әмма пәйгамбәр, тыныч кына:

— Хатыныңны эзлисеңме? — дип сорап куйды. Аның бу сүзләре шундый да ягымлы вә назлы иделәр ки, Галинең күзләреннән чак кына яшьләре тәгәрәп төшмәде. Үз хәсрәте үзе белән булганлыктан, хисләрен тыя алды һәм дә тыныч кына җавап бирергә тиешлеген аңлады.

— Әйе, йа Рәсүлуллаһ, атам-анам синең юлыңда корбан булсыннар!

— Фатыйманың җиһазларын һәм барча туй кирәкләрен тәмам иттеләр! — дип белдерде пәйгамбәр.

Шунда гына Галинең күзләре Мөхәммәд галәйһис-сәламнең нурлы йөзенә күтәрелеп карады, сәерсенүе якты балкыш белән аңлашылды, күңеле сөенеч белән тулды. Әйтер сүзләре бәгыре төбендә кайнады, әмма ачык тел белән бер генә кәлимә дә әйтә алмады.

Гали китергән мәһәрнең бер өлеше Өмме-Сәлимәдә иде. Ул аларны егетнең үзенә кайтарды. Хөрмә, йөзем җимеше һәм кара җимеш алырга боерды. Гали Әл-Мортаза бине Әбу-Талип биш дирһәм бәягә хөрмә, дүрт дирһәмгә кара җимеш, бер дирһәмгә йөзем алды. Боларны пәйгамбәр каршысына китерде. Мөхәммәд галәйһис-сәлам кулын җиңеннән чыгарды һәм, сәхтийаннан эшләнгән бер ашъяулык соратып, аның өстендә берәр уч өч төрле ризыкны бергә бутады, хөрмә белән кара җимешне юдырды, бер-берсе белән аралаштырды. Аннан соң:

— Йа Гали, бар, кемне беләсең, дәш! — дип боерды.

Егет капкадан чыгуга, шәһәр урамында күп кенә кешенең җыелыш корып торганлыкларын күрде һәм аларны Рәсүл Әкрам каршына дәште. Һәммәсе дә керделәр.

— Халык күп җыелыр, йа Рәсүлуллаһ! — дип белдерде пәйгамбәргә Гали, гүяки монда үзенең гаебе бар кебек уңайсызланып.

— Мактаулы затка бәйрәм вә хафада кеше күп килер, борчылыр урын юк, — диде Мөхәммәд пәйгамбәр. — Керә бирсеннәр, әмма унар-унар итеп чакыр, туй табыныннан теләкләрендә бар кадәр тәгам җыйсыннар.

Мәҗлес башланды. Берләреннән икенчеләре ишетте һәм мөһаҗир вә әнсардан барлыгы 700 кешедән артык ирләрдән-хатыннардан кунаклар килделәр, пәйгамбәр кушканча унар-унар кереп, ризык җыйдылар, кәләш вә кияү өчен догалар кылдылар. Шулай итеп, аларның бәйрәм-туй мәҗ-

лесләре тәмам ителде, өлешсез калган кеше булмады, һәммәсе канәгатьлек тапты.

Аш мәҗлесе тәмам ителгәч, Рәсүлуллаһ бер кулы белән кызы Фатыйманы җитәкләде, икенчесенә Галинең кулын алды, аларны зөфаф кичәсе уздырылачак бүлмәгә китерде, адымнары салмак, үз-үзен тотышы тыныч иде. Ул Фатыйманы кочагына алды, самими бер иркәләү белән аркасыннан сөйде, гүяки: «Кызым, балам, син инде зур үстең, хәзер башка кешенең кулына тапшырам...» — дигән сүзләрне әйтәдер төсле иде. Фатыйма да әтисенең кочагына елышканнан елыша бирде. Күзләрендә бәхет-сәгадәт билгесе булган күз яшьләре күренде. Әмма серен сиздермәде, орылып бәрелмәде. Аллаһы тәгаләнең әмере, әтисе пәйгамбәрнең боерыгы аның өчен терәк иде.

Мөхәммәд галәйһис-сәлам кызының кулын үпте. Аннан, Галигә мөрәҗәгать итеп:

— Хатының бер олуг заттыр, кече күңелле сөекле хатындыр,— дип киявенә мәгънә бирде, кабат кызына кайтып:

— Ирең олуг ир, бер-берегезгә җәбер-җәфа кылмагыз, хөрмәтегездән бер-берегезне аермагыз,— диде, ике ярны үзара багышлап вә лаеклы күреп тәбрикләде, ихластан дога кылды һәм аларны калдырып китте. Бүлмәдән читкә атлаганда, ишек төбендә генә агасының кызы Әсмага тап булып:

— Нигә монда тукталып калдың? — дип сорады.

— Йә Рәсүлуллаһ,— диде Әсма.— Кызларның зөфаф вакытында хаҗәте була, шуны үтәү өчен торам.

Аның бу сүзләренә Мөхәммәд галәйһис-сәламнең күңеле килде һәм дә:

— Хак тәгалә синең дөньяда вә Ахирәттә хаҗәтләреңне бетерсен! — дип дога кылды.

Гали белән Фатыйма вакыйгасы менә шулай тәмам булды. Алга китеп, шуны әйтик: аларның никяхларыннан алты бала дөньяга килде: Хәсән белән Хөсәен, Зәйнәп, Өмме-Гөлсем, Ракыя, Мөхсин. Соңгысы туган вакытта Фатыйма күп кан китүдән мәңгелек йортка күченде. Пәйгамбәр вафатыннан соң алты ай үтүгә булды ул вакыйга. Аны Мәдинә шәһәрендә җирләделәр, Рәсүл Әкрамның өйрәтүенчә, озакламый каберен оныттылар, бүгенге көнгә кадәр кайда күмелгәнлеге билгеле түгелдер...

Һиҗрәттән соң мәйданга чыккан иң олуг эшләрдән Аллаһы тәгаләнең әмере белән изге сугыш, ягъни җиһад билгеле булды. Мөхәммәд саллалаһу тәгалә галәйһи вә сәлләм белдерде: «Әгәр дә кяферләр үзләренең ахмаклыклары аркасында иманга килмәсәләр вә күңелләре һаман да кара хәлендә кала икән, ул вакытта дин аларга кылыч ярдәмендә керер!» — диде. Бу сүзләре әнсари вә мөһаҗирләрнең күптән көтеп алынганлык сәбәпле, кемнәр моны ишеттеләр, алар сугышка дәртләнделәр вә билләренә хәнҗәр-кылычларын бәйләделәр. Вакыйгалар озак көттермәскә тиеш иделәр.

Билгеле булсын: ул вакытларда дәүләт мәнфәгатьләре дигән төшенчә халыклар арасында юк иде. Киресенчә, һәркем үз милкен саклап, үз ирege белән яшәүне өстен күрә иде. Пәйгамбәрнең әмереннән шул аңлашылды: мөэминнәрнең милке — ул аларның иманы, ислам дине. Кемнең күңелендә Аллаһы тәгаләгә ышаныч вә мәхәббәт бар, шулар аның әмерен үтәүне бар нәрсәдән дә өстен күрделәр. Мөһаҗирләрдән утыз кеше Мәккә кяферләренең юлын кисәргә вә аларның сәүдә сәфәрен бозарга теләк белдереп, пәйгамбәр каршысына түнделәр. Мөхәммәд галәйһис-сәлам бу гаскәрнең башына Хәмзәне куйды. Максат юлына китерде. Бу вакытта Шамнан Мәккәгә корәишләрнең сәүдә кәрваны кайтып килә иде. Мөэминнәр аларга каршы чыкты, солых таләп иттеләр вә иманга дәштеләр. Әмма кяферләр сәфәре 300 кешедән төзелгән һәм

яхшы коралланган булып, мөһаҗирләрне тиз чигенергә мәҗбүр иттеләр. Алар Мәдинә шәһәренә кире кайттылар. Икенче юлысында гаскәр башы Гобәйдәт бине Әл-Харис, пәйгамбәрнең агасының улы 60—80 кешелек яу белән кяферләргә каршы чыкты. Мөшрикләрнең көчләрен Әбу-Суфийан җитәкләде, алар 200 гаскәридән хасил иде. Әмма эш кылыч орышуга кадәр барып җитмәде. Ике як бер-берсенә каршы килеп, ук атыша башладылар. Ислам ягыннан беренче булып кулына җәясен Сәгад бине Әбу-Ваккас алды. Ул төз атучылардан иде. Садагында егерме угы булып, берсе генә дә дошманнарга тимичә калмады. Шушы маһирлыгы аркасында һәртөрле мактауларга лаек күрелде. Әмма бу очракта да аларга җиңү насыйп ителмәде, 15 көн дәвамында юлда йөреп, ахырда Мәдинәгә кайттылар.

Болар әлегә көчне сынап карау гына иде. Уен сыйфатында гына кабул күрелеп, Зөлгаширә вакыйгасы исә ирләрнең дәртен сынауда зур эш башкарды.

Әбу-Суфийанның Мәккәдән, күп кешеләрне вә сугышчыларны туплап, Шам тарафына сәүдәгә киткәнлеге билгеле булды. Мөхәммәд пәйгамбәр, моны ишетүгә, гаскәр тәртип итеп, аның җитәкчесе сыйфатында Хәмзә бине Габделмотталипны билгеләде, Әбу-Сәлимә бине Әл-Әсадин Мәдинә шәһәренә башлык урынына куйды. 15—200 ләп мөһаҗир вә әнсарны сугышка күтәреп, Мәдинәдән чыктылар вә сәүдә юлына төштеләр. Гашәрә дип аталган урынга җитеп, корәишләрне шунда көтәргә ниятләнделәр.

Гаскәрләре арыган иде. Ул арада эшнең узганлыгы, кәрванның күптән үтеп киткәнлеге беленгәч, ирләр бөтенләй эленке-салынкыга калдылар. Гали сәхабә белән бергә Гомәр бине Йасир хөрмә агачы күләгәсендә эссе кояштан качып йоклый иделәр; өстенә туфрак өелеп, аны тәмам оеткан иде. Шунда һәммәсен барлап йөрүче Мөхәммәд пәйгамбәр шушы хөрмә янына килеп чыкты һәм кияве Галинең һичбер исе китмәстән йоклап ятуын күреп, аны уятырга кирәк тапты һәм дә:

— Уян, тор, Әбу-Торап! — диде.

Бу сүзләрнең Галигә карата әйтелгәнлеген һәркем аңлады. Әбу-Торап дигәндә «туфракның атасы» дигән мәгънә булганлыктан, Гали бераз сәерсенә калды. Мөхәммәд галәйһис-сәлам аның өстен-башын туфрактан тазартты, маңгаеннан сыйпап вә җилкәләреннән кагып:

— Халыкның бәдбәхете кем, сиңа хәбәр биримме? — диде.

— Әйе! — диде Гали, һаман да сәерсенеп вә күңеле киселеп, бу сүзләрне үзенә әйтелгән дип кабул итәрәк.— Йа Рәсүлуллаһ, тыңлыйм, боерыгыз!

— Халыкның бәдбәхете ике кеше,— диде пәйгамбәр, борчылган кыяфәттә торган Галине юк-бар уйларыннан аерып.— Аларның берсе — Салих пәйгамбәрнең дөясен суючы, икенчесе — синең йөзең вә каның белән буялучы! — дип кулы белән башын-йөзен сыйпады.

Мөэминнәр бу сәфәрдән дә файда тапмадылар һәм Мәдинәгә кире кайтырга мәҗбүр булдылар, әмма күңелләрендә җиһад өчен каннары кайный, теләкләре тагын да ныгыйрак төшкән иде. Моннан соң да берничә тапкыр ирләр сугыш коралларын кулларына алдылар һәм мәккәлеләрнең кәрваннарына һөҗүмнәр ясадылар. Беренче кяфер әсирләр рәвешендә Госман бине Габдулла һәм Хәким бине Кисанны кулга алдылар. Алардан Госман бине Габдулла иман китерүдән баш тартты, шуның белән үзен үлем җәзасына хөкем итте, Хәким бине Кисан исә Рәсүлуллаһны таныды, иман китерде, шуның белән мөэминнәр хисабына кертелде вә карендәш аталды.

Мөселманнарның үз-үзләрен тотышлары һәм сәүдә юлларын һаман саен борчып торулары Мәккә кяферләрен куркуга салды, әмма алар көчнең әлегә үзләре ягында икәнлеген аңлый һәм Мәдинә белән сугышырга кирәклеген төшенә иделәр. Шулай итеп, Мөхәммәд пәйгамбәр кяферләрне үгет-нәсыйхәт белән исламга күндерү вә иманга чакыру сәясәтен

кылыч вә сугышка күчерергә мәҗбүр һәм тиеш иде. Моны әнсарилар да, мөһаҗирләр дә яклап чыктылар. Корәишләрнең һаман да исламнан йөз чөерүләре, пәйгамбәрне танырга теләмәүләре ахыр чиктә хәл ителеп, хакыйкать өскә чыгарга тиеш иде. Җиһад мәсьәләсе көч-куәт ала бирде. Әгәр дә моңа кадәр мөэминнәр эшне күндәмлек вә хөрмәт белән йөрткән булсалар, хәзер үзләренең кемлекләрен аңлап алдылар, кяферләрне акылга утыртуны кирәк таптылар. Юкса алар кайда гына йөрсәләр дә, мөселманнарны оятсыз рәвештә хурладылар, кимсеттеләр, үз якларына һәртөрле халык вә кабиләләрне авыштыра бирделәр. Менә да чик куярга вакыт иде. Боларның барысын да Җиһад, ягъни Изге сугыш хәл итәчәклеге һәрбер әнсари вә мөһаҗиргә аңлашылды. Шулай итеп, ислам тарихында олуг исем белән аталган Бәдер сугышы мәйданга чыкты. Зур бәрелеш вә көрәшләрнең башы шушыннан китте, исламның кылыч ярдәмендә җиңә башлавы да шул, Бәдер сугышы белән бәйле иде. Кемнәр үгет-нәсыйхәт илә иманга килмәде, алар кылыч куркынычы астында хакыйкатьне таптылар. Бу хәл ул вакытлардагы кешелек дөньясы өчен хас күренеш һәм ачык күренеп торган юлларның берсе иде. Әгәр дә шунда мөселманнар кылыч ярдәмендә мохтаҗ булмасалар, бәлки тарих башкачарак юлдан киткән булыр иде.

## Бәдер сугышы

Бәдер — бер коеның исеме булып, аны казыган кемсәнең ләкабенчә шулай аталып йөртелә иде. Урыны Мәккә белән Мәдинә арасында, кәрван юлларына туры килә, сәүдәгәрләр өчен ышанычлы җир иде. Бәдер сугышы шунда булды.

Әбү-Суфийан карар итте һәм Шам тарафына юлга әзерләнде. Әйттеләр үзенә, сак бул, диделәр, шәһәребездән ерак китәсең, Мөхәммәд кавемен беләсең, юлларыбызга төшә, дошманлык кыла башладылар. Сүзләрендә дөреслек бар иде. Мәккәдә кысрыкланган мөэминнәр Мәдинәдә сыенып урын таптылар, кадерле кунаклардан гына түгел, бәлки дус-карендәшкә әверелеп киттеләр. Әнсари белән мөһаҗири арасында ныклы ант вә сүзләр беркетелеп, һәрдаим эшне уртак фикер илә йөртә башладылар. Һәрхәлдә, бер «башка» буйсынмасалар һәм аның сүзен тотмасалар, болай ук бердәмлек көче хасил да итмәс иделәр, мөнафикълар өчен дә җиңелрәк яшәү мөмкинлеге югалмас иде. Корәишләргә тегеннән дә, моннан да сүзләр килеп торганлыктан, белә иделәр, аңлый иделәр: Мөхәммәд кавемен кылыч аша үткәрергә кирәк. Тик сылтаусәбәп кенә күренмәде. Мөнафикъларның атаклысы, калку гәүдәле, йөзгәбиткә камил сызыкларга ия Әбү-Суфийан, шулай итеп, бу уйлар эчендә кәрванын сәфәргә әзерләде. Шактый гына иптәшләрен ияртеп, алдан шымчы вә сакчыларын куалап, шактый гына мал-туар белән Мәккәдән чыкты, Гамру бине Әл-Гас та монда иде.

Бу хакта хәбәр Рәсүл Әкрамга килеп ирешүгә, мөһаҗирләрдән бер гаскәр туплап, Зөл-Гашир дигән урынга барырга вә кәрван белән очрашып, Мәккәдә мөэминнәр калдырырга мәҗбүр булган малларны кайтарып бирү таләбен куярга боерды. Илчеләр соңардылар. Бу ара вакыт эчендә Әбү-Суфийан кәрванны Шам тарафына алып китәргә өлгергән, Зөл-Гаширне күптән узган иде. Мөһаҗирләр боерыкны үти алмауларыннан оят вә гарьлек йомгагына бөгырьләрен төйнәп кайттылар, гүяки пәйгамбәрнең олуг сүзен бозганнар да, шул сәбәптән бу хәлгә төшкән иделәр.

Әмма Мөхәммәд галәйһис-сәлам орылып бәрелмәде. Аңа илчеләкне түгел, бәлки сугыш өчен гаскәр күндерергә кирәк иде, чөнки үгет вә нәсыйхәт, өндәү вә юмалау, акыл бирү вә аңлату Мәккә мөнафикълары өчен күптән яраксыз, көч вә кылычка сүз бирергә вакыт иде. «Кяферге

мәгънә белән иман мөмкин түгел, мәгәре кылыч һәм гаскәр ярдәмендә тиешле булыр!—дип фикер йөртте Рәсүл Әкрам.—«Моның өчен аларның мал вә табышына комачау итәргә кирәк!»

Вакыт чылбыры тормыш тәгәрмәчләрен әйләндерде дә әйләндерде. Рәсүл Әкрам, иртәме-соңмы, шушы фикеренә килергә тиеш. Аллаһы тәгаләнең әмеренә буйсынырга мәҗбүр вә шуның белән мактауга лаек иде. Мөэминнәрдән рух ныклыгын гамәл аркылы дәлилләү таләп ителде. Бу эш сугышка сусау түгел, бәлки кяферләрнең ислам динендәгеләрне һәрдаим җәберләвенә җавап вә хакыйкать, дөрес дин икәнлеген тануташыту өчен мәйданга чыгып, ирлекне сынау иде.

Мөхәммәд пәйгамбәр дин өчен батырлык үрнәкләрен күрсәтеп көрәшергә әзер торган Талиха бине Габдулла һәм Сәгад бине Зәйд кебек мөселманнарга үз фикерен белдерде. Пәйгамбәрдән шушы сүзләрне ишетүгә, алар моңа куандылар. Әбу-Суфийан кәрванының йөрешен алдан ук белешеп хәбәр кылу өчен шам тарафына юл алырга вә шымчылык кыларга кирәклеген таләп итеп, үзләре моңа әзер икәнлекләрен белдерделәр. Мөхәммәд галәйһис-сәлам ризалыгын бирде.

Болар китүгә, ул көн шимбә кичәсе Рамазан шәрифнең икеләре иде, ун көн үтеп, уникеләре ирешүгә, Гамру бине Өмме-Гөлсемне Мәдинә шәһәренә хуҗа-әмир итеп калдырып, ягъни гарәп сүзенчә атаганда, хәлифә итеп сайлап, 365 җәмгысы булган мөселман, шуларның 80 не мөһаҗирдән, калганнары әнсарилар, сугышка күтәрелеп, гозерләре аркасында һәм башка сәбәпләр белән 52 се кире кайтарылып, 313 мөэмин Бәдер тарафына таба юл алдылар.

Талиха белән Сәгад, Мәдинәдән чыккач, шактый юллар үтеп, Мәккә кәрваны тукталып узарга мөмкин булган Хура җире Җәббап дип аталган урынга ирештеләр, халык арасына кереп, корәишләрнең сәфәрләре хакында белештеләр. Үзләренең кайдан вә ни эш белән килгәнлекләрен сиздермәстән, максатларына җитеп, яңадан көн-төн Мәдинә тарафына туктаусыз кайттылар. Әмма пәйгамбәр мөэминнәрне шәһәрдән алып чыккан иде инде. Талиха белән Сәгад ялга да туктап тормыйча, ислам гаскәре артыннан юл алдылар. Рәсүл Әкрамга аларның хәбәре кирәк иде, шунлыктан ашыгуны мәслихәт күрделәр.

Мөхәммәд галәйһис-сәлам һәрдаим халыкның хәлен белешеп торды, арада авырулар була калса, аларны кире Мәдинәгә күндерде. Өлкән яшьтәгеләрне вә буыннары ныгып җитмәгән үсмерләрнең барлыгын-юклыгын тикшерде.

Гаскәр Мәдинә шәһәреннән кузгалып киткәндә Мөхәммәд галәйһи вә сәлләм янына Гали Әл-Мортаза һәм Әбу-Либаба килделәр. Аларның горурлыгы вә сөенече йөзләренә чыккан иде. Әйттеләр:

— Йа Рәсүлуллаһ, без синең янәшәңдә җирдән генә барса идек?

Ислам гаскәрендә 70 дөя һәм 2—3 ат кына бар иде. Пәйгамбәр һәр дөягә ике-өч кешене утыртты. Әбу-Либаба белән Гали җәяү барырга да риза иделәр, бары тик Мөхәммәд галәйһис-сәлам ялгызы ияр өстендә утырсын! Әмма Рәсүл Әкрам каршы төште:

— Сез миннән өстенрәк түгел һәм мин әҗердә сездән өстенрәк түгел!

Моннан шул аңлашылды: алар барсы да ислам дине өчен җаннарын бирергә кызганмаучы кешеләр иделәр, шунлыктан бөтенесе тигез күрелде, арада өстеннәр вә түбәннәр юк, бары тик куркаклар вә батырлар гына булырга мөмкин иде.

Шулай итеп, Мөхәммәд пәйгамбәр, Гали бине Әбу-Талип һәм Әбу-Либаба бергә утырып бардылар. Аннан соң Әбу-Либаба урынына Зәйд ибне Харис менде. Барысы да тигез күрелделәр. Әбу-Либаба исә Мәдинә шәһәренә әнсариларның хәлифе итеп кире кайтарылды.

Ислам гаскәре Әбу-Гукбә коесына җитеп, Мөхәммәд пәйгамбәр шунда тукталуны мәслихәт күрде. Чатырлар кордырып, һәммәсенә ял бирелде. Рәсүл әкрам һаман-һаман гаскәрен барлап, тәртипкә кертә

торды, арада олы вә кече яшьтәгеләрне белешеп, аларга кире Мәдинәгә кайтырга боерды. Шулай итеп, нибарысы 305 сугышчы калдылар, шуларның сигезе генә кылыч белән коралланган, башкаларында ук-җәя, очланган таяк-сөңге, пычак-хәнҗәр кебек һәртөрле кораллар сугыш өчен тәгаен кылынган иде. Гаскәрен йөреп-тикшереп һәм дә тәртипкә салып чыккач, Рәсүл Әкрамның күңеле бераз тынычлана төште һәм үз чатырына кайтып догага утырды.

Бәдергә килепирешкәч, тагын да ике кешене кәрван хакында хәбәрләр белешергә җибәрделәр. Аларның берсе — Гадийә бине Әбуз-Загыйбә Җәһини, икенчесе Бәсбәс бине Җәһини иделәр. Сәүдә юлына урнашкан бер кабилә арасына кереп йөрделәр. Шунда ике жариянең әңгәмәсенә колак салдылар. Болар кәрван хакында сөйләшә иделәр. Аларның берсе:

— Берничә көннән монда кәрван киләчәк, Шамнан Мәккәгә ашлык китерәләр. Алар белән безнең дә хуҗаларыбыз кайтыр,— дип, икенчесенә зарланды.

Моны ишетүгә, ике хәбәрче уртак фикергә килеп, тиз ара Мөхәммәднең үзенә хәлне сөйләп бирергә кирәклеген төшенделәр һәм Бәдергә ашыктылар. Алардан соң бу кабиләгә Әбу-Суфийан кәрван китерде. Халык каршында дәрәҗә тоткан Галийә бине Гамрудән хәлләрне сораштыра башлады һәм:

— Мөхәммәд шымчыларының килеп киткәнлеге, белешкәләп йөргәнлекләре хакында берәр нәрсә белмисеңме? — дип үтенде, билгеле, ул сак эш йөртә белә иде.

— Юк! — дип җавап бирде Гадийә бине Гамру.— Әмма дә ләкин монда ике кеше килеп, бераз торып киткән иделәр. Кемнәр икәнлеге белән кызыксынмадык.

Әбу-Суфийан аларның кайда тукталганлыкларын сораштыра башлады һәм, белешеп, аларның дөяләре торган урынны карарга китте. Күптән киткән булсалар да, аны-моны караштырып, дөя тизәкләре янында хөрмә җимешләренең төшләрен тапты һәм шунда ук серне төшенеп тә алды: болар Мәдинә кешеләре, Мөхәммәднең шымчылары икәнлеген аңлады, хәвеф уты күңеленә капты, кәефе кырылды. Димәк, аның һәр адымын күзәтеп тә белеп торалар икән. Гәрчә сәүдә юлыннан борылу файда бирмәсә дә, аларның кулына барып керүдә дә мәгънә юк. Әбу-Суфийан кәрванны турыдан куып, Бәдернең сул ягыннан узарга, дәрья тирәләп Мәккәгә кайтырга ниятләнде. Бу рәвешле хәрәкәт итсәләр, Мөхәммәд гаскәреннән имин котылырга мөмкин иде. Ничек тә Мәккәгә кайтып җитәргә һәм халыкка хәбәр салырга кирәктер, ярдәм таләп итмичә дә булмас. Ташламаслар, килми калмаслар.

Мәккә эче әле хәвефтә, әле гайбәттә, әле бәйрәмдә иде. Мөхәммәд гаскәре хакында күчмә гарәпләр тиз ара хәбәр йөртә-йөртә, аларга алдан белдереп куйган, җаннарына ут салган иделәр. Күпләрнең теләге — сугыш, мөэминнәрне канга батыру булганлыктан, Әбу-Җәһил аларны яуга күтәрергә әзер торды. Әмма шәһәр эченә Гатикә бинте Габделмотталиптан бер хәбәр таралды. Ул төш күргән иде. Аны карендәше Габбаска сөйләде.

— Мәккәгә бәла килер,— диде.— Төшемдә бер дөя һәм җитмеш кеше күрдем. Көтмәгәндә кайдандыр аваз ишетелде, өч тапкыр кычкырды: «И корәиш, һәлакәт җиренә төштең!» — дип. Аннан соң Хәрам мәсҗеденә килде. Артыннан барча халыклар иярде. Кәгъбәгә чыгып, элеккечә тагын өч тапкыр кычкырды. Аннан Әбу-Кабис тавына күтәрелде, кабат аваз бирде. Корәишнең мәетләре аның артыннан килә иделәр, шул юл белән китеп бардылар. Теге тавышның өченче тапкыр кычкыруында таудан таш тәгәрәп төшеп, чәрдәкләнеп чәчрәде һәм һәр кисәге Мәккәдәге өйләрнең берсе өстенә төште, бары тик Бәни-Һашим һәм Бәни-Зөһрә йортларына гына тимәде, алар исән калдылар, ватылмадылар... Бу олуг хәвеф вә бәла билгеседер.

Боларны ишеткәч, Габбас борчуга калды. Яхшы танышы саналган, эч серләрен уртаклашучы дусты Вәлид бине Гутбәт бине Рабгага Гатикә бинте Габделмотталипның төшен сөйләде, әмма кисәтеп тә куярга кирәк тапты:

— Кешегә белдермә, юкса әллә нинди уйдырмалар чыгарырлар, халыкны beләсең бит!

Тик Вәлид сүзне теш арасында тота алмады, тулысынча бәйнә-бәйнә итеп атасына хәбәр итте. Максаты да начарлыкта түгел, бәлки кисәтү уе белән генә иде. Әмма сүз шул көндә үк Мәккә шәһәрендәге барча олуг вә кечеккә таралып өлгерде. Яхшыдан әйтелгән булса, озак йөрер, күпләр ишетми дә калыр иде, яманнан телгә алынганлыктан шулай бер колак-тан-колакка күчә-күчә, тарала бирде. Әйтерләр, күркәм сүз атлый бир-гәндә, яманы чабып узар.

Гатикәнең төше Әбу-Җәһил колагына да барып керде, аның ачуын кузгатты. Иртәнге якта Габбас ялгызы Кәгъбәне тәваф кыла иде. Хәве-фле сүзләрне телләреннән төшерә алмыйча газапланган кяферләр, аны күреп, бер-бер хәл булачагына игътибар юнәлттеләр. Араларыннан чы-гып баскан Әбу-Җәһил шунда Габбасның каршысына килде һәм болай да чытык йөзен тагын да җыерып:

— Йә Әбел-Фазыл, кайсы вакыттан бирле ул гаурәт-хатын пәйгам-бәрлек кыла башлады? — дип ачулы сүз ташлады.

— Нинди гаурәт? — диде аптыраган һәм бераз артка чигенү җаен караган Габбас, аңламамышка салышып.

— Кыз карендәшең Гатикә шундый да бер төш күргән икән!

— Минем ул төштән хәбәрем юк,— дип котылмакчы булган иде дә, Әбе-Җәһил көләргә тотынды. Габбасның курка калуы аңа бик ошады, форсаттан файдалану җаен ычкындырырга теләмәде. Ни дисәң дә, Мө-хәммәд пәйгамбәрнең карендәш-туганнарыннан бит, Габделмотталип нәселеннән.

— Ирләрегезне пәйгамбәрлек дәгъвасыннан азат итмәдегез, инде гаурәтләрегез башладымы? Сездән булмаса, үзебез эшләрбез. Аны гына акылга утырту җае табылыр. Өч көн сабыр итәрбез,— дип белдерде Әбу-Җәһил, көлгән җиреннән кабат кырыслана төшеп.— Әгәр дә сүзе дөрескә чыкмаса, хатлар язып, кабилә гарәпләренә күндерербез: «Халык эчендә һашим нәселе ялганчылар!» — дип. Юлыгыз киселер, гомерегез өзелер, бәхетегез качар!

— Ялган сүз үчен бездән алырсыңмы! — диде Габбас, Әбу-Җәһилгә ачуы килеп. Бу дошманлыклар олуг җәбберләр чыгарга мөмкин иде.

Кичке якта Габделмотталип нәселеннән барча хатыннар, җыелы-шып, киңәш-табыш кордылар һәм ачык бер фикергә килделәр:

— Бу Әбу-Җәһил безнең ирләребезне кимсетте, һичкем каршы чык-мады, инде безләргә дә тыкшына башлады,— диделәр һәм дә үз ир-ләренә карап: — Гайрәтегез юкмы әллә сезнең! — дип йөзләренә оят кы-зыллыгы ямадылар.

Шунда гына Габбас:

— Тагын да тел озайта калса, һич куркып тормамын, үзен инкарь итәрмен! Юкса бик дөрес кеше кебек кылана,— дип кисте, әмма шушы сүзеннән соң, төне буена күзенә йокы кермәде, аклы-каралы уйлар челтә-рендә акылы чебен хисабында бәргәләнде, күңелендәге рәнҗү әле кайнар-лык, әле түзем белән алышынды, ник әйттем, дигән фикергә килмәде.

Иртәнге якта гадәт буенча тагын Мәккә урамыннан туры Кәгъбәгә юнәлде, тәваф кыла башлады, шунда эчке яктан күзәтеп торган Әбу-Җәһилне күреп алды, аның ягына борылып, каршы килде.

Теге дә эчтән тышка таба чыкты. Төнге уйлары аны бер-бер нияткә китергәнлектән, хәзер ни дә буласы иде. Габбас кинәттән Әбу-Җәһилгә авыр итеп дәште. Әмма тегесенең йөзендәге кичәге мәсхәрә вә миһербан-сызлык чаткылары сүнгән иде инде. Сәбәбе — ул шушы иртәдә генә Зәмзәм Гаффари хәбәрен ишеткән, шунлыктан тыела калган иде...

Бу зат сәүдә белән Мәккәгә кайтып төшәр көненең алдыннан гына кичке йокысында төш күрде. Башта аны-моны аңламады. Кызыллык иңгәндәй иде, әмма кан икән. Мәккә эче кан тулып, харап икән, имештер. Зәмзәм Гаффари йокысыннан уянуга, үзеннән-үзе куркыбрак торды. Бик начар шул тәгъбире, бигрәк начар. Ничек хәвеф йотмыйсың, ди, шәһәргә бәла киләсе икән бит!

Мәккәгә ирешүе булды, бу төшеннән хәбәрне Зәмзәм Гаффари тиз ара таныш-белешләренә сөйләп, хәлләрен сораштырырга тотынды. Мөселманнарга каршы кутәрелмәскә өндәргә җөрьәт итмәде, юкса үзен дә Мөхәммәд пәйгамбәр ягына күчкән дип таныячаклар, харап та итеп ташларга мөмкиннәр.

Бу иртәдә Гаффариның хәбәре Әбу-Җәһилгә килеп ирешә. Ул уйлана калды һәм Гатикәнең төшенә кергән хәлләрдә дә хикмәт юк түгелдер дигән фикергә килде, шунлыктан тәүваф кылучы Габбаска миһербанлык вә яхшылык белән елмайды, йокысыз төннән соң тупасланган ирнең йөзеннән үпкәләү вә кимсенү сызыкларын шулай сөртеп ташлагандай итте. Әмма бу елмаюында хәйлә дә юк түгел иде. Төшне бит аны юрый белсәң генә юрау, юрый белмәсәң — каза! Ә бәлки якшыгадыр? Мөхәммәд кавеме җиңеләчәк, Мәккә халкы өстен чыгачак. Көч кемнең ягында? Әбу-Җәһилгә иярүчеләрдә. Аларның берсенә каршы Мәккәнең унбиш ире күтәреләчәк, кабиләләр ярдәмгә киләчәк. Яңа дин уйлап чыгарып, Аллаһы тәгалә исеменнән сөйләнгәләп йөрү генә әле бер нәрсә дә түгел ул. Аның бер Алласына каршы минем егерме аллам бар! — Әбу-Җәһил шулай уйлады, күңелен вә фикерләрен өмет вә сафсата ныгытты. Мәккәме инде җиңелә торган шәһәр?

Гатикәнең хәбәрен дөрескә чыгарып, аңардан көлүне туктатырга теләгән Әбу-Җәһилнең уенда олырак мәсьәлә дә бар иде: әгәр дә сүз озынга сузылса, һашим кабиләсе, бигрәк тә Габделмотталип балалары аның үзенә үпкәләп, Мөхәммәд пәйгамбәргә каршы сугышка бармаслар, кәрванны бәладән йолып калырга булышмаслар бит! Һәм, чыннан да, эшләр шулайрак юл алырга тора төсле иде. Башында акылы, маңгаенда күзе булмаган кеше генә моны аңламас. Юк, бу сөйләнгәләп йөрүләре кан карендәшләре Мөхәммәдне җәберләүдән курку түгелме соң? Теге вакытларда, үзләрен мөселман дип атаган кавемгә бойкот игълан иткәч тә, ничек яклап чыктылар үзләрен! Әгәр дә һашим кабиләсе пәйгамбәр ягына ауса, Мәккә бушап калачак. Юк-юк, бу эшкә бер дә юл куймаска, һәрдаим диярлек бабалардан балаларга күчеп килгән диннәрен исләренә төшереп, ул вакытларда ни рәвешле итеп яшәүләрен хәтергә алгаларга кирәк булыр!

Әбу-Җәһил кара уйга, яман хәйләгә бик оста кешеләрнең берсе булып, тарихны һәм гореф-гадәтне саклау вә яклау ягында торса да, ни хикмәт, килер көннәрнең нинди һәм ни рәвешле барачагын күз алдына китерә алмый, киләчәктән пәрдә белән аерылган, бәхет күзе сукырайганнардан берсе иде. Шулай да ул арада иң мөхтәрәм мәҗүсиләрдән исәпләнеп, әйткән сүзе җиргә салынып тапталмый иде. Ничек шул Мөхәммәдкә игътибар күзе җитмәгән дә, шушы Ислам коткысыннан Мәккәне саклап кала алмаган соң ул? Кем уйлаган ул ятимнең бу рәвешле хикмәт иясе кемсәнә булып, күпләрне, хәтта ни ерактагы Мәдинә халкын үзенә ияртә алыр дип? Менә бит тормыш, менә бит дөньялар! Көне төнгә ялганып өлгерми, үзгәрә дә куя! Юк, бозылды халык, тәмам азынды. Артыннан иярүчеләре күренмәсә, Мөхәммәд тә эш майтара алмас иде. Акылга утыртырга иде үзләрен. Һай җае килеп чыкса, күрсәтер иде Аллаларының кем икәнен! Әллә Алласыныңмы? Бер һәм кодрәт иясе, имеш? Кайда һәм кайчан күрелгән ул? Кәгъбә эчендәге туксан тугыз пот-алиһәме, әллә инде ялгыз Алламы көчле? Юк инде! Бер тиен акчадан ун тиен зуррак!

— Ә алтын булса ул бер акчаң?

Әбу-Җәһил сискәнеп китте. Юк, аңа һичкем эндәшмәде. Аны уйланган уе, күңеленең кинәт ачылып алуы сискәндерде.

Кояш үз эшен башкарды, Мәккәнең түбәсе кызып, адәмнәре күләгәле урыннарны сайладылар. Әбу-Җәһилнең уйлар тезмәсе бәгырен сытты. Җаны кайнарланды, ачуы килде.

Халык Әбу-Җәһил тирәсенәрәк җыела, шаулаша башладылар. Мөхәммәд пәйгамбәрнең аеруча зур дошманнарыннан һәм аның белән тарткалашучыларның иң дә алусызы, Мәккәнең көферлек башы бит ул. Әбу-Җәһил сүз дилбегәсен үз кулына алырга өлгергәнче, кабиләләрнең өлкәннәреннән берничәсе юлдагы кәрванны саклау өчен яуга җыенырга кирәклеген дәлилләп тә өлгерде.

Шулай да Габделмотталип кызы Гатикәнең һәм Зәмзәм Гаффариның төшләреннән алынган хәбәрләр аларның күңелләрен какшатмый калмый иде. Ничек тә аларны рухландырырга, юрауларының ялган икәнлеген расларга кирәк.

Халык каршына Әбу-Җәһил күтәрелде:

— И мөхтәрәм җәмәгать...— сүзенең куәте югалып калды. Әмма гәп коручылар аңа колак салмый калмады. Бу исә Әбу-Җәһилне гайрәтләндереп җибәрде. Күптән башын катырган мәсьәләгә җавап тапкандай, күңеленә килгән нечкә генә фикер җебенең очына ябышып, йомгагын акрынлап сүтә башлады. Сөйли торгач, акылы ачылып киткәндәй булды, күзләрендә кайнар очкын, йөзендә елмаю балкыды.

— Җәмәгать! — Бу юлысы тавышы да көр, йодрыгы да алга чөелгән иде.— Җәмәгать! Ник әле сез буш сүзләргә колак салып торасыз, ә?! Мин әйтәм! Мин сезгә әйтәм: әгәр дә без кәрванны бәладән коткарырга күтәрелмәсәк, гаскәр белән сакка бармасак, чыннан да, һәммәбез дә байлыкларыбыздан колак кагарбыз. Балаларыбызның ризыгын алар тартып алыр...

«Алар» сүзенә шактый басым ясап, Мөхәммәд пәйгамбәр тарафдарлары хакында белдергәнен аерып күрсәтүе файдага китте. Балаларын һәм малларын да исләренә төшерү йөрәкләрен үк кузгаттымы, шаулашып та алдылар. Арадан берничәсе:

— Дөрес әйтә! Хактан да шулай! — диешеп куйдылар.

Сүз айгыры тезгенне өзде. Инде дә Әбу-Җәһил чыбыркы шартлаткандай өстәп җибәрде:

— Һәммәбез бәлаләнәчәк! Кәрваныбызны таласалар, кешеләребезне үтерсәләр, бетте бит, җәмәгать, бетте! Менә нәрсә хакында уйларга кирәк. Кая арагызда гайрәтле ирләр? Нигә әле хатыннар кебек тел чайкап, баш белән уйламыйсыз? Мөхәммәдкә иярүчеләргә угрылыктан бүтән эш калмаганлыгын алдан ук әйтеп куйган идем бит! Без моңа юл куярга тиеш түгелбез! Менә төшне ничек юрарга кирәк! Аң булыйк, җәмәгать.

Кем дә кем, әмма Әбу-Җәһил авызда телне тота, телдә сүзне йөртә белә иде. Ни әйтсә, шул булып бара түгелме соң?

Аның сүзләрен Сөһәйл бине Гамру, Рабигат бине Әл-Әсвад нәселе күтәреп алды. Алар да, Әбу-Җәһилне кабатлый-кабатлый, һәммә кабиләләрне Мөхәммәдкә каршы сугышка чакырырга тотындылар. Болай уңай барып чыгачагына әллә ни ышанычы булмыйча сүз башлаган иде, менә бит, Әбу-Җәһилдән дә дөресе арада табылмады. Һәммәсе, коралланып, кәрванны каршы алырга һәм ярдәмгә барырга карар бирделәр. Һәр йорттан икешәр кешене чакыртып, тәмам сугышчан халәттә килергә куштылар. Әгәр дә ниятләре барып чыкса, гаскәр шактый гайрәтле һәм зур булырга тиеш иде.

Әмма Әбу-Ләһәп каршы төште. Бу кәрванда аның малы юк, шунлыктан ул хәсрәттән азат, килеп чыккан тавышка битараф иде.

Халык моңа аптырабрак калды. Моңа кадәр Мөхәммәдкә каршы һәртөрле усаллыктан баш тартмаган иде бит, ничек болай? Аның карышуын аңларга да, белергә дә теләмәделәр һәм:

— Син кавемеңә үзең хуҗа, нәселдә өлкәне дип үзеңне таныйлар, без дә шулай ук сине өстен күрәбез. Син кавемнең юлбашчысы, әгәр дә

безнең белән бармасаң, халык бүтән кешегә буйсынмас. Йә үзең яу башы бул, яки арадан берәүне билгелә,— диделәр.

Бу сүзләргә дә туры җавабын бирмәгәч, аның хакында икенче төрле сүзләр кузгалды. Имеш, ул, мөселманнар ягына чыккан да, Мөхәммәд пәйгамбәрнең яшерен кешесе икән...

Әбу-Ләһәп монсын ук көтмәгәнлектән, чарасыз калды. Ә сүз кеше үтерә. Әгәр дә бер ышанычларын югалтса, кайчан кайтарыр? Башкалардан кушылудан бүтән чара калмады...

Сугыш алдыннан корәиш халкы, яуга барыргамы-юкмы икәнен белү өчен, үз гадәтләренчә фал ача һәм шобага тарта торган иделәр. Бу юлысы да шулай эшләделәр. Йола буенча, бер укны сындырып, башкалары белән буташтырдылар да, потлары исеменнән сүзләр әйтеп, арадан тартып алдылар. Сынган ук «яуга бармаска!» дигәнне аңлата иде. Шунысы чыкты. Әмма Әбу-Җәһил монын белән килешергә теләмәде. Мөхәммәдне акылга утыртырга бик тә омтыла һәм үзләренең өстен чыгачагына тәмам ышана иде.

— Юк, болай булмый! — дип тагын укларны буташтырдылар һәм арадан берсен тартып алдылар. Икенче юлы да сыныгы чыкты.

Әбу-Җәһил кабат карышты һәм, кистереп:

— Мин мондый ахмак һәм һичбер нигезсез юрауларга ышанмыйм, дөрес түгел ул. Шобагада булдымы хаклык? — дигәч, халык аның белән тагын килеште.

Мәккәлеләргә яуга бару өчен әзерләнү вакыты бирелде.

Шәһәрдән күтәрелеп чыктылар. Сугышчыларга аш-су хәстәрен күрү һәм ризык пешерү өчен хатыннарын да алдылар. Гаскәрнең үзендә генә дә 950 кеше булып, күпчелеге яхшы сугыш киеменнән иде. Алар 700 дөягә, 100 атка йөкләнделәр. Арага шагыйрьләрне дә кертеп, алар шигырь сөйләргә һәм сугышчыларны җиңүгә дәртләндерергә тиеш иделәр. Һәр кабиләдән гайрәтле һәм сугыш уенын яхшы белгән кешеләрне сайлап, тугыз юлбашчы куйдылар, һәркайсына ярдәм хәрәкәт итәргә боерылды. Пешекче хатыннар һәркөнне ризык әзерләп, һәркемне тукландырып тордылар. Барсы да баштанаяк уйланылган һәм җиңү өчен дип эшләнелгән иде.

Шушы кадәр зур яуның күптән бу тирәләрдә күрелгәне юклыктан, боларны күреп калган бәдәви гарәпләр арасында соклану сүзләре таралырга өлгерде. Арадан кайбер кабиләләр шушы гаскәргә кушылырга теләк тә белдерделәр. Әмма Мәккә халкы болар белән җиңүне бүлешергә теләмичә, үзләре генә хәрәкәт итеп, алга баруларында булдылар.

Әмма барысы да алай ук яхшы гына түгел иде. Тагын Зәмзәм Гаффари төш күрде. Монысы аеруча гаҗәбрәк иде. Имеш, Әбу-Җәһил, мәшәкатьләнеп, дөя бугазларга җыенган икән. Менә ул малны егып сала. Бугазына пычагын китерә, чалып җибәрүенә, дөя сикереп тә тора, һәммә җирне һәм Әбу-Җәһилнең үзен дә канга батырып, юкка да чыга...

Шушы төшеннән соң, куркынып уянган Зәмзәм Гаффари аны юрап та куйды: Әбу-Җәһил үзенең һәлакәтен эзли, аңа ияргән халык та харап булачак! Бу аңа бүтәннәр арасында коткы салырга җитә калды. Ни дисәң дә, икенче тапкыр керә бит төшенә. Әгәр дә эшләре юньлегә булса, шушы рәвешле итеп күрмәс тә иде. Язмышны ике тапкыр сынамаган төсле, монда да шаярырга ярамый...

Гаскәр арасына кереп, Әбу-Җәһил һәм башкаларга:

— Мөхәммәд хактан да Аллаһы тәгаләнең пәйгамбәре, бу сугыш барыбызга да һәлакәт кенә китерер, бәласеннән котыла алмабыз, бармагыз! — дип үтенде Зәмзәм Гаффари.

Мондый да дәрәҗә иясенең курка калуы, әлбәттә, берсенә дә ошамады. Ни өчен соң әле ул гына шулай күрә дә килешмәгәнчә юрап аптырата? Кәрван малын Мөхәммәд кулына тапшырсыннар мыни?

Зәмзәм Гаффариның сүзләрен ишеткән һәм шуннан күңелләре кузгалган мөнафик мәккәлеләр хәвефкә төштеләр. Иртәгә кемне нәрсә

көтәсен белмәгәнлектән, аларның моңа хаклары бар иде. Боларның болай үзгәреп китүләрен күреп алган Әбу-Җәһил тиз арада башын эшләтеп өлгерде. Җыелган гаскәриләрне күзе белән айкап, чөйне чөй белән бәреп чыгарырга кирәк, дигән гыйбарәне аңлаганга, йөрәкләренә курку салырга уйлады. Карашларына туры килгән гарәпләрнең кайсы арткарак чигенде, кайсысы күзләрен яшерү өчен башын түбән иярга ашыкты. Әбу-Җәһил, үзенең уңышына сөенеп, тиз ара халәтен үзгәртте, көтелмәгән яктан кайтарып:

— Җәмәгать, бу бәндә сырхауланган, авырудыр! — дип авызын ерды.

Аңа барысы да кушылырга мәҗбүр иделәр. «Әбу-Җәһил, шушы сүзләреннән соң, Зәмзәм Гаффарины читкәрәк этәрде. Алар берсен-берсе аңламадылар. Зәмзәм Гаффари моңа үпкәләде, әмма Әбу-Җәһил аны башкалардан аерып сөйләшергә теләде. Инде аралары ераклашкан, тиз генә аңлашмаячаклар иде.

Әбу-Җәһил үзе оештырган яуны күздән кичерде. Юк, ялгыша Зәмзәм Гаффари, юри котырта! Боларны хәзер һичкем җиңә алмас. Баштан-аяк коралланган, гайрәтле егетләрдән генә диярлек торган бу гаскәриләрнең башында кемнәр тора соң? Нәсел-кабилә җитәкчеләре, илнең мөхтәрәм затлары түгелме? Пәйгамбәр атасының энесе Габбас бине Габделмотталип монда, Гатибәт бине Габигат, Өммийаһ бине Хәләф, Хәким бине Хизам, Назыйр бине Әл-Харис, Сөһәм бине Һишам, Хиҗаҗ, уллары Нәбия белән Мөнбия һәм үзе — Әбу-Җәһил. Барысы тугыз ир, яу күргән, сугыш уенын оештыра белә торган баһадир йөрәкле адәмнәр! Шушы тугыз гаскәр башына таянганда әллә нәрсәләр майтарырга, җирен-иен әйләндереп ташларга мөмкин түгелме?

Сугышчылар Әбу-Җәһилнең теләгенә буйсындылар. Әмма көннәрдән беркөнне алар арасында тагын иске сүз яңарып китте. Ялга тукталган вакытларында Шәйбә белән Гутбә, билгесезлек каршысында курка калыпмы, Гатикәнең төшен исләренә алдылар. Аларның гәпләре башкаларның да колагына керде. Ни дисәң дә, Гатикә Мәккәнең изгеләреннән, һаман да макталып телгә алына торган затлылар нәселеннән, Габделмотталип баласы иде. Ә моның белән исәпләшмичә ярамый. Әллә күпләргә Әбу-Җәһилнең ул төшкә үзенчә фал ачканлыгы билгеле булмау, әллә инде аның белән исәпләшмәү дә бар идеме, яуның кабат рухы сынды. Гүя үзләрен якларлар дигән уй белән гаскәриләр Шәйбә белән Гутбә тирәсенәрәк елыштылар. Ни бар сүзгә колак салып, эшнең ахыры хакында уйландылар.

Аларның болай җыелып торганлыгын күреп алган елгыр Әбу-Җәһил җәһәт кенә араларына килеп керде дә:

— Ни сөйләшәсез? — дип йөрәкләренә шом салды.

Көтелмәгән бу хәлдән гаскәриләр югалып калды. Баштарак сүзне нәрсәдән башларга да белмәделәр, әмма, яуга баруны туктату һәм Мәккәгә кире кайту кирәклеген төшендереп, гапләренең асылын ачып салдылар. Алар аңлатып бетергәч, Әбу-Җәһил, җикеренеп:

— Исләрем-акылларым китә,— дип кайнап чыкты.— Габделмотталип улларыннан пәйгамбәрлекне кабул итмәдегез, Мөхәммәдне Мәккәдән чыгардыгыз, анысы ошамадымы? Инде хәзер кызлары-хатыннары пәйгамбәрлек кыла башлады, шул акылсыз башка колак саласызмы? Мәккәгә генә кайтыйк, аңа үзем җәза бирәчәкмен!

«Җәза» сүзе гаскәриләргә җитә калды. Гатикәгә карата әйтелгән ул хөкем камчы очы төсле барысына да тиеп узгандай булды.

Шәйбә белән Гутбә артыграк шөлләгән иделәрме, шундук үзләренә җай карый башладылар һәм:

— Йә, Әбу-Җәһил, килештек... Гатикәгә җәза тиешледер. Хәзер үк кузгалып, Мәккәгә кайтып, аңа хөкем карарын йөртик. Җәза бирик. Каршы килмәсәгез, әмерегез кичектерелмичә үтәлер,— диделәр. Исәпләре тизрәк бу баладан котылу һәм гаиләләре янына кире кайтып керү иде.

Әмма Әбу-Җәһил аларның хәйләсен тиз төшенеп алды. Ачуы килсә дә, бу урында каты бәрелүне кирәк тапмады.

— Хөкемемне бүген үтәргә әзер булуыгыз өчен мактармын, анысы. Ләкин дә бит шунысы бар: сез үз кавемегезнең өлкәннәре, сез торсагыз, алар торыр, сез йөрсәгез, алар йөрер, сез китсәгез, алар сезне эзләр. Юк, алай ярамас. Мәккәгә кайткач та, житешербез, беркая да качмас. Монда калыгыз!

Аның болай йомшарып китүе Шәйбә белән Гутбәнең телләрен кабат ачты. Алар:

— Син барчабызны һәлакәткә алып барасың. Мөхәммәд ягында синең кемең бар? Безнең карендәшләребез аның белән! Ничек итеп аларга кул күтәрик тә, туганнарыбызны, балаларыбызны кылыч белән орыйк ди? Андый эш кулыбыздан килми,— диделәр.

— Минем ахмак улым Әбу-Хөзәйфә дә Мөхәммәд янында бит. Ни сөйлисез? Ул мине сатты, динемне, бабаларын сатты... Баскан җиремдә түнеп китим, мин аны да акылга утыртырмын! — дип, Әбу-Җәһил кызып китте. Әле яңа гына тынычланган йөрәге, улын исенә төшерүдән һәм гаскәренең бозыла башлавыннан, шашынып дәрәҗәгә җитте. Барысы берьюлы килеп тыгылган хис вә тойгылар теш кысу белән генә басылыр хәлдә түгел иде. Авызлыкны тартып торган дилбегәнең бушый төшүеннән форсатны файдаланып калырга теләгән сугышчылар:

— Син түнеп китсәң китәрсең, әмма без күрә торып һәлакәткә барырга теләмибез, бармыйбыз да! — дип тавыш күтәрделәр.

Әбу-Җәһил үзенең җиңелгәнен аңлады. Барча гаскәриләрне котыртып бетермәсеннәр өчен болардан котылу хәзер аның өчен кулайрак иде. Шунлыктан аларны тыярга теләмәде. Шәйбә белән Гутбә һәм аларга ияргән берничә адәм башкалардан аерылдылар. Болардан тизрәк котылу яхшырак иде. Әбу-Җәһил исә гаскәрен күтәрде һәм юлны дәвам иттерде. Ә тегеләр Мәккә ягына төбәп киттеләр. Инде кирәкләре юк иде.

Әмма дә ләкин бүтәннәрне ташлап калдырулары йөрәкләренә авырлык салды. Илдән аерылып, соңыннан һәртөрле хакарәтләрне дә тыңлап, көлкегә каласылары килмәде. Кире борылдылар. Яуны куа киттеләр.

Гаскәргә барып кушылганда, аларның бер югалып, бер пәйда булуларын һичкем белми калганлыкны күреп, олы канәгатьлек таптылар. Әмма икенче көнне күңелләренә кабат шик корты төште.

Ул кичтә Җәһим бине Әс-Сәлат бине Габделмотталип бине Габдеманаф төш күрде.

Имеш, атлы бер кеше гаскәр кунган җиргә якынлашып килә иде. Янында бер дөя дә бар. Ул адәм атыннан төшмичә генә кычкырып әйтте:

— Гутбә белән Шәйбә, Зәмига бине Әл-Әсвәд, Өммийә бине Халәф, Әбу-Бухтури, Әбул-Хәким бине Һишам, Нуфал бине Хөвайлид!

Тагын да берничә кешене дәште, арадан аларны эзли башлады һәм боларның гомерләре аз калганлыкны һәм харап булачакларын белдерде.

Ул да түгел, шушы аталган кешеләрне җыйдылар һәм катил кылыначак җиргә китерделәр.

Сөһәйл бине Гамр исә әсир төште. Харис, аның янында буласы урынга, сугышчыларны ташлап, качып китте. Моннан элгәре бер дөянең бугазына пычак йөгертте. Канга баткан яралы мал исә, корәишләр арасына ташланып, чатырларын пыран-заран китерде, күпләрне канына буяп бетерде...

Бу төшнең асылы бер генә иде: корәишләр гаскәре һәлакәткә очраячак, алар Мөхәммәд пәйгамбәрдән тәмам җиңеләчәкләр!

Хәбәр тиз арада Әбу-Җәһил колагына да барып ирешә. Инде генә гаскәрен яуга рухландырган, сагайган күңелләрне куркудан араларга өлгергән иде бит. Янадан барсы да кабатланды. Моңа аның ачуы килми мөмкин түгел иде.

— Габдеманаф нәселеннән тагын бер пәйгамбәр мәйданга чыкты, җәмәгать! — дип ысылдады ул.— Берне икесе алмаштыра. Икесе бергә тормый. Пәйгамбәрләр, имеш. Аларга гына бар сер ачык, билгеле, имеш!

Әбу-Җәһилнең ачулы тавышы сүзләренә колак салып торучыларны сискәндереп куйды:

— Ахырда барсы да беленер: безме һәлак булырбыз, әллә инде Мөхәммәднең әсхабәләреме пыран-заран килер! Вакыт күрсәтер! Көч безнең якта!

Аның усал күзләре гаскәриләрне айкап узды. Баштан-аяк коралланган сугышчылары яуга әзер һәм җиңелмәс кодрәтияләре, нык беләкле баһадирлар төсле. Гомерендә дә сугыш уенының нәрсә икәнлеген белмәгән Мөхәммәдме аларга каршы тора алыр? Мөмкин эшме бу? Кая ашкына ул? Һәлакәтен эзли! Һәлакәтен!

Яу башының бу сүзе ганимәт малына кызыккан кешеләрнең генә түгел, хәтта инде шактый талчыккан адәмнәре дә сугышка дәртләндерде. Гүяки менә хәзер Мөхәммәд кешеләре белән очрашалар да, һәммәсен турап, изеп, кырып бетерәләр һәм бетерәчәкләр иде.

Гутбә бу вакыйганы ишеткәндә бүтәнчә бер тетрәнү һәм курку кичерде. Тиз арада Шәйбәне эзләп тапты һәм аңа барысын да сөйләп бирде. Болардан ул әле хәбәрдар түгел икән.

Киңәштеләр, белештеләр. Гутбә:

— Без корәиш гаскәрен ташлап китик. Сугышка катнашмыйк. Шушы рәвешле, Мөхәммәд белән сугышып, һәлакәт табудан котылырбыз. Канга-кан килеп орышудан да азат калырбыз. Туганы туганын суя дигән хурлыклы сүзләрдән дә башларыбыз имин кылыныр. Әгәр дә Мөхәммәд үзе пәйгамбәр түгел икән, ялганчы икән, аны Алласы саклап калмас, гарәпләр үтерерләр. Бу эштә безнең катнашыбызның кирәге юк. Безне туганын үтерүче буларак гаепли дә алмаслар. Әгәр дә инде ул пәйгамбәр икән, димәк, аның шулай дәрәҗә табуы яхшылык китерер: нәселебез сөекле күрелер. Дөресе шул: мин әйткәнчә эш кылсак, тегеләй дә, болай да халык арасында бәхетле булырбыз! Һәммәсе безне хөрмәт итәрләр,— дигән фикерен белдерде.

Шәйбәнең дә күңелендә шушындый уйлар кайный иде. Серләшүләренең азагында Мәккәгә китәргә дигән нәтиҗә ясадылар.

Гаскәриләр эчендә сүз тарала башладымы, гадәте буенча, алдан сизенеп, Әбу-Җәһил дә арадан Гутбә белән Шәйбәне эзли, чөнки аларның нәрсә маташтыруны белеп калырга ашыгуны соңгы вакытларда үзенең гамәлләреннән берсе иткән иде. Ялгышмады. Боларны тагын авызга колак куйган җирләрендә күреп алды, яннарына килде. Ни хакында сөйләшкәннәрен чамалый иде. Фикер һәм ниятләрен тыңлап бетергәч, шулкадәр аларны вәсвәсә кыла башлады ки, ышанмас җирләреннән ышандырды да, акылларын томалап, күңелләрен үз ягына авыштырды. Ныклы иман ияләре булмаулары сәбәпле Гутбә белән Шәйбә шушы рәвешле әле бер якны, әле икенче тарафны сайлап, икеләнеп, буталып калдылар. Әбу-Җәһил сүзләренә ияреп, Мөхәммәднең һәлакәтенә карар иттеләр.

Кәрванның җитәкчесе Әбу-Суфийан, ни хикмәт, мөселманнар тарафыннан әзерләнгән тозакны читләтеп үтте һәм алардан имин калды. Бу шатлыгына тәмам бирелеп китәргә теләмичә, сак хәрәкәт итте. Инде котылулары тәгаен билгеле булгач, кәрванын бәладән коткарырга килүче корәиш гаскәрен кире кайтырга өндәүне кирәк тапты. Кайс бине Әмрел-Кайс исемле кешесен тиз арада Әбу-Җәһилгә җибәреп әйттерде:

— Мөхәммәд белән сугышыр өчен һичнинди ихтыяҗ калмады!

Әмма бу хәбәр инде максатлары ачыкланып җиткән һәм ганимәт малына өмет тоткан корәишләрне канәгатьләндермәде. Мәккәгә кире кайтырга күпчелеге теләмәде. Кәрванны бәладән коткарырга чыккан гаскәр хәзер үзе мөселманнарның малын талап алырга атлыга, үзләренең җиңәчәгенә ышана иде.

Күпчелек гаскәриләр Әбу-Җәһилдән бер кулай сүз көтте. Яу башы ашыкмады. Мәккәдән Әбу-Суфийан кәрванына ярдәмгә чыкканнарын ишеткәч, Мөхәммәднең әсхабәләре качып киткәннәрдер дип уйларга аның хакы бар иде. Шунлыктан:

— Җәмәгать, данлыклы корәиш гаскәре! — диде ул, сүз көткән кешеләренә җылы караш ташлап.— Кире чигенмибез! Кире чигенүгә дә һичбер ихтыяҗ юк! Шәһәренә барып, ата-баба йоласына каршы килгән шул ахмакларны аннан куып чыгарып, рәхәтләнеп кәеф-сафа кормыйча, хатыннары белән туйганчы шаярмыйча, татлы җимешләрен ашамыйча, данлыбыз барлык гарәп кабиләләре эченә дә таралмыйча кире кайтмабыз! Арагыздан кемнәр минем белән килешә һәм артымнан иярә, шуларга карата йөрәгемдә мәхәббәт хисе булыр! — дип күпләрне татлы хыялга күмгән нотыгын сөйләп, ґаскәриләрнең рәхмәтен казанды. Һәммәсенең дә өмет биштәре мулдан иде.

Әбу-Җәһилнең сүзләрен ишеткәч, Кайс баштарак аңламыйчарак калды. Инде дә кәрванны коткарабыз дип килгән гаскәрнең, киресенчә эш йөртеп, халыкны таларга омтылганын күрде. Сүзләренә һичкем дә колак салмаганлыктан, Әбу-Суфийанга, кире кайтып, алар хакында сөйләргә булды.

Бу вакыйгалар күпләрнең күзләрен сукырайтты, акылларын алды. Әгәр дә Мөхәммәд чыннан да Аллаһы тәгаләнең пәйгамбәре икән, ул вакытта, әлбәттә, аның кулына кәрван малы керер, моңа уңайлыклар килеп торыр иде дигән сүзләр таралып, һәммәсе вәсвәсәгә биределәр.

Әбу-Суфийанга барып, Әбу-Җәһилнең ни рәвешле эш йөртергә ниятләнгәнен Кайс бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Тиз арада кәрванны Мәккә шәһәренә китереп җиткерделәр. Ашыгуларының сәбәбе бар иде. Әбу-Суфийан кабат юлга чыкты һәм Әбу-Җәһилне куа китте. Гаскәргә килеп кушылып, ул да вәсвәсә итә башлады. Әгәр дә Мөхәммәд чынлыкта Аллаһы тәгаләнең пәйгамбәре икән, ул вакытта кәрван аның тозагында калыр иде, дигән сүзләрне күп сөйләштеләр.

Бәну-Зөһрә кабиләсенең шәехе Әхнәс бине Шәррыйк кәрванның котылуын ишеткәч тә, яуга баруны туктатырга һәм кире кайтырга теләде. Шунлыктан үз халкына да фикерен белдерде:

— Безнең анда йөрү өчен һичбер сәбәп калмады. Кәрваныбыз Мәккә шәһәренә исән-имин иреште, инде без дә кире борылыйк,— диде.— Әгәр дә Мөхәммәд пәйгамбәр түгел икән, аны Аллаһы тәгаләсе якламас, әмма без түгел, аны башкалар һәлак итсеннәр. Ул безнең карендәшебез, аның канын түгүдә катнашырга хакыбыз юк. Карендәш карендәшнең канын агызмас. Моннан да олуг гөнаһ була алмый. Бармыйк, йөрмик.— Аның сүзләрендә хаклык бар иде, шунлыктан кабилә кешеләре бердәм килештеләр.

— Әгәр дә Мөхәммәд чынлап та пәйгамбәр икән,— дип сүзен дәвам итте Әхнәс бине Шәррыйк, бераз уйланып калганнан соң,— ул вакытта без халыклар каршында газиз һәм мөхтәрәм күрелербез. Безгә аның пәйгамбәрлегеннән зыян юк. Мәккәгә кайтыйк,— диде.

Бәну-Зөһрә кабиләсе кешеләре бу сүзләре белән дә килештеләр, әмма алар Әбу-Җәһилнең нәфрәтеннән һәм башкаларның көлүеннән шикләнә иделәр. Ни дисәң дә үзләрен сугыш кырыннан качып киткән куркаклар белән тиңләргә мөмкин иделәр.

— Безгә нишләргә соң? Бу хәлдән ничек котылырга? — дип, шәехләренә мөрәҗәгать иттеләр.

Ул аларга серен чиште:

— Иртәгә гаскәр, йокыдан уянып, юлны дәвам итү өчен кузгалгач, мин дөядән егылып төшәрмен һәм аңсыз кыяфәттә ятармын. Шунда хәбәр бирерләр. Әбу-Җәһил килеп: «Ни булды?» — дисә, сез барыгыз да беравыздан: «Елан чакты!» — диярсез. Шулай котылырбыз,— диде.

*Ахыры бар*



# ТЫЕЛГЫСЫЗ КОШ СЕРЕ

**Асыл сүз үзе Ходай Тәгалә яраткан һәр җан иясенә барып ирешергә ашкынып торган серле бер кош булып тоела миңа.**

Безнең Мөслим халкы шул хикмәтле кошның канат җиленнән яралгандыр инде. Ягыбыз нинди — холкыбыз шундый: яратканны изү ертып аңлатабыз, җен чыккан чакларда теш кысабыз. Харрас Әюпнең шигырьләрен укыганда да әнә шулар хакында уйланам.

Чын шагыйрь дөньяга килгәнне кем генә чамалый икән? Колынның Дөлдел булып туганын сизәргә кирәк бит моның өчен. Харрас Әюпнең өр-яңа хисләр уятырдай шагыйрь булып үсәсен әти-әнисе дә күз алдына китермәгән, әлбәттә. Минем өчен күрше авыл егете ул. Заманында Түрешкә — минем туган авылым Яңа Сәетнең куе урманы аша атлы арба юлыннан гына теркелдәргә була иде. Түрешләр безнең бер генә Сабан туен да калдырмый иде ул чакларда. Шагыйрь безнең ул җыеннарны әле дә сагынып искә ала. Йомшак печән түшәлгән ат арбасында безнең югароч болынына килеп төшкәннәрен әле дә сагына.

Кунакка килгән күрше авыл малайлары белән уйнарга, аларга үзебездә генә булган уеннарны күрсәтеп мактанырга ярата иде безнең Яңа Сәет малайлары. Харрас белән дә лапта сукканбыздыр. Булмыйча калмас.

Бу шигырьләрне укыганда һаман бер хис күңелдән китмичә тора. Үтә дә таныш халәт түгелме соң, бу — чабышкыларның әллә кайдан ук кайнар мышнавы, көрәш батырларының чи күкәйне итек башына бөреп ватулары... Шагыйрь бары тик минем авылны гына сурәтли сыман тоела. Кечке назлы Ай яктысына чумган черкиле чикләвек әрәмәләрендә гармун очына... Шунда егетләр белән кызлар ни хакындадыр пышылдашалар да тыенкы гына көлешеп алалар. Шуларның көлүенә пар булып Яңа Сәет сандугачы сайрарга тотына... Егетләр, абаганы сындырып алып, кызларның аякларына ябырылган черкиләрне куа...

Менә шулай күз алдыма килә дә, Харрас тәмам минем авылдашым, күршем, хәтта газиз туганым сыман тоела башлый. Беләсегез килсә, үзенең туган як табигате өчен оялган, аның бүтән төбәкләрдән кайтыш булуына рәнҗегән каләмдәшләрем дә бар минем. Ә Харрас Әюпнең исә барлык шигъри гөлләре бары тик туган туфракта — телгә, гөлгә бай Мөслим туфрагында гына тугарылып, җәелеп үсә.

Адәм баласы кая гына күченеп китсә дә, Туган Җире белән тоташтырган изге тамыр кала. Без аңа киндек белән береккән.

Ярар, бераз тыңлап карагыз:

«Кылычларың бер яктарак торсын,
Гармуннары барда татарның...»
«...Ваклыклары өчен түгел,
Җирне
Аклыклары өчен яраттым».
«...Дөньялыкка нинди хәлдә бирсә,
Шулай алсын Ходай бу җанымны...»
«Безнең сөюләр дә яктыртачак
Җирнең әле әллә кемнәрен...»

Һәм янә, Мөслимнәрнең ничек иттереп ярата белгәнен һәркем чамаласын өчен, Харрас Әюпнең тагын берничә

юлын искә төшереп алыйм әле:

«...Дөньяга мин сине эзләп килдем.
Эзләгәнем, шөкер, табып китәм:
Үтеп чыга алмас ут икәнсең...
Үземне мин утка ягып китәм.
Дөньяга мин сине эзләп килдем.
Эзләгәнем, шөкер, табып китәм.
Соң булса да,
Өрфиядәй жанны
Иңнәренә синең ябып китәм...»

«Шигырьгә анализ ясау» дигән ифрат та мәгънәсез сүз бар (Эчен ярып тикшергән кайсы да булса жан иисе исән калды микән?). Әгәр дә мин шушы шагыйрьнең дөньяга әйткәннәренә «анализ» ясый башласам, нишләргә тиеш булам инде? Димәк, мин — тинтәк — газиз туган якларыбызның тал сыгылып торган чишмәләре чылтыравына, балачактан ук өстебездә әле моңлы, әле шомлы шаулап утырган урманнарыбызның Ай керендергән тынлыгына, таң алдыннан күл өстенә сикереп чыгып чумган ялтыр балыкларга, карап торуга сай гына булып аккан, әмма табаның астыннан тере комны умырып кына ала торган изге Ык елгабызга «анализ» ясарга маташкан бер ахмак булыр идем. Чын шигырьне тикшереп тә, аңлатып та булмый. Ихлас жанлы кеше тоя гына ала аны!

Харрасның әле күптән түгел дөнья күргән китабын беренче тапкыр укып чыккач, мин үземне таң сызылып кына килгән чактагы йөгерек Ыкка чыклы чирәмне ера-ера йөгереп килеп чумгандай, тәмам сафланып ярга чыккандай хис иттем. Үзебезнең ике авыл арасындагы урман өстенә калыккан галәмәт зур Ай нурында беткәнче эреп, аулак алландагы хуш исле кибән төбендә йолдызлы күкнең чиксезлеге хакында иксез-чиксез уйларга талгандай булдым.

«Син белдең бит Җирдә мин икәнне,
Белдең бит син Айга карасым.
Тик белмәдең бугай карашымның
Мәңгелеккә анда каласын...»

Чын шигырьнең бер «начар» ягы бар — йөрәкне әрнетә, жанны талый ул. Әмма шигырьдән әрнегән, шигырьдән талкынган жан тәмам сафлана, канат җилпергә кирәклеген дә онытканын искә төшереп, киерелеп канат җилпеп җибәрә.

...Харрасның күп кенә шигырьләре миңа кара бер төндә ындыр артына чыгып, көзге озак яңгырлардан чылангын салкын, юеш, ялгыз шомырт кәүсәсенә мең төрле уйлардан янган кешенең маңгай терәп өзгәләнүен хәтерләтә. Шагыйрь кичергәннәрне сезгә дә кичерергә язсын. Сүзем матур булсын өчен генә әйтүем түгел. Изге Коръән дә пәйгамбәребезгә шигырь булып иңгән ләбаса!

Укыгыз, жаныгыз пакьләнсен!

ЗӨЛФӘТ.

# Харрас Әюп

## ХӘТЕР ТАУЛАРЫННАН

### Авырткан жир

Авырткан жир бәрелүчән була,
Тагын бәрдек сине, милләтем!
Чорга бәрдек,
Игелексез чорга,
Ничек түзәсеңдер син ятим.

Наркотиклар кадамакчы сиңа,
Чыгып басып кемдер мөнбәргә,
Күзләреңә карап алдамакчы...
Сөяк-фәлән юк шул телләрдә.

Авырткан җир бәрелүчән була...
Бу юлы да саклый алмадык.
Сизмәмешкә күпләр салындылар,
Дәрәҗәгә, малга алданып.

Мәнсезлекнең аның милләте юк,
Кемдер бәрә — халык сызлана:
Башкаенда йөрер йөз төрле уй,
Йөрәгендә сыкрар йөз яра.

Замананың башы авыртмый шул...
Булмаган баш ничек авыртсын!
Барсына да эндәшмичә түзгән —
Без бу чаклы нинди халык соң?!

Әллә халык, әллә кара сарык:
Тел — йозакта, язмыш — киртәдә.
Авырткан җир бәрелүчән була,—
Кая бәрелербез иртәгә?

## Йа илаһым!..

Онытыламыни кечкенәдән
Колагыңа кергән:
— Йа илаһым!..—
Аптыраган әнкәемнең сүзе...
Аның өчен тагын кем еласын?!

Йөрде ул сүз, өйдән-өйгә йөрде,
Язмышларга каршы ни кыласың?
Яраланган саен ярасына
Япты аны халык:
— Йа илаһым!..

Инде менә мин әйтергә тиеш:
Ничек ишетмисең илнең «аһ»ын?
Бүтән сүзләр беткәнмени безгә,
Нигә болай соң бу,
Йа илаһым?!.

Бөтенесе белдекләләр үзе,
Тик берсе дә белми ни буласын.
Мәңгелектән карап тора безгә
Аптыраулы кояш:
— Йа илаһым!..

## Өч кенә сүз...

Бер ишеләр яратылган базар өчен,
Икенчеләр яратылган азар өчен,
Өченчеләр яратылган илдәгенең
Бөтенесен бәйнә-бәйнә язар өчен.

Базарларда йөргәнем бар, беләм ансын,
Төртеп куям, аз булса да телдә калсын:
Сине дә бит илең белән арзан хакка,
Сата заман, иренмәгән килеп алсын!

Азулары беркемгә дә ерак түгел.
Акыл-фәлән өйрәтмәгез, кирәк түгел! —
Күпме генә изге сүзләр сөйләсәң дә,
Нәфес — нәфес бит инде ул, йөрәк түгел...

Язар өчен яратылган — язар ла ул!
Һичберкайчан ярый алмас базарга ул.
Газраил килеп тотар бугазыннан,—
Өлгералмый калыр, фәкыйрь, азарга ул...

Гыйбрәт өчен алган идем өч кенә сүз,
Өч сүз аша язмышларны кычкырасыз,
И кешеләр!
Заманнардан олы килеш,
Кайчагында мизгелләрдән кечкенә сез...

## Язмыш

Үткәннәрдән гыйбрәт алыр өчен,
Колак салыр өчен сүзенә,
Дөньядагы барлык дәверләрнең
Шагыйрьләрен җыйдым үземә.

Мине дә бер тыңласыннар, дидем,
Ишетсеннәр безнең заманны...
Белмәгәнмен икән:
Җирдә мәңге
Бер үк якты, бер үк караңгы!

Мәңге шулай үреләсе икән
Караңгыдан һаман яктыга,
Ике арада бәргәләнә икән
Кешеләргә диган Ак Дога...

Дәверләрне, шагыйрьләрне күрдем,
Бәгырьләрне...
Түздем, дәшмәдем:
Без әрнегән җиткән, үткәннәрне
Әрнетмәсен ачы яшьләрем!

Дөньядагы барлык шагыйрьләргә
Бер үк якты, бер үк караңгы...
Чакырганнар иде,—
Китми калдым:
Үтәсе бар шушы араны...

## Түтәл-түтәл ак болытлар

Офыкларда ак болытлар түтәл-түтәл,—
Йа ходаем, кемнәр нәрсә чәчеп үтәр?
Дөнья буйлап таралышкан түтәлләргә
Күз ташларга куркып торам: яшен үсәр!..

Ата-бабам күп заманнар моннан элек
Болытларга өмет төртеп киткән кебек:
Җәйләр җитсә, һавалардан җилли-җилли
Җир өстенә бәрәкәтләр ява килеп.

Җаннарында беркадәре орлык барда
Кыймылдыйсы улларыңа, оныкларга,—
Җиһан буйлап талгын гына агып бара,
Түтәл-түтәл ак болытлар офыкларда...

## Сулар тирән...

Иделләргә төшсәң, сулар тирән,
Тел тибрәтәсе булсаң, сүз тирән.
Сиңа тигән хак язмышлар тирән,
Тирән булгангадыр — күз тигән.

Күзләр тигән — өмет өзелмәгән,
Мәсхәрәләгәннәр — төзелгән.
Иделләрдә сулар тирән дә бит,
Заманалар чыпчык тезеннән...

## Хәтер-тауда

Язганнарым әгәр ялган булса,
Үпкәләмәм, Вакыт сызып ташлар:
Басканнар да Хәтер тау башына,
Кул болгыйлар миңа сабакташлар.

Менеп кенә булмый,—
Күпме җәйләр,
Күпме көзләр анда киртләч-киртләч;
Биегәя гомер узган саен.
Сузылырсың — сулуларың җитмәс...

Кул болгыйлар...
Ниләргә дип инде
Алар шулай биек менде икән?
Хәтер тауларыннан төшәлмәсне
Берсе дә соң әллә белми микән?!

Ул тауны бит сабакташлар белән
Бергә өйгән идек ташлар ватып.
Мин кучереп кенә алдым бары...
Сыза алса, сызып ташлар Вакыт.

Сызып ташлар,
Ләкин гөнаһысы,
Гөнаһысы берүк миңа түгел!
Күпме таулар калган...
Кул болгыйлар...
Бездән генә күчкән йола түгел!..

## Әрәмә бар...

Ул яклардан искән хәтер җиле
Әрәм икән сиңа, әрәм әле:
Онытклансың, бик тиз онытклансың
Ындыр артлап үткән әрәмәне.

Үзең менә заман уртасына
Килеп җиткәнсең дә исән-имин,
Үтмәс балта белән утын кисеп,
Әрәмәдә калган әнкәң синең...

Еллар буе
Агач башларында
Кычкыручы — кәккүк түгел бит ул! —
Каян эндәшсен соң,
Синең өчен
Мәңге өзгәләнгән күңел бит ул...

Бар гаепне бүген заманага
Аударасың, беләм, тотасың да.
Бер колак сал:
Утын кисә әнкәң...
Әрәмә бар заман уртасында!

## Ат җикте малайлар...

Ат җикте малайлар.
Шул көнне
Аерылып калгандыр малайлык.
Калгандыр... Җәяүле гомергә
Атларны узардай чама юк.

Ат җикте малайлар.
Юлларда —
Һаман да җигүле атлары,
Тарталар... Елларның тын гына
Ир булып өлгергән чаклары.

Ат җикте малайлар, ат җикте! —
И, инде әткәйләр куаныр.
...Малайлар җиккән ул атларны
Бер көнне бабайлар тугарыр...

## Мөслим көзе

Офыклардан-офыкларга кабынып,
Ык буена керә Мөслим көзе.
Шушы якның кешеләре сыман
Колачы киң аның, ачык йөзе.

Алларыңа синең тып-тын гына
Хәтфә паласларын җәеп сала.
Дәвер түпләреннән бәреп чыккан
Чишмәләрен авыз итми кара!

Әрәмәдә балан каршы ала
Бүген монда киләсеңне белеп.
Сине чакыргандай, җил сызгыра
Әби чәчле тауларына менеп.

Күренеп тора: җаннардагы җылы
Кибән-кибән икән, эскерт-эскерт.
Бер яктырыйм дисәң, Мөслимгә кил:
Күптән белә моны күрше-күкерт.

Каеннарга килеп сарыладыр
Өрфиядәй җиңел Мөслим көзе.
Шушы якның кешеләре сыман
Колачы киң анын, ачык йөзе...

## Кырынтау[1]

Алмагачлар безне аңламаслар...
Юатмакчы булып, сентябрь
Ятим калган алмаларның яшен
Сары кулъяулыкка сөртәдер...

«Бу заманда шигырь нигә кирәк,
Язма»,—диләр...
Ничек язмыйсың?!
Таулар кырын түгел икән лә бит,
Түгел икән... Кырын—язмышың!

Быел монда сабантуйлар узган.
Авылы юк... Туе... туе—бар!—
Авылларның гына язмышымы?
Халкы барның уйлар уе бар...

Алмаларга ничек аңлатасың
Кешеләрне, илне, дөньяны?!
Алдадылар...
Алар берсе дә бит
Алмалардай ихлас булмады...

Хуш, Кырынтау!
Моңсу кулъяулыгым—
Язганымны биреп калдырам:
Баш очында бер болгарсың бәлки
Сабантуйлар бетәр алдыннан...

*1995.*

---

[1] Кырынтау—Татарстанның Мөслим районындагы таралып беткән авыл исеме.



## Госман Гомәр

# МӨҺЕР

МАҖАРАЛЫ ПОВЕСТЬ

*Татар галиме Җәвад Алмазның якты истәлегенә багышлыйм*

Сугыш чоры яшьләренең һушлылары, җигүле үгезләрен фронтовикларга яки инде гыйлем эстәү дәрте сүрелгән өлкәнрәк туганнарына калдырып, югары уку йортларына дип, Казан тарафына юл тотты. Авыр заман иде, әмма ачлы-туклы яшәсәләр дә, укудан ваз кичүче булмады, һәркем үҗәтләнеп мәгърифәткә, аң-белемгә омтылды. Ашау дигәннән, кем кайдан ни юнәтте — шуны тәгам итте, әмма һич тә урлашып, хәрәмләшеп түгел. Шәкертләрнең күбесе дәрестән соң Усиягә йөгерде, баржадан утын, ташкүмер, тоз һәм башка йөкләр бушатырга; икенчеләре тимер юл вокзалы тирәсенә елышты — көче-куәте бар кешегә монда да эш җитәрлек иде. Акчасын да шактый гына тамызалар, кайвакыт, тамак туйдырудан тыш, берәр картуз яисә чүпрәк ботинка сатып алырлык рәт тә кала әле. Кайберәүләр әнә вельвет күлмәккә кадәр тиенде.

Сабакташлары арасында Касыйр Черкиев кенә бик күренмәде. Дөрес, бүлмәдәшләренә ияреп бер-ике кич Усиягә баржадан такта бушатырга төште төшүен. Ай-яй, ул чи такталарның авырлыгы! Буе алты ярым метр — стандарт үлчәм, диләр, киңлеге утыз биш-кырык сантиметр булып, калынлыгы — алтмышлы, ягъни алты сантиметр, чилектән сулары саркып тора. Ике башыннан ике студент күтәргәч, уртасы җиргә тиямтиям дип бара, шуның астында үпкәләрең өзелеп төшәр хәлгә җитә. Өчәүләп күтәрерләр иде — акчага суга, яшь егетләр кан төкерә-төкерә баржадан яр өстенә таба атлый, гөпелдәп егылгач, андыйлар икенче рәт тактага килеп орынмый инде. Ни пычагыма кирәк мондый тәмуг газапларың Касыйрга. Бөгәрләнә дә ята ул караватына, кирәкми кызыл унлыклары. Бер көн ятты, ике көн... өченчесендә торып утырды егет, корсагында пәриләр утын кисүгә чыдый алмагач.

Туктале, чыннан да, берәрсенең утынын кисеп-ярып бирергә кирәктер, бәлки? Ул Кольцодагы сөт кибете ягына таба юнәлде. Шушында бит

инде утынчыларның законлаштырылмаган «биржасы». Стена буйлап, гадәттәгечә, кулларына балты-пычкы тоткан мари хатыннары тезелеп тора. Алып киткәлиләр тегеләрне икешәрләп, ә Касыйрны күрмиләр дә — әллә бар ул байлар өчен бу дөньяда, әллә юк. Күрерләр иде — егетнең ни балтасы, ни пычкысы юк. Их, ияртсен иде, ичмасам үзе белән әнә шул ыштыр-чабаталы мари хатыны, аның кадәр генә тартыр иде әле пычкыны шәкерт егет.

Өмете киселде Касыйрның. Инде нишләргә? Авылда тикмәгә генә «черкинекеләр» дип йөртмиләр шул аларны, ишектән кусаң, тәрәзәдән керә торган нәсел.

Йөгереп тулай торакка кайтты да ясканып шигырь язарга утырды Касыйр. Менә икән аның тамагын туйдырачак һөнәре! Шагыйрь булу күптәнге хыялы ич. Авылда шигырь тулы әллә ничә дәфтәре калды. Ничек онытып җибәргән соң ул үзенең бу тылсымлы һөнәре турында?! Әллә артык дулкынланганга, әллә инде корсакта инкыйлаб уты туктамаганга, ничектер, шигырьләре килеп чыкмый җәфалады. Бер-ике дәфтәрне сызгалап-ерткалап тумбочка тирәсенә чүмәлә өеп куйды. Ниһаять, туган авылына багышлап өч куплетлы «Чыршылым» дигән шигырен язып бетерде. Шагыйрьләр көрәп ала ди бит акчаны. Касыйрга да кичке ашлык кына тамар әле, бәлки. Хыялында инде чалбар кесәсе бүлтәеп чыккандай ук тоелды. Әнә унлыклар кыштырдаша да башлады бугай. Болай булгач, нигә чи такта ташып изаланырга, яз да яз рәхәтләнеп. Егетләр шаккатсын әле бер, бигрәк тә кызлар үрсәләнер инде!..

— Нишләп болай соң бу? — дип гаҗәпсенде редакциядәге әкәмәт озын абзый, кулъязманы кат-кат укып.

— Ник алай дисез?

— Иң әүвәл исеме белән имзасы буталган моның.

— Ник буталсын ди.

— «Ник» тә «ник»? — дип үртәлде теге озын кеше. — Шигырьнең исеме «Чыршылым» — бусы аңлашыла, авылыңны сагынасың, димәк, ә монда автор урынына тагын Чыршылы.

— Ник, Максуд Сөндекле, Сахаб Урайскийлар бар ич.

— Бар анысы, әнә, Сахаб абыең үзе утыра!

— Молодец, энем! Минем дәвамчым булырсың, — диде кара тутлы, кызлар шикелле чибәр Урайский. — Ә сезгә, егетләр, көнләшеп яшәүдән башкасы калмаячак, анысын белеп торыгыз.

Озак әүмәкләде дәфтәр битен редакциянең әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире. Кат-кат укыгач, шигырьне кире авторга сузды.

— Пешеп җитмәгән бу, Чыршылы иптәш, бигайбә.

— Зәки, яшь шагыйрьне рәнҗетмик инде без, минем янга җибәр булмаса, — дип, кабат сүзгә кушылды Урайский. — Кил, энем, кил, пешерәбез аны, язарбыз да, бастырып та чыгарырбыз, шулай бит, соңыннан үзең дә танымассың әле шигыреңне.

Бүлмәдәгеләр шәрран көлешеп алды. Дорфалыгы өчен мөдирләре Зәкине битәрләделәр.

— Чын исем-фамилияң ничек соң, энем?

— Черкиев Касыйр.

— Эшлисеңме, укыйсыңмы?

— Студент.

— У-уу!

— Фамилиям уңайсызрак шул минем. Шуңа да авылым исемен куйдым ахырда, — дип акланды егет. — Университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыйм. Чыршылыдан икәнемне беләсез инде хәзер.

— Фамилияң чепуха, исемең бик хәтәр икән синең, Чыршылы иптәш! Гарәпчә мәгънәсе диюем.

— Анысын искә алмыйк, Зәки. Монда барысы да гап-гади, егет шигырь китергән, — диде Сахаб Урайский, эчке бер җылылык сирпеп. — Нипочем бу безгә, энем, шулай бит, ялт иттерәбез аны бергәләп тотын-

сак. Әмма син, хөрмәтле Чыршылы иптәш, главный, язудан туктама, кара аны, икенчеләрен Зәки абыең шикелле дүртьюллыклар рәвешендәрәк язарга тырыш, югыйсә, тагын «пешмәгән» дияр.

— Бәлки, бергәләп иҗат итәрсез, Ильф белән Петров,— дип, мыскыллы шаркылдады мөдирләре, Урайский төрттергәнне өнәп бетермичә.

Черкиев университетта укыса да, Ильф белән Петров турында хәбәрдар түгел иде, кемнәр соң үзләре, дип сорарга кыймады, наданлыгын сиздерәсе килмәде. Ә Сахаб абыйсы сүзендә торды, Касыйр Черкиевнең шигырен бер атна дигәндә «Яшь сталинчы» гәҗитендә бастырып та чыгарды. Автор теләгәнчә, «Чыршылы» имзасы белән, ә менә шигырьнең исемен үзгәрткән, «Авылым» дип куйган. Дөрес әйткән икән шагыйрь, үзең дә танымассың шигыреңне дип, әсәрнең эчтәлеге бөтенләй башка иде, матуррак та булган.

Унбиш көннән соң редакциягә килеп, шигырь өчен ике йөз илле сум каләм хакы алды Касыйр. Тиенен дә тотмыйча бүлмәдәшләренең борын төбендә озаклап селкеде ул шыгырдап торган сумнарны, түгел лә, гонорарны. Бу чакта инде шигырь басылган гәҗит, кулдан-кулга күчеп, тәмам таушалып, ертылып ук беткән иде. Шул көннән сабакташлары арасында шагыйрь булып, башны югары күтәреп йөрергә керешге Касыйр.

Редакциядәге дуслык моның белән генә бетмәде. Сахаб абыйсы шәкертне Матбугат йортының беренче катындагы китапханәләр коллекторына алып төшеп, вакытлыча эшкә дә урнаштырды. Касыйрның җәйге каникуллары башланган иде, ә коллекторда кешеләрне чираттагы ялга җибәрергә кирәк икән, куанып кабул иттеләр. Хезмәт авыр түгел: шәһәр, район һәм авыл китапханәләренә җибәреләчәк китапларны төреп-бәйләп торасы — ике кулга бер эш. Тик менә шигырь язарга вакыт калмый. Аның каруы нинди китап укыйм дисәң, шул бар.

Шулай өч ел буе җәйге каникулларда Касыйр китапханәләр коллекторында эшләде. Илья Ильф белән Евгений Петровларның кемлеген дә белде, чөнки бу мәлдә коллекторга аларның яңа гына басылып чыккан «Алтын бозау» (нигә «Бозау чаклы алтын» дип куймаганнардыр исемен), «Унике урындык» әсәрләре килеп керде. Ярослав Гашекның «Швейк солдат маҗаралары»н ул ике көндә укып чыкты, бусы тагын да көлкелерәк иде. Күп яңалык белде Касыйр соңгы өч елда. Вакыт-вакыт Остап Бендер шикелле йөрисе, Швейк солдат кебек башкаларны көлдерәсе килеп китә аның. Аспирантурада калдырылгач та эшләп маташты әле ул китаплар бәйләүче булып.

* * *

Берәү Касыйрны, Бауман урамыннан узып барышлый:

— Сәлам иске дусларга! Яшь галим танымый да хәзер безне, эреләнде паринек,— дип, урысча-татарча сәламләде.

Борылып караса, исе китте: китап сөюче дусларыннан Мусин икән.

— И Абрам Моисеевич, Сезмени әле, гафу итегез, күрми дә торам, исәнмесез!

— Фән биеклекләренә үрмәлим, дисең алайса?

— Тырышабыз инде, Абрам Моисеевич.

— Китаплар төзүче һәм галим.

— Әлегә аспирант кына.

— Кызык шулай да.

— Нис кызык инде аның, Абрам Моисеевич, җырлыйм да ич мин.

— Аспирантурадамы?

— Юкла инде, үзешчән сәнгатьтә актив катнашам, җырлавымны ошаталар, шуңа да университеттан җибәрәселәре килмәде. Җырчылар-

ны, шагыйрьләрне, бигрәк тә спортчыларны аспирантурада калдыралар — ярышларда университет даның якларга. Мин дә шундыйлар арасына килеп эләктем,— дип аңлатты Касыйр, үзенең аспирантурада калу сәбәбен.

— Анысы шәп булган, шулай да җәйләрен «Бибколлектор»ны ташлап ук бетермәссең әле, бер дә җибәрәсе килми үзеңне, син сайлаган китаплар — иң әйбәтләре була торган иде.

— Ул кадәресен генә чамалыйбыз инде, Әдһәм абый.

— Һаман шаяртасың, егет, ярар, мин үпкәләмим.

— Соң исемегез генә түгел, фамилиягез дә татарча лабаса.

— Анысы күп милләтләр өчен уртак. Дөрес әйтәсең.

Абрам Моисеевич Мусин — яһүд, китап җене кагылган адәм. Бигрәк тә яңа басылып чыккан һәм сирәк очрый торган китапларны җыя. Шул маһирлеге аны Татарстан китапханәләр коллекторы директоры Гыймран Кадиков белән дуслаштырган. Авылларга җибәрелергә тиешле урыс китапларының бер өлешен Абрам Моисеевич алып кала. Коллекторда ул тәмам үз кешегә әйләнеп беткән. Китап төрүче кызларга кесә тутырып конфет, чикләвек алып килә, алар белән дустанә, шаяртып сөйләшә. Теге чакта Касыйр аңа Ильф белән Петров, Гашек, Кочетков, Асеев, Твардовскийның яңа басылып чыккан китапларын төреп биргән иде. Шул мәлдә дуслашып калдылар. Абрам Моисеевич татарча әйбәт белә, хәтта җырлый да, «Эшче» операсыннан Нигъмәт ариясен искиткеч шәп башкара!

— Эшләмичә булмас инде, акча кирәк бит,— диде Касыйр, үзен мактауга кәефе килеп.

— Күпме түлиләр?

— Житә. Өч йөз унике.

— Хәзер кая чабасың соң?

— Ә монда гына, язучыларның Тукай клубында бүген җыелыш, татар халкының борынгы шагыйре Кол Гали иҗаты тикшереләчәк. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының күп кенә кульязмасы табылган, ахырдан зур концерт куябыз. Әйдәгез, Абрам Моисеевич, минем белән. Ничек җырлавымны да тыңларсыз.

— Кульязмалар дисеңме?

— Әйе, әйе, кичә бик күңелле булачак.

— Син нык активлашып киткәнсең әле, егет,— дип, салпы ягына салам кыстырды тегесе.

— Рәхәтләнеп ял итәрсез бер.

— Күндерден,— диде яһүд.

Абрам Моисеевич татар зыялыларының күбесен белә, язучылар, журналистлар, рәссамнар, композиторлар, артистлар, юристлар, табиблар арасында дуслары күп, аларның кайберләре белән кунакка йөрешә, теттереп татарча сөйләшә, әңгәмә вакытында канатлы сүзләр, халык мәкальләрен кыстырып җибәрә. Кем әйтмешли, эчеңә-бавырыңа үтеп керә белә. Шуңадырмы, аның үзен дә хөрмәт итәләр, Абрам Моисеич, дип өзгәләнеп торалар. Тукай клубында да булгалый, монда күпләр таныш аңа.

— Теге кем ул? — дип кызыксынды Абрам Моисеевич, янәшәсендә утырган берәүдән, президиум өстәленә таба ымлап.

— Кайсын әйтәсез?

— Үзбәк түбәтәйлесен, бер дә күргән кешем түгел.

— Ә-ә, Ташкенттан ул. Бөтенләйгә күчеп кайткан, диләр. Бүген нотыкны шул галим ясаячак. Үзебезнең татар кешесе Сәйдел Турай. Зур белгеч, имеш,— дип аңлатты Мусинның күршесе.

Җыелышны алып баручы сүз бирер алдыннан галим Сәйдел Турай белән кыскача таныштырып үтте. Аның татар, гарәп, фарсы әдәбиятларын яхшы белүе, Ташкент, Сәмәрканд, Бохара, Хива уку йортларында һәм китапханәләрендә зур фәнни тикшеренүләр алып барганлыгы, татар әдәбияты өчен кыйммәтле мәгълүматлар туплаганлыгы турында искәрт-

те. Бер үк вакытта Кол Гали иҗаты белән дә шөгыльләнгән, шагыйрьнең «Кыйссаи Йосыф» поэмасының күп кенә басмаларын һәм кульязмаларын табып өйрәнгән. Хәзер инде Казан дәүләт университетының фәнни китапханәсендә Галинең барлыгы йөз алтмыш бер китап һәм кульязмасы теркәлгән, шуларның йөз унбише Татарстан җирендә табылган. Арада җитмеш басма китап булып, калган туксан бере кульязма рәвешендә сакланган.

— Әлеге байлык арасында төп нөсхәне, беренчел кульязманы аерып алырга кирәк, шунсыз без «Кыйссаи Йосыф»ны китап итеп бастыра алмыйбыз. Галимнәребез арасында бу хакта бәхәснең тынганы юк. Уртак фикергә килергә бик вакыт канә. Ә без әсәрнең нинди телдә язылуын шик астына куябыз. Белә торып нигә катлауландырырга мәсьәләне — кайберәүләрнең тоткан кыйбласын һич аңламыйм. Минемчә, Сәйдел Турай бу бәхәскә нокта куярга омтыла. Галим күп эш башкарган, күп нәрсәне ачыклаган, дәлилләре ышандырырлык. Хәзер мин сүзне аңа бирәм,— диде мәҗлес рәисе, галимне мөнбәргә чакырып.— Рәхим итегез!

Сәйдел Турай — уртача буйлы, түгәрәк, җыйнак гәүдәле, ачык йөзле, зәп-зәңгәр елтыр күзле, бик тә тере, хәрәкәтчән кеше икән, нотык мөнбәренә атылып диярлек чыгып басты. Казан каласында шагыйрь Салих Батталдан башка түбәтәй киеп йөрүче кеше калмаган иде — күпләр түбал кадәр чәч үстерүне кулай күргән заман. Үзенә күрә сәбәбе дә бар иде моның. Түбәтәй киюне Мәскәүдән көлү дип аңлыйлар иде җитәкчеләр. Ә монда — үзбәк түбәтәе! Бераз сәерсенде сәерсенүен Абрам Моисеевич, әмма галимгә түбәтәй, үзбәкнеке булса да, ифрат килешеп тора иде. Күнегелмәгән күренеш һәрвакыт сәер тоела. Татарның милли төсе югалып бара шул, дип фикер йөртте яһүд кешесе, үзенең балачакта күргәннәрен хәтерләп.

Галим фәнни эзләнүләре, «Кыйссаи Йосыф» поэмасының аерым вариантлары, аларның кайларда табылуы турында озаклап, тәфсилләп сөйләде. Аннары кульязмаларның телен, стилен, аерым сүзләрне анализлап күрсәтте. Бу мәсьәләдә кайбер галимнәр белән килешеп бетмәвен әйтте. Поэманы берәүләр уйгыр-хәрәзем теле тәэсирендә язылган дип исәпли. Бәгъзеләре төрек телен алга сөрә, угыз-кыпчак теле элементларының күплеген танучылар чынбарлыкка якынрак тора, дигән карашта икән галим үзе. Ул әлеге мәҗлестә фикерен кистереп әйтте:

— Кол Гали — Болгар шагыйре, «Кыйссаи Йосыф» борынгы болгар-татар телендә иҗат ителгән. Аерым сүзләргә генә игътибар итегез: ата, сату, богау, сүз, йөз, кара, юк, һич, үзе, ярлы, куен, кал һәм башка сүзләрнең бүгенге көндә дә бер авазы да үзгәрмәгән бит — чын татарныкы. Китап һәм кульязмаларның дүрттән өч өлеше Болгар һәм Казан ханлыгы җирләрендә табылуы үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйлидер. Монда, минемчә, бәхәс куерту бөтенләй урынсыз. Тикшерү нәтиҗәләренә таянып, мин «Кыйссаи Йосыф» поэмасы 1212—1233 елларда, ягъни Болгар-Казан җиренә монголлар килгәнче язылып беткән, дип саныйм. Тиздән без кадерле мирасыбызның 750 еллыгын билгеләп үтәрбез, ә аңарчы менә бу кульязманы, ул фәнни китапханәдә 19—33 саны белән теркәлгән, нәшриятта бастырып чыгару өчен әзерләргә кирәк. Мин кульязманы автор текстына якын торган бердәнбер вариант дип исәплим. Әгәр кызыксынсагыз, кульязманың кайдан табылуын да күрсәтә алам. Ул Казан ханнары нәселеннән килгән Әҗемевләр китапханәсеннән алынды. Игелекле җаннар аны буыннан-буынга берничә йөз еллар буе саклап килгәннәр. Бүген мин бу мәҗлестә катнашучы Яңа бистә карты мөхтәрәм Исмәгыйль абзый Әҗемевкә кыйммәтле мирасыбызны саклап калуы, киң күңеллелек күрсәтеп, аны университетның фәнни китапханәсенә тапшыруы өчен милләттәшләрем исеменнән бихисап рәхмәтләр белдерәм. Иншалла, кадерле ядкяребез тиздән китап шөрлекләребезне бизәп торыр, киләчәк буыннарда гүзәллеккә, иляһилыкка омтылыш тәрбияләүдә булышлык итәр. Хәзер безгә бу изге эшкә бергәләп тотынырга

кирәктер дип беләм. Шәхсән, мин үзем кулдан килгәнчә булышлык күрсәтергә әзермен. «Кыйссаи Йосыф»ның яңа басмасын мөмкин кадәр тизрәк чыгарасы иде шулай да. Чөнки ядкяребезнең юбилее якынлаша, китап итеп өлгертергә кирәк кулъязманы. Мин бүген галимнәребезгә, нәшрият хезмәткәрләренә, китап сәүдәсе кешеләренә мөрәҗәгать итәм... Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

Нотыкның соңгы җөмләсе Мусинга аеруча ошады. Күпме җыелышларда катнашып, үз чыгышын рәхмәт сүзе белән тәмамлаучыларны ишеткәне дә, күргәне дә юк иде әле аның. «Бу карт (галим чәчсез булганга, түбәтәй киеп йөргәнгә, аны һәркем өлкән яшьтә дип кабул итә иде) Казанга Шәрекъ мәдәниятен алып кайткан», дип уйлап алды Абрам Моисеевич.

...Чыннан да Касыйр ярыйсы гына җырлый икән бит, тавышы көчле, әмма урыны-урыны белән кычкырыбрак җибәрә, нотадан сикереп чыга. Гомумән, концерт уңай тәэсир калдырды.

* * *

Матбугат йорты, үзенең авыр имән ишеген ачып куйган да, халыкны урамга коя. Кечкенә генә Тукай клубына ничек сыйды икән соң бу чаклы галәм, дип шакката Абрам Моисеевич. Әнә, таякка таянган карт-карчыкларга тиклем килгән, студентларны әйткән дә юк инде. Кая соң әле үзләре?..

Иң ахырда ишектән дәррәү генә шәкерт-артистлар килеп чыкты. Куанычлары эчләренә сыймый, берсен-берсе бүлдереп гөж итәләр, концертның ничегрәк узуын тикшерәләр. Ә менә шундый зур җыелыш турында телгә алучы да юк, әйтерсең, концерт өчен генә җыелганнар да инде бөтенесе хәл кылынган, филармониягә эшкә урнашу өчен җыйнаулашып гариза гына илтеп бирәсе калган үзләренә.

— Әй, җырчы егет, Касыйр-паша, кил бире, дусларың белән таныштыр,— диде Абрам Моисеевич, ишектән чыккан көтүне каршылап.— Шәп концерт куйдыгыз, егетләр-кызлар, барысы да искиткеч, профессиональ артистлардан ким түгел.

Студент халкына ни кирәк соң? Ите кимерелгән бер сөяк җитә аларга. Мактау сүзеннән түбәләре күккә тиеп, тегеләр Мусинны чорнап та алдылар. Әлеге юантык гәүдәле, калын күзлекле, эре шакмаклы пиджәк кигән ачык күңелле кеше белән күрештереп:

— Иң якын танышым Абрам Моисеевич Мусин,— дип тәкъдим итте Касыйр.

Кул сузганда шәкертләр үз исем-фамилияләрен атадылар.

— У-у, әйттем бит, талант ияләре дип, хәтта, үзегезнең шагыйрәгез дә бар икән ич,— диде Абрам Моисеевич.

— Берәү генә дә түгел,— дип чәчрәп алга чыкты чегән төсле капкара күзле, кара кашлы, баскан җирендә биеп торучы Ниса.

— Кәүсәрия, син дә кил!

— Ул нигә читтә?—дип кызыксынды Мусин.

— Минем йөргән кызым анысы, Абрам Моисеевич,— дип пышылдады Касыйр, бөтерчек кадәр генә чибәркәй ягына ымлап.— Ояла ул. Шәкертлектән чыкты инде, фәнни китапханәдә эшли, Кәүсәрия Галимова.

— Килегез, кил.

— Исәнмесез!

— Менә никадәр туйда катнашасы бар икән әле,— диде Мусин, һәркемгә тигез елмаеп.

— Бүләгегез җитәрме соң?

— Абрам Моисеевичта елан мөгезе дә булырга мөмкин,— дип шаяртты Касыйр.

— Килсәгез, чакырырбыз,— диеште кызлар, шакмаклы пиджәк җиңенә кагылгалап.

Язгы кичләрдә генә була торган сафлык, уңышлы узган концерт яшьләрне тәмам исерткән иде. Алар күкнең җиденче катына ашарга теләп канатландылар, куаныштылар, урам яңгыратып көлештеләр. Кайсыдыр сәхнәдә башкарырга өлгермәгән җырын көйләде.

— Дусларым, әгәр сез каршы килмәсәгез, мин менә бу парны үзем белән кичке ашка алып китәр идем,— дип рөхсәт сорады итагатьле Абрам Моисеевич.

— Әлбәттә, әлбәттә.

— Барсыннар гына.

— Без хәзергә калып торабыз,— дип шаяртты, теге җор телле чегән Нисасы.

— Сезнең белән, әйтелгәнчә, туйда очрашырбыз,— диде Мусин, шаяртуга шаярту белән.

Егетләр-кызлар күңелле гөрләшеп, китеп тә бардылар.

— Мин дә кайтам,— диде Кәүсәрия.

— Ни булды, туташ?

— Белмәгән кешеләргә кунакка йөриләр димени.

— Мин белгәч, җиткән инде. Әйдә, Абрам Моисеевичның китапханәсен дә күреп кайтырсың,— дип кыстады Касыйр.

— Үзең генә бар.

— Юк инде.

— Әйтмәдемме әллә, бүген апаларга барасым бар, дип. Сезгә бик күп рәхмәт, Абрам Моисеевич, чакыруыгызга, бер туры килер әле!

— Гафу итегез, мин чын күңелдән юкса.

— Хушыгыз! — Кыз тиз-тиз генә китеп тә барды.

— Характер күрсәтмиме? — дип сорады Мусин аспиранттан.

— Юк, һич юк, әйттем бит, оялчан, дип.

* * *

Мусиннар шәһәрнең иң чиста урынында, үзәгендә — Комлев урамында торалар икән. Хезмәт Сараена каршы гына. Ике катлы агач йортның түбән каты гел аларныкы, зур заллары — китапханә, аннан тыш тагын өч-дүрт бүлмәләре бар. Залның түрдәге тәрәзәләрен кирпеч тезеп томалаганнар, чөнки анда ике рәт итеп китап шүрлекләре ясалган, яндагы биш тәрәзәдән төшлектә кояш нурлары кереп тора, шунлыктан, китапларга зыян килми, бозылмыйча әйбәт саклана, ди Абрам Моисеевич. Түргә генә түгел, барлык стена буйлап шүрлекләр ясалган аларның кайберләренә китаплар икешәр өчәр рәт итеп тезелгән.

— Ай-яй, нинди зур китап! Теге «Янтарь» сәгате кадәр бардыр бу,— дип гаҗәпсенде Касыйр, шүрлекләрнең берсе янында туктап.

— Алып кара.

Китапны актара башлагач, аспирант егылып китә язды. Мондый мал да була икән дөньяда! Чыннан да, шул сәгать тартмасы зурлыгында бу. Китап Чыңгыз хан армиясенең сугыш тактикасын өйрәнүгә багышланган иде. Сугыш һөнәрен өйрәнүчеләр өчен чыгарылса да, Мусин китапханәсендә саклана ул. Менә нинди мал җыя икән бу яһүд! Дөньяда сирәк очрый торганнарын.

— Чыннан да, китапханәләрдә очратканым юк, ә миндә саклана,— ди Абрам Моисеевич.— Безнең бурыч китапны киләсе буыннарга илтеп җиткерүдән гыйбарәт. Син, Касыйр, һәрвакыт шуны исеңнән чыгарма. Минем бу гамәлем бервакыт үзенең бәясен алачак әле, күрерсең менә. Әйдә, иң элек чәйләп алыйк. Хәзер мин сине хатыным һәм кызым белән таныштырам, алар үз бүлмәләрендә.

Күрше бүлмәнең ишеген шакып:

— Фреда Ароновна, безнең янга чыгыгыз әле,— дип аваз салды Мусин.

— Ой-уй,— дия-дия, залга алсу җирлеккә эре-эре ак чәчәк төшерелгән бик матур халат кигән Фреда Ароновна килеп керде. Бигрәк сөйкемле хатын икән, кем әйтмешли, кешене йөзе белән сөендерә.

— Бу ни була инде, Абгам Моисеич, чыктың да югалдың, сине көтәбез, пилмән суынып бетә язды,— дип шелтәләде хуҗабикә ирен.

— Таныш бул, Фреда Ароновна, татар халкының яшь галиме Касыйр Черкиев дигән егет бу.

— Исәнмесез, Фреда Ароновна. Мин — аспирант кына әле, Абрам Моисеевич бераз арттырып җибәрде.

— Шатмын. Безнең Абгам кешеләрне таный белә ул,— диде хуҗабикә, иренә ягымлы елмаеп.— Әйдәгез, табынга рәхим итегез. Калганын шунда сөйләшербез.

Ач аспирант ике тәлинкә пилмәнне бөкләгәч, кузгалырбыз, дип уйлаган иде. Аның белән генә бетмәгән икән әле Фреда Ароновнаның сые, табынга икенче аш итеп яһүдләрчә тәмле итеп кыздырылган чуртан балыгын кетердәтеп кыздырылган бәрәңге белән чыгарды. Корсак тулды дип, ашамыйча, кайтып китеп булмый бит инде, Касыйр анысын да ялт иттерде. Шунда, табын янында, кызлары Берта Абрамовна белән дә танышты. Әллә инде анысы кияүгә чыкмаган карт кыз, әллә бер тапкыр булып кайткан — ул кадәресен егет төшенеп бетермәде.

Кичке аш дәвамында аспирант ашханә стенасындагы картинадан күзен алмады. Анда җәелеп яткан шәрә хатын-кызны арыслан ботарлый иде: Христианнарның, бу очракта яһүдләрнең, дини темага язылган рәсемнәре икән. Тапканнар бит буявын да, сурәт нәкъ тере кеше тәне төсле, каны — кан. Үзләре белән утыз тугызынчы елда Англиядән алып кайтканнар.

— Сез анда булдыгызмыни, Абрам Моисеевич?

— Лондонның үзәгендә яшәдек.

— Ә нигә кайттыгыз?

— Мин бит Казанда туып-үскән кеше. Туфрак тарткан, күрәсең. Баштарак сугыш буласын да чамаламаганбыз. Югыйсә, кузгалмас идек. Юк, кайтуыбызга тамчы да үкенмибез хәзер. Ярар, Касыйр, бу башка тема. Бер сөйләрмен әле кызыксынсаң,— дип, хуҗа сүзне икенчегә борды.— Берәр төрле фильм карыйсың килмиме?

— Нинди фильм?

— Мәсәлән, «Тарзан»ның беренче сериясен. Моннан ун-унике еллар элек Казанда зур уңыш белән барды ул. Янкиләр эшләгән.

— Кемнәр анысы тагын?

— Американлылар, гап-гади американнар. Шәп төшерәләр үзләре кинофильмнарны. Бөтен шәһәр егылып карады.

— Үзегез чамалыйсыз инде алайса, Абрам Моисеевич.

Мусиннарның киноаппаратлары да бар икән. Кыргый кеше, аның көче-куәте турында гаҗәеп фильм булып чыкты монысы. Бүгенге кичнең тәэсирләре әйтеп бетергесез иде. Юкка гына чыгымлады Кәүсәрия, чүпрәк баш, нинди форсатны кулдан ычкындырды бит. Касыйр аркасында рәхәтләнеп сыйланып кайтасы урында, характер күрсәтә, тиле бәрән орлыгы ашаган нәрсә.

Кинофильмнан соң Абрам Моисеевич хатынына берәр чынаяк кофе кертергә кушты, ирләрнең үзләрен генә калдырырга боерды.

Серләре килә: берсе китап сөюче, икенчесе — яңа басылган китапларны матур итеп төреп бирүче.

— Касыйр, син ничек уйлыйсың, «Кыйссаи Йосыф»ның табылмаган кулъязмалары тагын калдымы икән әле?

— Ник калмасын, берәр авыл карчыгының сандык төбендә яки шүрлекләрендә яшеренеп ятадыр, бәлки.

— Шулай дисеңме?

— Димичә. Ничә ел буе җыя киләләр, ул һаман табыла тора. Ә бүгенге җыелышта телгә алынганы — сирәк очрый торган нөсхә, анысы китап итеп басу өчен саклана.

— Үзем дә бик кызыксынам шуның белән, бер нөсхәсен китапханәмдә булдырасым килә,— диде Мусин, әкрен-әкрен сүзне бер ноктага җыеп.— Югыйсә, тәмам югалтып бетерерләр татар халкының мирасын, миндә, һичшиксез, әйбәтрәк сакланыр иде.

— Җәй көне, авылга кайткач, сораштыргалармын.

— Анысы икенче мәсьәлә,— дип, диван буйлап Касыйрга таба шуышты Мусин.— Мине Сәйдел Турай әйткән кульязма кызыксындыра, хакыннан тормаячакмын, бер ел буе стипендиясез яши аласың. Өс-башыңны да яңартырсың, син бит булачак галим, кеше арасында матур, пөхтә киенеп йөрергә тиеш.

— Анысы шулай инде.

— Соң, эш нәрсәдә?

— Номерланган ич ул, Абрам Моисеевич.

— Дөрес әйтәсең, мәнә мин аны бүген язып та алдым: № 19-33.

— Кульязмага китапханә мөһере сугылган.

— Бусы да хак. Әмма мин ул мәшәкатьләрне үз өстемә алырмын.

— Касыйрдан нәрсә таләп ителә, Абрам Моисеевич?

— Ризалыгың.

— Сезгә ярдәм итәргә һәрвакыт әзермен.

— Мәнә рәхмәт. Ә син акча турында борчылма, күпме телисең, шул хәтле алырсың. Татар халкының кадерле ядкярен саклап калу ниятем.

Мусин кунагына өр-яңа фотоаппарат китереп тоттырды. Касыйр китапханәнең теләсә-кайсы китабына сугылган мөһер сурәтен шушы аппарат белән төшереп алырга тиеш булды. Тасма тапшырылгач, фотоаппаратның аспирантка бөтенләйгә калачагын искәртте Абрам Моисеевич, юмартланып.

Икенче көнне төшке ашка Касыйр чатыр чабып килеп тә җитте. Китап һәм кульязмалардагы мөһер сурәтен күпләп төшереп алган иде аспирант. Хәер, бу кадәресен Мусин үзе генә дә эшли ала иде анысы. Тик башкачарак фикер йөртте: кармакка каптыру өчен моны Черкиевтән эшләтте. Беренче адым ясалды, инде икенчесен, өченчесен атлатырга да була.

Ашап-эчкәч, Мусин аспирантның муенына вәгъдә ителгән фотоаппарат каешын кигезде. Хуҗа да, кунак та шушы чүп кадәрле гамәлдән канәгать булып калганнар иде.

— Хәзер нишлибез, Әдһәм абый?

— Әйдә, шаярта бир.

— Чыннан да, әйтик, минем күк шагыйрь булсагыз, шундый кушамат килешер иде үзегезгә. Әдһәм Муса... Шәп бит, ә!

— Минем шагыйрь дустым бар инде, шул җиткән. Ул — син, Касыйр.

Бүгенгә сүзләре очланды бугай. Касыйр китәргә җыенды.

— Кунып кына калмыйсыңмы, соң бит инде? — диде Мусин, эчке бүлмәгә ымлап.

— Юк-юк, булмаганны, без төнге берсез барыбер йокламыйбыз әле анда.

— Ихтыярың, алайса. Хуш хәзергә, кереп йөр, ял көнне чәйгә рәхим ит,— дип озатып калды аспирантны йорт хуҗасы.

Касыйр яһүднең тагын ни кылырга җыенуын ачык кына шәйләп бетерми иде. Шунысы мәгълүм: аңа Сәйдел Турай тапкан кульязма кирәк. Ә кульязма Кәүсәрия Галимова карамагында. Алдан сизенгәндәй, ярый әле шул кыз белән танышты, аның ярдәмендә ни дә булса майтарып чыгачак барыбер. Ләкин кызның үзенә сиздерергә ярамас, тәртәгә тибүе ихтимал, артык гадел, үзсүзле, баш-аягың белән сатып җибәрергә дә күп сорамас.

Мусиннардан аспирант шундый уйлар белән китте.

* * *

Университетта үзенчәлекле, көчле галимнең пәйда булуы күпләрнең йокысын качырды. Киң белемле, кыю фикерле, сүзен кистереп әйтә белүче галим болай гади солдат рәвешендә генә калмас шул, кимендә доцент дәрәҗәсен таләп итәр. Бигрәк тә татар теле һәм әдәбияты кафедрасы җитәкчеләре үзләре утырган урындыкның шуып китүеннән шүрләделәр. Сәйдел Турайга карата төрле мәкер ятьмәләре үрелде, әләкләр башланды, аның шәхесен кимсетердәй, дәрәҗәсен төшерердәй уйдырмалар уйлап чыгарылды. Бу эшкә кайбер шәкертләр дә тартылды...

Галим үзе, алдын-артын исәпләп бетермичә, самимилеге, гадилеге белән татар мәдәнияте үзәгенә омтылуы нәтиҗәсендә Казанга кисәк кенә кайтып төшкән иде. Шунда ук аны университетта укытырга калдырдылар. Шәкертләрнең беренче тулай торагыннан кечкенә генә бер бүлмә бирделәр — болары өчен ул җитәкчелеккә рәхмәтләр укыды, билгеле. Әмма гаиләсеннән аерылып яшәү җиңел булмаячагын да белеп тора иде. Ташкентта хатыны, ике баласы, өч бүлмәле фатиры бар. Берәр ай эшләгәч, хатыны белән балалары тулай торакта кунак булып киттеләр китүен, тик менә бөтен уңайлыклары булган фатирдан кечкенә генә бүлмәгә күчеп кайтырга җөрьәт итмәделәр, аерым фатир биргәнне көтәргә ниятләделәр.

Сәйдел Турай баш-аягы белән фәнгә чумды. Дәрестән соң сәгать кичке унга чаклы китапханәдә казынды, ул ябылгач, унбер-уникеләргә кадәр кафедрада шөгыльләнде, инде кайтып життем дисә, тулай торакта аны шәкертләре көтеп торган була. Ялтыраган такыр башлы, үзбәк түбәтәйле, урта яшьләрдән узып китүенә карамастан, гаять хәрәкәтчән, җор телле, артист кебек һәрчак, һәркемгә елмаю бүләк итүче өлкән мөгаллимне кызлар-егетләр дустанә яраталар, хөрмәт итәләр иде.

Бер генә кичне дә тулай торакка буш кул белән кайтып керми, сумкасында кекс, прәннек-печенье, тәмле-татлы шоколадлар була, кайчак тартмасы белән торт та күтәреп кайта. Чәй куеп, шәкертләрне шулар белән сыйлый. Аннары кызларга эш бүлеп бирә: кем «Кыйссаи Йосыф»ка карточкалар тутыра, кем «Җөмҗөмә солтан»ны күчереп яза.

— Син бүген ялгызың гына мыни Ниса-хан? — дип сорады мөгаллим, ишек төбендә үзен көтеп торучы Даутовадан. Гел шулай, Миңленисаның алгы өлешен кыскарта да ахырга «хан»ын китереп куша укытучы абыйсы.

— Кинога чакыручы булмагач, ишек төбен саклыйм шул менә,— диде кыз чытлыкланып.

— Мә, ач.

— Ачу гына түгел, эченә дә керәбез әле аның, Сәйдел абый, шулаймы?

— Ишек керер өчен ул Миңлениса-хан.

— Нисасы Ниса да инде, Сәйдел абый, ханы нәрсә соң аның? Егет кеше түгел ич мин хан булырга.

— Егеткә «җан» дияр идем, кызларга «хан» тиешле.

— Сәер икән үзбәк исемнәре.

Инде әйтелгәнчә, Ниса — чибәр, ут борчасыдай тере, бераз әрсезрәк, теле бер генә секунд та тик тормас, ә үзе саф күңелле, гади. Шуңадырмы, Сәйдел абыйсы аны башкаларга караганда яратарак төшә. Бүген дә алар икәүдән-икәү тәмләп чәй эчтеләр. Ниса үзбәк мәзәкләрен тыңлап рәхәтләнде.

— Җитәр, көлештек, инде эшкә утырыйк,— диде мөгаллим, кәгазьләрен актаргалап.— Син бүген Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан»ын күчереп бетер, язуың бигрәк матур.

— Үзем хужы шту-ли? — дип чыркылдады Ниса.

— Әйтерең бармы, кызый, бәяңне беләсең тагын...

Бу Нисада ниндидер Шәрекъ чалымнары ярылып ята: ук булып сузылган кашлар, нәзек туры борын, бантикланып торган калын иреннәр, очкын чәчрәткән карлыгандай кара күзләр сине каядыр тарих чоңгылына алып китә. Йосыфның Зөләйхасы түгелдер бит бу Ниса? Күлмәген тыгызлап торган тулы гәүдә — кызның тәмам өлгереп җитүен раслый. Юка күлмәген бүлтәйтеп ике алмасы калкып чыккан, монысы зифа буй-сынның өстәмә бизәге.

— Кайсы якныкы үзең, Ниса-хан?

— Әллә яучы җибәрәсезме, Сәйдел абый?

— Телеңә шайтан төкергән икән тәмам.

— Болгар иленеке мин.

— Төшенеп җитмәдем.

— Әлкидән.

— Мишәрмени?

— Безнең авыл гел татарча сүләшә.

— Сөйләшми, димәк.

— Юк. Әнә, Сәмия Мотыйгуллина яра инде мишәрчәне, ул Пәнҗәдән.

— Бүген кая соң әле үзе?

— Исләкәев белән киногә киттеләр, тегесе шуның артыннан шашып йөри ич.

— Бу кадәресе безнең эш түгел, Ниса-хан.

— Болай гына әйтүем, эш калдырып чапканга.

— «Кыйссаи Йосыф» карточкаларын бүтән кызга бирергә туры килер, ахрысы. Зачетың да тапшырасы бар аның,— диде укытучылары.

— Мин дә шуны әйтәм шул, Сәйдел абый.

Мөгаллим белән шәкерте шулай, гәпләшә-гәпләшә эшләп, сәгать ике тулганын сизми дә калдылар. Бер-беренә карата эчкерсезлек, үзара ихтирам итешү, олы белән кече булып калу аларны аеруча нык дуслаштырган иде.

— Син, Ниса-хан, чыгып йөрмә, әнә, минем караватка ятып йокла, мин менә монда идәнгә тәгәрим, бик ардырды бүген,— диде мөгаллим, одеалы белән мендәрен кочаклап.

— Әйем лә.

— Хәзер соң, йокла.

— Дәртегез почмаклансын, алайса, калам.

— Бер дә уйлап-нитеп сөйләшмисең сүзне, кызый.

— Нәрсәсен нитеп торасың инде аның Сәйдел абый. Калдым мин монда кунарга. Тыныч йокы Сезгә!

— Үзеңә дә.

* * *

Менә без сүз башындагы «шәкертләр тартылды»га да якынлаштык. Сәйдел Турай бүлмәсендә куныш калучы бер Ниса гына түгел иде, башкалар да аз йокламады ул бүлмәдә. Ләкин мөгаллимнәре кызларга ниндидер интим хисләр белән өметләнмәде, саташып, карават белән идәнне бутамады, хәтта тиешле-тиешсез сүз ычкындырып, аларны һич рәнҗетмәде. Сабый җанлы, гөнаһсыз бер адәм иде мөгаллим абыйлары. Аның өчен иляһилык кыйммәт, кешеләрнең үзенә карата булган җылы мөнәсәбәте, елмаеп караулары галимне күкләргә ашыра, илһамландыра — ул шуннан артыгын кирәксенми дә.

Шәкертләр арасында төрлесе бар иде, әлбәттә. Әнә курстан курска адашып йөри торган Эльза Бакирова үзе муеныңа сарылырга әзер. Мотыйгуллинасы, әлеге дә баягы, колхозда шофер белән яшәп кайткан, бер кичне: «Бүлмә кызларын уятып йөрмим, Сездә генә кунам, Сәйдел абый, икебез бер караватка ничек тә сыярбыз әле»,— дип конарсызланды.

Анысына, билгеле инде, зачет кирәк. Зачетны бит аны белемеңне раслап алалар, җан кисәгем. Карасаң-баксаң, үзе өчен генә дә сырпаланмый икән, Әлтүф Исләкәевнең беренче яртыеллыкта калган бурычлары хакында кайгыртып йөри — сукыр мәхәббәт менә нишләтә кешене, тар караватка да сузып сала. Анысына катырак бәрелде бугай мөгаллим, теге ишекне ачу белән шапылдатып чыгып китте.

— Бер исегезгә төшәр әле, шул чакта әйтермен мин Сезгә.

Монысын берничек тә аңлау мөмкин түгел иде. Ни әйтергә теләде Сәмия Мотыйгуллина — ул яңа укытучыга караңгы булып калды. Тагын бер атнадан барысы да ачыкланды. Кафедрада партия, профсоюз һәм комсомол оешмалары белән берлектә чираттан тыш җыелыш үткәрелде. Көн тәртибендә бер мәсьәлә: «Мөгаллим С. Тураевның шәхси эшен тикшерү!» Шәхси булгач, ни пычагыма дип җыйганнар соң бер көтү халыкны? Шәхси эшне гавәм белән тикшерәләр димени? Теге кыз әйтмешли, кемдә кемнең ни дәхеле бар? Нинди әхлакый кысаларга сыя бу кадәресе? Моңа җавап юк. Совет системасының кануны шул: телиләр икән, тикшерәләр, гаепилиләр, судка салалар, җәза бирәләр. Кирәк дип санасалар, ата җинаятьчене иректә саклыйлар, түрә итәләр, түшенә орден-медальләр тагалар.

Җыелышта иң элек шәкертләрнең кафедра мөдире Фатыйх Үпәй исеменә язган гаризалары укылды. Анда бәян ителгәнчә, кайбер шәкертләр Сәйдел Турай дәресләренә керүдән баш тарталар икән. Гаризага сырлап-сырлап имзалар куелган. Чигенерлек урын юк. Утыз җиденче елларда кулга алынып, Лаеш шулпасын татыган Ф. Үпәй тәмам коелып төште. Инде менә С. Тураев. Юк, яклый алмый Үпәй хезмәттәшен, өлкә комитетына язачакбыз дигәннәр бит.

Мөгаллим үзе моның кафедрадагы кайбер галимнәр тарафыннан оештырылуын белми иде, әлбәттә. Бүлмәдән бүлмәгә йөреп имза җыючылары — шул ук Исләкәев белән Мотыйгуллина, җитәкчелек күрсәтмәсен үтәүчеләр.

Ф. Үпәй җыелышны коры тотты:

— Хөрмәтле иптәшләр, мин сезгә турыдан-туры бер сорау бирәм: без нинди илдә яшибез, кайда укытабыз һәм кайда укыйбыз? Йәгез, кем җавап тота? Җавап бирүче юкмы? Юктыр шул! Ник булсын ул! Чөнки гаебегезне үзегез дә сизеп торасыз. Алайса, мин әйтәм: без барыбыз да Бөек Советлар Союзы дигән илдә яшибез, Бөек Ленин укыган университетта укыйбыз, шулай ук кайберәүләр безнең белән беррәттән шушы бинада укытып йөргән булалар. Совет студенты исемен күтәреп йөрүчеләр дә юк түгел. Гомердә күрелмәгән хәл, иптәшләр, данлыклы университетыбыз тулай торагында разврат,— бу сүзне кафедра мөдире Ф. Үпәй, көчлерәк яңгырасын өчен, юри урысчалап әйтте,— сөйләргә дә оят. Әмма ләкин без бу эшәке эшне болай гына калдырырга тиеш түгел. Сүзнең кем хакында барганын беләсез — бүген без Сәйдел Тураевның шәхси эшен тикшерәбез.

— Университеттан куарга кирәк!

— Егерме дүрт сәгать эчендә,— дип өстәде кайсыдыр.

— Ни өчен куабыз соң, конкрет әйткәндә?

— Сәбәпләр җитәрлек, яклаучыларсыз да ерып чыгарбыз,— дип кисәтте Үпәй, яшь галимне.

Җыелышта чыгыш ясаучыларның күпчелеге С. Турайны тәнкыйтьләде, аңа инде канатлы сүзгә үк әйләнгән «әхлакый череп таркалган» дигән тамга сугылды. Хәер, яшь укытучы Әһлетдинов белән шәкертләреннән Даутова, башкалардан аермалы буларак, Сәйдел Турайны уңай яктан телгә алдылар, аның фәнни эшен югары бәяләделәр.

— Хатның язылу сәбәпләре ачыкланмаган, кайберәүләр ни өчен дәрескә керүдән баш тарта, аңлатсыннар шушында,— диде Даутова, җыелышка салкын су бөркегәндәй.— Ә бүлмәгә җыелуыбыз гел эш өчен, ул карточкаларны без тутырган бит. Мин үзем дә Сәйдел абый бүлмәсендә куныл калгаладым, шуннан ни булган, ул кристалдай саф кеше...

— Тукта-тукта, Даутова,— дип бүлде аны Фатыйх Үпәй.— Шәкертләрне кундырып ятуы дөрес, димәк, син менә шуны раслыйсың, безгә башкасы кирәкми.

— Сезгә нәрсә кирәген мин белмим, Фатыйх абый, сүземне кыекка борып утырмагыз.

— Аңладык-аңладык, монда Тураевның икенче бер гаебе ачылды бит әле, иптәшләр,— шәкертләрне үз мәнфәгатьләрендә файдалану, ягъни мәсәлән, аларны эшкә җигә, замана эксплуататоры, мин әйтер идем. Ишетүемчә, студентка Эльза Бакирова да укытучысының бүлмәсеннән чыгып тормый ди анда. Дөресме шул, Бакирова!

— Без картотека тутырабыз.

— Алай гынамы икән?

— Тагын ни соң?

— Анысын сез әйтегез инде.

— Яше кырыкка җиткән кешедән нәрсә таләп итмәкче буласыз, мин аңламыйм,— дип, Бакирова бик тыныч кына җавап кайтарды.— Әгәр инде егетләр турында әйтсәгез, мин, әнә, Зөлфәт Гәрәевне алдым киттем үзем белән.

— Гәрәев! Монысы нәрсә, синеңчә?— дип, Фатыйх Үпәй инде аю гәүдәле Гәрәевне торгызып бастырды.

— Беркөн үзе белән пляжга төшкәнне әйтәдер Эльза.

— Шуннан, шуннан?

— Шуннан шул: урыс зираты аша кайттык.

— Ник кердегез анда?

— Эльза үзе әйдәкләде...

Үпәйнең һәркемнән сорау алуы малайлар үртәшен хәтерләтә иде. Әңгәмә төчеләнеп китте. Үпәй үзе дә, залдагылар да сизде моны, шунлыктан җыелышны кыскарак тотарга омтылды:

— Җитте, бүтән сөйләмә, полнейший разврат,— диде баягы сүзен кабатлап.

— Сөйләсеннәр, тагын нинди гаепләрем бар, зиратта мине очраткannармы соң?— диде Сәйдел Турай, тирән сарказм белән.

Шулчак кафедрада яшен яшьнәгәндәй булды. Президиум өстәле янына чүпрәк сумка тотып студентка Сәмия Мотыйгуллина чыгып басты. Галимгә бер караш ташлап, теге көнне әйттем бит мин Сезгә, дигәндәй, кинаяле елмаеп, сумкасыннан берәм-берәм эчке күлмәк, рейтуз, күкрәкчәише нәрсәләр тартып чыгара башлады, аларны Сәйдел Турай тарафына томырды.

— Менә боларны миңа Сез бирдегез, елышырга теләдегез. Кире алыгыз бүләкләрегезне.

Зал телсез һәм өнсез калды!

— Башта ник алдыгыз соң боларны?— дип кызыксынды Әһлетдинов.

— Бүлдермәгез, сөйләсен.

— Ник дип сорыйсыз, хәзер аңлатам анысын да,— диде Мотыйгуллина, яшь укытучы Әһлетдиновка ачулы караш ташлап.— Үзган ел колхозга эшкә баргач, мин бер шоферга кияүгә чыктым, язылышмыйча, әлбәттә.

— Ни өчен «әлбәттә»?

— Мин болай сөйли алмыйм.

— Кабатлап әйтәм: бүлдермәгез, иптәш Әһлетдинов,— дип кисәтте Үпәй укытучыны.— Дәвам итегез, Мотыйгуллина.

— Чөнки... Кайда калган идем соң әле? Әйе, чөнки гариза биргәч, үзегез беләсез, сынау срогын үтәргә, бер ай көтәргә кирәк. Ә безең кайтыр көн килеп җитте. Сез бу мәсьәләдә бик төпченмәсәгез икән, чөнки бу минем шәхси эшем. Мин уйлыйм: бәлки Тураевны шушы вакыйга җилкендергәндер дип. Бусы — нигезе. Хәзер конкрет сүзгә күчәм. Сәйдел Турай үзенең дәресләрендә борынгы Шәрекъ әдипләрен пропагандалый.

Минемчә, безгә аларның һич кирәге юк, студентларның болай да башы каткан, дәрестә өлгермиләр. Әнә, кайберәүләрнең ярты ел буе зачетлары тапшырылмаган, димәк, белемнәре җитенкерәми, вакытында тиешлесен ала алмаганнар. Кыскасы, студентлар бүгеннән башлап Сәйдел Турай дәресләренә керүдән баш тарталар,— дип, Мотыйгуллина кискен төстә урынына барып утырды.

Шулай итеп, сәбәбен төшенмичә, гаебен ачыкламыйча, бердәнбер портфилен күтәреп, Сәйдел Турай, кайчандар күңелен җилкендергән, зур өметләр баглаган Казан каласыннан Ташкентка кире кайтып китәргә мәҗбүр ителде.

...Алга китеп шуны әйтик, энциклопедик гыйлемгә ия булган Сәйдел Турай Ташкентта алтмыш өчтә — нәкъ Пәйгамбәр яшендә дөнья куйды. Кемнәрдер аның бай китапханәсен вагонга төяп, Казанга алып кайттылар. Һәм ул хәзинә эзсез югалды. Элек, Советлар Берлеге елларында музейга тапшырылган мирасыбызның күп өлешен Санкт-Петербургка, Мәскәүгә озату гадәткә кергән иде, әйтмим китап-кулъязмалар дип, татар халкының башка милли кыйммәтләре дә, хәтта, Имәнкискә авылы зиратындагы борынгы кабер ташлары да вагонга төяп Мәскәү тарафына озатылды. Югыйсә, ул ядкярләр «Бегемот» дигән йортның томаланган капкалары эчендә күп еллар сакланган да иде, кайсы кяфернең күзе кызыккандыр шуларга?! Сәйдел Турай китапханәсе дә, күз буяу өчен генә калдырылган әсәрләрне искә алмаганда, «үзәккә» озатылганмы, әллә инде Казан залимнәре тарафыннан үзләштерелгәнме — ул кадәресе билгесез. Бүген моңа җавап тотучы юк. Ахирәттәге сыман гөрзи орып сорау аласы иде үзләреннән. Менә бүген, дөньялыкта!..

Теге каһәрләнгән җыелыш үткәннең икенче атнасында, тулай торактагы бүлмәләренә кайтышлый, балчык күпер тирәсендә Әмир Әһлетдиновның поезд астына эләгеп өзгәләнгән гәүдәсен табып алдылар. Кемнәр белән йөргән, кемнәр белән кайткан ул кичне Әһлетдинов, ничек итеп ике яр арасындагы поезд юлына барып эләккән — аларын ачыклаучы табылмады. Ә бит күндезен күреп, белеп торучылар булган. Ахырдан андыйлар авызларына су каптылар. Тикшерүче беркетмәсендә: «Үлемнең сәбәбе — поезд астына эләгү, башка сәбәпләр ачыкланмады»,— дигән сүзләр генә язылган иде. Туры сүзле яшь галимнең хатыны, ике баласы тулай торакның кечкенә бер бүлмәсендә яшәп калды. Алар хакында инде кем кайгыртыр, кафедрадан кем фатир юллап йөрер?! Тәмам туйдырган икән Әһлетдинов житәкчеләрне шул торак мәсьәләсе белән. Барысы бергә өелеп килгәндер, мөгаен.

* * *

Фатир бәласе Касыйр башына да килергә мөмкин, әгәр немканы җайлый алмаса. Немка — университетның алман теле укытучысы Бауши. Яшь галим булып йөргәч тә, Черкиев кандидатлык минимумын тапшырып бетермәгән иде әле, алман телен бер елга кичектереп тордылар. Ә вакыт дигәнең узды да китте. Хәзер инде Бауши чын-чынлап чыгымларга кереште, телне өйрәнүне, тиешле егерме мең сүзнең тәрҗемәсен таләп итте. Диссертация темасы да бик тапталган булып чыкты, «Татар әдәбиятында совет патриотизмы» күпләргә галимлек дәрәҗәсе китерсә дә, фәнгә әллә ни яңалык өстәмәде. Хәзер галимнәр үзләре дә аның мәгънәсезлеген таныйлар, теманы дәвам итүнең кирәге калмады. Көймә комга терәлгән очракта Касыйрны тулай торактан сөрәчәкләр, фатир эзләми дә ярамас.

Абрам Моисеевичка шулар хакында сөйләп, эчен бушатты аспирант. Тегесенең моңа әллә ни исе китмәде, уенга гына борып җибәрде.

— Нәрсә әйтә сезнең Тукай бу очракта: «Шагыйрь күңелендә кыш булмый да кар яумый», диме? Дөрес әйткән бит, күңеленә кар яумасын да боз катмасын. Калганы җайлана аның, дөньясы бер алман маржасына гына килеп терәлмәгәндер.

— Терәлгән шул, Абрам Моисеевич, бүген генә алман телен өйрәнә алмыйм ич инде мин.

— Шигырь яз!

— Һәр студент шигырь яза хәзер.

— Синдә илаһи тавыш. Шагыйрь булмасаң, җырчы ясарбыз. Бүген үк Хаим белән таныштырырмын үзеңне, анысы өчен кайгырма. Менә бит әле мин сиңа нәрсә әзерләп куйдым,— дип, төйнәлгән кульяулык почмагын чишеп җибәрде Мусин.

— Ни бу?

— Китапханә мөһере, «Татполиграф» егетләре күз ачып-йомганчы эшләп бирделәр, хәрефендә димим, өтерендә дә хилафлык юк — төгәл тәңгәллек!

— Нишләтәбез инде моны, Абрам Моисеевич!

— Ашыкма.

Хуҗа кеше кесәсеннән алтын чылбырлы кечкенә генә ачкыч тартып чыгарды, аннары чикләвек агачыннан ясалган зур комодның аскы тартмасын тартып ачты. Анда бизәкләп эшләнгән бик матур шкатулка бар икән. Менә әкәмәт, китап зурлыгындагы шул шкатулка кәгазь акчалар белән шыплап тутырылган. Мусин тиз-тиз генә шытырдап торган йөзәрлекләрне санады да аспирантка сузды.

— Бераз аванс алып тор әле, Черкиев, кирәк-яракларыңны карарсың.

— Ни өчен?

— Дустымның хәерчелектә яшәвен теләмим. Ал, ал!

— Шушы кадәрнеме?

— Аванс бу, аванс.

Шуннан соң Мусин шүрлектән бер кочак китап күтәреп килде. Барысы да гарәп хәрефләре белән басылган, шуларның берничәсе матур кул белән язылган кульязмалар иде.

Башына кайгы төшкән кеше шикелле, кулларын җәеп, юеш иренен тагын да юешләп, яһүд тәкърарларга керешге:

— Үзең күреп торасың, Касыйр, менә никадәр хәзинә монда, гомер буе җыям. Әгәр дастанның берәр китабы булса, мөһерне шуңа шапылдатыр идек, нишлисең бит, моңарчы кулыма төшмәгән. Инде нишләргә дисеңме? Минемчә, менә боларның берәрсенә төшерик тә мөһерне, теге кульязманың номерын язып куярбыз. Туксан бернең берсе безгә күчкәннән дөнья җимерелмәс, татар милләте өчен тырышабыз лабаса.

«Чура батыр»ның титул битенә һәм китапханәләр өчен закон буларак кабул ителгән унҗиденче биткә әлеге мөһерне сугып, 19—33 санын язып куйдылар. Китап белән кульязманы алыштырасы гына калды.

— Мөһер шәп чыккан,— дип мактады Касыйр.

— Инде эш синдә, дускай.

— Тырышып карармын.

— Сак эшлә, кабаланып, сиздерә күрмә! — дип кисәтте Мусин аспирант егетне.

— Кәүсәриянең ышанычын яуларга кирәк миңа.

— Киногә алып бар, театрга чакыр, акчаңны кызганма. Тагын өстимме әллә?

— Юк-юк, Әдһәм абый, җиткән монда.

— Ярар, соңыннан алырсың, сиңа дигән сиңа булыр,— дип килеште Мусин.

Шул кичне үк китап «барышнигы» аспирантны «Казан» ресторанында музыкант булып эшләүче Хаим Моисеевич белән таныштырды. Кул

биреп күрештерү генә түгел, иртәгедән башлап үз ансамбленә җырчы итеп алырга боерды.

— Бу хакта нинди сүз булуы мөмкин, Абгам, баш өсте, что син,— диде Штырштейн, ризалыгын белдереп.

— Галим кешегә ресторанда җырлау килешерме икән соң, Абрам Моисеевич?

— Ние бар аның, җыр сәнгате белән шөгыльләнәсең ич — барыбер иҗат, төшеме бар, тамагың да тук булыр бер очтан.

— Ну-ну, Абгам, нигә кысасың, егеткә җайлырагын да табабыз, аның,— дип, элеп алды Хаим дигәне.— Минем бер төркем кинотеатрда эшли бит, анда Роза Салихова янына нәкъ менә ирләр тавышы кирәк. Сеанс саен унбиш сум — ел дигәндә аспирантың чын капиталистка әйләнәчәк. Что син!

— Бусы бата моның,— диде Касыйр, килешеп.

Менә бит ул, бирим дигән колына — чыгарып куяр юлына! Эшләре көйләнде аспирантның. Кинотеатрда сеанс башланыр алдыннан тамашачыларга егерме минутлык концерт. Төшкә кадәр Роза Салихова җырлый, ул төштән соң буш түгел, эшче яшьләрнең кичке мәктәбендә укыта, ә Касыйрга көндез университетта, китапханәдә булырга кирәк — кич аңа уңайрак. Көнгә өч-дүрт концерттан кырык биш-алтмыш сум кереп кенә тора. Якшәмбе һәм бәйрәм көннәрендә концертны бергәләп үткәрәләр, көндезге сәгать уннан кичке унгача. Тамашачы канәгать, концерт бушлай булгач, тыңлыйлар, гөрләтеп кул чабалар, артистларга да күңелле.

Абрам Моисеевич өчен ниләр майтарсаң да үкенечле түгел, юмартлыгы, илгәзәклеге бар. Төкерә Касыйр аспирантурасына, әгәр эшләр алайга китсә...

* * *

Кәүсәрия — авыл кызы, төпле, акыллы бала, җилбәзәкләрне җаны сөйми. Укыганда университетның тулай торагында яшәде. Укуын тәмамлагач, җыйнаклыгын, төгәллеген, китап яратуын, тикшеренүгә һәвәслеген искә алып, аны фәнни китапханәдә эшкә калдырдылар. Югыйсә, авылларында быел сигезъеллык мәктәпне унъеллыкка әверелдерәбез, укытучылар җитми, эшкә үзебезгә сора, дип, директорлары хат та юллаган иде, ничектер Казан ымсындырды үзен. Болай, син хәзер шәкерт түгел дип, тулай тораклан да чыгармадылар, әмма кыз, фатир табып, бер әби янына күчеп яши башлады. Баштарак тулай торакта калдырганга куанган да кебек иде, соңрак әби белән килешеп киттеләр: татар карчыгы, пөхтә, намаз-ниязлы, кич кайтырына ашарына пешереп тора, фатир хакы сорап тинтерәтми, анысын Кәүсәрия үзе белеп бирә. Җан рәхәте. Шуның белән хәзер барысы да көйләнгән шикелле иде.

Кайдан килеп чыкты соң бу Касыйр тагын? Чат ябышты Кәүсәриягә, өйләнешәбез дә өйләнешәбез, дип сагызлана. Көннәр буе китапханәдән чыкмый, рәтләп укыган китабы да юк үзенең. «Туктале, бераз йөрик, бер-беребезне белик, гадәтләребезне өйрәник»,— дип тә карады Кәүсәрия, һаман үзенекен тукый. Касыйр болай чибәр егет, үткенлеге, кыюлыгы бар, тик һәрнәрсәдә арттырып җибәрә төсле, тотнаксызлык күрсәтә, ихлас түгел. Бер карыйсың, китап җене кагылгандай китапханәдә актарына, икенче карыйсың, шагыйрь булам дип лаф ора, инде менә мин артист, ди. Чыннан да, кинотеатрда концертлар куеп йөри, акчаны көрәп ала, имеш. Моңарчы нинди дер бер яһүд белән дуслашкан иде, хәзер икенчесен тапкан, соңгысы гаҗәеп фамилияле — Штырштейн, телеңне сындырырсың, билләһи! Тегесе Абрам Моисеевич иде, бусы — Хаим Моисеевич, таба бит чебеннәрен дә. Башын әйләндермәсәләр ярый инде.

Юкка гына көлде бугай Кәүсәрия музыкант фамилиясеннән, сонрак кирәк булачак әле ул аңа. Ничек кенә әле!

— Диссертацияңне нишләтәсең? — дип кызыксынды Кәүсәрия, өстәл тирәли уралган Касыйрдан.

— Фатыйх Үпәйгә кереп чыгарга исәп, Бауши белән үзе сөйләшсен, күпме йөрергә була шул фашист теле аркасында. Ә эш әйбәт бара минем. Үзең күреп торасың, Кәүсәрия, туйга акча җыям, көн-төн чабам,— дип зарланды Касыйр, шүрлекләр арасына кереп китеп.

— Анда бик тугыланма, ачуланалар, чит кешегә ярамый,— диде кыз.

— Мин читмени?

— Китапханәче түгел ич.

— Ерунда. Бәлки сиңа булышамдыр.

— Үзем дә өлгерәм.

— Йә инде, матурым, ачуланган булма, без бүген иртәрәк китик әле,— дип, егет кызның иң башларыннан кочып алды.— Менә монда бер адрес биргәннәр иде, берәүләр Эт тыкрыгында фатирга кертәләр икән, шуны барып карыйк, дигән идем, ошаса, күчеп, бергә яши башларбыз.

— Иске авыздан яңа сүз.

— Ничек?

— Шулай.

— Өйләнүне әйтәсеңме?

— Юк, сөйләнүне әйтәм. Сиңа кем кияүгә чыгам дип тора әле монда. Базардан кәҗә сатып алмыйсыңдыр ич, ачуым килмәгәе.

— Юләр син, матурым,— дип, Касыйр тагын кызга елышты.— Туйга дигән акчаны күптән тупладым инде мин, анысын болай гына әйтәм. Барысы да кешечә булачак, хәтта бераз арттырып та җибәрербез әле. Рәт бар хәзер. Синең белән килештек бит инде.

— Андый хәл булмады, Касыйр, син уйлаганыңны әйтәсеңдер, гомумән, эш урынында ул хакта гапләшмик, яме.

— Соң әйдә, чыгабыз, бар, ю кулыңны, үзем каравылда калам.

— Биш минут бар әле.

— И, ходаем, харап икән, син кул юганда биш минутка узып та китә ул.

— Ярый алайса, мин хәзер, тик кара, студентлар кереп йөрмәсен монда.

— Юк инде, юк!

Касыйрга шул гына кирәк тә. Кульъязманың урынын белә, бер көн укып утыргач, «Кыйссаи Йосыф»ны Кәүсәриянең кайсы шүрлеккә, илтеп куйганын карап торды. Ике атлап, бер сикерүдә барып та житте, кульъязманы кесәсенә бөтереп тә тыкты, аның урынына «Чура батыр»ны калдырды. Булды гына бу! Инде Касыйр беркайчан да шүрлекләр арасына кереп йөрмәс, кирәге калмады...

Кыз башта ук фатир эзләргә каршы иде. Урамга чыккач та Эт тыкрыгына барудан баш тартты. Әмма Касыйрның бирешергә исәбе күренми, күңеле күтәренке, илһамы ташый иде, Кәүсәриянең бер алдына, биш артына төшеп бөтерелде, үгетләде, ялварды.

— Барып кына карыйк, килгән өчен акча сорамаслар, ошатсам, торып та калырмын, миңа барыбер фатир кирәк булачак, туй алдыннан син дә күчәрсең, хәзер синнән башка бер көн дә яши алмам кук,— дип, Касыйр туры төбәп атарга керешге.

Алар фатирда күп дигәндә бер ел яшәячәкләр икән, аннан үз куышлары булачак. Дуслары бар, акчасы житәрлек Касыйрның. Шул чор эчендә ике бүлмәле фатирны җайлый алмаса, тота да Чыңгыз тавына барып өй сала. Кәүсәриягә тормыш мәшәкатьләре тимәячәк. Тик Касыйрны читкә генә этәрмәсен, кайнар мәхәббәткә кайнар мәхәббәт белән генә җавап кайтарсын.

— Икебез дә пешеп һәлак булмабызмы соң, Касыйр?—дип көлде кыз беренче мәртәбә, егеткә каты бәрелмәскә тырышып.
— Син минем бәямне белеп бетермисең әле, Кәүсәрия.
— Акчалы егет кыйммәт йөридер, мөгаен.
— Шулай шул.
Эт тыкрыгындагы фатир бер катлы агач йортның подвалында булып чыкты. Шактый гына зур бүлмәне урталай бүлеп, ике яклы ясаганнар, кухня өлешен аерып куйганнар, юыну урыны шунда ук, бәдрәфкә ишек алдына йөрисе.
— Айга алтмыш сум булыр,—диде хуҗа хатын.
— Күбрәк түгелме соң, апай?
— Икебезгә дисез ич, утызардан шулай чыга лабаса. Тагын икешәрдән икегезгә дүрт кубометр утын, анысы ел буена. Кыш чыгарга барыбер җитми ул утын, сездән килгән акчага үзем сатып алам. Кеше бәясе, миңа артыгы кирәкми. Акчасын әйтәм, ике-өч айга алдан түләп куйсагыз, үзегезгә җайлы булачак. Сез әнә теге бүлмәдә торырсыз, кызым белән без менә монысында. Ул быел эшкә керде, кондитер фабрикасында.
— Апай, хәзергә мине исәпкә алмагыз, ярыймы, ул үзе генә яшәп торыр,—диде Кәүсәрия, икесен дә гаҗәпкә калдырып.
— Бәтәч, ничек була инде анысы?
— Хәлләр шулайрак безнең.
— Ә-ә, аңладым, арагызга дошман кергән, алайса.
— Ие.
— Ул чакта бәя кырык биш сум булыр, бүлмә биләгәч, шулай тиеш.
— Ярый, апай, ярый, Касыйрның акчасы аңа гына җитәр,—дип, Кәүсәрия килешүне йомгакларга ашыкты.
Касыйрның чәчләре үрә торды.
— Син ни маташтырасың монда, Кәүсәрия?
— Хатын-кыз сөйләшкәндә ир-ат тик торсын иде ул, апай, әйеме.
— Шулай, наным, бик дөрес әйтәсең.
Кәүсәрия фатир эзләүдән Касыйрның телен кисеп чыкты. Югыйсә, мин дә мин, ул гына белә дә, ул гына хуҗа, ул гына әллә кем. Булмый торсын әле! Кыз, гадәттәгечә, апаларына кунакка барырга ашыкты, ә Касыйр шуннан туп-туры Комлев урамына күтәрелде. Чәпчеп әллә кая китә алмассың бер дә, гадел китапханәче дигәч тә. Гаделлек менә монда хәзер—Черкиевнең куен кесәсендә, әйдә, олага бир...

* * *

Шундый четерекле эшне аспирант көне-сәгате белән майтарып чыгар, дип көтмәгән икән Мусин. Кульъязманы алгач, балалар шикелле куанып, Касыйрга килеп сарылды, аны күтәреп әйләндерергә тотынды, ничек җенләнүен күреп, тегесе яһүднең чын фанатик булуына тагын бер мәртәбә төшенде. Синең тарихың турында уйлыймы, әллә күбрәк үз мәнфәгатен кайгыртамы—анысы караңгы. Мәче җиргә сырты белән төшмәгән кук, яһүд абзаң да аркасы белән егылмас, бу кадәресе тормышта сыналган бит инде. Синең алда тәлинкә тота, икән, димәк, төп башына утыртырга җыена. Мусин да үз эшенә җигәргә дигәндә, каршында тал булып бөгелә, елан булып шуыша. Кызганыч, ахирәтенең бу серле гадәтен Касыйр гына чамалый алмады. Бәлки, сизенгәдер дә, әмма теге шкатулкадагы йөзлекләр көчлерәк тәэсир иткәндер, аңын томалагандыр, күрәсең. Ничек кенә димә, эшләнәсе этлек эшләнгән иде инде. Шул хөрмәткә дип, Фреда Ароновна табын әзерләгәнче, берәр рюмка коньяк салып эчтеләр.
— Бүген бездә кунасың,—диде хуҗа.
— Сез нәрсә инде, Абрам Моисеевич!

— Җибәрмим. «Тарзан»ның соңгы сериясен дә карыйсың бар. Мин хәзер,— дип, Мусин тагын теге әкәмәт шкатулканы өстерәп чыгарды.

— Егет икәнсең, тәк-тәк, эһем-эһем, менә сиңа төгәл биш мең сум — Мусин акчаны күз алдында берәмләп санап бирде.

— Мин ни...

— Канәгатьме син?

— Бик җиткән, Абрам Моиссевич. Күп бу, теге көнне дә бирдегез ич.

— Әйдә, ал-ал!

— Киләсе буыннарга саклыйм, дисез бит кульязманы.

— Моңа бәя куя алмаячаклар берзаман, син шуны аңлыйсыңмы, дускай, рәхмәт үзеңә.— Мусин әле һаман да тынычлана алмый иде, күрәсең, китапханәсенең бер башыннан икенче очына туктаусыз йөреп торды.

Кичке аштан соң вәгъдә ителгән кинофильмны карадылар. Аннары кофе эчтеләр. Абрам Моиссевич кунакны йокы бүлмәсенә озатып куйды. Әмма чыгып китәргә ашыкмады, журналлар өстәле янына барып утырды. Икенче кәнәфине Касыйрга тәкъдим итте.

— Кофе тиз генә йоклатмый ул, бераз гәпләшеп алыйк,— диде хуҗа, өстәлдәге бәллүр савытны Касыйрга таба этәрәк төшеп. Ә анда сап-сары кипкән йөзем иде.— Капкала, йокы өчен ифрат файдалы җимеш, нерв системасын көйли.

Абрам Моисеевич китапханә хәлләре, андагы тәртипләр белән кызыксынды, татар халкының тагын нинди онытылган мирас-хәзинәләре булуын сорашты, аларны ничек җыярга, нинди юллар белән кулга төшерергә мөмкин, дип белеште. Имештер, ул да шушы юнәлештә татар халкына изге хезмәт күрсәтергә омтыла, җыйган китаплары тарихка калачак — аның бүтән максаты юк икән. Бераз маташтыра, әлбәттә. Фәнни китапханәдә әнә мең еллык китап-кульязмалар да саклана. Мусинның сүзен җөпләсә дә, бердәнбер кульязмаларны китапханәдән чыгарырга ярамаганлыгын төшенә иде Касыйр. Ә «Кыйссаи Йосыф»ка килгәндә, аның тагын йөз алтмыш данәсе калды бит әле, киләчәктә дә табылыр. Хакын шәп түләде ич, үпкәләп булмый яһүдкә.

— Сез әйткәннәрне истә тотармын, Әдһәм абзый, хәзер тәмле төшләр күрергә кирәк миңа, йокы басты, катырак төшердек, ахрысы,— диде Касыйр, сүзне уенга борып.

— Фреда Ароновна ишетсә, егылып көләчәк синнән.

— Беләсезме, Абрам Моисеевич, кунак нинди төш күрсә, барысы да йорт хуҗаларына була, имеш. Минем әби шулай ди торган иде.

— Ярый, иртән сөйләрсең төшеңне. Тыныч йокы!

— Үзегезгә дә, Әдһәм абый.

— Ну, шаян да син, артист тек артист...

Әллә, чыннан да, коньяк-кофесы күбрәк киттеме, әллә башка сәбәбе булдымы, Черкиев төн буе саташып чыкты. Гел китапханә шүрлекләре арасында буталды, ниндидер кара сакаллы адәмнәр пычак тотып куып йөрде үзен. Ул да булмый бугаздан эләктереп алалар, буыла, бастырыла башлый, каравыл кычкырып уяна. Иртән торганда баш куйган мендәре манма су иде, оятыннан Касыйр аны әрә-әрә, селки-селки киптереп азапланды.

Иртәнге аш янында инде бөтенләй тузга язмаган нәрсәләр хакында сөйләп куандырды аспирант йорт хуҗаларын. Имештер, Мусиннар ниндидер Алтын сарайда яшиләр икән, тирә-яклары яшел бакча, бакчада аллы-гөлле чәчәкләр, агач башында төрле-төрле кошлар сайрый, ә чәчәкләрдә берсеннән-берсе матур күбәләкләр. Хәйран-тамаша, җир оҗмахы! Ни күрсен, чәчәкләр арасыннан Абрам Моисеевич белән Фреда Ароновна култыклашып бара, артыгыздан, күбәләкләр белән шаярып, патша кызы булып киенгән Берта Абрамовна атлый. Сезне куып җитте дә икегезгә дә берәр чәчәк бүләк итте.

— Безгәме? Ике чәчәкме? Ишетәсеңме, Абгам?!

— Иң кызыгы алда әле, Фреда Ароновна. Чәчәк өчен рәхмәт әйттегез, нәрсә турындадыр сөйләштегез. Менә шулчак каршыгызга тарантаска җигелгән алтын тояклы, ефәк яллы бик шәп ат килеп туктады. Кузлада яшь кучер утыра икән. Әйтә бу:

— Мин Берта Абрамовнаны алырга килдем, аны Сарайда патша улы көтә,— ди. Сез куанып елашырга тотындыгыз. Минем әби әйтә торган иде: төштә елау — өндәге шатлык ул, дип. Димәк, сезгә дә шатлык киләчәк.

— Шуннан, шуннан,— дип куырды Фреда Ароновна.

— Шуннан — утырган да шуган, Берта Абрамовна, тютю!

— Йә, Аллам, Абгам, ни була инде бу?!

— Сезгә шатлык килә, дидем бит инде, Фреда Ароновна. Бер дә борчылмагыз, кызларга гомер буе әти-әнисе янында яшәргә димәгән...

— Касыйр дөрес әйтә.

— Бездә, яһүдләрдә кызны алып китмиләр бит, Касыйр, кияү үзе кәләш йортына күчеп килә.

— Шулай булуы да бик мөмкин. Монда гамәл турында сүз бара, Фреда Ароновна.

— Ярый, алайса, хәерлегә юрыйк.

Төш һәм аны юрау аеруча тәэсирле килеп чыкты, югыйсә, кичтән дә уйлап ятмаган иде Касыйр иртән ни сөйләргә тиешлеген. Тегеләр өчен тавык төшенә тары ярмасы кергәндәй булды. Бертаның кияү куенына иңәсе, бәлки матур-матур оныклар алып кайтасы бар икән әле. Хуҗалар каршында Черкиевнең дәрәҗәсе бик нык үсте.

Мусиннар белән саубуллашкач, Касыйр тагын Эт тыкрыгына төшеп китте. Инде фатирга урнашасы бар иде аның, тулай торактан барыбер чыгарга туры киләчәк.

* * *

Казаннан китәр алдыннан Сәйдел Турай китапханәгә кереп, үзе тапшырган кулъязманы тагын бер актарып карарга ниятләгән иде. Бәлки, берәр урынын күчереп алырга уйлагандыр. Кәүсәрия галимгә карточка тутырырга кушып, кулъязманы алырга кереп китте. Кат-кат актарды шүрлекне — кулъязма табылмады. Шул тирәдәге башкаларының да астын-өскә китерде, ә ядкяр берсендә дә юк иде. Эрегән, җилгә очкан диярсең. Инсафлы адәм башына сыймаслык әхлаксызлык инде эшләнгән: сигез гасыр буе тормыш зилзиләләрен исән-имин кичкән, күпләр тарафыннан иң борынгы дип йөртелгән «Кыйссаи Йосыф» поэмасының кулъязмасы — татар халкының кыйммәтле мирасы фәнни китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк очрый торган китаплар хәзинәсеннән эзсез югалган иде. Аның урынына киштәгә, исәпкә алу кенәгәсендә күрсәтелгәнчә, шул ук 19—33 саны белән «Чура батыр» менеп кунаклаган. Титул битенә китапханә мөһере сугылган. «Чура батыр» да әдәби мирас, билгеле, әмма ул тарихыбызның соңгы чоры ядкяре, берсе икенчесен һич тә алыштыра алмый бу очракта. Димәк, кулъязманы урлаучы ни дәрәҗәдә явызлык кылуын белеп эш иткән.

Хәлне аңлап, Сәйдел Турай да өнсез калды. «Барысы да бетте, димәк»,— диде дә ишеккә таба юнәлде. Кәүсәрия күз яшьләре белән аның юлын бүлде.

— Миңа ни була хәзер, Сәйдел абый? — дип инәлде.

— Кая куйдың соң?

— Теләсә-кая куярга бүген генә эшләмим бит инде мин.

— Димәк, урланган.

— И Аллам, ниләр генә кылыйм икән? Сәйдел абый, әйтегез, нишләргә кушасыз? Китмәгез, ичмасам!

— Сиңа берни булмас анысы, тарих югалган менә. Карап чыгасы урыннары бар иде үземә дә.

— Үләм, үләм, яшәмим дөньясында! — дип үкседе яшь китапханәче.

Галим сумкасын идәнгә куеп, кыз янына килде, аны юатырга тырышты, күңеленә ышаныч салды. Башка галимнәр, студентлар белән дә сөйләшеп чыгарга кушты — бәлки, берәрсе яздырмыйча гына алып торгандыр?

— Ярый, Галимова, минем Ташкентка китеп барыш, бөтенләйгә, сәгать дүрттә поезд. Борчылма, бер эзенә төшәрсең бәлки, шунсыз булмый ул, — диде Сәйдел абыйсы кызны юатып. — Әгәр кульязма табыла калса, хәбәр итәрсең, белеп торырмын. Менә Ташкенттагы адресым, җыеп куй, югалтма. Хуш хәзергә, бирешмә, күңеленне төшермә, эзлә дә эзлә, тапмыйча туктама, җиде-сигез гасырлык тарихыбыз, әдәби җәүһәребез бит ул, шуны онытма, Галимова.

— Сез дә киттегезмени инде, Сәйдел абый! Кем белән киңәшергә соң миңа? Бу эшне болай гына калдырырга ярамый ич инде, — дип, чәбәләнеп-чәбәләнеп елады китапханәче кыз.

Эш зурга китте. Бүлекне махсус комиссия төзеп тикшерделәр, ревизия ясадылар. Әгәр кульязма урынына, исәп-хисап санын язмыйча, мөһерсез китап кына куйсалар, караклыкны төшенергә дә мөмкин булыр иде, монда бит урлашу мөһер сугып, сан язып башкарылган, димәк, китапханә хезмәткәрләреннән берәрсенең кулы уйнаган. Җинаять эшен турыдан-туры Галимовага китереп бәйләделәр, чөнки матди җаваплылык аның өстендә иде.

Елаудан тәмам шешенеп беткән Кәүсәрия, суга батканда саламга ябышкандай, йөгереп Бауман урамына төште, билет-фәлән алып тормастан, кинотеатр фоейсена узды, артист Черкиевкә дигәч, үткәрделәр тагын. Концерт икенче кат фоейсенда бара иде, түземсезлек белән Касыйрның җырлап бетерүен көтеп торды. Бигрәк сузды тегесе дә, ичмасам, урысча җырлаган була, сүзләре гел татарча. Ниһаять, тамашачылар кинозалга тарала башлады, буш фоейда җырлауның хикмәте калмады. Касыйр өтәләнеп Кәүсәрия янына килеп тә җитте. Кыз аны кулыннан җитәкләп бер кырыйга өстерәде.

— Килдеңме, матурым, ник төсең киткән?

— Туктат әле шул кәнфитләнүеңне, зинһар, эшләр шәптән түгел минем, зинданга ябып куюлары да ихтимал. — Кыз яңадан еларга керешге.

— Ни бар? — дигән булды Черкиев, үзе шунда ук хәлне төшенеп тә алды. Шома гына үтәргә тиеш түгел иде шул теге атнадагы «кул юу» вакыйгасы.

— Әйт әле, Касыйр, «Кыйссаи Йосыф»ны укырга син алып тордыңмы?

— Менә әкәмәт, нишлим мин аның белән.

— Теге чакларда гел шуңа ябыштың ич.

— Сәйдел Турай бик мактагач кына караштырдым, минем диссертациягә катнашы юк ул әсәрнең.

— Урлаганнар, — диде Кәүсәрия.

— Кит аннан!

— Нишләргә дә белмим менә.

Сөйләшүнең барып чыкмаячагын сизеп, Кәүсәрия тактиканы үзгәртергә булды. Күңелендә давыл котырса да, бәгыре сызласа да, сер бирмәскә тырышып, Касыйрның култык астына сыенды, тегене эретүенә өметләнде.

— Бу бәладән коткарсаң, бары син генә коткарасың, бәлки студентлардан берәрсе яздырмыйча алып торгандыр. Йә үзем ялгыш бүтән шүрлеккә илтеп куйганмындыр, хәтерләмим, тәмам башым катты, — диде кыз, күзләрен сөртеп. — Өстәлемә кире кертеп куйсалар, бәладән котылыр идем анысы. Мин әллә синең портфельдә киттеме, дигән идем. Шулай да кайткач, актарып чык әле бер.

— Актарырмын анысы, юклыгын беләм түлке.
— Үзең кайда торасың соң? — дип кызыксынды Кәүсәрия.
— Бер атна теге хатыннарда яшәдем, үз кызыннан үзе көнләшә торган нәмәстә булып чыкты ул хатын, понимаешь, шуңа киттем, фатир өчен түләгән акчам әрәм калды. Подвалда череп ятканчы, юньлерәк фатир эзләрбез,— дип, яңалыкларын тезде егет.
— Миндә фатир кайгысы түгел хәзер, син дә ярдәм итмисең.
— Чык ул эштән, Кәүсәрия.
— Китмәсәм дә куачаклар, әгәр утыртып ук куймасалар. Кешеләрдән хурлык, валлаһи, башларымны кайларга алып олагасы икән? Теге чакта туган авылыма кайтмавыма үкенеп бетә алмыйм хәзер. Йә, берәр җылы сүз әйтә аласыңмы син бүген, табылыр, дип ышандырасыңмы мине?
— Кайдан табыйм?
— Шүрлекләр арасына синнән башка берәү дә кереп йөрмәде, Касыйр. Мөһер сугып, уйлап эшләнгән явызлык бу!
— Нәрсә, әллә миннән шикләнәсеңме?
— Чыны шулай ич!
— Миндә синең кайгың түгел, үземнеке үземә җиткән,— дип, әйтеп ычкындырды Черкиев, кызның аптыратуына каршы.
— Шулайдыр шул, бүтән минем янга аяк басасы булма,— дип, Кәүсәрия кырт борылды да аскы катка йөгереп төшеп китте.

Егетнең үзенеке үзенә җиткәнен Кәүсәрия белми иде, әлбәттә. Хуҗа хатын иртүк торып меховойга эшкә йөгерә, ә уналты яшьлек кызы Венера, икенче сменага барганлыктан, йоклап кала. Венера, яшенә караганда күп өлкән күренә, чөнки әнкәсенә охшаган — эре гәүдәле, тәмам пешеп җиткән чагы. Юынганда, чәй куйганда кыз ягына күз салгалап узды Касыйр. Венера йокы аралаш юрганын идәнгә тибеп төшергән, болай да кыска эчке күлмәге җыерылып өскә таба күтәрелгән, баганадай юан ботлары ачык, бер генә сыпырып карамыйсыңмы, дигәндәй, ап-ак булып, күзне кызыктырып тора. Аяк очларына гына басып Касыйр кыз бүлмәсенә барып керде, караватчитенә килеп утырды.
— Йоклыйсыңмы соң,— дигән булып, кызның уң ботына бармак очларын тиерде. Ой, нинди кайнар! Кыз кинәт күзләрен ачып җибәрде, куркып, торып ук утырды, кыска күлмәгенең итәкләрен тарткалады.
— Сез нишлисез?
— Мин менә...
— Хәзер үк чыгып китегез үз бүлмәгезгә.
— Йә инде, шулкадәр шаулама.
— Шаулау гына түгел, каравыл кычкырам, бөтен йортны күтәрәм, чыгыгыз!
— Ит яхшылык, көт явызлык инде бу, Венера!
— Нинди яхшылык? Алып бирегез юрганны идәннән һәм китегез моннан.
— Эшкә кайсы сменага барасың, дип сорамакчы идем.
— Күрсәтермен мин сезгә сменаны, ато, белмисез!
— Шулай да сөйләшәсе иде синең белән, Венера,— дип, һаман да сагызланып маташты Касыйр.
— Или мин кычкырам.
— Ярар, ярар, чыгам, дөнья җимереп разбой саласы юк,— дия-дия чигенергә мәҗбүр булды мәхәббәт «каһарманы».

Төнге сәгать уникедә, кызы икенче сменадан кайткач, иртән ни булганын белеп, хуҗабикә Касыйрның очтыкыен очырды. «Чыгып кит, күземә күренмә, иртәгә университетыңа барам мин синең!» — дип дулады хатын.
— Апай, бер генә сүз әйтәм, тыңлагыз әле,— дип ялыныргa-ялварырга керешә Черкиев.— Иртәгә иртүк китәрмен, Венераны эшкә уятырга дип кенә кергән идем, ялгышканмын, ул тавыш куптарды. Мин сезнең

икегездән дә бик нык гафу үтенәм, зинһар, зурга җибәрмик. Дуслар булып калыйк, апай җаным! Иртән үзегез белән бер ишектән чыгармын. Төн уртасында кая барыйм хәзер, начарлык эшләмәдем ләбаса. Ачу саклый күрмәгез берүк?!

Гафу сорап, матур итеп ялынгач, хуҗабикә йомшара төште, шул ук вакытта җиткән кыз янында ир-ат тотуның ярамаганлыгын абайлап, гаепнең бер өлешен үзенә алды.

— Ярый әле пропискага кертеп өлгермәдем,— дип куанды апай.

— Әйтәм аны хатының күтенләде баштан ук, юньсезлегеңне сизгән икән.

— Хатын түгел ул, йөргән кызым гына.

— Йөргән кыз белән фатирга керәләр димени, тиле. Күңелең кара синең егет, иртәгә ук үкчәңне күтәр, бигайбә...

Менә нинди бәлага тарыды кичә Черкиев. Акылына сугып, теге хатын университетка килеп йөрмәсә ярый инде. Берәр тартма шоколад кертеп чыгар иде дә, үзләренеке бар, Венерасы ташып кына тора. Бәлки, икесенә дә берәр косынка-мазар бүләк итәргәдер, күңелле яшәгән өчен, рәхмәт әйтеп. Монысы җитди гамәл булачак, нәкъ Мусинча. Яхшы кешеләрдән үрнәк алырга кирәк бу дөньяда.

* * *

Китапханә тирәсен кара сөрем сарды. Галимнәр бер-берсе белән сөйләшмәс булды, студент халкы курсташына күтәрелеп карарга базмады. Кешеләр үз күләгәләреннән дә шикләнә башладылар. Моңа университетка килгән тикшеренүчеләрнең күбәеп китүе сәбәп иде, һәркайсын дастанның язмышы кызыксындырды. Хәер, барысын да түгел: Дәүләт иминлеге комитетыннан килүчеләр югалган мирасны эзләп табу урынына, чит ил шпионы үтеп кермәдеме икән, дип төпченде.

Таякның авыр башы, билгеле инде, китапханәче Кәүсәрия Галимова аркасына төште, аны, хезмәт турындагы Законның кайсыдыр матдәсен кулланып, эшеннән кудылар. Хәзер инде китап тирәсеннән ерак киткән, Казан кинотасма фабрикасына гади эшче булып урнашкан иде ул. Бәлки, хезмәт кенәгәсендәге теге матдә мәҗбүр иткәндер, фабрикага синең Кызыл дипломыңның бер тиенгә дә кирәге юк. Бүлектә кайсы галим, аспирант һәм шәкертнең ешрак чуалуын, укыр өчен карточканы кемнәрнең күбрәк тутырганын тикшерү әле һаман да дәвам итә, фамилияләр ачыклана — каракның эзенә төшәргә җыеналар. Милли хәзинәнең югалуына чын-чыннан кайгыручылар да бар.

— Нинди милләтчелек ялкыны ул тагын, сүндерәбез аны,— диде Абрам Моисеевич, Черкиев килеп сөйләгәннән соң.

Шапырынадыр бу, юри тынычландырыр өчен әйтәдер, дип уйлаган иде Касыйр, яһүднең сүзләре хак булып чыкты. Икенче көнне университетта барысы да тынып калган, элеккечә гамьсез генә дәвам итә иде. Гаҗәп шулай да?! Хәтта Иминлек комитетыннан килүчеләре дә: берни юк, тыныч кына эшли бирегез, дип киткәннәр.

Мусин серне ачты. Ул партия өлкә комитетының бүлек мөдире булып эшләүче яһүд дусты Бушканга шалтыраткан икән, ә теге үз чиратында Югары уку йортлары һәм идеология бүлекләренә җиткергән. Шуннан башлана инде ялкынга салкын су сиптерү, дерелдәтерлек итеп сиптерәләр. Өлкә комитетыныкылар университет җитәкчеләрен берәмберәм утлы табага бастыралар, милләтчелекнең тамырын корытырга вәгъдә итәләр.

— Студентларга белем бирәсе, иҗади эзләнүләр белән шөгыльләнәсе урында милли хисләр белән мавыгасыз, тулай торакларда фахешханә ачкансыз, безгә барысы да билгеле. Карагыз аны, моның ахыры яхшы булмас,— дип кисәтә идеология бүлеге мөдире Армавиров, телефоннан.

— Разврат мәсьәләсе болай,— дип аңлатырга ашыкты Фатыйх Үпәй, утыз җиденче елларны хәтергә төшереп. Ул заманда бер чиркан-чык алган иде абзагыз, шуңа да хәзер тиресеннән чыгып кылана, ләббәй-кәлекнең бөтен нечкәлекләрен белеп эш итә.— Чыннан да, бездә андый берәү табылган иде, гомуми җыелыш ясап кудык үзен, беркетмәнең бер нөсхәсен хәзер үк китереп тапшырырмын кулыгызга. Калган яклар— тәртип. Сез әйткәннәрне истә тотарбыз. Сәгать ничәләрдә кабул итәрсез икән? Бик күп рәхмәт, мин килеп җитәрмен...

Шау-шу тынган иде инде, болары теш күрсәтү өчен генә булып алды.

— Көч бар икән үзегездә, Әдһәм абый,— диде Касыйр, яңадан элеккеге хаятенә кайтып.

— Шаяртасың, димәк, барысы да тәртиптә.

— Китапханәче кыз бәйләнә генә бит, югыйсә, син генә йөрдең шүрлекләр арасында,— ди.

— Инде тынычлан. Миңа «Төхфәи мәрдән»не вәгъдә иткән идең, онытa күрмә.

— Белмим шул, тәртипләр үзгәрде хәзер анда.

— Тәртипләр үзгәрде дип, син китергән «Кыйссаи Йосыф»ны кире илтеп бирмәбездер ич, мәңгелек төрмәгә кереп утырасың килмидер бер дә.

— Сез нәрсә инде, Абрам Моисеевич.

— Һич ашыктырмыйм, үзең белеп, җайлап кына дим.

— Баш тартканым юк лабаса.

Черкиев менә хәзер генә үзенең нинди тәбегә килеп эләгүен шәйләде. Кара син аны, ничек суктырып кадый йөрәккә, яһүдне хәйләкәр төлке диләр аны, дөрес икән. Бүтән кульязма тәтемәс, билгеле, җае да юк хәзер, акча түгел, алтын түләсә дә булмый. Шулай да, Мусин белән араны бозарга ярамый, кертеп утыртырга да күп сорамас. Артыгын кыса башласа, берәр районга укытучы булып китәр дә барыр анысы, эз югалту өчен. Аның белән бала чукындырасы юк.

Теге көнне кызы өчен ярсыган хатынны Касыйр косынка белән тәмам җайлады, китапханә мәсьәләсендә тынычланды. Кәүсәрия белән араның өзелүенә күнекте, хәтта сөенде дә. Тик менә Үпәйдән генә хәбәр-хәтер юк, сөйләшә алганмы-юкмы Бауши белән— билгесез. Хәер, бу көннәрдә каты эләкте аңа өлкә комитетыннан, тиз генә айный алмас шул. Татар мәдәниятенә керткән олы хезмәтләре өчен гафу иткәннәрдер инде бер юлга. Касыйр сабыр итәргә булды.

Аның каравы, кинотеатрда эшләре көйле. Хәзер алар ресторанда да чыгыш ясыйлар. Бернинди ояты юк икән ресторанда җырлауның, дәрә-җәлерәк тә әле. Еш кына концерт бирәрсенең өстәле янында, шампан шәрабе эчә-эчә дәвам итә. Заказ биреп җырлаталар да акчаны йөзәрләп кенә томыралар. Кереме шәп! Ашау-эчү түләүсез. Шулкадәр кәттә киенде Касыйр, Бауман урамыннан барганда иң якын дуслары да танымыйча узып китәләр. Үзе дәшеп туктаткач кына аһ-уһ килеп сарылалар егеткә, мактыйлар, көнләшүләрен яшермиләр.

— Ялгызыңа кала барысы да,— диде бер кичне хезмәттәше Роза Салихова.

— Аңламадым.

— Мин китәм, Петрозаводск театрына чакыралар.

— Бөтенләйгәме?

— Әлбәттә.

— Үзең белән мине дә алмыйсыңмы соң, Роза туташ?

— Опера театрынамы?

— Ә нигә?..

— Башта сиңа консерваторияне тәмамларга кирәк, минемчә.

Роза Салихова— Себер кызы, Тубыл педагогия институтында укы-ган, аннары Мәскәү Консерваториясенең вокаль классын тәмамлаган. Милли кадр дип, Казанга җибәргәннәр. Әмма опера һәм балет театрын-

да буш урын булмаганлыктан, Роза кичке мәктәптә укытып йөри. Шул ук вакытта, тавышын югалтмас өчен, ресторанның тәмәке төтененә ысланган залында җырларга мәҗбүр. Тавышы көчле, башкаруы профессиональ югарылыкта, аңа сүз әйтерлек түгел. Ниһаять, игътибар иткәннәр, профессиональ сәхнәгә чакыру алган. Китәчәк, әлбәттә.

Концерттан соң Касыйр кызны фатирына чаклы озатып куйды. Күпме бергә эшләп, тәүге мәртәбә. Роза үзен һавалырак тоткангамы, ничектер, моңа кадәр озата барырга кыюлыгы җитмәде Касыйрның. Бүген исә, форсаттан файдаланып калырга ниятләде.

— Сине Казанда калдырып булмады, ахрысы, Роза туташ.

— Нишлисең бит.

— Әгәр алданрак үтенгән булсам?

— Сәбәбе?

— Сәбәбе дип, дуслык югала.

— Әллә анысына юл куяр идеңме,— дип көлде кыз, көлтә чәчен артка сирпеп.

Чибәр кыз иде Салихова. Озын буйлы, ак йөзле, аксыл чәчле, күк йөзедәй зәңгәр күзле, йөргәндә тавис кош сыман көязләнеп кәз-кәз атлый, гәүдәне тиешенчә генә уйната. Роза елмайганда, кинәт тәрәзәдән Кояш иңгәндәй, тирә-як яктырып китә. Менә хәзер дә ул төнге караңгылыкны балкытып, Касыйр күңеленә очкын ыргытты.

— Хатны язарбыз анысы,— диде Черкиев, кызның шаяртуын туры мәгънәсендә аңлап.

— Кунакка килерсең,— дип, Роза егетне бөтенләй васвасәгә салды.— Шулай да консерватория турында уйлап кара әле, Касыйр, вокаль белемең юк бит синең.

— Беләм.

— Килешеп, тату эшләвебез өчен рәхмәт яусын үзеңә!

Кыз тагын бер очкын ташлады. Монысы очкын гына түгел, ниндидер өмет ялкыны булып тоелды Черкиевкә. Күңеле кубып, ул хезмәттәшенә, аннан да битәр, чибәр кызга нәрсәдер әйтергә җыенган иде, әмма Роза саубуллашып, тизрәк кереп китәргә ашыкты.

— Ярый, вакыт соң, мин керим, иртәгә Штырштейн бүлмәсендә очрашырбыз, кечкенә генә хушлашу мәҗлесе үткәрергә җыенам, килми калма тагын.

— Аллам сакласын,— диде Касыйр, куанычыннан капка баганасын кочаклап.

Шушы бер-ике атна эчендә Черкиев башыннан әллә никадәр вакыйгалар кичте. Сөенечлесенә караганда көенечлеләре күбрәк булды. Ләкин аның кемне дә булса гаепләргә хакы юк — кылган гамәлләре гел үзенеке иде.

* * *

Галимнәр, «Кыйссаи Йосыф» дастаны һәм татарның башка тарихи җәүһәрләре хакында тагын дистә еллар буе дәшми торырга мәҗбүр ителде. Әгәр шул чакта дастан урланмыйча, тавышгауга кубарылмаган булса, бәлки Сәйдел Турай кузгатып җибәргән йөк тиешле урынына барып та житәр, кульязма аерым китап рәвешендә басылып та чыгар иде. Кызганыч ки, игелекле эшнең юлына киртә корылды.

Кәүсәрия Галимова, югалган ядкәрнең эзенә төшеп булмасмы дип, берничә ел рәттән талпынып карады, әмма элеккеге студентлар белән очрашып, тагын кемнәрнедер күреп сөйләшү генә нәтиҗә бирмәде. Бу эштә аспирант Черкиевнең кулы уйнаганлыгын сизә иде ул, тик тотынып жире юк, жепнең очы нык яшерелгән булып чыкты. Кая куйган, авылына озатканмы, берәрсенә биргәнме — хәзер ничек ачыклыйсың инде, вакыт

дигәнең уза тора. Шунысы аңлашылмый: нигә кирәк булды икән Черкиевкә кульязма? Икенче бер китапка мөһерне ул гына сугарга мөмкин, ник дигәндә, өстәл янында Черкиевтән башка кеше буталмады, ә өстәл тартмасы бикле түгел иде. Мөһер шунда ята. Үзен тагын бер күреп сөйләшим, дип, эзләп тә карады — табылмады «кияү егете». Шунысы ачыкланды: диссертация белән эшләре барып чыкмаган, хәтта минимум имтиханнарын да тапшыра алмаган, шуңа аспирантурадан сөргәннәр үзен, ресторан сәхнәсенә дә юлы ябылган — бер кичне исерек хәлдә кемнәргәдер бәйләнгән, өстәлләр җимереп сугышкан, унбиш тәүлек утырып та чыккан. Дөрес, соңрак сынау срогы белән берәр ай балалар газите редакциясендә эшләп йөргән, тик анда да төпләнеп кала алмаган, хезмәт кенәгәсен кире тоттырып озатканнар үзен.

Берәр елдан соң тагын шунысын ишетте Кәүсәрия: элек бергә җырлап йөргән артистка Роза Салихова артыннан каядыр төньяк өлкәләрнең берсенә чыгып киткән Черкиев. Шул китүеннән Казанга әйләнеп кайтмаган, яшьләр арасындагы бер низагка эләгеп, кыйнап үтергәннәр бичараны. Һәрхәлдә, авылга, әниләренә шундый хәбәр килеп төшкән. Бәлки ресторан тирәсендә бөтерелеп, эчкечегә салышкандыр, безгә гонаһысы тимәсен. «Кыйссаи Йосыф»ны Касыйр туганнарына кайтармаган булып чыкты.

Шундый күңелсез хәбәрләрдән соң Кәүсәрия беркадәр сүрелә төште, әмма Сәйдел Турайның «эзлә дә эзлә» дип, өзгәләнеп әйткән сүзләрен бер генә көнгә дә хәтереннән чыгармады. Тик кемгә барып сыенырга, нәрсәдән тотынырга кирәклеген белмәде. Чүплеккә ыргытыр өчен алмаганнардыр бит инде дастанны, ул чакта, мөһер сугып, икенче бер китапны куеп калдырмаслар иде шүрлеккә. Кеше башына мәңге бетми торган гомерлек хәсрәт килсә килә икән ул...

Кәүсәрия шактый сазап кына чыкты кияүгә. Ире әйбәт кеше, бергә эшлиләр. Аннары бер-бер артлы кызлары туды. Гаилә ишәйгәч, иске йорттан булса да өч бүлмәле фатир бирделәр — Маяковский урамыннан. Эшкә йөрергәераграк ерагын, аның каруы, фатирлары шәһәр үзәгендә тыныч урында.

Тыныч урын дигәннән, ял көннәрендә Кәүсәрия еш кына якындагы Эрмитаж бакчасына чыгып утыра. Монда тавышланып, музыка акыртып йөрүче яшь-җилкенчек күренми диярлек, гел карт-коры да бала-чага, көмәнле хатын-кыз саф һавада рәхәтләнеп ял итә, берәү дә килеп сине бимазаламый. Күпләр бер-берен белә, таный, исәнләшеп уза яки янына утырып әңгәмә куерта.

Шулай беркөнне Кәүсәрия, эскәмиядә йокымсырап утырган картка игътибар итте. Кем соң әле бу? Юк, хәтерләми. Кеше каршында кукыраеп тору килешми, әлбәттә, ханым уңайсызланып, арырак атлады, хәтерен эшкә җикте. Юк кына бит, кем дип әйтергә дә белми, ә бабайның йөзе таныш. Ул тагын бер урап узарга ниятләде. Тукта-тукта, хәтерләде ич, исем-фамилиясе ничек соң әле? Фамилиясе бик сәер иде шул, онытылган. Исеме менә...

— Исәнмесез, Абрам Моисеевич!

— Хәерле көн. Әмма сез ялгыштыгыз, мин Абрам Моисеевич түгел.

— Ничек?

— Шулай, Хаим Моисеевич булганга.

— Зинһар, гафу итә күрегез, Хаим Моисеевич, аз гына бутадым, ахрысы.

— Була торган хәл.

Карт кабат черем итәргә ниятләп, башын арткарак чөйде, күзләрен йомды. Кәүсәрияне үз юлы белән китеп барыр дип уйлады, ахрысы.

— Утырырга мөмкинме, Хаим Моисеевич!

— Рәхим итегез, монда иркенлек.

— Сездән гафу үтенәм,— дип башлады Кәүсәрия сүзен.— Мине хәтерләмисез, әлбәттә. Сез бит атаклы музыкант, «Татарстан» кинотеатрында эшләдегез.

— Булды андый чаклар да,— диде яһүд карты, мактауга кәефе килеп.
— Ансамбльдә җырлаган Черкиев дигән егетегезне хәтерлисезме?
— Ничек, ничек?
— Черкиев фамилияле.
— Юк бугай, онытылган инде.
— Алтмышынчы еллар башында сезнең ансамбльдә Роза исемле кыз белән бергә җырладылар. Хәтерләгез әле, Хаим Моисеевич!
— Статный гына, кара бөдрә чәчле егетне әйтәсездер, исем-фамилиясе онытылган шул.
— Нәкъ үзе. Мин аның танышы идем, концертларыгызда булгаладым,— дип, иркенләп аңлатырга керешә Кәүсәрия, картка таба шуыша төшеп.— Ничектер, мин сезне Абрам Моисеевич дип хәтерләп калганмын.
— Андый кеше дә бар иде.
— Китап сөючеме?
— Нәкъ үзе.
— Миңа шул Абрам Моисеевичны табарга кирәк. Сез ярдәм итә алмассызмы икән?
— Нигә кирәге чыкты кинәт кенә?
— Үзен күреп сөйләшермен дигән идем.
— Моннан өч ел элек дөнья куйды Абгам.
— Шулаймыни?! Әйбәт кеше иде.
— Сез хаклы, күгәрченкәем.
— Гаиләсе исәндер бит?— дип төпчендә ханым.
— Фреда Ароновна үзенә чаклы ук вафат булды шул.
— Фатирларында берәү дә калмадымы хәзер?
— Кызлары исән әле.
— Күрештерсәгез икән, Хаим Моисеевич?— Кәүсәриянең алай тиз генә бирешәсе, борылып китәсе килми иде.
— Йөрергә читенсенәм,— диде яһүд карты, гамьсез генә.
— Машина белән килеп алып, китереп куяр идек, Хаим Моисеевич. Зинһар, үтенечемне җиргә салмагыз, егерме өч ел буе көтеп алдым мин бу көнне.
— Сәер, әлбәттә.
— Теге егетнең әманәтен тапшырасым бар,— дигән булды Кәүсәрия, картның кире төнүеннән шүрләп.
— Ә-ә, алай дисәгез генә...
— Калганын үзләренә баргач, сөйләшербез, Хаим Моисеевич.
— Теге якшәмбедә шушында көтәрмен, көндезге унберләр тирәсендә,— дип җаваплады карт.
— Алдан ук рәхмәтләр инде Сезгә, хөрмәтле Хаим Моисеевич, ышанып торам, алайса.
— Исән булыгыз.

* * *

Әйтелгән көннең әйтелгән сәгатендә яһүд карты үзенең «пропискага» кергән эскәмиясендә, гадәттәгечә, йокымсырап утыра иде. Кәүсәриянең куанычы эченә сыймады, әйтерсең, эскәмиядә карт түгел, дастанның кульязмасын калдырып киткәннәр. Иренә артыгын сөйләшмәскә кушып, сәлам бирергә ашыкты.
— Хәерле иртә, Хаим Моисеевич.
— Ә-ә,— карт күзләрен ачты,— килдегезме, исәнмесез!
— Машинаны бакча буенда калдырдык, Хаим Моисеевич, кузгалыйк алайса. Бу минем ирем — Басыйр.
— Штырштейн,— диде карт, ниндидер горурлык белән.
Көннең кызулыгы турында гәпләшеп, әкрен генә чыктылар бакчадан. «Жигули» янына да килеп җиттеләр. Басыйр, картны утыртырга

дип, кабаланып ишекне ачты. Керәм дигәндә генә кинәт Штырштейн артка таба чигенде.

— Шулай да кешене борчуыбызга төшенеп бетмәдем, хөрмәтлеләрем,— диде ул, Кәүсәриягә мөрәҗәгать итеп.

Хатынның коты ботына төште. Бар да бетте болай булгач. Нишли бу исәр карт?! Ничек тә җайларга иде үзен.

— Әйткән идем ич, Хаим Моисеевич, теге егетнең әманәте бар, дип.

— Нинди әманәт соң ул — шунысын искәрмим. Үзе ник килмәде?

Аңлатырга, нәрсәдер сөйләргә кирәк хәзер моңа, югыйсә, борыла да китә. Шикләнүчән халык диләр иде үзләрен, дөрес икән.

— Үзе төньякта, Коми республикасында яши, кайта алмый,— дигән булды Кәүсәрия.— Әманәте шул: Абрам Моисеевичларда китабы калган, шуның язмышы белән кызыксына, югалтмасыннар иде, ди. Зинһар, үтенечебезне кире какмагыз, бик дуслар иде ич, үзегез дә беләсездер.

— Хәтерләдем, ансамбльгә Абгам китергән иде ул егетне. Әйдәгез, барыйк.

— Сезне борчыдык инде.

— Кирәк, димәк ки.

Штырштейн машинада дип, бер дә куанмады Кәүсәрия, киресенчә, шик-шөбһә дәрьясында чайкалды. Ничек килеп чыгар бит әле алга таба, Абрам Моисеевичнең кызы өенә кертерме, сөйләшергә теләрме, үзен ничегрәк тотар? Ишек төбеннән кире борып җибәрүе дә ихтимал. Менә бусы да машинага утырдым дигәндә чыгымлый башлады ич. Икесе бер үк тамырдан. Ә анда кульязма турында сөйләшергә кирәк, хәлне ачыкламыйча ярамый. Тик ядкяр генә табылсын иде!

Хискә бирелеп, Кәүсәрия яһүдне игътибарсыз калдырган иде. Башына төрле юк-бар уй килмәсен тагын дип, шикләнә куйды. Игътибарын җәлеп итәргә кирәк, салпы ягына салам кыстырсаң да комачауламас.

— Хаим Моисеевич, мин әле сезнең чәчәк аткан чагыгызны хәтерлим. Казан каласында сездән дә оста скрипкачы юк иде. Ул оештыру сәләтегез тагын, нинди шәп ансамбль төзедегез бит. Ә җырчыларны ничек сайлап ала идегез! Роза Салихова дигән артистканы өлкә театрына турыдан-туры сезнең ансамбльдән чакырып алдылар, минемчә. Шәһәрдә исем-фамилиягезне белмәгән кеше калмагандыр,— дип, үз рухына каршы килеп булса да, Кәүсәрия музыкантны мактап барды. Штырштейнны шулай гына кулда тотарга кирәклеген чамалый иде ул.

— Берта Абрамовна, кунаклар алып килдем, каршы ал,— диде Хаим Моисеевич, керә керешкә.— Телефоннан хәбәр иткән идем бит. Абрам Моисеевичнең элеккеге дуслары болар.

— Узыгыз, уз.

Кәүсәрия иренә баш какты, тегесе шунда ук төшенде, култык астына кыстырылган ике тартманың берсен хуҗабикәгә сузды.

— Кечкенә генә күчтәнәч.

— Рәхмәт, мәшәкатьләнмәскә иде.

— Бусы сезгә, Хаим Моисеевич.

— Миңа нигә инде?

— Кайткач, хатыныгыз белән чәй эчәрсез, Сезнең кебек өлкән кешене бимазалап йөрибез шунда,— дигән булды Басыйр.

Мусиннарның китапханәсе зурлыгы ягыннан район китапханәләреннән ким түгел икән. Залдагы киштәләр арасында тар аралыклар гына калдырылган. Кәүсәрия элек үзенең китапханәдә эшләвен, матбугатны бик яратуын әйтте. Йомышын йомышлаганчы китапларга күз салырга рөхсәт сорады.

— Басыйр, сез Хаим Моисеевич белән гәпләшә торыгыз.

— Алайса, мин тиз генә чәй куеп җибәрим әле,— дип, Берта Абрамовна кухня ягына чыгып китте.

Абрам Моисеевич чын-чыннан китап сөюче булган икән шул, барысын да алфавит тәртибендә тезгән. «Р» хәрефе язылган киштә турына

килеп җиткәч, Кәүсәрия туктап калды, «рукопись»ны шүрлыннан эзләргәдер бәлки, «Научный» дигәне юктыр инде шөт. Киштә кырыенда, китаплар алдында таныш агач кисәген күреп алды хатын, бу — овальформасында эшләнгән китапханә мөһере иде. Кәүсәриянең башы әйләнеп китте, күз аллары караңгыланды, йөрәге дөпелдәп типте. Ничек килеп эләккән монда мөһер? Ул беркайчан да югалмады бит. Әллә соңыннан урланганмы? Кәүсәрия эштән киткәч. Алай дисәң, «Чура Батыр»га мөһер ул эшләгәндә сугылган иде ич. Димәк, үзләре ясаганнар. Хәер, бүген моның әһәмияте юк инде. Тынычланырга да кульязманы эзләп табарга кирәк.

Кәүсәрия шашынып «Р» киштәсендәге китапларны авыштырырга кереште. Роллан, Рерих, Распутин, Рэхтау... Менә кульязмалар: «Акбузат», «Бакырган», «Кыйссаи Йосыф»... Дастанны кулга алуга, Кәүсәрия хәле китеп, идәнгә үк чүкте, калтыранды, куанычыннан нишләргә дә белмәде. Кульязмадагы мөһер дә, үз куллары белән язган исәп саны да аермачык ярылып ята. Барысы да аңлашылды. Кульязма белән мөһерне үз урыннарына куеп, Кәүсәрия кухняга, Берта Абрамовна янына ашыкты, аулакта икәүдән-икәү генә сөйләшергә иде аның нияте.

— Сез гәпләшә торыгыз,— дип, узып китте ул ирләр янынан.

Фатирлары берничә бүлмәле икән Мусиннарның. Шунда Берта Абрамовна бер ялгыз башы яшәп ята, димәк. Ә алар ике бала белән егерме елга якын унике квадрат метрда чиләнделәр. Хәзер дә күпме кеше фатирсыз интегә. Менә сиңа тигезлек!

— Берта Абрамовна, сез Касыйр исемле аспирант егетне хәтерләмисезме болай? Фамилиясе Черкиев. Кара гына, чибәр кеше.

— Мине патша улына кияүгә чыга дип, әнинең котын очырган адәмне әйтәсездер, мөгаен. Төшендә күргән, имеш. Ул әкиятче егетне бик яхшы хәтерлим, бездә кунгалап йөрде, фәкыйрь студент дип, әти кызгана иде үзен. Ә мин барыбер иргә чыкмыйча картайдым менә. Ни булган дидегез егеткә?

— Хафаланырлык нәрсә юк. Еракта яши ул хәзер — Коми республикасында.

— Юк-барны сөйләп ташладым, ахрысы. Сезгә кем тиешле? — дип сорады хуҗабикә, уңайсызлана төшеп.

— Кайчандыр минем арттан чапкан иде.

— Иске дусларны оныта алмыйсыз, димәк.

— Сез бигрәк инде, Берта Абрамовна, шаяртмасагыз да була,— диде Кәүсәрия, сүзне ничек башларга белмичәрәк аптырап.— Мин китапханәдә эшләгәндә шул егет бер тарихи кульязманы алып торган иде, китереп тапшырырга онытты. Ул хәзер сездә саклана икән, Берта Абрамовна.

— Ялгышасыз, бездә кеше малы юк. Һәммәсе дә әтием Абрам Моисеевич тырышлыгы белән тупланган, аның истәлеге бу китапханә.

— Зинһар, авырга алмагыз, Берта Абрамовна, кульязма сездә.

Хуҗа хатын кулларын алъяпкычына сөртеп алды, аннары аларны җәеп җибәрде, иреннәре калтыранды, күзләре зәһәрләнде, битләренә ут капты, ниндидер ачу катыш гаҗәпләнү иде аның йөзендә. Беркадәр сүзен әйтә алмый интекте, ниһаять, Кәүсәриягә ук кадагандай итте.

— Кеше фатирында актарынырга ничек оялмыйсыз?

— Черкиев хәбәр итте,— дип ялганларга мәҗбүр булды Кәүсәрия, чия төсле кызарып. Җир ярылса, җир тишегенә кереп китәр хәлдә иде ул бу мизгелдә.

— Саклана, димәк, әйбәт.

— Сез аны безгә кире сатмассызмы икән, Берта Абрамовна?

— Һәйкәлләр сатылмый, гражданка.

Көймә комга терәлде. Әңгәмә мондый ясссылыкта барыр дип һич уйламаган иде Кәүсәрия. Әллә инде үзе кешечә сөйләшә белмиме? Хәзер үк куып чыгаруы да мөмкин, башка бу йортка аяк баса алмассың аннары.

Ничек кенә тотынырга соң? Мондый туры юлдан барып рәт чыкмаячак, анысы көн кебек ачык хәзер. Штырштейн алдында тавыш куптарырга да ярамый. Һәрнәрсәдә дипломатия булырга тиеш ләбаса.

— Сүз сөйли белмәвемне кичерә күрегез, Берта Абрамовна,— дип, яңадан башлады Кәүсәрия.— Менә ничә еллар инде диссертациямне тәмамлый алмыйм, бер-ике сәгать эчендә кулъязманы укып чыгарга иде ниятем, әгәр рөхсәт итсәгез, күчереп аласы урыннары да бар. Минем өчен бик мөһим бу кадәресе. Иртәгә шушы вакытларда килеп китәр идем, каршы килмәсәгез.

— Шуннан башларга иде сүзне, югыйсә, маклер шикелле алу-сатудан тотындыгыз,— диде хуҗабикә, йомшара төшеп.

— Ай, нинди генә рәхмәтләр әйтим икән Сезгә.

— Әйдәгез, чәй эчик, хәзер ирләрне чакырам,— дип, Берта Абрамовна китапханә залына юнәлде.

Уф! Бүген берни майтарып булмаячак монда. Икәүдән-икәү генә сөйләшеп хәл кылынырга тиешле нәрсә бу. Уйлап эш итәргә кирәк, артык күз, артык колак зыян салырга мөмкин. Гомерендә ялганны белмәгән Кәүсәрия бүген әнә ниләр сөйләп ташлады бит. Сәнгать корбаннар сорый, дип бик белеп әйткәннәр. Барып терәлсәң, намусыңа каршы килеп сөйләнәсең икән ул юк-барны. Үзе өчен түгел, милләт, тарих турында кайгыртып басты бу юлга Кәүсәрия, шуңа җаны гарьләнә, әмма түзәргә туры килә. Хаклык җиңсен өчен.

* * *

Кичтән, теге чакта үзе биреп калдырган адрес буенча Ташкентка, Сәйдел Турайны телефоннан сөйләшергә чакырып заказ ясады Кәүсәрия. Әле кулга килеп кермәсә дә, кулъязманың табылу шатлыгын галим белән уртаклашасы килде аның. Иртүк элемтә бүлегенә китте. Сәйдел абыйсы алга таба ничегрәк эш йөртергә кирәклеген әйтер бәлки. Галимнең киңәшләренә мохтаҗ ул бүген.

— Элемтәдә — Ташкент, унөченче кабинага рәхим итегез,— диде диктор кыз.

— Ало! Ташкент! Ташкент!

— Сезне Ташкент тыңлый, сөйләшегез.

— Миңа Сәйдел Тураев кирәк иде.

Телефонда ниндидер хатын-кыз тавышы, бик тонык ишетелә, сүзләре аңлашылып җитми, шунлыктан Кәүсәрия җан-фәрман кычкырып сөйләшергә мәҗбүр иде.

— Казан бу, Казан. Сәйдел абыйны чакырыгыз, зинһар, мөмкин булса? Ишетелми, нәрсә дидегез? Тагын бер кабатлагыз әле? Сез җәмәгате? Үзе вафат дисезме? Алай икән. Кайчан үлде соң? Бүген өчесен уздырасыз. Алай, алай... Кирәк бит. Ничә яшьтә иде Сәйдел абый? Алтмыш өчтә. Яшьләй киткән икән. Яшьләй дим. Туган көнендә үлде дисезме? Ә-ә... Кайгыгызны чын күңелдән уртаклашабыз. Мин — элеккеге шәкерте, Кәүсәрия исемле булам. Бездән дә дога аңа, әйбәт кеше иде. Яхшы кеше иде, дим, урыны оҗмахта булсын! Хушыгыз, алайса, хушыгыз яме!..

Болай икән эшләр, диде Кәүсәрия уйга калып. Димәк, берни белмичә китеп барган абзыкаем. Нинди үкенеч! Өч кенә көнгә түзсә дә беләсе иде бит. Хәзер үк күрше карчыгына сәдака кертәм, рухына багышлап дога кылсын, дип ниятләде Кәүсәрия, элемтә бүлегеннән чыга-чыгышка. Авыр хәбәр иде бу аның өчен, өенә ничек кайтып кергәнен дә абайламый калды.

Әллә милициягә гариза язаргамы, бергәләп барыргамы Мусиннарга? Төрлечә уйлады Кәүсәрия элемтә бүлегеннән кайтып кергәч. Кулъязманы барыбер бирмәячәк, һәйкәлләр сатылмый, диде бит. Ул

яктан яһүдә дөрес әйтә. Шулай ук кулъязманы тагын бер тапкыр кулга тотып карау белән канәгатьләнергә туры килер микәнни Кәүсәриягә? Гариза язып та кемне өркетәсең, аннан ни файда, гаепләләр үзләре юк хәзер. Тавыш куптарганчы, бәлки болай гына килешә алырлар Берта Абрамовна белән. Күбрәк итеп акча алырга кирәктер, бер-ике мең тирәсе, кооператив фатирга дип җыйган акчалары бар ич. Бушка мал бирмәс шул хуҗабикә. Әгәр дә мәгәр, берни дә барып чыкмаса, ахыр чиктә инде судка, милициягә мөрәҗәгать итмичә дә булмас, татар халкының бөтен бер тарихы, рухи хәзинәсе бит ул, аны читләр кулына калдырырга ярамас, язык булыр, тарих тарафыннан гафу да кылынмас. Тикмәгә генә Сәйдел Турай шушы нөсхәгә тукталмагандыр. Болай да Мәскәү ташып бетерде ич инде татарның мирасын. Сөембикә ханбикәнең дөньяда тиңе булмаган таҗын, халык күзеннән яшереп, кайдадыр урлап саклыйлар, юкса ул бит Татарстан музеенда сакланырга тиешле мөлкәт!

— И-и, нишләдем мин, нишләдем?..— дип үкенде Кәүсәрия, кинәт нидер искәреп.

Ничекләр итеп хәтереннән чыгарды икән?! Кулъязманың соңгы битендә гади карандаш белән гарәпчәләп: «Әҗемев Исмәгыйль. 1961 ел.» — дип язылган иде ләбаса. Кулъязма хуҗасы үз кулы белән язган, шул хакта Сәйдел абыйсы да искәртте теге чакта. Ә менә дастанны күрү шатлыгыннан кичә шуңа игътибар итмәгән, нөсхәне әйләндереп карарга онытkан. Бу өстәмә дәлил булып тора. Югыйсә, эшләр зурга китсә, моны истән чыгарырга ярамас.

Шулай да яһүдә белән куркып сөйләшмәскә карар кылды Кәүсәрия, яннарында башка кеше булмаячак бүген...

— Кулъязманы сатып бирү турында әйткәч, кичә мине әрләп ташладыгыз, Берта Абрамовна. Сез аны үзегез дә бушка гына алмагансыздыр, дип уйлаган идем. Акчам бүген дә үзем белән, күп итеп алып килдем, монысы ул чаклы мөһим түгел, дөрес әйттегез,— диде Кәүсәрия хуҗабикәнең күзләренә туры карап. Тегенең йөзе кичәгечә зәһәрләнә башлады, әмма кунак аңа игътибар итмичә сөйли бирде: — Хәзер сезгә кулъязманың тарихы билгеле — ул борынгы ядкяр, татар халкының тарихы. Шушы дөнья бәясе торырлык мирасны бер юньсез адәм, анысы да үзегезгә мәгълүм инде, китапханәдән урлап качты. Ә кулъязма минем җаваплылыкта иде. Шуның аркасында эштән сөрелдем, чак-чак кына тимер рәшәткә артына утыртмыйча калдылар. Кичә сезгә әйткән диссертациямне шул чакта ук ертып ыргытырга туры килде. Ниһаять, менә егерме өч ел зарыга-эзли торгач, дастан сезнең киштәдән табылды. Бүген иртән тагын бер фаҗига турында ишеттек. Шушы мирасны эзләп табучы, аны тикшереп өйрәнүче галим, минем шикелле үк эшеннән куылып, зур хәсрәтләр кичереп, моннан өч көн элек Ташкентта вафат булган. Күрәсез, Берта Абрамовна, барысы да Сез уйлаганга караганда катлаулырак.

— Нигә дип сөйлисез боларны миңа?

— Хәлне төшендерү өчен.

— Аңлыйм Сезне, әмма берничек тә ярдәм итә алмыйм.

— Димәк, аңлап ук бетермисез яки теләмисез?

— Карагыз әле, Сезнең миңа нинди үпкә-дәгъвагыз бар?

— Үпкә түгел, таләп бу!

Берта Абрамовна да шактый гына тәэсирләнгән иде булса кирәк, артык каты бәрелмәде, залны куллары белән айкап, әйтте:

— Мондагылар — безнең шәхси мөлкәтебез, таләбегез урынсыз.

— Кулъязманың урлануы хак бит, булган эш, Берта Абрамовна, бусы Закон нигезендә җинаять санала,— дип, мәсьәләне юридик яктан аңлатырга кереште кунак хатын.— Монысы, беренчедән. Икенчесе — кулъязмада китапханә мөһере ярылып ята, өченчедән, дастанның титул битендә һәм унҗиденче битендә безнең тәртип саны тора. Алар минем кулым белән тутырылган. Телисез икән, дүртенчесен дә әйтә алам, анысы

тагын да хәтәррәк, ялган документлар ясауга кагыла. Әгәр баштан ук килешкән булсак, Сезгә мондый күңелсезлекләрне һич тә сөйләмәгән булыр идем. Зинһар, кичерегез. Эшне суд, милиция кулына тапшырмыйк.

— Нинди милиция?

— Нигә кирәк Сезгә картайган көнегездә болары? Дуслар, таныш-лар булып калыйк, Берта Абрамовна. Күрәсез, мин бер ялгызым килдем, беркемгә дә шикаять язмадым. Мондый байлык туплый алуыгыз үзе мактауга лаек, югыйсә, дәрәҗә, Сезгә хөрмәт белән карарга мәҗбүр итә торган факт. Ант итеп әйтәм — шулай. Әмма без бүген кыйммәтле мирасыбыз, Татарстан дәүләт милке турында сөйләшәбез. Мине дөрес аңларга тырышыгыз. Кульъязма өчен артыгы белән түләргә дә риза. Тагын шунысын да белеп торыгыз: әсәр аерым китап булып басылып чыгу белән берничә данәсен үзегезгә бүләк итеп китерәчәкмен. Закон нигезендә кульъязма бары тик музейда яки фәнни китапханә фондында гына сакланырга тиеш.

— Алай ничек булыр икән соң ул? Абрам Моисеевичның рухы рәнҗемәсме, хәзинәне саклауны миңа васыять итеп калдырды бит әти-ем,— дип икеләнде мөлкәт варисы.

— Ул Сезгә ахирәттән рухи рәхмәтен җиткерәчәк,— дип элеп алды Кәүсәрия. Шунда ук салам да кыстырды: — Татар халкының әнә ни чаклы хәзинәсен саклап калган әтиегез, күз салыгыз әле шүрлекләрегезгә. Безнең кульъязманы да югалтмаган, мең-мең рәхмәт үзенә! Инде аны китап итеп чыгарырга вакыт җитте. Галимнәребез көтә дастанны.

Карчык Кәүсәрия сөйләгәннәрне күңеленә хуш алып тыңлаган кук иде. Әтисе исеменә әйтелгән рәхмәт сүзләреннән күзләре очкынланып, ирен кырыйлары елмаеп-елмаеп куйды. Бу мизгелдә кунак ханымга да рәхәт иде. Тик менә Берта Абрамовна кинәт кенә әллә нишләп китте. Җылы өйдән соң салкын карга баскандай калтыранып алды. Маңгаен тотып, уйга чумды. Шатлыктан күкнең җиденче катына күтәрелгән Кә-үсәрия, куркып, хуҗабикәгә текәлде. Бу ни тагын?! Хәзер генә өметле сүзләр әйткән карчык йөзеннән ниндидер сизелер-сизелмәс дулкыннар, кара күләгәләр узып киткәндәй тоелды Кәүсәриягә. Мондый дулкын-күләгә йөгерүен төнге поезд тәрәзәсеннән карап баручы юлчы йөзендә генә шәйләргә мөмкин. Караңгы вагон эчендә тыштагы ут баганаларын-нан сирпелеп уза ул шомлы шәүләләр. Карчык йөзендә дә нәкъ менә шундый куркыныч шәүлә дулкыннары биеште. Кәүсәрия үзенең хафалы чоңгылга очуын шәйләде.

— Бәлки бирермен дә... Без башта тәмләп кенә чәй эчик әле.

— Ә, нәрсә дидегез, Берта Абрамовна? — Кәүсәрия онытылудан айнып киткәндәй булды.

— Кухняга керик, күгәрченкәем.

— Чәй кайгысымыни миндә, Берта Абрамовна?!

— Ә Сез борчылмагыз.

— Кульъязманы чәй өстәлендә күрәсем килә,— диде Кәүсәрия, тәка-те бетеп.

— Анысы шулайдыр да...

— Сез мине кабат утка саласыз, Берта Абрамовна.

Кәүсәрия чын-чынлап шөбһәгә төште. Өй хуҗасының кинәт үзгәрүе, икеле-микеле сүзләре тәмам гаҗиз итте кунакны. Кухня юлыннан туктап, китап шүрлекләренә тартылды.

— Алыйк, Берта Абрамовна.

— Хикмәт тә шунда шул,— дия-дия карчык әкрен генә шүрлекләр арасына юнәлде. Кәүсәрия аңа иярде.

Хуҗабикә бер атлый да биш туктый дигәндәй кылана. Әйтерсең лә, шүрлектәге китапларны бер төн эчендә укып чыккан да, инде шулардан аерыла алмый җафалана. Китапларны сөеп-яратып сыпыргалый, кайбер-ләрен кулына тотып иркәли, иреннәренә тиерә, әкрен генә нидер пышыл-дый, «Исән генә була күрегез»,— ди бугай. Кәүсәрия ул сүзләрне аер-

мачык ишетте. Теге килүендә мондый хәлне күрмәгән ханым бөтенләй үк коелып төште. Берта Абрамовна барысына да битараф иде бит. Ул бары тик хәзинә сакчысы кук күренде. Ә бүген, әнә нишли, китаплардан аерыла алмый.

...Кәүсәриянең тез астына хәнҗәр белән сызып җибәрделәр, ахрысы. Аяклары тыңламас булды, хәлсезләнеп, әкрен генә идәнгә чүгәләде, күзаллары әлҗе-мөлҗе килде. Бусы нәрсә инде?! Китапханәнең «Р» бүлегендә бер киштә бушап калган... Куаныч-шатлык тулы шүрлектә җилләр уйный. Шүрлек елый... Кәүсәриянең башы авырая...

Тик анысы гына кирәкми. Юк, юк, моның булуы мөмкин түгел. Андый хәл була күрмәсен. Берта Абрамовна ни кылыр, ни дип җавап тотар? Менә ул Кәүсәрия янына идәнгә чүгәләде. Ханымның ике битен чәбәкләргә керешге. Йөрәк тибешен тыңлады. Аллага шөкер! Тагын чәбәкләде. Кәүсәрия күзләрен ачты, тирән итеп сулыш алды.

— Мин хәзер...

Әвеш-тәвеш килеп, Берта Абрамовна кухняга йөгерде. Шундый ук кызулык белән әйләнеп тә чыкты.

— Мәгез, су йотыгыз!

— Рәхмәт, Берта Абрамовна, агу эчерсәгез, яхшырак буласы иде.

— Юкны сөйләмәгез.

— Шүрлек буш бит,— диде Кәүсәрия, ни әйтергә сүз таба алмыйча.

Берта Абрамовна кунак хатынга ул-бу булмагае дип бик курыккан икән. Инде тынычланды. Шөкер, Мусиннардан үз аягы белән китәчәк.

Шүрлекнең бер өлеше бушап калуын хуҗабикә болайрак аңлатты, кайбер китап-кульъязмаларны туганы Моисей алып торган икән. Китерәчәк, әлбәттә.

— Кем ул Моисей?

— Хаим Моисеевичның улы. Без аның белән туганнан туганнар.

— Фамилияләрегез төрлечә бит,— дип тинтерәтте Кәүсәрия карчыкны.

— Бездә, яһүдләрдә, шулай инде.

— Ничек?

— Өйләнешкәч, әтиләребез хатыннары фамилиясенә күчкәннәр, элек-электән килгән гадәт ул.

— Абрам Моисеевич белән Хаим Моисеевич бертуганнар, димәк.

— Сез дөрес аңлыйсыз, күгәрченкәем.

Кәүсәрия Моисей дигәннең кемлеген төпченеп, кульъязмаларны ни сәбәптән алып китүен сорарга да онытып җибәргән. Су эчү, Берта Абрамовнаның үз янына идәнгә чүгәләп йомшак сүзләр сөйләве аны беркадәр тынычландырган иде. Хуҗабикәгә шул соравын бирде:

— Моисей Хаимович нишли кульъязмалар белән?

Хуҗабикәгә дә хәл кергән иде. Йөзеннән теге кара күләгәләр тәмам югалды. Хәтта сөйләшкәндә елмаеп та җибәргәли.

— Дөнья эшен белеп булмый, күчермәләрен алып куям, ди Моисей.

— Миңа күчермә түгел, төп нөсхә кирәк бит, Берта Абрамовна.

— Хафаланмагыз, бераз сабыр итәргә кирәк булыр, күгәрченкәем,— диде, йомшак кына итеп хуҗабикә.— Әйдәгез, кухняга керик.

Кәүсәрия киштәләргә тотынып, әкрен генә торып басты. Бераз гына күңеле болгана иде. Берта Абрамовна кулындагы чынаякны алып, берике йотым су капты. Ләкин нидер кылырлык, сөйләшерлек әмәле дә, теләге дә юк иде. Кухняга кереп тормады, кайтасы итте. Берта Абрамовна кунакны аркасыннан сөеп озатты. Үзе туктаусыз сөйләнде:

— Сез, күгәрченкәем, зинһар, борчылмагыз инде, килеп йөрегез, ташлап бетермәгез. Күреп торасыз, бер ялгызым яшәп ятам. Рәхмәт Моисей туганыма, ул булыша. Ә Сезнең өчен ишегем һәрвакыт ачык. Көтеп алган кунагым булырсыз. Мин Сезне аңладым: изге ният белән йөрисез. Ходай саулык бирсен безгә, шуңа өметләник...

* * *

Көнгә ни булган тагын?! Күк йөзен кара болыт томалаган. Кисәк кенә җил купты. Җил, агач кәүсәләрен чайкый-чайкый, яшел яфракларны өзгәләде, аларны тузанга урап, урамның икенче очына йөгерде. Урам чүп-чардан арынып калды. Кара болытны ярып ак тасма ялтырады, дөбер-шатыр килеп күк күкрәде. Тузаннан котылган асфальтка беренче тамчылар тыпылдады. Тамчыларга Кәүсәриянең күз яшьләре дә өстәлде. Менә ничек килеп чыкты бит әле монда...

Яңгыр тамчылап түгел, чиләкләп коярга кереште. Кәүсәрия күрше йорт капкасына барып сыенды, монда аңа яңгыр бик үк эләкми, асфальттан чәчрәп кенә аякларны чылата. Түзәргә була. Җәйге яңгыр тиз узучан, ялтырап кояш та чыгар әле. Әнә, Хезмәт Сарае ягыннан аязып та килә инде... Сәйдел абыйсы да мәрхүм икән бит... Аның васыятен Кәүсәрия мәңге онытмас. Һичшиксез, киләчәк ул монда. Килер, килми калмас!

*Казан, 1995.*

## КИЛӘСЕ САНДА УКЫГЫЗ!

***Марсель Гали***

# ДОГАЛЫ ЕЛЛАР

ӘСӘРДӘН ӨЗЕК

«Туган авылымның исеме — Балтач.

Күңел диварына җуелмас мөһер итеп сугылган бу атаманың ярлыгы-тамыры каян килә: бал-данмы, балта-данмы? — бу мине һәрчак уйландыра иде. Украинада Балта дигән поселок, Балтача фамилиясе йөртүчеләр бар. Моның кыпчаклардан күчкәнлеге бәхәссез.

Халык телендә йөргән риваятьләр мондый: имеш, безнең авыл урынында элек кичеп чыккысыз кара урманнар булган. Юан кәүсәләренә оялаган бал кортларының гөҗелдәве агач шауларын да күмеп китә икән. Эссе җәй көннәрендә агач ботаклары арасыннан тач-тач бал тамып торган. «Тачбал»лы төбәк, әнә шулай, тора-бара халык телендә «Балтач»ка әверелә имеш. Кара урманнар булуына да, бал тамып торуына да ышанам. Әмма телдә нинди дә булса атаманың кирегә әйләндерелүе — юк дәрәҗәсендә сирәк була торган хәлдер».

**Марсель Галинең киләсе санда чыгачак «Догалы еллар» дип исемләнгән әсәренең «Сөйлә, җил... Юат мине...» бүлегеннән китерелгән юллар болар. М. Гали — нечкә психолог һәм «сүзләрдән чәчәкләр» ясарга сәләтле талантлы әдип. Аның портретлар остасы икәнлеге Р. Яхин («Сүзсез дога»), Р. Нуриев («Мин яшим әле!»), Х. Сарьян («Ике урман чигендә») иҗатларына багышланган эссе-уйлануларда бик ачык чагыла.**

# Шигърият



## Нәҗибә Әминева

### ДУСТЫМ БУЛАСЫГЫЗ КИЛСӘ

* * *

Иң авыры түгел әле
Исән яши алу.
Иң авыры — түбәнсенмәү,
Җаның горур калу.

Зур чинлы түрәләргә дә
Тәлинкә тотмау.
Син — үзеңә үзең түрә,—
Шуны онытмау.

Һәм кемдер сине кешегә
Санамаганда,
Ямьсез һәм кадерсез күреп
Санламаганда,
Бел, син гел бала:
Сине газиз, матур күргән,
Кадерләгән...
Әнкәң дигән
Бер зат бит кала.
Әйтмәгез:
«И, харап икән,
Шуны белмәскә!»

...Үземне үзем өйрәтәм
Түбәнсенмәскә.

### Хаталана-хаталана...

Кайда син, ялан тәпиле
Хыялый бала чагым?

Белмәгәнмен кадереңне,
Кайт әле миңа тагын.
Кайда син, зәңгәр яшьлегем —
Яшендәй яшьнәр чагым?
Яшьнәп үк яшәлмәгән күк,
Кайт әле миңа тагын.
Яшьлек һәм картлык арасы
Бар иде әле тагын.
Их, дөрес үк яшәлмәгән
Дөп-дөрес яшәр чагым.
Хаталанган-ялгышканмын
Гомеремнең һәр мәлендә.
Хаталана-хаталана
Яшим микән әле дә?!

* * *

Ышанам: ерак йолдызда
Сез дә барсыз, кешеләр.
Чиксезлектә ераклык ни?! —
Сез безгә тик күршеләр...

Күптән инде, бәлки, безнең
Барлыкны беләсездер.
Бездә туктап үтәсездер,
Күрергә киләсездер.

Билгеле, тимисез безгә —
Бездән сез бөегрәк,
Сездәдер дибез камиллек,
Һәм чын гамәли йөрәк...

Без дә юк өчен тартышып,
Ду кубып тормыйбыз гел —
Җирдәгеләрдә дә кайчак
Кабына бөек мизгел...

Башкалар өчен янганда
Онытыла үз гамебез.
Башкалар гомерен саклап
Бар безнең үлгәнебез.

Кызыксынучан үзебез —
Кайда соң сез бар тараф?..
Булсагыз, килсәгез, безгә
Ник сез салкын, битараф?!

Сездә дә бардыр кимчелек —
Бөеклекнең чиге юк...
Тик булсын гына күршебез,
Чәчәкләр алып, үзебез
Керербез бер —
Шигем юк!..

## Каберлектәге язу хакында

Каберлектәге бер язу
Йөрәгемне өзде кебек:
«Сезнең кебек булдык,
Сезгә
Буласы бар безнең кебек...»

Үләсе ич,
Нигә әле
Онытылып мин яшим соң?..
Зиярат тулы калкулык,
Сүнгән күпме бөек җисем.

Һәм ник әле кемнәрнеңдер
Бу дөньяга туасы бар:
Туасының да, мәрхүмнәр,
Сезнең кебек буласы бар.

Тетрәндергеч язу шул бу,
Әйткән дөнья фанилыгын.
Каберлектә булса да, ул —
Тере кеше даһилыгы.

Үлгәннәр мондый сүз әйтсә,
Бер әйтер идем ичмасам:
«Сезнең кебек булырбыз,
Сез
Безнең күк инде һичкайчан...»

...«Сезнең кебек булдык,
Сез дә
Безнең кебек буласы бит.
Туфрак түгел,
Күзегезгә
Әле кояш туласы тик.

Кеше дә чәчкә шикелле
Балкыйсы да суласы бит.
Нурланып яшәп калыгыз,
Булганчы сез безнең кебек,
Дөнья кадерен белер өчен,
Бу җиргә йөрегез килеп».
Куйдым шул язуны элеп.

* * *

Яшим — кемгәдер
Ышанып җитмим,
Кемнеңдер эшен
Ошатып җитмим.

Кемгәдер, түзми,
Авыр сүз атам —
Кешенең, димәк,
Гомерен кыскартам.

Кемнеңдер күңелен
Гел шулай кырам.
...Мине дә күпләр
Рәнҗетеп тора.

Хакыйкать кайтып
Каламы шуңа:
«Кеше җитә гел
Кеше башына...»

## Аңлармын

Башым исәм, яшем түксәм,
«Җиңелде бу!» — димәгез.
Һәм: «Ниһаять, безнең йөккә
Җигелде бу!» — димәгез.

Дөнья тынгач — тынычлангач,
Карармын әле уйлап:
Бүген нинди тормыш аккан
Кан тамырларым буйлап?

Һәм аңлармын бу көндәге
Дөреслекне, ялганны,
Кем таптап үткән йөрәкне,
Кем күтәреп алганны.

Һушына килер дә йөрәк
Шау боз, ут булыр, бәлки.
Нәфрәтле йә мәхәббәтле
Шигырь үк булыр, бәлки...

* * *

Яшәвең ни,
Йөрәкләрдә сиңа
Бер ихтирам, сөю тумаса?
Барын-югын шуның аңлар өчен
Бер чирлисе иде, булмаса!
Каты итеп...

Гомерем өчен янып,
Баш очымда
Күп булырмы ул чак елаучы?
Минем өчен аккан күз яшьләре
Булырлармы икән чын, ачы.

Әгәр булса,
Шундыйларның җанын
Юк, телмәскә иде шул чакта.
Ә булмаса —
Инде бөтенләй дә
Терелмәскә иде шул чакта...



**Нәҗметдин Хаҗи Әминуглы,**
төрек язучысы

# НИШЛӘРГӘ?

хикәя

Атнаның дүрт көне саен диярлек без аның белән автобус тукталышында очрашабыз. Шактый иртәнге сәгатьләр бу, шуңа күрә урамнар да, тукталыш та кешесез һәм буш. Баштарак әлеге очрашуларга әһәмият тә бирмәдем кебек. Зиһенем шулкадәр мәшгуль иде ки, тирә-юнем белән кызыксынырга вакыт юк. Дөресрәге, һәр төрле урам очрашуларына әһәмият бирергә ни холкым, ни мәсләгем туры килми минем. Өстәвенә, һәрвакыт рәсми костюмнан йөрим. Юлымда очраган гүзәл хатын-кызларга күз төшергәләп алсам да, алар бер гүзәл чәчәк яисә витринадагы манекен кебек хәтеремнән тиз юылалар. Аннан соң мин хатын-кыз белән әллә нигә бер генә күрешкән, сөйләшкән кеше түгел. Бу өлкәдә бераз тәҗрибәм бар, чөнки лицейдә дә, университетта да катнаш төркемнәрдә, ягъни кызлар һәм егетләр бергә укыган бүлекләрдә укыдым. Шуңа күрә кызлар арасында да дусларым, танышларым җитәрлек булды дип исәплим. Аннан соң, хатын-кызлар барысы да бер камырдан түгелме соң?..

Көннәр үтә торды, мине бу бичара кызкайның кем булуы, бу кадәр иртәдән япа-ялгызы кая баруы уйландыра башлады. Карап торуга ул гади һәм хәтта җитди кыяфәттәге киемнәр кия. Йөзенә текәлеп карамасаң да, аның чибәрлеге ерактан сизелеп тора.

Хәтердә: кышкы яңгырлы бер февраль иртәсе иде. Тукталышка килдем дә үземнең аны көтүемне аңладым. Бер сылтау табып, аның белән сөйләшеп карарга уйладым. Әмма бераздан бу уемнан да кире кайтам.

Яңгыр коя гына. Шыгрым тулы автобуслар безнең яннан выжылдап кына узып китәләр. Җилләр ыжгырып торган тау башы урамында һаман шулай автобус көтәбез. Юеш, салкын. Әлеге теге кызга исем китә. Шундый иртәдә кая бара икән ул? Хезмәткәргә охшамаган. Эшче түгел дә түгел инде. Ә бәлки университет студентыдыр? Алай дисәң, һәрвакыт Аксарайда төшеп кала. Миңа ул гел борчылган, дулкынланган кебек тоела. Үзе белән кызыксынганымны сизенгәндер инде, миңа ачуы килмиме икән? Әллә аның шундый төшенке кыяфәттә сыман булып, үзенә игътибар иттерү чарасымы? Бәлки, ул үзе мине игътибарга алгандыр?.. Яисә миңа бөтенләй дә игътибар итмидер әле, әллә бар мин, әллә юк. Кем белә, бәлки, үз-үзе белән ялгызы калып, шулай рәхәтләнеп хыял диңгезендә йөзәдер? Шулай өеннән иртә чыгып та, каядыр ашыккан кеше сыман да түгел бит үзе. Һаман саен бушрак автобусны көтә. Әллә соң кешесез урамнарны яратамы? Була бит шундый хәлләр дөньяда — кешенең өендә дә торасы килми, эшендә дә кызык тапмаганлыктан, урамга ташлана. Иртәнге сәгатьләрдә бу тау башы урамы кыр кебек буш була бит. Шуңа күрә дә ул табигатьнең цивилизация кагылмаган аулак бер почмагы дип тә кабул итәлергә мөмкин.

Менә кинәт кенә кызның алдына «Мерседес» килеп туктады. Машинаның пыяласы ачылып, аннан яшь кенә бер егет минем танышмаган таныш кызыма: «Әйдәгез, илтеп куям»,— дип кул изәде. Карап карыйм әле, мине дә чакырырмы, дип уйладым мин. Кыз, гүя егет бөтенләй аңа эндәшмәгән кебек, башын бераз гына янга борып, узучы машиналарга карый башлады. Егет, чигенә-чигенә килеп,

кызның икенче ягына килеп туктады да: «Аксарайга алып барам, утырыгыз»,— диде. Ләкин кыз башын бормады. Ә мин кыз әлеге чакыруны ничек кире кагар икән, дип тамаша карарга җыенган идем. Әмма араларында сөйләшү булмады, егет машинасы белән китеп барды. Мин горур кызга карадым. Теләгем — аның күз карашы белән очрашу иде. Әмма ул мантосына күмелеп, кулларын кесәсенә тыккан да карашын еракка, таулар ягына төбәгән. Аякларында итек, башына шарф ураган. Сумкасын җилкәсенә аскан. Яшь, чибәр, затлы кыяфәттә. Аның күзләренә карыйсым, күзләренең тирәнлеген күрәсем килә. Әмма, якынрак барсам, өркетермен дип куркам. Шарфы астынан чыккан чәчләрен җил уйната, ә озын керфекләре күзләрен томалаган. Бәлки, ул елыйдыр? Дөресен әйткәндә, аның шул кыяфәттә иртә таңда автобус көтеп торуы күбрәк чик буенда сакта торучы гаскәрине хәтерләтә иде. Мин аның белән, һичшиксез, сөйләшергә тиеш дип, күңлемә беркетәм. Шул гүзәл күзләренә багып, эчемдәге хисләремне белдереп карарга кирәк... Кыяфәтенә, буй-сынына киемнәре әнә ничек килешә, мин аңа шул хакта әйтергә тиешмен... Үземне аның белән төрле урыннарда: урамда, өйдә, салонда, пляжда бергә итеп күз алдыма китердем. Төрле рухи халәтләр: мәхәббәт, сөю, мәрхәмәт, үпкә, нәфрәт, кинә кебек бер-берсенә каршы торган хәлләрдә икебезне бергә итеп күз алдына китердем... Әнә ул, ниндидер ерак галәмнән килгән чит кеше сыман, минем янымда ук диярлек басып тора. Суык яңгырлы җил рәхимсез рәвештә өшетергә, битенең төсен алырга тырышса да, ул әле барыбер салоннарда утырган иркә ханымнарга караганда күпкә чибәррәк күренә. Люкс, казиноларда затлы эчемлекләр эчеп утырган хатын-кызлардан сөйкемлерәк күренде ул миңа. Кыскасы, табигый матурлык бар аңарда. Куллары, яңаклары да туңа, бары иреннәреннән ут бәреп тора бугай... Бер-бере белән очрашкан язмышның бердәй булып упкынга сикерүен теләдем. Мин аның өчен саклаучы — терәк, ул минем өчен өмет чыганагы булыр иде. Шулай танышмаган да көе гашыйк булу мөмкин түгелмени? Болай гашыйк булу бәлки бигрәк тә гүзәлдер. Бер-берләренең телләрен белмәгән килеш бер күрүдә гашыйк булган ике чит ил кешесе мәхәббәтенә охшаштыр бу, бәлки? Мондый төрле мәхәббәтне китаплардан укымыйбызмыни, киноларда карамыйбызмыни?

Һәртөрле ялганның, алдашуларның сәбәпчесе булган тасма телдән башка — күзләр белән генә сөйләшеп гашыйк булу... Менә ул чынлап та ялгансыз, риясыз, берни дә катнашмаган чиста мәхәббәт... Халык әкиятләрендәгечә шаһзадә белән көтүче кызының, принцесса белән тазның бер-берләренә гыйшык тотулары кебек булыр иде бу мәхәббәт. Китаплардан балачагымда алган тәэсирләр диңгезендә менә хәзер яшәп алырмын төсле иде. Малай чакта берәр кучмә бәдәви кызына, яисә берәр башка ерак көнчыгышның әкияти гүзәленә гашыйк булырга хыяллангап кебек... Кинәт кенә кабынып, еллар буе сузылачак мәхәббәт турында хыялланам! Малай чагымда җәйге кичләрдә яр буенда чам агачы астында утырып, диңгездәге пароходларны күзәтәм, ә икенче ягымда — өскә чөелгән фонтаннар тавышы... Мин әллә кайларга китеп хыялланам... Аннан иртәгесен үземнең шундый хыялларымнан үзем көлә идем. Менә хәзер шушы ундүрт яшемдәге хыялларым эченә яңадан кереп барам бугай. Бүгенге көн тәэсиренә бирелеп, мин бу салкын яңгыр астында күчмә бәдәви кызы кебек чыныккан кыяфәттә автобус көтеп торган таныш түгел кызны үземнең хыялыма урыйм. Миңа калса, ул миннән дә ныграк романтик бугай... Мөгаен, әллә нинди галәмнәрдә йөзәдер әле. Тормыштан, чынбарлыктан гаять тә ерак кебек тоела. Аның сер дөньясына ни күз белән, ни күңел белән атлап кереп булмыйдыр... Горурлыгы күзгә бәреп тора. Мәхәббәтең белән дә тирәсендә ни еллар буе йөрсәң дә ачылмастыр кебек.

Хәер, уйлап карасаң, мин бар дип тапкан ул сыйфатлар аңарда чынлыкта да бар идеме соң, әллә бу минем теләк, хыял гынамы? Бәлки, ул бик тиз кызып китә торган чәүчәләк һәм дә киребеткән бер кыздыр? Яки бөтенләй дә җиңел холыклы, бозык хатындыр. Әмма минем аның турында һич тә болай начар уйлыйсы килми. Әгәр дә аның белән бәйле шундый матур хыяллар корам икән, нишләп начарлык көтәргә? Гүзәл хисләр белән кеше күңеленә якын килсәң икән, аңарда бик күп күркәм якларны ачарга мөмкин ич. Кемнәрдер кимчелек итеп кабул иткән нәрсә икенче берәүләргә гүзәллек булып күренергә мөмкин. Нәтиҗәдә, үзең өчен өр-яңа кеше ачасың...

Каршыбызга килеп туктаган автобус эченә мин, бер сүз дә әйтмәстән, кызны алга уздырдым.

Янәшәсенә утырдым. Күземнең очы белән генә аны яшертен күзәтәм. Шарфын чишеп, яңадан бәйләде, кульъяулыгын чыгарып, сөртенеп алды, аннары мантосы чабулары белән тезләрен томалап, утыргычка сөялә төште. Борылып йөзенә туры карамадым. Таныш булмаган хатын-кызның йөзенә карар өчен бик

тә нигезле сәбәп кирәк шул. Миңа куллары гына күренеп тора — йөзеге юк. Бармаклары нәфис, тырнаклары ал төскә буялган. Хатын-кызның күзләреннән соң иң әһәмиятлесе — аның куллары. Бер фәйләсуф: «Куллар акылның тышкы күрсәткече»,— дигән. Кешенең даһилык билгеләре дә кулында чагыла. Мин хатын-кызлар өчен бу гыйбарәне тагын да үстереп, болай дияр идем: «Куллар гүзәллекнең, нәфислекнең, күркәмлекнең билгесе булып тора».

Теге көнге хәлдән соң да безнең очрашулар элеккечә кала бирде. Күңелемнән мин очрашуны көтәм. Шулай һәркөнне очрашабыз да. Мин тукталышка килгәч, аңа биш-алты адым каларак, баш иеп исәнләшәм дә бер сүз дәшмичә, бер читкәрәк барып басам. Ул да миңа җиңелчә баш кагып җавап бирә. Тукталышка аңардан алдан килсәм, автобуска утырмыйча аны көтеп торам. Кызык, ул да мине шулай көтеп торганга күрә без гел бергә очрашабызмы икән әллә? Бәлки, чыннан да, бер-беребезгә гашыйк булып китәрбез? Мәхәббәт хисе бездә әкренләп-әкренләп кенә көчәйсен, үссен, серләнсен. Бөтен рухыбызны ташкын кебек күмеп китсен. Без исебезгә килгәндә инде эш узган булсын. Ихтыярыбыз буйсынсын, мәхәббәткә баш исен. Шуңа күрә дә андый хәлнең булу мөмкинлеген сиздереп, аны куркытып куярга ярамас. Минем бердәнбер чарам — сабыр итмәк.

Матур һавалы көннәрдә мин аның төрлечә киенгәнен күрдем, әмма һәрвакыт киемнәре зәвык белән сайланган булыр иде. Шотландка итәге, чикләвек төсендәге кофтасы, төтен төсендәге курткасы — һәммәсе дә күркәм. Инде йөзенә дә бераз күз сала башладым, үземнең хисләремне сиздерүдән дә тайчынмый башладым. Баш әйләндергеч күзләре, чем-кара керфекләре, гәүдәсенең һәрбер хәрәкәте гүзәл иде. Якты йөзе, буялмаган иреннәре аның табигать кызы икәнлеген күрсәтеп тора. Беләсе иде, музыканы, шигырьне ярата микән? Үзебезнең милли көйләребезне беләме икән?

Көннәр үткән саен сабырсызлана башладым. Баштагы көннәрдә үзем беркетеп куйган сабырлык турындагы фикерем бозылыр, ахры. Тукталышта очрашуыбыз да аксый башлады. Кайсыбер көннәрдә бик иртә килсәм дә, аны очратмыйм. Бәлки, минем серләремне сизенгәндер дә качадыр. Әгәр кача икән, моның инде төрле сәбәбе булырга мөмкин. Йә мине үзе артыннан йөгертмәкче, яисә үзенең дә гашыйклыгын сизә башлауга, өркеп качуы. Булса да булыр. Яшь аермабыз бар. Өйләнгәнлегем күренеп тора. Тормышының башында ук шундый куркынычлы вә билгесез мажарага кереп китәргә теләмәстер. Язмышын ялгышка бәйләргә теләмәгәнлектән качуыдыр аның?

Шулай ихтималлавым мине сыта, сындыра иде. Әмма кызыксынуым кимемәде. Һич югында аның кем икәнлеген беләсем килә... Берәр мәртәбә булса да яшел үзәнлеккә чыксак, яисә берәр тау куышында кайнар чәй эчсәк?.. Карлы-яңгырлы бер көнне аны суыктан җылытсам, яисә берәр ерткыч хайван тырнагыннан коткарсам... Аны яклап, кырык карак белән якалашсам...

Мавыгуларымның романтик хис кенә булудан узып, тыелгысыз теләк рәвешендә ээзәрлекләвеннән куркам. Ни эшләргә тиеш соң мин?.. Ерактан баш кагып исәнләшүнең мәгънәсе калмады. Нәрсәдер эшләргә кирәк. Бер иртәдә, диңгез кебек тирән күзләренә карап: «Сезгә шулкадәр иләштем, иртән сезне күрмәсәм, бөтен көнем шундый күңелсез уза, үземне кая куярга белмим, сезне сагынам»,— дип әйтергә кирәктер. Аннан соң, кайнар пышылдап: «Мәхәббәт танышуга китерде»,— дип өстәргә була. Ләкин моны эшләү куркыныч та. Аны бөтенләй югалтуым бар. Әгәр дә: «Сез саташтыгызмы әллә?» — дип тупас җавап бирсә? Яшемне, өйләнгәнлегемне, матди хәлемне искә алса?.. Мине бу хәл бөтенләй аяктан егачак. Минем уемча, бөтен хилафлыклардан да азат дип хисаплаган бер гүзәлнең шулай тупас җавап бирүе бик тә күңелсез хәл булыр иде, егыл да кит! Юк инде, миңа тагын да озак вакытлар сабыр итәргә кала... Ягъни аны югалтсам да, хыялымда ул яхшы кеше булып яшәп калачак.

Кит син. Әмма елаган күңелемә өмет кайтавазы булып кайтырсың...

**Бикә РӘХИМОВА** тәрҗемәсе.

# ШИГЪРИЯТ



## Илгизәр Солтан

## КӨШЕЛ-КӨШЕЛ УЙ

* * *

Көн белән Төн кочагында
Бертуктаусыз тирбәләмен.
Көшел-көшел уйларымны
Тиргә батып җилгәрәмен.

Дөньям тулы уйлар белән,—
Ниндиләре генә юк ла?!.
Бар да миңа оран сала:
«Эшлә, ал, бир, аша, йокла...»

Чиста уйлар өем-өем...
Чүп-чарлары җилгә оча.
И шатланам, канатланам,
Мәңгелекне коча-коча...

Чиста уйлар өем-өем,
Җылы, якты күңел өем.
Моң яратсаң — кил яныма
Минем дә бар моңлы көем.

«Җаннан чыккан җанга керә» —
Бик тә дөрес аңлыйм моны.
Көнен-төнен «мин монда» дип,
И талпына күңел моңым...

...Өлешенә тигән көмеш,
Шулдыр инде, шулдыр, шулдыр.
Минем язмыш — үзгә моңдыр,
Ә гомерем — шигъри юлдыр.

Көн белән төн кочагында
Бертуктаусыз тирбәләмен.
Көшел-көшел уйларымны
Моңым белән җилгәрәмен,
Сезнең янга җибәрәмен...

Дөнья — матур, яшәү кызык,
Алам кайчак кызып-кызып,
Ни булса да, алгы көнгә
Буш кул белән кергәнем юк,
Керәм һәрчак моңны сузып...

* * *

*Математика укытучысы Әлфия Әсәт кызы Мәҗитовага*

Мин — чип-чиста,—
мин түгел!
Мин алындым, бүлендем.
Сүз өеменә күмелдем,
Мин кыйналдым, сүгелдем,
Барыбер өскә үрелдем —
Бу дөньяга күрендем,
Ярсып-ярсып түгелдем...

Мин — чип-чиста,—
мин түгел!
Кушылдым, тапкырландым.
Бер сүрелдем, бер яндым,
Тамчылар булып тамдым,—
Һәм үзем булып калдым,
Барыбер акыллыландым,
Дөньядан акыл алдым...

Мин — чип-чиста,—
мин түгел!
Шуңа уйланам мин гел.
«Дөнья шундый инде, бел» —
Диеп юата күңел;
Түгелдең икән, түгел! —
Шиңмәсен җанында гөл,—
Мәхәббәтле туган тел...

Мин — чип-чиста,—
мин түгел!
Әмма шунысы бик хак,—
Мине китмәсләр таптап,
Намусны яшим саклап,
Сатмадым аны ваклап,
Кабатлыйм моны кат-кат:
Мин исән, барам атлап...

* * *

Үз гомерендә кеше
Нихәтле уй уйлый,—
Санап бетергесез,
Бихисап.

Күпме уең
Чынга ашты, туган? —
Заман көн дә сорый,
Бир хисап!..

* * *

Башым иелә башлады,
Йөрәк тибенә ярсып:
— Уяу бул,
Тагын каршыңда
Дошманым тора басып!

Рәхмәт инде, и йөрәгем,
Гел саклыйсың син мине.
Мәңгелеккә әйтим әле
Илаһи исемеңне...
Үземнең исемемне!

* * *

Җыр янына җыр җыела,
Моң янына моң.
Мин аның шулай булганын
Күптән аңлыймын...

Җан янына җан тартыла,
Уй янына уй.
Җаныңдагын,
Җәлләмичә,
Өеп-өеп куй...

Аң янына аң сыена,
Хис янына хис...
Кеше булып яшәү шулдыр,
Ялгышмыймдыр ич?

## Ерак юлдан кайткач

Ишекне
тутырып ачтым.
Йөгереп килеп,
муеныма
Сарылды өй һавасы...
Нәни баланы

Күтәргәндәй,
Ике куллап, аны өскә
Килде күтәреп аласым...

## Авылым урамы

Бөтен нәрсә
Монда миңа таныш,
Монда яши,
Яши минем тавыш.
Әкрен атлыйм,
Уятмаска иде
Күңелем тулды,—
Күңелем тулы сагыш.

Ә ул сизгән,
Сизгән мин кайтканны.
Дөбердәтеп йөри
Капкаларны...
Тәрәзләргә чиртеп,
Чиертеп китә,
Уята бит
Йоклаганнарны.

Минем яннан
чабып кайта тавыш.
Мине бик тә,
Бик тә сагынганга...
...Мин имәнеп китәм,
Капка ачык—
Әни чыккан
Мине каршыларга...



# Флера Гатина

## ХӘТЕР

ПОЭМА-БАЛЛАДА

### I. Болгар иле

Мең ел элек газиз җиргә иман иңде,
Шәрекъларга капка иде Болгар иле.

Ул илаһи азаныңны кылыч бүлде,
Учагыңда балкып янган утың сүнде.

Ачыргалап тавыш бирде аккошларың,
Сынып ауды тояклардан камышларың.

Чулман-суда йөзеп бара акбүз атлар,
Ярларында камчы селти явыз-ятлар.

Бишекләрне корым сарды, дөрләп янды,
Чәчәкләргә кызыл чыклар таңда тамды.

Чыңгыз явы ак Болгарны таптап үтте,
Диварларың кара сөрем төтен өтте.

Курган үсте улларыңның вөҗүденнән,
Кояш качты бу дәһшәтле кара төннән.

Базар тоткан Биләреңнән көлләр калды,
Манараңның алтын аен вәхшәт алды.

Яу чапканда һәлак булды алыпларың,
Кабердашта әрнеп елый оныкларың.

Берсен-берсе төрки халык тураклашты,
Шанлы илдән дан, бәрәкәт шулай качты.

### II

Ватан китә, халык үлми, аһ, «сөт кала»,
Елан тауда калкып чыкты яңа кала.

Биек тауда дөрли-дөрли учак яна,
Җырлый-җырлый казан аса бер кыз бала:

Ак калфагың ак атластан,
Кемнәр бүләк иттеләр.
Энҗе-мәрҗән сәйләннәре
Суларга агып киттеләр.

Казан аскан Елан тауда кала шаулый,
Ефәк парча, җимеш тулы базар кайный.

Идел-суның алтын ае — шәһре Казан,
Манарадан ишетелә моңлы азан.

Сарайдан да, Җаектан да илче килгән,
Димли илче сылу кызны Агыйделдән...

Туй — далада, барча халык бәйрәм итә,
Шанлы илгә килен булып гүзәл китә.

Курай уйный Казансуның ярларында,
Кем баш имәс гүзәл гөлнең алларында.

Асылташлар тоныклана ул барында,
Зөбәрҗәт каш Сафа-Гәрәй билбавында.

Бәйрәм итә барча халык, Идел шаулый,
Дала кызы ил халкының күңелен яулый.

## III. Афәт

Шанлы илем, дәртле Казан, гамьле Казан,
Манараңнан ишетелә моңлы азан.

Шәһрәтең зур, күгең биек, табының мул,
Иделсуга, комсызланып, сузыла кул.

Үткен кылыч шәфкать белмәс явыз кулда,
Кургашындай кара дулкын Казансуда.

Кансыз Иван кылыч белән айкый Җирне,
Канлы сөрем, кайгы басты шанлы илне.

## IV. Һәлакәт

— Шаһ Гали хан, нигә газиз җирне саттың,
Үз халкыңа кылыч селтәп, пычрак аттың...

— Кызыктыңмы Сафа-Гәрәй тәхетенә,
Елан булып уралдың ил бәхетенә.

— Ятим иттең Сөембикә — гүзәл ярны,
Халкың сиңа гафу итмәс аккан канны.

— Җаның сатып, ил тамырын син корыттың,
Алтын күреп, ана сөтен ник оныттың?..

Тарткалашты берләшмичә төрки халык,
Ауды сыкрап ялгыз калган батыр Алып.

Сынып төште ялгыз сөңге газиз җиргә,
Моннан да зур җәза бармы шанлы илгә.

Аерылганны аю ашар, бүре ашар,
Ул халыкка хәсрәт, кайгы ишеген ачар.


Балта тоткан кулдан ауды манаралар,
Бу афәттән газиз җирне кем аралар?

### V. Дога көтеп

Ничә гасыр төзәлмиләр бу яралар,
Елый таңда кылган үскән киң далалар.

Җил уйнаган киң далада биек курган,
Дога көтеп, бабам рухы күзен йомган.

Уян инде, уян, халкым, уян, Казан,
Ак курганда бабам рухы көтә азан...





**Нариман Фәтхуллин**

# РОССИЯДӘ ҖИНАЯТЬЧЕЛЕКНЕ ҖИҢЕП БУЛЫРМЫ?

(СОЦИОЛОГИК УЙЛАНУЛАР)

**Нариман Садри улы Фәтхуллин (1936) — чыгышы белән Сембер ягыннан, Иске Кулаткы районыннан. М. В. Ломоносов исемендәге Мәскәү университетының философия факультетын тәмамлаган. Фәлсәфә фәннәре докторы, профессор, милиция полковнигы. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Юридик институты Казан филиалында иҗтимагый-сәяси фәннәр кафедрасы начальнигы. Ике монографик хезмәт һәм дистәләгән мәкаләләр авторы. Фәнни эшчәнлегенең төп юнәлеше — җинаятьчелекне социологик яктан тикшереп өйрәнү.**

**Журналыбызда дүртенче мәртәбә катнаша. Аның бу хезмәте «Казан утлары»ның 6—7 саннарында басылган Ә. Борһановның «Кая бара бу Россия?» һәм Р. Вәгыйзовның «Татарстанда җинаятьчелеккә каршы көрәш чаралары» дигән мәкаләләренә авазаш.**

**Н. С. Фәтхуллинга август аенда 60 яшь тулды. «Казан утлары» редакциясе галимне гомер бәйрәме белән котлый һәм фәнни-педагогик эшчәнлегендә зур уңышларга ирешүен теләп кала.**

*Умом Россию не понять...*
Федор ТЮТЧЕВ.

Хәзерге Россия дәүләтендә, шул исәптән Татарстаныбызда да, җинаятьчелек туктаусыз үсә бара. Илдә үзгәртеп кору чоры башланып, сәяси һәм икътисади реформалар барышында дәүләт җитәкчеләре бер-бер артлы ясаган тупас хаталар ул үсешне тагын да тизләтте, тирәнәйтте, котылгысыз итте. Бу күңелсез хәл җинаятьчелекнең барлык төрләренә дә карый, әмма авыр җинаятьләр — бигрәк тә кеше үтерүләр аеруча ешайдылар. Россиягә (таркалган СССРга) элгәре бөтенләй хас булмаган яңа төр җинаятьләр барлыкка килде, болар: куркытып акча бирергә мәҗбүр итү — рэкет, наркотиклар белән сәүдә итү — наркобизнес, акча түләтү максатыннан кешеләр урлау (хәтта бала-

ларны да!), сәяси яки башка максатларда заложниклар — тотыклар алу һәм — иң яманы! — бер гаепсез кешеләрне үтерү, төрле диверсияләр-шартлатулар оештыру — террорчылык. Аннары акча түләп, заказ белән кеше үтертүләр дә соңгы елларда бик ишәеп китте, моңарчы без ишетеп тә белмәгән киллерлар — түләүле үтерүчеләр пәйда булды. Һәм, ниһаять, җинаятьчел оешмалар һаман берләшә бара, алар дәүләт аппаратларына, хокук саклау органнарына да үтеп керә башладылар. Бу куркыныч күренешләр, һичшиксез, тирәнтен һәм махсус өйрәнүне сорый.

Җәмгыятьнең куркынычсызлыгына янаучы, кешеләрнең хокукларын таптаучы һәртөрле законсыз күренешләрне тагын да күпләп санарга булыр иде. Хәзер без шәхескә карата җинаять кылуның көннән-көн шәфкатьсезләнә, рәхимсезләнә баруын күрәбез. Җинаятьче үз корбанын кешелексез рәвештә, садистларча ләззәтләнеп мәсхәрәли-мыскыллый, бернинди әхлакка, шул исәптән, хәтта җинаятьчеләрнең язылмаган кануннарына да сыймый торган гамәлләргә бара. Шулай итеп, социаль тип буларак, җинаятьченең дә йөзе үзгәрә. Шуңа күрәдер дә, хәзер дөньяның төрле кыйтгаларындагы илләрдә «урыс мафиясе» дигән сүздән дер калтырап, куркып тора башладылар.

Россиядә җинаятьчелекнең шулай тыелгысыз рәвештә үсә баруын нинди сәбәпләр аркасында дип, ничек итеп аңлатып бирергә соң? Сәбәпләре күз алдында: илнең асты-өскә килгән заман, Россия дигән (СССР дисәк тә ярый) бөек империя таркала. Әмма бу җавап берьяклы гына булыр. Моннан тыш шундый сорау да туа: ә җинаятьчелекнең болай котырынып азуы озак дәвам итәрме? Ахыр чиктә ул безнең җәмгыятебезне ни-нәрсәләргә китереп җиткерер? Бу җимергеч процессны туктатырлык чын социаль көчләр һәм мөмкинлекләр бармы? Булса, ничек, ни рәвешле һәм нинди хак биреп туктатырга аны?

Гаять авыр, тиз генә җавап биреп, чишеп булмаслык авыр сораулар...

Мин, шушы мәсьәләләрне тикшерүче-өйрәнүче галим буларак та, гаилә башлыгы — балалар атасы буларак та, борчылып уйланам: балаларым-оныкларым нинди дөньяда, нинди җәмгыятьтә яшәрләр соң?

Хокук саклау органнарына бәйле махсус уку йортында эшләвем сәбәпле, мин һәр көнне әлеге явызлыкка каршы көрәшүче кешеләр белән күзгә-күз очрашып торам, аралашам. Алар белән фикер алышканда, әңгәмә корганда — гади сержантмы ул, полковникмы, яисә тикшерүчеме, судьямы — һаман да шул бер хакыйкатьне ачыкларга тырышам: җинаятьчелекнең болай азып китүе — вакытлы күренеш; ул тиз бер эзгә төшәр, кимүгә йөз тотар; кешеләр бер-берсен үтерүдән, талаудан, көчләүдән тыела башлар; урамнарыбыз тынычланыр, без курыкмый-шикләнми яши башларбыз... Мин әнә шундый фикерләр ишетергә телим. Ләкин, ни аяныч, әңгәмәдәшләремнең күпчелеге тирән төшенкелек хисе кичерәләр, өметләндерерлек сүзләр әйтмиләр.

Әлбәттә, бу мәсьәлә фәнни нигездә өйрәнүне, дәлилле нигезләүләргә корылган тирән тикшеренүләрне таләп итә. Тормыш безнең алга китереп куйган мөһим сорауларга күпкырлы, җентекле хезмәтләр белән, мөмкин булган барлык ысулалымнарны кулланып кына җавап таба алырбыздыр. Кызганычы шул: мондый өйрәнү-тикшеренүләр бездә әле бары тик яралгы хәлендә генә.

Бу нисбәттән табигый сорау да туа: башка илләрдә хәлләр ничегрәк тора икән? Алар да без кичерә торган газаплы-җафалы чорны кичерделәрме икән? Һәм аннары ничегрәк котылдылар икән?

Моннан ике ел элек миңа җинаятьчелеккә һәм наркобизнеска каршы көрәш мәсьәләләре буенча Санкт-Петербургта үткәрелгән халыкара фәнни-гамәли конференциядә катнашырга туры килгән иде. Анда Россиянең атаклы криминологы, Эчке эшләр министрлыгы Академиясе профессоры Г. М. Минковский чыгыш ясады. Ул үзенең чыгышында тыңлаучыларны, Россиядәге җинаятьчелекнең үсешеннән куркырга һәм өметсезлеккә бирелергә кирәкми дип, ышандырырга тырышты. Дәлил итеп күп кенә чит илләрдә җинаятьчелекнең бездәгедән шактый югары булуына басым ясады. Әмма, имеш, барыбер халык, үзенең киләчәге өчен курыкмыйча, исән-аман яшәп ята, балалар үстерә икән.

Хөрмәтле профессорыбыз бу очракта бераз гына күзгә төтен җибәрде: җинаятьчелекнең үсеш динамикасын исәпкә алып, тирән анализ ясаудан, нигезле нәтиҗәләр чыгарудан баш тартты. Әйе, чынлап та, бүгенге Америка Кушма Штатларында җинаятьчелек зур, кайбер төр җинаятьләр буенча ул Россияне дә узып китә. Әмма эш шунда ки, җинаятьчелекнең ул югары дәрәҗәсе инде озак еллар дәвамында бер урында тора, ул үсми, арта бармый. Хокук саклау эшчәнлеге дә анда шулай куелган — һәрбер төрле җинаятьләр контрольдә, күзәтү астында тотыла, аларга азарга ирек бирелми. Андагы икътисади-матди мөмкин-

лекләр һәм тәртип сагында торучыларның үз эшләрен оста белеп башкарулары тегe яки бу чайпалышларга юл куймый, аларны шунда ук баса ала. Анда көрәш һәм профилактик тәрбия чаралары җитәрлек, илнең гражданнары да законны, закон сагында торучыларны ихтирам итәләр. Кыскасы, тәрәккыяте алга киткән бай ил ул.

Шул ук Г. М. Минковский безне Россиядәге хәлләр өчен борчылмаска чакырып, Монголиядә җинаятьчелекнең бездәгедән өч мәртәбә артык икәнлеген әйтеп узды.

Һәрбер илнең үз язмышы, үз гореф-гадәтләре, үз үсеш дәрәҗәсе бар. Һәм, шуңа нисбәтле рәвештә, җинаятьчелекнең нигезле үз сәбәпләрен дә эзләргә кирәктер. Россиядәге хәлләрне АКШ яки Италия, Колумбия яки Мексикадагы хәлләр белән чагыштырып, бер аршинга үлчи башласак, бер мәгънә дә чыкмас, хакыйкатьне таба алмабыз. Илләр белән илләрне чагыштырганда җитәрлек логик дәлилләр булырга тиеш. Мәсәлән, Бәйсез Дәүләтләр Берләмлеге — БДБ илләренең күпчелегендә якын елларда җинаятьчелек Россиядәге тизлек белән яки аннан да тизрәк үсеш алыр дип юрау хаклы булыр. Чөнки ул илләр кичәге бердәм империя — СССР составындагы союздаш республикалар иде һәм шунлыктан бертөрлерәк социаль-тарихи шартларда яшиләр иде. Россия, дәүләт буларак, үзенең үсеш тарихында чын мәгънәсендә капиталистик илгә әверелә алмый калды. Аны, феодализм дәвереннән чыгып җитмәгән көенчә, егерменче гасыр башында ук рәттән өч революция кичерергә мәҗбүр иттеләр. Ничәмә-ничә гасырлар дәвамында тирә-күрше халыкларның җирләрен басып, үзләрен яулап-талап, бинһая зур булып күпергән-кабарган Россия империясе, күпчелек Европа илләреннән аермалы буларак, чын тәрәккыят ала алмады, чын цивилизацияле, алга киткән, укымышлы-белемле ил булып җитлегергә өлгермәде. Бер-бер артлы яулап алынган һәм СССРга мәҗбүри көчләп кушылган-укмаштырылган илдәүләтләр дә шул ук язмышка дучар булдылар.

Урыс шагыйре Федор Тютчевның: «Умом Россию не понять...» — дигән канатлы сүзләрен үзләренчә аңлатырга теләп, Россия өстенә нинидидер серлелек пәрдәсе эләргә омтылган «акыллыбашлар» элек тә күп булган, хәзер дә җитәрлек. Теләгәндә, бу империянең — урыслар үзләре ятарып-горурланып әйткәнчә, «бүленмәс бердәм бөек Россиянең» асыл сыйфатларын акыл белән да аңларга була, хәзерге фәнни ачышлар белән дә расларга була. Ничәмә-ничә гасырлар буена урыс халкы үзен иксез-чиксез уңдырышлы җирләрнең, киек-җәнлекле, үтеп чыга алмаслык карурманнарның, балыкка-кош-кортка бай исәп-хисапсыз елга-күлләрнең-диңгезләрнең, меңәр еллык җир асты байлыкларының әзергә бәзер хуҗасы итеп тойды, шуны буыннан-буынга канына сеңдерде. Шул җирләрдә яшәүче халыкларны изде, колы итте, тамак хакына гына эшләтеп яшәтте. Үзе исә яңадан-яңа яулау сугышлары белән мәшгул булды. Бу җинаятьчел сәясәт күп кенә аз санлы халыкларны бөтенләй юкка чыгуга китерде. Бүгенге җинаятьчелекнең үсеш тамырларын да әнә шул чорлардан ук эзләргә кирәк түгелме икән?

Әйе, Россия империясендә иҗтимагый-сәяси дәүләт төзелеше, хокук һәм хокукый мөнәсәбәтләр, милек-мөлкәт төшенчәсе, хезмәткә булган карашлар Европа илләрендәгедән бөтенләй үзгә иделәр. Сәяси тел белән әйткәндә — биредә башка менталитет. Татар исә аны: «Пәри — башка, җен — башка!» — дияр иде.

Бу уңайдан, күптән түгел булып узган бер вакыйга искә төшә. Россиянең бүгенге җитәкчеләреннән берсе, Рязань якларында йөргәндә, авыл агаеннан сораган булып кылана: «Йә, ничшлибез, Курил атауларын японнарга бирәбезме?» — янәсе. «Юк, юк! Бирмибез!» ди агай. Җитәкчене дә, авыл агаен да мәсьәләнең икенче ягы бөтенләй кызыксындырмый: Курил атауларындагы халык коточкыч шартларда — баракларда, ачлык-ялангачлыкта яши, аны төрле авырулар кыра...

Хәзерге Европа кешесенең хокукый аңы россияннарныкыннан җир белән күк шикелле аерылып тора, чөнки аның аңы күпгасырлык тәрәккый-мәдәни үсешләр аша, социаль-икътисади шартлар аша буыннан-буынга күчеп формалаша килгән. Бу процесс һәр кешенең хосусый милеккә булган хокукын ныгыту-яклау юнәлешендә үскән, хокукый мөнәсәбәтләрне исә гадел законнар билгеле бер какшамас тәртипкә салган. Кабатлап әйтергә туры килә: җир арты җирләр, халык арты халыклар яулап үскән-күпергән Россия империясенең иҗтимагый-дәүләт төзелеше тәсбихендә бер төймә — капиталистик төймә җитми кала. Нәкъ менә шуңа күрә дә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне тәртипкә китереп, җайга салып торырлык хокукый институтлар юк (бу очракта «институтлар» төшенчәсен «иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең бәрәр өлкәсендә хокук нормалары барлыгы» дип

аңларга кирәк), алар да үсеш ала алмый калган. Хәзер без һәркайда хокукый аң үсешенең юк дәрәҗәсендә «юылып беткән» булуын, ягъни хокукларны танымау — хокукый нигилизм күренешләрен, чикләнмәгән хокуксызлык гамәлләрен күрәбез икән — бер дә гаҗәп түгел.

Җәмәгать тәртибе сагында торучылар белә: хәлләрнең болай начараеп китүе, законсызлык һәм чикләнмәгән криминаль процесслар бигрәк тә совет дәүләте таркалганнан соң башланды. Билгеле булганча, СССРның Сталин заманнарындагы үсеше чорында дәүләтнең социаль-сәяси кармавычлары җәмгыятьнең һәр күзәнәген кармап-тикшереп торалар иде. Юрист галим Г. П. Федотов бу хакта: «...дәүләт органнары кешеләрнең торакларындагы һәр почмакны, күңелләрендәге һәр тирбәнешне үз күзәтүе астында тотып килделәр»,— дип яза. Ил халкының бөтен тормышы, үз-үзен тотышы әнә шундый гомумкүләм тоталь күзәтү астында булганга күрә, ул вакытларда хокук бозу һәм җинаятьчелек чагыштырмача түбән дәрәҗәдә иде.

Икенче бер галим В. В. Лунеев исә болай яза: «Хокукка кагылышлы барлык гамәлләр дәүләтнең һәртөрле хокукларын, аерым алганда, шәхес хокукларыннан өстенлеге, аның законлаштырылган беренчеллеге белән билгеләнә, шуңа нигезләнә; ә оештыру эшләре хәзер яманаты чыккан демократик централизмга таяна иде, «демократик» дигәне биредә тышкы бизәк кенә булып, хакимиятнең барысын да колачлаган каты централизмы — һәрнәрсәне үзәкләштерүгә бу тәгълиматның төп эчтәлеген тәшкил итә иде». Социаль күзәтүнең бар нәрсәне тикшереп белеп торуның барлык җепләре бер үзәккә тупланганлыктан, киң катлам халык үзе исә андый вазифалар башкарырлык иҗтимагый хокук нормаларыннан мәхрүм ителгән «шөреп» кенә иде.

Ахыр чиктә нәрсә килеп чыкты соң? Дәүләт тарафыннан шулай күзәтүнең тоталь формалары йомшара төшү белән, илленче еллар уртасыннан илдә җинаятьчелек туктаусыз үсә бара һәм ул 1991 елга инде алты мәртәбә артты. Менә шулай! Партократик система җимерелеп, КПСС таратылгач, аннары СССР да таркалгач, җәмгыять иҗтимагый мөнәсәбәтләрне тәртипкә-җайга салып торучы мөмкинлекләрсез калды. Приватизацияләштерү дигән сылтау белән дәүләт милке юкка чыгарылды, төрле дәрәҗәдәге түрәләр арасында коррупция-ришвәтчелек чәчәк ата башлады. Юридик фәннәр докторы, Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәре, генерал В. С. Овчинниковның әйтүенә караганда, куркытып-көчләп акча таләп итү һәм ришвәтчелекнең туксан сигез проценты (!) рәсми урыннарда утыручы түрәләр тарафыннан эшләнә икән. Әзерлексез башланган «демократик реформаларның» ачы җимешләре бу.

Җәмгыятьне алай үзгәртеп коруга тотынудан элек, ул реформаларны башкарып чыгарлык һәм җайга салырлык махсус чаралар оештыру мәгъкуль иде. Барысы да әзерлексез башланганга күрә, күпчелек матур уй-гамәлләр тормышка аша алмады, җимерелеп-коелып төште. Бер селтәнү белән КПССны юкка чыгару, шул рәвешле үзәкләштерелгән идарә итүне таркатып ташлау асылда илгә-халыкка хыянәт итү иде.

Инде түбәндәге нәтиҗәләргә килергә була.

Беренчесе. Җинаятьчелеккә каршы көрәш һәм профилактик тәрбия эшендә, фән теле белән әйтсәк, субъектны югалту килеп чыкты. Көрәш субъекты һәрвакыт объекттан анык аерым торырга тиеш. Ягъни бер якта дәүләтнең хокук саклау органнары, законнар иҗат итү, хокук тәртибен тәэмин итүче матди көчләр була. Болар, бердәй булып, субъектка каршы, ягъни закон бозучыларга, җинаятьчеләргә каршы көрәшергә, аларны эзләп табарга, кулга алырга, законлы җәзасын бирергә тиешләр. Хәзер исә менә шушы кара-каршы тору халәтенең диалектикасы бозылды. Субъект белән объект үрелеп үсә башлады. Хокук саклау органнарына һәртөрле явыз ниятле, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучы шәхесләр үтеп керә. Хокук саклау органнары үзләре дә төрле басым ясаулардан йомшап төшә, һәртөрле яшерен сөйләшүләргә, законсыз элемтәләргә барырга әзер тора.

Эчке эшләр органнарында кадрларның алмашынып торуы, эштән китүләр бик ешайды. Әлбәттә, житәкчелек һәртөрле намуссыз бәндәләрдән котылырга тырыша, үз хезмәткәрләренең закон бозуларына каршы аяусыз көрәшә. Ләкин башка сәбәпләр белән эштән китүчеләр дә байтак. Берәүләр милициядә эшләүнең авырлыгына түзә алмый, икенчеләренә тәвәккәллек һәм кыюлык житенкерәми. Хезмәт хакы да, башка тармаклардагыдан чагыштырмача югарырак булса да, ул хезмәттә сарыф ителгән көчкә бәрабәр түгел әле.

Милиция органнарыннан эшкә чын күңелдән бирелгән, иң тәҗрибәле белгечләрнең китүе бигрәк тә аяныч. Алар милиция эшчәнлегенә үтеп кергән законсыз-

лыклар белән килешә алмыйлар, коррупция сазлыгына баткан сатлык түрәләр басымына да, җинаятьчел оешмалар басымына да бирешергә теләмиләр — шуңа күрә ул вазифаларда озак тотрыклы тора алмыйлар. Һәм шунысын да әйтергә кирәк, бу тәҗрибәле-белемле профессионалларны шунда ук төрле фирмалар, акционерлык оешмалары, сәүдәгәрләр һ. б. үзләренә чакырып ала, зур акчалар тәкъдим итә. Кызганычы шул, законнарны яхшы белүче, тәҗрибәле бу кешеләрнең күпчелеге элек җәмгыятьтәге хокук бозуларга каршы көрәшкән булса, хәзер инде үзе хезмәт иткән фирманың мәнфәгате өчен төрле хокук бозуларны оештыра башлый.

Дәүләт хәзер Эчке эшләр министрлыгын югары юридик белемле белгечләр хисабына тулыландырырга кирәклеген аңлый башлады һәм шул мөмкинлекләрне эзли шикелле. Шундый максаттан чыгып, яңа уку йортлары да ачыла башладылар. Мисалга РФ Эчке эшләр министрлыгының Юридик институты Казан филиалы ачылуны да китерергә мөмкин. Әмма шунысы бар, югары дәрәҗәдәге белгеч дигән төшенчә ул әле хокук белемнәренә ия булган һәм шул белемнәрен куллана ала торган шәхес кенә дигән сүз түгел, ул шәхес дәүләт югарылыгында фикер йөртә белергә һәм дәүләт мәнфәгатьләренә тулысынча турылыклы булырга да тиеш. Халык телендәге милиционер — ул дәүләт кешесе. Аның әхлакый сыйфатлары да тотрыклы-нык, сатылмас-хыянәт итмәс, кыю һәм тәвәккәл төшенчәләр белән генә билгеләнә ала.

Һәр милиция хезмәткәренең шундый сыйфатларга ия булуын ничек тәэмин итәргә соң? Моның өчен бик күп мәсьәләләрне хәл итү сорала. Милиция органнарына яңа кадрлар сайлаганда аларның социаль чыгышларын да белергә, аны җиде кат җиз иләктән үткәреп, конкурс-ярыш шартларында алырга кирәк. Аннары, эшлекле сыйфатларына карап, аны вакытында үстерә дә белү мөһим.

Икенчесе. Татарстан Дәүләт Советында эчке эшләр органнарының, шул уңайдан иң элек милициянең эшчәнлеге яхшырту мәсьәләләре буенча кайнар бәхәсләр барганы хәтердә калган. Кайсы гына мәсьәләгә кагылмасыннар, сүз матди чараларның җитәрлек булмавына килеп терәлә. Үзеннән-үзе шундый сорау туа: җинаятьчелекне җиңү өчен күпме хак түләргә кирәк икән? Туп-туры әйтик: ил-дәүләтнең андый байлыгы юк. Җинаятьчелеккә каршы көрәштә АКШтагы шикелле итеп иркенләп, кыю һәм нәтиҗәле гамәлләр Россиянең хәленнән килмәстәй авырлар алар. Ул таланган, ул ярлы-хәерче ил. АКШта шымчылар тоту өчен генә дә безнең илдә бөтен хокук саклау органнарына тотылган кадәрдән күбрәк суммалар тотыла.

Әмма эш бит әле вакытында тиешле чыгымнарны бүлеп бирү белән генә дә бетми. Әйтик, безнең Татарстаныбыз Президенты, искиткеч зирәклек күрсәтеп, ул чыгымнарны ике-өч мәртәбә арттырырга мөмкинлек тапты, ди. Хәлләр күпкә яхшырачак, әлбәттә. Әмма җинаятьчелекне тулысынча җиңү өчен димик, аны сизелерлек киметү өчен генә дә хокук саклау органнарына кагылмаган бик күп башка мәсьәләләрне хәл итү кирәк булачак.

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев 1993 елда «Җинаятьчелеккә каршы көрәш буенча гадәттән тыш чаралар турында» Указ да чыгарды. Аның нигезендә, һичшиксез, зур уңай эшләр эшләнде. Бу Указ гамәлдәге конституциябезгә каршы килеп, чарасызлыктан кабул ителгән булса да, нәтиҗәсез калмады. Аннары Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы арасында җинаятьчелеккә һәм башка хокук бозуларга каршы көрәшне җайга салу турында килешүләргә кул куелды. Ул да матур нәтиҗәләр биреп килә. Хәтта, Татарстан тәҗрибәсен өйрәнгәннән соң, Россия Президенты Б. Н. Ельцин да шундый Указ чыгарырга мәҗбүр булды.

Ләкин бу чараларга карап кына ил-дәүләттә җинаятьчелеккә ышанычлы киртә куелды дип һич тә әйтеп булмый әле. Илдәге эшсезлекнең арта баруы урамнарга көн саен яңадан-яңа кешеләрне, шул исәптән яшьләрне дә чыгарып ташлый. Сүз дә юк, аларның бер өлеше оешкан җинаятьчелек үзенә тартачак, бер өлеше исә җинаятьчелекнең иң аскы катына төшәчәк: бакча йортлары басу, вак-төяк караклык, хулиганлык һ. б. шундый җинаятьләр дә арта барачак. Болар янына Россиядәге чамасыз эчкечелекне дә, соңгы елларда урын алган наркоманлыкны да өстәргә кирәктер.

Юриспруденция фәнендә бер төшенчә бар: җинаятьчелектәге сан чиге төшенчәсе. Әгәр дә ул тиешле бер дәрәҗәдән артып китсә, буйсындырып-тыеп булмаслык хәлләр дә килеп чыгарга мөмкин. Дәлил итеп шундый мисал китерергә була: кибетләрдә теге яки бу товарның житенкерәмәве дүрт кенә процентка төшсә дә (ә аны сәүдә эшенә кереп оялаган җинаятьчел төркемнәр оештыралар), халык арасында тәшвиш-паника башлана, кибет киштәләреннән еллар буе сатылмый яткан һич кирәксез товарларны да себереп алып бетерәләр. Безнең илдә

мондый хәлләрнең шырпы-тоздан башлап спиртлы эчемлекләргә кадәр бер генә тапкыр булмаганын һәркем белә.

Тагын бер чагыштыру: теләсә кайсы ил-дәүләттә эшсезләр саны биш-алты процентка артып киткән очракта җәмгыятькә җимергеч зыян китерердәй яңа дулкыннар хәрәкәтләнә башлый.

Җинаятьчелекнең әнә шул без телгә алган сан чиге артып китсә, ул хокук саклау мәсьәләләре генә булып калмый, ә социаль-сәяси мәсьәләләргә әверелә. Юридик фәнни әдәбият шул караштa тора. Әмма, безнең уйлавыбызча, хокук тәртибе һәм законлылык һәр җәмгыятьтә баштан ук социаль-сәяси, дәүләт күләмендәге мәсьәлә булып каралырга тиештер. Һәм бирешә аны ачык аерып күрсәтергә кирәк: кайсы бурычлар эчке эшләр органнарына карый, кайсылары закон чыгаручы депутатлар өстенә йөкләнә, ә кайсылары шуларны тормышка ашыручылар җаваплылыгында кала.

Көндәлек тормыштагы чынбарлык һәр көнне диярлек катлауланып тора, аны гамәлдәге законнарга гына сыйдырып бетереп булмый. Бик күп җинаятьчел эшләрне хәл итүдә ачыклык булмау милиция, прокуратура, судларның кулын бәйли; вакытында тиешле законнар кабул ителмәү аркасында, алар нәтиҗәле чаралар күрә алмый.

Бу хәл бер безнең илдә генә түгел, ул төрле дәрәҗәдә башка илләрдә дә очрап тора. Шунлыктан, закон бозучылар һәрвакытта да тиешле җәзаларын алмыйлар. Җинаятьчелекнең социологик шартларын тикшерүче америка галиме Э. Шур теге яки бу җинаятьләрне «йомып калдыру» очракларын өйрәнгән. Аның мәгълүматлары мондый: җинаятьчеләре кулга алынса да, полиция фаш иткән җинаятьләрнең барысы да тикшерелеп бетми; кулга алынучыларның һәрберсе дә суд җаваплылыгына тартылмый; судка тартылган очракта да, һәр суд эше гаепләү белән тәмамланмый; гаепләнеп хөкем карары чыгарылган җинаятьчеләрнең дә барысы да төрмәгә утыртылмый. Нәкъ шундый ук тикшеренүләрне өстәрәк без телгә алган В. В. Лунеев та үткәрә. Ул Россиядә бүгенге көндә суд җаваплылыгына тартылган җинаятьчеләрнең бары тик дүрттән берсенә генә тиешле хөкем җәзасы бирелә, дигән фикергә килә. Ә инде иң югары җәзага — үлемгә хөкем итүне хәзер бөтенләй алып ташларга кирәк, дигән карашлар белән һич килешәсе килми. Россиядә көн саен кеше үтерүләр булып торганда, бу чарага барырга ярамаганлыгы ачык бит, югыйсә.

Э. Шур һәм В. Лунеев бервакыттарак уртак нәтиҗәләргә килсәләр дә, сәбәпләре төрле, әлбәттә. Милиция, эзәрлекләү һәм тикшерү хезмәткәрләре зур киеренкелек белән эшлиләр, шуннан да артыгы аларның хәлләреннән килми. Судлар да шул кадәр күп җинаять эшләре ташкынын тиз генә ерып чыга алмыйлар. Төрмәләр һәм тикшерү изоляторлары җинаятьчеләр белән тулып ашкан. Шунлыктан, бик җитди җинаятьләрне дә, вак-төяк дип исәпләп, тизрәк суд эше кузгатуны ябарга тырышалар. Мәсәлән, корбанына авыр тән җәрәхәтләре ясаган җинаятьчене хәзер еш кына «вак хулиганлык» дип кенә иреккә чыгарып җибәрәләр. Милиция, прокуратура һәм суд хезмәткәрләрен җинаятьчел оешмалар йә куркытып, йә сатып алу очраклары да бик ешайды. Телефоннан шалтыратып янаулар, дисеңме, судьяны: «Бу җинаять эшен фәлән статья буенча гына карагыз...» — дип сатып алырга тырышулар, дисеңме, адвокатка «зур гонарар» төртүләр, дисеңме — хәзер болар барысы да артып ашкан.

Адвокатлар эшчәнлегенә аерым тукталып үтү кирәктер. Хокукый дәүләт төзү, Россия законнарын гуманлаштыру — кешелеклерәк итү дигән максатлар суд эшләрендә адвокатларның дәрәҗәсен-абруен арттыру өчен эшләнгән кебек иде. Чынлыкта исә алай булып чыкмады. Хәзер адвокат урынын яулап алу җиңел түгел, чөнки ул бик төшемле һөнәр. Әлбәттә, барлык адвокатлар да сатлык түгел, араларында намуслылары да байтак. Әмма, шул ук вакытта, аларга зур хокуклар бирелеп, эшчәнлек иреге белән дә ныгытылганнан соң, суд барышында теге яки бу җинаятьченең язмышын үзләренчә хәл итү, аны котылгысыз җәзадан коткарып калу мөмкинлекләре дә туа. Адвокатларның күпчелеге судьялар белән яхшы мөнәсәбәттә, судьялар исә, үз чиратларында, теге яки бу адвокатның элемтәләрен, эшчәнлек сыйфатларын яхшы белеп тора. Шул рәвешле, әйбәт түләнгән гонорар хисабына алар бер-берсе белән килешеп эшли башлыйлар. Ә җинаятьчел төркемнәр аларның тегесен дә, бусын да үз ягына аудару җаен таба.

Ә инде Россиядә тырышып-тырмашып присяжныйлар суды (ягъни хакыйкатькә һәм законга турылыклы булырга ант бирүче кешеләр) кертергә тырышу бигрәк тә сәер. Вәхшилектән, наданлыктан чыгып җитмәгән илдә шуны эшләргә мөмкинме соң?!

Соңгы елларда уйланып-эшләнеп җитмәгән законнарның күпләп чыгуы, аларның хәтта кайбер очракларда бер-берсенә каршы килүе җинаятьче төркемнәргә рәхәтләнеп яшәргә мөмкинлекләр ачты. Мәсәлән, М. С. Горбачев заманында ук шәхси эшмәкәрлек турында кабул ителгән закон шундыйларның берсе булды. Нәтиҗәдә хәйләкәр эшмәкәрләр дәүләт оешмаларын рәхимсез талый башладылар. Икенче «тарихи факт» шул иде: «тыелмаган һәр нәрсәгә рөхсәт», имеш. Бу, әлбәттә, дәүләт җитәкчеләренең ил-халык алдында җавапсызлыгын күрсәткән бер эш. Бу гамәлләрдә төп ике шарт исәпкә алынмаган иде. Беренчесе — Россия законнары бервакытта да дөнья таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәдә эшләнмәгән, алар буталчык хәлдә. Икенчесе — Россия халкының хокукый аңы һәрвакытта да бары тик үзенең тар мәнфәгатьләре ягына таба гына юнәлдерелгән булуында. «Һәр нәрсәгә рөхсәт» дигән сүзләргә төренеп, әлегә кадәр «күләгәдә яткан» җинаятьчел икътисад мәйданга чыкты һәм дәүләт оешмалары белән үрелеп берләшә башлады. Бирегә инде Явлинский, Гайдар, Чубайсларның «эшчәнлеге» бала-чага уены булып кына калды. Дәүләт икътисады тулысынча җимерелде һәм ул унбер ел дәвамында аякка баса алмый.

Оешкан җинаятьчелек ил хуҗалыгының һәр күзәнәгенә үтеп керде, аны «ашый» башлады. «Комсомольская правда» газеты күзәтчесе П. Вощанов илдәге нефть-газ җитештерү тармагын тикшереп чыга һәм шундый нәтиҗәгә килә: җинаятьчел көчләр рөхсәтеннән башка бер генә цистерна нефтьне дә ала алмыйсың. Өстә — министрлыкларда утырган түрәләр ярдәме белән бүгенге «рәхимшәфкатьсез егетләр» («крутые парни») нефтькә-газга бәяләрне дә үзләре куя һәм сата икән.

Рәсми дәүләт оешмалары вәкилләренең шул җинаятьчел төркемнәргә керүеберләшүе дигән төшенчә безнең гамәлдәге «Җинаятьләр кодексы»нда юк. Оешкан җинаятьчелеккә бирелгән аңлатма-төшенчә дә һаман искечә кала бирә.

Оешкан җинаятьчелек — үсеше алга киткән тәрәккыятле илләрдә (әйтик, АКШта, Италиядә һ. б.) ул, кагыйдә буларак, үзенә күрә өч катлы бәлеш-бөккән шикелләрәк була икән. Россиядәге бу «бәлеш-бөккәнне» шулай ук өч һәм хәтта дүрт катлы итеп күз алдына китерәләр. Мәсәлән, җәмгыять белеме буенча танылган галим А. Бутенко аны болай аера: беренче кат — эшмәкәр, икенчесе — алыпсатар, өченчесе — финанс эшлеклесе, дүртенчесе — сәясәтче (соңгысы — киң мәгънәдә алганда, ул дәүләт аппаратындагы берәр түрә). П. Вощанов исә «бәлеш-бөккәнне» үзенчәрәк бүлә: сәясәтчеләр, эшмәкәрләр һәм бандитлар. Бандитларны, үз чиратында, «авторитетлар» (ягъни башлыкларга), урта катламга һәм иң түбәндә — «төптә ятканнарга» аерып күрсәтә.

Чит илләрдә дәүләт оешмаларындагы хезмәткәрләрне еш кына бер «эш» майтару өчен генә сатып алалар. Җинаятьчел эшкә кат-кат катнашкан очракта да, ул барыбер мафиоз төркем әгъзасы булып санала алмый. Кирәге беткәч, аны юк итәләр. Ә бездә исә икътисади җинаятьләргә тартылган андый шәхесләр даими рәвештә «үз кешеләренә» генә хезмәт итә. Хәтта шундый кагыйдә дә бар: минем кешемне минем рөхсәтемнән башка беркем дә үзенә хезмәт иттерә алмый.

Чит илләрдә әгәр дә берәр министрның яки конгрессменның (безнеңчә, депутатның) җинаятьчел дөнья белән бәйләнеше ачылса, аның карьерасына шунда ук чик куела, ул эшеннән китәргә мәҗбүр була һәм хәтта суд җаваплылыгына тартыла. Ә бездә исә «бәлеш-бөккәннең» бу катламына, татарча әйтсәк, суд та юк...

В. Лунеев: «Югары даирәләрдәге берәрсенең җинаятьчел эшләре фаш ителү күбесенчә кагыйдәдән чыгарма рәвешендә генә була һәм ул төрле төркемкланнарның үзара көрәшеп чыгарып селки торган бер чара гына, еш кына «буялган шәхестән» үз вакытында котылу юлы гына. Эш судка барып җитсә дә, ул «судан коры чыга» һәм тизрәк берәр «җылы урынга» эшкә урнаша», — дип яза.

Бу хәлләргә һич гаҗәпләнергә кирәкми, чөнки демократик булмаган социаль системаларда, — Россия нәкъ шундый дәүләтләргә тартыла, — хокук саклау органнары һәм судлар тулысынча югары даирәләргә бәйле һәм үз эшчәнлекләрендә законга гына таяна алмыйлар. Алай гына да түгел, идарә итүче элитар төркемнең бер өлеше үзләренә кагылгысыз хокуклар ала (дәүләт думасы депутатлары һәм кайбер җитәкчеләр). Җинаятьчел шәхесләр дә, әгәр җитәрлек байлыгы һәм элемтә-бәйләнешләре булса, депутатлыкка сайлана һәм шундый ук хокук ала ала (М. Мавроди мисалы).

Оешкан җинаятьчелек — безнең заманның бер билгесе ул. Шунысы кызганыч, профессионал җинаятьчеләр үзләренең позицияләрен ныгытканнан-ныгыта баралар, сәяси хакимият арасына да күбрәк үтеп керәләр. Моның нәтиҗәләре бик куркыныч һәм җитди булачак. Бу — дәүләткә каршы җинаять дигән сүз.

«Балык башыннан чери»,— ди халык. В. Лунеев болай яза: «Җинаятьчелек дәрәҗәсе сәяси һәм идарә итүче даирәләрнең әхлакый-хокукый нигезләре белән шундый тыгыз бәйләнгән ки, җинаятьчелек аза барган саен, идарәче даирәләр дә аза бара һәм, киресенчә — идарәче даирәләр аза барган саен, теге яки бу илнең халкы да аза бара.

Теоретик криминология фәне, акрынлык белән булса да, иске догма-төшенчәләрдән арына килә. СССРда җинаятьчелек «капитализм калдыклары» ул, дип кенә аңлатыла иде бит. Моннан да куркыныч саташтыру-буташтыруны һәм спекулятив карашны уйлап табарга да кирәк. Кызганыч, бу догмалар күп кенә «акыллыбашлар»да, шул исәптән зур хакимият түрәләрендә дә, әле булса сакланып килә.

Берничә ел элек республикабыз җитәкчеләренең бер бәхәсендә катнашырга туры килгән иде. Сүз Татарстанның суверенитетын-бәйсезлеген ныгыту турында барды. Аңа кайсы яктан, нинди куркыныч яный? Капма-каршы фикерләр чарпалашты. Берәүләр куркынычны «сулдан» — милләтчеләрдән (Ф. Бәйрәмова, «Азатлык» берләшмәсе һ. б.) эзләделәр, икенчеләре исә, киресенчә, «уңнардан» (Михайлов, Штанин һ. б.) күрделәр. Безнеңчә, Татарстанның суверенитетына чын куркыныч оешкан җинаятьчелектән килә, шул республиканың бәйсезлегенә яный. Җинаятьчелек һәрвакыт милләтләрдән өстен тора, аның милләте юк. Безнең демократик үсешебезнең, киләчәгебезнең иң төп дошманы шул.

Россиядә яшәүче халыклар белән нәрсә булып бетәр, аларны нинди язмыш көтә, ил-дәүләт кая таба бара? Галим А. Бутенко: «Мафия Россиядә яшәп килгән иҗтимагый-сәяси системаның бөтен тәненә-күзәнәкләренә таралган коточкыч рак авыруы — яман шеш ул. Оешкан җинаятьчелек хәзерге дәүләт төзелешен үзенә яраклаштырып төзи»,— дип яза. П. Вощанов белән В. Лунеев та шул фикерләрне алга сөрәләр.

Шулай да мин төрле ил һәм халыкларда җинаятьчелек — сыйфат ягыннан да, сан ягыннан да төрлечә чагыла, дигән фикердә торам. Аңа каршы көрәш халыкларның гасырлар буена тупланган гореф-гадәтләр, әхлак нигезләре аша, аның менталитеты аша алып барыла. Мәсәлән, күп кенә мөселман дәүләтләрендә каракларның кулларын кисеп, базарларга чыгарып эләләр. Россиягә килсәк, андагы җинаятьчелек тамырлары, югарыда әйткәнебезчә, мең елларга сузыла. Бу аның «аерым казанышы».

Җинаятьчелекне чын уңай реформаларга нигезләнгән тәрәккый үсеш аша гына җиңәргә мөмкин. Социаль организм күзәнәкләрен «яман шештән» бары тик шулай гына савыктырып була.

Моның исә бер генә юлы бар — иң әүвәл империя амбицияләреннән котылырга кирәк. Республикаларда, барлык өлкә-крайларда яшәүче халыкларның яңарыш кичерүе мөһим. Россиянең тәрәккыяте бар тик федерализмнан конфедерализмга бару юлыннан гына булырга тиеш. Гасырлар буена бастырылып килгән эреле-ваклы милләт-халыкларга күбрәк азатлык, күбрәк бәйсезлек биргәндә генә аларның социаль җегәре уяначак. Бу — урыс халкының үзенә дә карый. Гомуми социаль савыгу юлы белән генә җинаятьчелекне җиңеп булачак, моңа шигебез юк. Эш бары тик уңай үсеш процессларының нинди адымнар белән, нинди тизлектә баруында гына тора.

Мин туган Татарстанымның кайгы-шатлыкларын уртаклашып яшим, башка якташларым-ватандашларым кебек үк, язмышымны республикам язмышыннан аерып карамыйм. Барлык республикаларга кирәк булган шикелле, Татарстанга да суверенитет кирәк, күбрәк дәүләтчелек кирәк. Демократия һәм ирекле тормыш өчен кирәк ул. Оешкан җинаятьчелектән һәм башка төрле кабәхәтләрдән арынып өчен кирәк.

# БУ НИНДИ БӘЙРӘМ?

**Быел җәмәгатьчелек Русия чикләре эчендәге беренче төрки дәүләтнең 1450 еллыгын билгеләп үтәргә тотынды. Бәйрәмне зурлап уздыру өчен РФ хөкүмәте рәисе В. Черномырдин боерыгы белән абруйлы комиссия төзелеп, аның составына ТР премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин, күренекле татар галимнәре Ә. Тенишев, Ш. Мөхәммәдьяровлар да кертелде. Мәскәүдә һәм башка мәркәзләрдә шушы юбилейга багышланган гыйльми җыйналышлар, тантана оештырыла, матбугатта һәм радио-телевидениедә сүз алып барыла. Шушы уңайдан журналыбыз хезмәткәре Тәүфикъ ӘЙДИ күренекле тарихчы, Татарстан Фәннәр академиясе академигы Миркасыйм ГОСМАНОВ белән очрашты һәм әңгәмә үткәрде. Түбәндә укучыларыбыз игътибарына шул әңгәмәне тәкъдим итәбез.**

*— Миркасыйм әфәнде, көтмәгәндә-уйламаганда пәйда булган бу юбилей мине аптырашка калдырды һәм күңелдә төрле-төрле шикләр уятты. Иң әүвәл, «Русия территориясендә беренче Төрки дәүләт» дип атау һәм аның барлыкка килү елын билгеләү, аннары Мәскәүнең чичәннәргә геноцид оештырган дәвердә ниндидер төркиләргә җылы, кайгыртучан илтифат күрсәтү. Кемнәр кыздыра бу бәйрәмне, бу бәйрәм артында нинди уеннар тора? Кыскасы, күңелдә сорау арты сорау борынлый. Татар җәмәгатьчелеге тулаем әнә шулай сәерсенеп калса, һич тә гаҗәп түгел. Без бүген менә шушы һәм тагын кайбер мәсьәләләргә кагылып, укучыларыбызга ышанычлы мәгълүмат бирергә тырышсак иде.*

— Казыныргa яратасың син. Әйе, сораулар күп, без аларга берәм-берәм тукталыйк инде. Юбилей дигәндә, безнең эраның беренче меңъеллыгының беренче яртысында барлыкка килгән Төрки каганлык күздә тотыла, күрәсең.

*— «Идел» журналында һәм академик М. Зәкиев мәкаләләрендә, Төркия төрекләреннән аерыр өчен, барлык төрки халыкларны тулаем атар өчен һәм борынгы бабаларыбызны белдерер өчен «түрек» атамасы кулланыла. Урысча «тюрк» мәгънәсендә. Минемчә, бу һәм дөрес, һәм уңайлы, без дә борынгы бабаларыбызны шулай атауны гамәлгә кертик инде.*

— Ихтыярың. Димәк, юбилей дигәндә, әлеге Түрек Каганлыгы күздә тотыла. Синең шикләнүең урынлы, бу Түрек Каганлыгын «Русия территориясендәге беренче төрки дәүләт» дию дөрес түгел. Сүзне һуннардан башлау кирәктер. Тик без бер нәрсәне бутамыйк: һун Каганлыгы күп кабиләле, ягъни этник яктан чуар дәүләт. Әмма анда төркиләрнең, синеңчә, түрекләрнең өстенлек итүе шик уятмый. Аннан элек тагын нинди түрек дәүләтләре, дәүләтчекләре булган — әйтүе кыен. Шулай икән, Түрек Каганлыгы түрек кабиләләре тарихы ачыграк, төгәлрәк күренә башлаганда барлыкка килгән.

Түрекләр бер заман жужан дигән халыкка буйсынып яши. Жужаннар аларны 460 елда Алтай тауларына сөрә. Түрекләр шунда тимер казып, аны эретеп, жужаннарга салым түләп яшиләр. 545 елда алар Асаншад һәм Бумыр бәкләр җитәкчелегендә жужаннарга каршы баш күтәрә һәм ирек яулап ала. 552 елда Бумын үзен каган, ягъни баш хан дип игълан итә һәм бу хәлне күрше илләр таный. Димәк, мостәкыйль дәүләт барлыкка килә. 555 елда шушы дәүләткә Үзәк Азия, Саян-Алтай таулары һәм Көньяк Себер җирләре керә. Дәүләт үзәге Урхан (Орхон) елгасы үзәгендә формалаша. Шунлыктан, аларга карата «Урхан төрекләре» исеме дә кулланыла.

Тора-бара бу дәүләтнең чикләре киңәя — Бөек Кытай диварыннан алып Кара диңгез буйларынача җәелә. Ләкин дәүләтнең төп өлеше Үзәк Азиядә (хәзерге Монголиядә) була. Ул якларда төрекләрдән тыш, мангул, угыр кабиләләре дә яшәве бәхәссез. Ләкин дәүләт башында нигездә төрки кабиләләр тора, алар арасында каганнар династиясен биргән Ашина ыруы мәртәбәле урын тота. Түрек Каганлыгы 580—620 елларда чәчәк ата. 618 елда Кытайда тәхеткә Тан династиясе килгәч, төрекләр тормышына Кытай дипломатиясе тыкшынуы көчәя — Бөек Ефәк юлы өчен көрәш кызып китә. Шуннан соң түрек хакимнәре арасында таркаулык башлана — тәхет өчен көрәш киңәя. Нәтиҗәдә 630 елда Түрек Каганлыгы икегә бүленә — Көнчыгыш һәм Көнбатыш Түрек Каганлыкларына аерыла. Борынгы Түрек Каганлыгына карата фәндә «күк түрекләр» төшенчәсе кулланыла. «Күк» — бөек, олуг мәгънәсен бирә. 630 елдан соң бу ике дәүләтнең Көнчыгыш Каганлыгы көчлерәк, тормышка сәләтлерәк булып чыга. Көнбатышы, зәгыйфь булганлыктан, тиздән Кытай тарафыннан буйсындырыла. Монда «Көнчыгыш», «Көнбатыш» атамалары шартлы рәвештә генә кулланыла, чынлыкта, «Көнчыгыш» дигәндә төньяктагысы, «Көнбатыш» дигәндә көньяктагысы (Тибет тирәсе) күздә тотыла. Аларны зәгыйфьләндерү һәм буйсындыру өчен Кытай ягы төрле дипломатик чараларны, сатып алу, дәрәҗә бирү, бүләк (ефәк, хәмер, кытай кызлары!) җибәрүне киң куллана. Шуңа да карамастан, «күк төрекләр» мирасының варисчысы Көнчыгыш Түрек Каганлыгы 716—734 елларда икенче сулышын ача — кабат көчәя, бу хәл аның бәйсезлекне кайтару өчен Кытай хөкүмәте белән актив көрәш алып баруы аркасында тормышка аша. Борынгы Урхан түрекләренең социаль үсешен, югары мәдәни казанышларын ачык күрсәтә торган вакыт — шушы дәвер. Руник язма истәлекләрнең иң әһәмиятлеләре дә шушы чорда барлыкка китерелә. Мисалга, мәшһүр Күлтәгин, Танйокук язмаларын атарга мөмкин. Алар 720—730 еллар арасында вафат булган дәүләт эшлеклеләре каберенә куелган һәйкәл үрнәкләре.



*Күлтәгин истәлегенә куелган һәйкәл — ташъязма VIII йөз.*

Бу заманда дәүләт тормышына, иҗтимагый хәяткә зур тәэсир ясаган шәхесләрнең берсе — Билгә каган һәм аның энесе, күренекле яугир Күлтәгин. Ләкин Билгә үлгәч, 734 елда Түрек Каганлыгы вак бәклекләргә таркала. Җыеп әйткәндә, Билгә каган, Күлтәгин чорлары Түрек Каганлыгының сүнәр алдыннан гөлт итеп балкып алган утны хәтерләтә.

Шуннан соң Үзәк Азиядә түрекләрнең яңа дәүләте — Уйгыр каганлыгы (745—840) барлыкка килә.

*— Миркасыйм әфәнде, киң катлам укучылар ерак ата-бабаларыбызның ул заманда корган дәүләтләре турында белми диярлек. Шунлыктан, түрек җәмгы-*

*ятьләренең социаль хәле, иҗтимагый төзелеше турында мәгълүмат бирү дә акланыр иде.*

— Түрек Каганлыгы оешкан һәм яшәгән дәвердә барлык түрек кабиләләре дә шактый зур казанышларга ирешкән була — алар феодальләшү заманын кичерә. Күчмәннәр дөньясында феодальләшү процессы бик иртә башлана, ләкин ул бик акрын бара. Җәмгыятьтә кешеләрнең милек буенча төрле катламнарга аерылуы күзәтелә. Ике төркем — аксөякләр һәм карасөякләр формалаша. Аларның беренчесен бәкләр, ыру-кабилә башлыклары тәшкил итә. Икенче төркем башкача «будун», «кара будун» дип тә атала.

Берничә кабиләдән оешкан берләшмәнең башында хан тора, ул сайланып куела. Шундый дәүләтчекләрдән оешкан берәмлек башында баш хан, ягъни каган тора (Бездә соңгы вакытта кахан, хакан, һакан һ. б. язылышлар да кулланыла, тик алар дөрес вариант түгел). Борынгы руник истәлектә каган сүзе каты «к», «г» хәрефләре белән билгеләнә. Каган — Ашина ыруы вәкиле, аның якын кан кардәшләренә, Европадагыча, принцларга карата, «тәгин», «шад» титуллары бирелгән. Хөкүмәт башында торучы баш түрәләргә «ябгу» атамасы кулланылган, бу дәрәҗә инде вәзиргә туры килә яза. Бу бүлгәләнү түрек җәмгыятенең шактый нык үскән булуын исбатлый.

Борынгы түрекләрдә хәрби көч, гаскәр системасы шактый алга киткән була. Сугышчы — сү, офицер — сүбашы була. Дивизия, армияне атар өчен «кул» сүзе кулланыла. Зур гаскәр башлыгы — «кулбашы». Борынгы түрек гаскәре — атлы гаскәр. Нәкъ менә шушы борынгы түрек дәүләтләре заманында (VI—VII йөзләр) каты нигезле ияр, өзәңге иҗат ителә. Ат өстендә нык утырган, өзәңгегә тибенеп барган сугышчы кәкре кылыч та кулланган. Андый кылыч сукмый, кисә. Туры кылыч (меч) сугып миңгерәтә. Җәяүледән биектә торган түрек сугышчысы яхшырак коралланган да була — ул җиңел җәя, калкан йөртә, тимер алкалардан үрелгән киемнәр (тимер күлмәк — сауыт) кия. Тимер бишмәт — күбә дә кияләр. Сугыш коралларының үсеш дәрәҗәсе шул җәмгыятьнең социаль-иҗтимагый алга китеш югарылыгын да чагылдыра. Басым ясап күрсәтергә кирәк: борынгы Түрек Каганлыгы заманында уйлап чыгарылган каты ияр, өзәңге, кәкре кылыч безнең көннәргә кадәр кулланылды, бу инде түрекләрнең кешелек тарихына нинди өлеш кертүе хакында үзе үк бик ачык сөйли.

*— Әмма борынгы түрекләрнең казанышлары сугыш чаралары белән генә чикләнми ич әле?*

— Әйе, аларның социаль-иҗтимагый үсешен күрсәтә торган бүтән нәрсәләр дә җитәрлек. Әйтик, дин. Гадәттә, түрекләрне мәҗүси булган, диләр, ләкин дөресе — алар тәңречелек ышанычын тотканнар. Тәңре — күктәге Илаһ. Кайберәүләр уйлавынча, Тәңре атамасы «тян ире», ягъни «күк ире» дигәнне аңлата. Эченә артык кереп тормасак, Тәңре — төп Ходай. Кайбер галимнәр, мисалга, күренекле алман тюркологы Дёрфер тәңречелекне «монотеистик (бер илаһлы) дин» дип аңлата. Түрекләрдә тагын «умай» — җир анасы һ. б. илаһлар була, тик алар тәңредән түбәнрәк санала. Менә шунлыктан, мин борынгы түрекләрне мәҗүсилекнең иң югары дәрәҗәсенә җитеп, бер илаһлы дин тудыруга якын килгәннәр, дип саныйм. Аларның мондый дини карашлары, дөньяны танып-белүләре Азиядәге борынгы цивилизацияләр (Кытай, Тибет) белән аралашулары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Димәк, борынгы түрекләргә кыргыйларга караган кебек карау хакыйкатьтән бик ерак тору дигән сүз.

Рухи мәдәниятнең дөньяви тармагында да борынгы түрекләрнең казанышлары аз булмаган. Мисалга, алар VI йөздә согд язуы нигезендә махсус алфавит барлыкка китергән, төрки телгә бик әйбәт яраклаштырылган 38 хәрефле язу бу. Ул түрек теленә шулкадәр нык яраклашкан ки, къ-к, гъ-г авазларына бәйле сингармонизмны гына түгел, т-ть, л-ль әйтелешләрен дә камил бирә алган.

Язма истәлекләр күрсәткәнчә, борынгы түрек телендә төрле стильләр дә аерылып камилләшкән — каберташ, сәяси декларация, тарихи публицистика стильләре барлыкка килгән. Шигъри юллар, ритмик проза үрнәкләре, лирик чигенеш кебек алымнар да шактый еш кулланыла. Мисалга берничә үрнәк китерик: «Тәңре тәг тәңредә булмыш түрк билгә къагъан бу үдкә ултыртым. Сабымын түкәтә әсидгел: улайу энийегүнем, угланым, бирекә угышым, будуным»...

Тәрҗемәсе: «Күк кебек күктә яралган, белекле түрек каганы бу урынга утырдым. Сүземне тәгәл ишетегез! Миңа ияргән энеләрем, угылым, туганнарым, илем-халкым!..»

(Күлтәгин хатирәсенә Билгә каган язмасының башы).


Бу язмаларда дәүләтне, бәйсезлекне югалтуга китерә торган афәтләр дә санала һәм шуларга юл ачкан өчен халыкка шелтәләр дә белдерелә. Борынгы язманың шул өлешен тәрҗемәдә генә китерик:

«Түрек халкы! Син ач калсаң да, тук булсаң да (алдагы хәлне) уйламыйсың. Бер туйдың исә, иртәгә нәрсә ашарыңны кайгыртмыйсың. Син шулай үз каганыңны тыңламавың аркасында төрле якка таралып киттең, көчсезләндең, хәлсезләндең; төрле җиргә сибелеп ач-ялангач каңгырып йөрдең. Тәңренең ярлыкавы буенча, үземнең котлы булуым хакына мин каган булдым. Каган булгач, сине — ярлы халыкны бай иттем, сине — аз халыкны күп иттем! Әллә бу сүзләремдә минем ялган бармы? Түрек бәкләре, түрек халкы, тыңлагыз моны!..»

Ул заманда тудырылган әсәрләрнең тел-стиль үзенчәлекләрен күрер өчен, тагын бер өзек китерик:

«Әгәр Күлтәгин булмаса, барыгыз да кырылып бетәр идегез. Энем Күлтәгин вафат булды — мин сыкрадым; күрер күзем күрмәстәй, белер акылым белмәстәй булып сыкрадым мин! Вакытны тәңре бирә, адәм балалары үләр өчен туалар. Шул хәтле сыкрадым мин — күзләремнән яшь акты, күкрәгемнән аһзарлар чыкты — тагын да сыкрадым мин!..»

Борынгы түрекләрдә хәрби эш, язу, әдәби тел мәдәниятеннән тыш казанышлар да булган. Шуларның янә берсе — унике еллык (җәнлек) календарь. Шул календарьның ничек иҗат ителүе хакында Мәхмүт Кашгарида бик кызыклы бер риваять теркәлеп калган. Имеш, борынгы түрекләрдә ел, календарь исәбе булмаган. Бер вакыйганың вакытын билгеләгән чакта төрле-төрле бәхәсләр туган. Берәү — утыз, икенче — кырык ел элек булганлыгын куәтләгән. Шул чак каган мондый чара тәкъдим иткән: кырга күп гаскәр белән чыгып, җанварларны Élә дәрьясына таба куарга кушкан. Әмерне үтәгәннәр — ябырылып килгән гаскәрдән качкан җанварлар Élә суын йөзеп чыккан. Унике җанвар! Беренчесе тычкан булган. Елганы кичеп чыгу тәртибендә шул унике җанвар унике елга беркетелгән, унике ел исә бер мөшәлне тәшкил иткән, аннары яңа мөшәл башланган. Менә шушы календарь бездә унтугызынчы йөзгә кадәр кулланылган.



*Агач ышыгында ял итү. Алтын тәңкәдәге сурәт.*

Дөрес, әлеге календарь нигезендә, Кашгари риваятеннән башка, Ерак Көнчыгышта түрекләргә кадәр берничә мең ел элек иҗат ителгән биш мөшәлле

(алтмыш еллы) календарь системасы гонсерләре ята. Бу хәл үзе генә дә борынгы төрекләр культурасы нигезендә бик борынгы цивилизация бөртекләре ятуын раслый.

*— Миркасыйм әфәнде, хәзер инде борынгы түрекләрнең, аларның дәүләтләренең мирасчылары кемнәр икәнлеген дә атарга вакыттыр?*

— Борынгы түрекләр яшәгән дәвердән соң мең елдан артык вакыт узган. Шул заманнан соң безнең көннәргә килеп җиткәнче түрек кабиләләре һәм халыклары үзара һәм ят кабиләләр белән әллә ничә мәртәбә аралашып, буталып беткән. Этник җәһәттән гасырлар буе үзгәрмичә килгән бер генә түрек кабиләсе дә калмаган, ләкин аларның һәркайсында шул борынгы Түрек Каганлыклары халкының каны ага. Шунлыктан, хәзерге төрки халыкларның барысын да борынгы түрек халкының варисы итеп санарга кирәк. Кайбер галимнәр тырышканча, бары географик яки раса сыйфатыннан чыгып кына карарга ярамый. Мәгълүм галимнәр: «Борынгы түрек кабиләләре үлеп беткән», ди. Бу да дөрес түгел. «Халык үлеп бетте», дигән фикер бер югары катламга карата гына дөрес булырга мөмкин.

*— Тарихи аң зәгыйфьләнгәнлектән, бездә шундый галимнәргә ышанучылар да табылып тора.*

— Минемчә, безнең җәмәгатьчелек татар тарихын гына түгел, түрекләрнең борынгы тарихын да, борынгы Түрек Каганлыгы язмышын да яхшы өйрәнергә тиеш.

*— Әмма бу борынгы Түрек Каганлыгының Русиягә нинди кагылышы бар? Аның юбилеен үткәрү уе аңа нәрсә бирә дә безгә нәрсә бирә?*

— Әгәр Түрек Каганлыгы оешуның 1450 еллыгын кешелек тарихында мөһим эз калдырган вакыйга сыйфатында билгеләп үтәбез икән, бу — дөрес һәм яхшы гамәл, чөнки әлеге дәүләтнең барлыкка килүе чыннан да әһәмиятле тарихи күренеш. Кәкре кылыч, каты ияр һәм өзәңге уйлап табу мисаллары үзләре генә дә ни тора! Түрек Каганлыгының күп кенә халыклар язмышына мәдәни тәэсире дә шулай ук бәхәссез. Әмма борынгы Түрек Каганлыгының барлыкка килүе фактын хәзерге яңа заман дәүләте койрыгына тага башласак, көлке хәлдә калуыбыз ихтимал. Моңа исә аерым игътибар итмичә булмый, чөнки әлеге фактны кайбер сәясәтчеләр күтәреп чыгып, шау-шу ясап йөри башлады. Имеш, «Русия территориясендә беренче түрек дәүләте!» Югыйсә борынгы Түрек Каганлыгының төп мәйданы, метрополиясе хәзерге Монголия һәм Кытай җирләрендә булган. Евразиянең башка җирләрендәге кайчандыр түрекләргә буйсынган җирләрнең дә борынгы Русь, Мәскәү Русе җирләренә бернинди мөнәсәбәте юк. Аннары хәзергечә «үз итү» алымы хронологик яктан да акланып җитми. Чөнки Түрек Каганлыгы оешкан, яшәгән һәм таркалган заманда урыс дәүләтенең проекты анасының карынында гына түгел, атасының биленда дә булмый әле. Әгәр евразиячеләр тарихта Русия империясенең элгәресен эзләсәләр, Алтын Урдага мөрәҗәгать итсеннәр, шуның тарихын әйбәтләп өйрәнсеннәр.

*— Русь империясенең элгәресе итеп Киев Русе карала шикелле? Бөтен дәреслекләр шундый фикер белән тулган ич!*

— Алай караучылар бар, ләкин ул караш Русия дәүләте тарихын озынайтып, Русия империясен мәңгелек итеп күрсәтергә теләүчеләрнең омтылышы. Югыйсә Киев Русе ул — бер дәүләт, Мәскәү Русе исә бөтенләй икенче нигездә оешкан башка дәүләт. Бу хакта Н. М. Карамзин да әйтеп калдырган. Киев Русе бердәм дәүләт буларак 1135 елда яшәүдән туктый. Мәскәү Русе исә XIV йөзнең икенче яртысы — XV йөздә генә формалаша. Арада ике йөз елдан артык бушлык бар, аны җиңел генә атлап үтеп булмый. Шушы ике гасырлык бушлык заманындагы Мәскәү кенәзлеге, ягъни урыс патшалыгы Алтын Урда белән тыгыз элемтәдә яши. Дөрес, Мәскәү патшалыгы оешуда Киев Русеннән калган кайбер рухи һәм сәяси элементларны инкяр итеп булмый. Әмма Мәскәү Русе оешкан вакытта борынгы Киев, Византия традицияләреннән тыш, Сарай ханнарыннан кабул ителгән тәртипләрнең дә күп кулланылуы бәхәссез. Моны исбат итә торган дәлилләрнең берсе — Мәскәү бөек кенәзенең патша титулын алуы. Дүртенче Иван тарафыннан патша титулы Сарайда Алтын Урда ханнары юкка чыккач

кына кабул ителә һәм бары шуннан соң гына Мәскәү кенәзлегенең элекке Алтын Урда җирләренә дәгъвасы башлана. Кызганыч ки, шушы фактлар тарихи әдәбиятта әлегәчә юньләп яктыртылмаган.

*— Соңгы вакытта татар халкы, Татарстан тарихы буенча мәктәп дәреслекләре языла һәм чыгарыла башлады. Аларның кайберләре инде кискен тәнкыйтькә дә очрады. XX йөз башында татар милли аңы кабат кабынуда милли тарихыбызны, телебезне һәм әдәбиятыбызны яктырту җанлана, үзен аз-маз укымышлы санаган күпләр дәреслек язарга керешә. Гасыр азагында яңа уяныш күзәтелә. Хәзер инде татар гаммәсенең укымышлылык дәрәҗәсе гасыр башындагыдан чагыштыргысыз дәрәҗәдә югарырак, әмма яңа каләм ияләребез элекке кимчелекләрдән арына алмый. Сез, Миркасыйм әфәнде, моны ничек аңлатыр идегез?*

— Дәреслекләрнең чыгуы, һичшиксез, уңай күренеш, ләкин аларның сыйфатларын, чыннан да, канәгатьләнерлек дип әйтеп булмый шул. Хикмәт шунда, финанс, икътисад өлкәләрендәге девальвация, ягъни кыйммәт төшү күренеше фикер дөньясына да үтеп керде. Урам чатларындагы сатучылар бер үк әйбергә төрле бәя куйган кебек, бер үк фактка төрле бәя бирүчеләр күбәйде. Моны аклап булмаса да, аңлап була сыман. Демократик фикер йөртүгә өйрәнү бик авыр бара, чөнки демократияне башбаштаклык дип аңлатучылар да җитәрлек. Аннары элекке фикерләрне киресенчә әйтүне тулы дәреслек дип уйлаучылар да бар. Кайвакыт шундый ялгыш фикерләрне тәнкыйть итсәң, ирекне буу, искелекне яклау, дип уйлаучылар үпкәли башлый. Кыскасы, социаль төзелешебез, җәмгыятебез үзе чирле булган кебек, безнең бүгенге тарихи фикерләребез дә сәламәт түгел. Сәламәтләнер өчен дару белән бергә вакыт та кирәк.

*— Бу өлкәдә сыйфат сикереше кайчан һәм ничегрәк булыр? Аны кемнәр тормышка ашырыр?*

— Иң төп бурыч итеп мин яңа белгечләр әзерләүне беренче урынга куяр идем. Иҗтимагый-социаль тормышта гына түгел, рухи дөньябызда да буыннар алмашынуы зарур. Сүзнең чын мәгънәсендәге яңа тарихи хезмәтләрне яңача тәрбияләнгән яңа кешеләр бирергә тиеш. Һәм белемле, һәм ирекле фикер йөртә торган галимнәр тәрбияләргә кирәк. Авыр булса да, зарур мәсьәлә бу. Димәк, мин олы буынга, яшьтәшләремә шактый тәнкыйть күзе белән карыйм. Бездә кайчак «яңа хезмәт» дип яңадан күчереп кенә язылган иске хезмәтләрне тәкъдим итүләр дә аз түгел. Аңлашыла ки, безгә яңа әйбер дип тузга язмаган уйдырмалар тәкъдим итүдән саклану кирәк булган кебек, бары яңа битлек кидерелгән иске карашлардан да арынырга хаҗәт. Бу эш исә тәнкыйди бәя бирүне, тырышлыкны һәм, кабатлап әйтәм, мәгълүм вакыт узуын таләп итә.



*Таш балбал — төрекләрнең ата-бабаларына куйган һәйкәле.*

*— Яшь галимнәрне тәрбияләүдә иң әһәмиятле таләп кайсы? Игътибарны аеруча нәрсәгә юнәлтергә кирәк?*

— Галим хезмәтенең югары сыйфатлы һәм нык нигезле булуы кадерле. Яшереп торасы юк, кайвакыт чиле-пешле әйберен күтәреп килүчеләр дә очрый. Шулчак аларга хезмәтенең сыйфаты түбәнлеген күрсәтсәң, моны «яшьләргә юл бирми», дип аңлаучылар һәм аңлатучылар табыла. Гыйльми фикеребезгә җиңел юл эзләүчеләр зарар китерә, андыйларга таләпчәнлек күрсәтү бары файдага гына булыр. Шулай да мин

киләчәктә үз иҗатларына таләпчән карый торган галимнәр дә үсеп җитәр, дип өметләнәм. Менә шул чакта фикергә һәм дәлилләргә бай, тарихи үткәнебезгә тирән күз ташлаган, ата-бабаларыбыз тормышын дөрес күзаллаган һәм сурәтләгән дәреслекләр дә барлыкка килер.

*— Илдә шау-шу кузгаткан 1450 еллык юбилей мәҗлесләре татар гаммәсенең ерак үткәннән хәбәрсезрәк яшәвен, Мәскәү сәясәтчеләренең империячел дәгъваларын ныгытуда теләсә нәрсәгә таянырга әзер икәнлекләрен тагын бер мәртәбә ачык күрсәтте. Чын бәйрәм уздыру өчен әүвәл Төрек Каганлыгына багышланган фәнни хезмәтләрне, күпчелеккә атап язылган җиңел аңлаешлы китапларны барлык төрек телләрендә, шул исәптән, татарча да бастырып чыгарырга кирәк иде. Безнең матбугат, радио-телевидение шул дәвердә яшәгән ата-бабаларыбызның торле тармаклардагы казанышларын сәнгатьчә осталык белән таныштырырга бурычлы. Әмма хәзергә боларның тиешенчә эшләнгәне юк. Бу җәһәттән, ихтимал, безнең «Казан утлары»нда да материаллар кирәк дәрәҗәдә чагылмыйдыр... Миркасыйм әфәнде, шушы уңайдан сез тарихи теманы яктыртуда вакытлы матбугатканиләр теләр идегез? Аеруча безгә?*

— Минемчә, гәзит-журналларның төп бурычы тарихта казынып яту гына түгел, бүгенге иҗтимагый мәсьәләләрне хәл итүдә актив катнашу. Аңлашыла ки, мин тарихи темадан бөтенләй ваз кичәргә кирәк, димим. Тарихи әсәрләрне, һичшиксез, бастырырга кирәк. Ләкин шаккатризм рухындагы уйдырмаларны түгел, хакыйкатькә тап төшерми торган югары сыйфатлы язмаларны. Соңгы елларда тарихи вакыйгалар, исемнәр белән уйнау да шактый таралды. Бу сүзем бигрәк тә «тарихи» романнарга кагыла. Аларның күпчелеген укырлык түгел, әсәрнең бармактан суырып язылуы күренеп тора, аларның тел-стиль ягы да күңелне рәнҗетә. Бәлки бу аларның ашыгыбрак иҗат ителүенә бәйләнгәндер.

«Казан утлары»на килсәк, безнең иң җитди, абруйлы калын журналыбыз буларак, анда киләчәктә тарихны өйрәнергә булыша алырлык чыганаклар, истәлекләр күбрәк басылсын иде. Чөнки әби патшаны минем мактап яки сүгеп язган хезмәтем тиз арада искерәчәк, ә тарихи чыганак, документаль чыганак кыйммәте беркайчан да югалмаячак. «Казан утлары» тәкъдим итә торган әсәрләргә мин әнә шундый озын гомерлелек теләр идем.



**Шәриф Хөсәенов**

# ГАЗАП ДИҢГЕЗЕН ЭЧЕП...

Рөстәм абый Яхин белән мине Академия театры сәхнәсендә барган «Профессор кияве» спектакленең 100 нче куелышында таныштырдылар. Бу — 1954 елның мартында булды. Ләкин мин композиторны читтән күреп күптән белә идем. Хәзер төгәл әйтеп бирә алмам, медицина институтында укып йөргән чак — миңа Татарстан композиторларының Офицерлар йортындагы колонналы залда уздырылган пленум концертында булырга туры килде. Шунда радиодан еш кына тапшырылып торган «Кем белер кадереңне?», «Кил, чибәрем» кебек күңелгә тирән кереп урнашкан романслар авторы Рөстәм Яхин үзенең оркестр белән фортепиано өчен язган концертын уйнады. (Җәя эчендә генә булса да әйтеп үтим: шылдыр-былдыр такмаклар чыгаручы «композиторлар» басып киткән бүгенге көн белән чагыштырганда, әйтеп бетергесез уңдырышлы булган икән ул ел композиторларыбыз өчен.) Шул ук концертта атаклы скрипач, инде мәрхүм Юлиан Ситковецкий Альберт Леманның татар темаларына язган концертын уйнады. Опера һәм балет театрына яңа гына кабул ителгән солист Аркадий Талмазов Нәҗип Җиһановның яңа язган җырларын җырлап күрсәтте. Шәехзадә Бабичка ошатып Әхмәт Ерикәй язган сүзләргә «Җырламыйм мин җырларымны» дигәне күңелгә бигрәк тә хуш килгән иде.)

Музыка яза алган кешеләр миңа элек-электән әллә нинди бер тылсым ияләре кебегрәк тоелалар, шуңа минем белән теп-тере композитор үзе килеп танышкач туган дулкынлануымны сөйләп торуның кирәге юк.

Ул елларда мин опера сәнгатенә мөкиббән киткән, һәрбер спектакльне әллә ничәшәр кат тыңлау белән бергә, читтән килгән гастролерларның да берсен калдырмыйча тыңлап баручы меломанга әйләнеп беткән идем инде. Еш кына театрда Рөстәм абый очрый торган иде. Шундый очрашуларның берсендә ул миңа үзенең опера язарга хыялланып йөрүен әйтте. «Син операда еш буласың, либретто язарга теләгең юкмы соң?» — дип кызыксынды. Мондый теләк миндә туып килә иде инде, Рөстәм абый шундый тәкъдим ясагач, җитдирәк итеп уйлый башладым. Күп кенә классик операларны кат-кат тыңлап, аларның эчтәлекләрен яхшы белгәнгә, опера өчен нindирәк сюжет кирәклеген чамалый идем. Ләкин — инде Сталин үлгән, Хрущевның «җепшеклек» еллары башланган булса да — цензура бик көчле иде әле ул чакта. Шуларны уйлап булса кирәк, татар халкының фаҗигале язмышы опера өчен бик ятышлы икәнлегенә карамастан, Рөстәм абый бу темага кагылмаска кушты. Миннән олырак һәм тәҗрибәлерәк кеше буларак, социалистик реализм дигән нәрсәнең иҗат кешеләре алдында нинди киртәләр корганлыгын ул яхшырак аңлаган, күрәсең. Көрәшеп иҗат итү аңа хас түгел иде, минемчә, шуңа ул үзенең җырлары өчен текстларны да шактый талымсыз сайлый торган иде. (Мәсәлән, берәр урында утырган йә булмаса худсоветта әгъза булып торган авторларны.)

Тема таба алмыйча шактый озак маташырга туры килде. Композиторның әнисе Мәрьям апа әллә кайдан табып биргән «Дим буенда» дигән повестьны укып чыктым, ләкин бу сюжет миңа ошамады. Оригинальлек юк иде анда, ул дөнья опера репертуарында инде күптән билгеле булган Виолетта белән Мими язмышының тагын бер варианты гына. Революциягә хәтле чыгып килгән «Аң» журналының тулы тегелмәсен табып, шуны карап чыктым, ләкин анда да безне дулкынландырырлык сюжет табылмады. Шуннан, әле яңа гына акланган Кәрим ага Тинчуринның «Беренче чәчәкләр» дигән пьесасына тукталдык. Дөрес, «Умырзая» дип аталган минем либреттоның, яза торгач, Кәрим ага пьесасы белән уртаклыгы бик аз калды, ләкин либретто өстендә эшләү өчен беренче этәргеч шул пьеса булды.

Шушы либретто өстендә эшләгәндә миңа Рөстәм абыйларның Париж Коммунасы урамындагы бәләкәй генә фатирларында да булгаларга туры килде. Шунда аның әнисе Мәрьям апа белән таныштым, ул пешергән тәмле-тәмле ризыклардан авыз иттем. Арада мин гомердә дә ашамаган, хәтта исемнәрен дә ишетмәгән ризыклар да була торган иде. Мәсәлән, «баганалы» дигән ризык. Рөстәм абыйларның революциягә хәтле зур завод тоткан атаклы байлар нәселеннән икәнлеген ул чакта мин белми идем, ул елларда Рөстәм абый бу хакта сөйләми торган иде. Алгарак китеп булса да әйтим: Рөстәм абыйның әнисе Мәрьям апа шактый алдынгы карашлы, заманы өчен укымышлы хатын булу белән бергә, искиткеч чиста һәм пөхтә, аш-суга бик оста хатын иде, аныкы кебек тәмле гөбәдияләрне, катлы паштетларны минем башка бер җирдә дә ашаганым булмады.

Тәмле ризыклар дигәч тә, Рөстәм Яхиннар барган саен мине гөбәдияләр, катлы паштетлар белән сыйлаганнар икән дигән фикер калмасын тагын. Юк, андый затлы ризыклар бәйрәм көннәрдә барып чыкканда гына була иде. Күмәч кисәге белән чәй эчеп һәм чәйсез генә сөйләшеп утырулар да күп булды. Рөстәм абыйлар, гомумән, шактый кысынкы яшәделәр. Ул гомер буе акчага туймады, гомер буе башы бурычтан чыкмады.

Мин либретто өстендә эшләгәндә эшемне хуплап, мактап кына торган Рөстәм абый, либретто язылып беткәч, кызганычка каршы, кинәт кенә суынды да куйды. Андый зур әйбер өстендә эшләргә алыну өчен кыюлыгым да җитми, сәламәтлегем начар, минем башым шул вак-төяк нәрсәләр язарга гына ярый, дип, опера язудан баш тартты. Бүгенге күзлектән караганда әллә ни булмаса да, заманы өчен ярыйсы гына либретто килеп чыккан кебек иде, югыйсә.



*Күренекле композитор Рөстәм Яхин.*

Ел буе түккән хезмәтем бушка киткәч, мин бик рәнҗегән идем Рөстәм абыйга. Без шактый вакыт аралашмый яшәдек, опера спектакльләрендә, концерт залларында очрашкач та коры гына исәнләшеп китү белән чикләнә идек.

Менә шулай — Рөстәм Яхиннан музыкаль җәмәгатьчелек көткән, Рөстәм абый үзе дә хыялланган, мин дә хыялланган опера язылмыйча калды. Кем һәм нәрсә гаепле булды моңа? Композиторның күңеле күтәренке чагыннан төшенке чагы күбрәк булумы? Әллә минме? Бәлки, композиторларга илһам канатлары үстереп җибәрерлек либретто яза алмаганмындыр? Гомерем буе шушы сорауга җавап эзлим.

Язмыштан узмыш юк, дигәннәр. Ахрысы чыннан да шулайдыр, озакламый язмыш безнең тормыш юлларыбызны яңадан китереп кушты. Илленче елларның икенче яртысында Рөстәм абыйларга Восстание урамыннан ике бүлмәле фатир бирделәр. Күп тә үтми, Язучылар союзы миңа да бер бүлмә бирде, ул бүлмә Кызыл Байрак урамының Восстание урамы белән кисешкән почмагында булып чыкты. Безнең кухня тәрәзәсеннән Рөстәм абыйларның аптека өстендәге квартиралары күренеп тора, эшкә барганда, эштән кайтканда мин еш кына балконда утырып торган Рөстәм абыйны күрәм, аңа кул болгап узам. Күршеләр булгач, яңадан аралаша башладык. Мәрьям апаның кан басымын үлчәргә бик еш чакыра торганнар иде. Ул елларда Мәрьям апа район поликлиникасына мөрәҗәгать итмәде дә бугай. Мин күрсәткән ярдәмнән канәгать булып яши иде. Ярдәм дип, авыз тутырып сөйләрлек авыруы да булмады Мәрьям апаның ул елларда, бөтен зарлары картлык белән, склероз белән бәйле зарлар була торган иде. Еш кына кан басымы күтәрелеп куя, врачлар гипертоник криз дип атап йөрткән халәт килеп чыга, укол ясарга кирәк була торган иде. Хикмәт: мин кергәндә урын өстендә яткан Мәрьям апа кан басымын үлчәп, бер-ике миллилитр дибазол кадагач, сикереп тора да кухняга чыгып чәй әзерли башлый иде. Чәй өлгергәнче без Рөстәм абый белән тегене-моны сөйләшеп утырабыз. Билгеле инде, сүз күбрәк музыка турында була, Рөстәм абый үзенең яңа гына язган җыр һәм романсларын уйнап-җырлап күрсәтә, фикерем белән кызыксына. Шушы фатирда яшәгәндә ул Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре»ннән алынган шигырьләргә бөтен бер цикл язды, бу җырларны иң беренче тыңлаучылардан берсе мин идем шикелле.

Музыкага мәхәббәт миндә кечкенәдән булса да, музыкаль зәвыгымның формалашуына Рөстәм абыйның да йогынтысы тими калмагандыр дип уйлыйм. Мәрьям апа чәй кайнатып йөргән арада, кайчакта чәй эчеп алгач та, Рөстәм абый дөнья классиклары Шопен, Падеревский, Лист, Рахманинов, Чайковскийларның фортепиано өчен язган әсәрләрен уйнап ала торган иде. Мәсәлән, Шопенның до-диез минор Экспромт фантазиясен мин беренче мәртәбә Рөстәм Яхин башкаруында ишетеп хәйран калган идем. Соңга таба мин бу үлемсез әсәрне исемнәре бөтен дөньяга билгеле Артур Рубинштейн, Дину Липатти, Белла Давидович һәм башка пианистлар башкаруында да тыңладым, лакин Рөстәм абый уйнаганнан калган беренче әсәрләнү әле бүген дә истә.

Өзеп әйтә алмыйм, бәлки, Рөстәм абыйның минем алда инструменталь әсәрләр уйнавы очраклы хәл булмагандыр, бәлки шулай итеп миндә музыкаль зәвык тәрбияләргә теләгәндер. Һәрхәлдә, ул опера сәнгате белән чамадан тыш мавыгуыма ирония беләнрәк карый, инструменталь һәм симфоник музыка белән дә кызыксыну кирәклеген әйтә торган иде. Шунысы да истә: бер көнне ул минем Пуччининың «Богема» дигән операсын тыңлап утырган чагыма туры килде. Мария Каллас һәм Джузеппе ди Стефаноның башкару осталыкларыннан һуштан язарлык хәлгә җиткән икәнлегемне күрде дә:

— Каллас бөек җырчы, билгеле, лакин иртәгә университетның Актлар залында Святослав Рихтер концерт бирә, син шунда эләгергә тырыш, — диде.

Ничек эләккәнемне сөйләп тормыйм, шулай да эләктем мин Рихтерның ул концертына. Зал котырынып кул чапты, тик минем бер тамырым да кыймылдамады, хәтта нәрсәләр башкарганы да исемдә калмаган. Ни өчен шулай булды икән? Минем музыкаль культурам түбәнлектәнме? Оста уенчыны коридордан гына, ишек төбенә басып кына тыңлагангамы? Ә бәлки, бу кичтә даны бөтен дөньяга таралган артистны Алла, илаһи дигән сүзләрдән ясалган илһам дигән нәрсә ташлап китеп торган булгандыр?

Хәтеремдә, Рөстәм абыйның рояле өстендә шактый озак вакытлар Чайковскийның балалар өчен язган «Ел вакытлары» дигән альбомы торды. Ара-тирә ул шул альбомны ачып, әле бер, әле икенче пьесаны уйнап җибәрә дә, безнең татар музыкасының ярлылыгына, балаларга атап язылган шундый әсәрләр булмауга ачынып куя иде. «Соң, яз, нигә язмыйсың?» — дия торган идем мин андый вакытларда. Рөстәм абый Чайковскийның пьесасын уйнап бетерә дә:

— Чайковскийны уздырып җибәреп булмас шул,— дип җавап бирә иде.
— Соң, узмаса узмас, килеп чыккан хәтлесе булыр.
Тәгаен белмим, әмма аның балалар өчен язылган «Нәни Чапай» дигән пьесасы шушы уй белән яшәгән вакытка туры килми микән?
Мондый сөйләшү минем күңелгә дә кереп калды булса кирәк. Күпмедер вакыт узгач, елның дүрт вакытын сурәтләгән кечкенә-кечкенә дүрт шигырь яздым, аларны Рөстәм абыйга күрсәттем. Ул шушы сүзләргә балалар өчен «Табигать күренешләре» дигән дүрт җырдан торган цикл язды.
Сирәк-мирәк шигырьләр язгалап куйсам да, мин үземне шагыйрь дип санамыйм. Ләкин Рөстәм абыйның яңадан-яңа җырларын ишетәсем бик килә иде. Шуңа, ахры, үз шигырьләрем булмагач, миндә бер шөгыль туды: газета-журналларда, җыентыкларда басылып чыккан шигырьләрне укыйм да, музыка өчен ятышлы шикелле тоелганнарын күтәреп Рөстәм абый янына керәм. Аның Хисам Камалов сүзләренә язган «Умырзая», Зөфәр Шәйхетдинов сүзләренә язган «Аяз төндә айга карыйм да мин» дигән романслары шулай туды. Кызганыч, мин күтәреп кергән шигырьләрнең күбесе композиторда илһам уты кабындырып җибәрми иде. Хәтеремдә, бер көнне мин аңа Клара Булатованың «Ә йөрәк соң, йөрәк нишләсен?» дигән шигырен алып кердем. Минем карашымча, бу шигырь «романс буласым килә!» дип үзе кычкырып тора. Ләкин Рөстәм абый шигырьне укып чыкты да, читкә куйды. «Бу шигырьдә поэзия да бар, фикер дә бар, ләкин ул фикер чәйни-чәйни кабатлап әйтеп бетерелгән инде, музыкага эш калмаган. Миңа музыка язу өчен әлләни зур фикере булган шигырь кирәкми. Әнә Чайковский да үзенең романсларын җыен чүп-чар текстка язган»,— диде.
Ул чакта мин композиторның бу сүзләренә җавап бирә алмадым. Бүген — бәхәсләшер идем. Чөнки, беренчедән, Чайковский язган романсларның сүзләрен чүп-чар дип атарга тел әйләнми, аларның һәммәсендә бәләкәй генә булса да шигъри фикер һәм хис бар. Икенчедән, Рөстәм Яхинның музыкабызның алтын фондына кергән җыр һәм романслары чүп-чар текстларга түгел, Габдулла Тукай белән Муса Җәлилнең тирән фикерле классик шигырьләренә язылган лабаса!
1966 елда мин яңа фатирга күчеп киттем. Фатирым шул Восстание урамында ук булса да, Рөстәм абыйларның күршесендә генә түгел иде инде. Йокы алдыннан һава суларга чыккан Рөстәм абыйның тәрәзәдә ут күреп миңа сугылулары бетте. Озакламый алар да өч бүлмәле яңа фатирга, Казанның үзе хыялланган почмагына, Лесгафт урамына күчеп киттеләр. Без сирәк очраша башладык, вак-төяк йомыш белән бер-беребезгә кереп йөрүләр сирәгәйде. Дөрес, «Әнигә синнән башка врач кирәк түгел»,— дип, Мәрьям апаның кан басымын үлчәргә чакыргалыйлар иде, ләкин аппаратларымны күтәреп баргач, «Борчыган өчен гафу итегез инде, зинһар, үлеп кенә китәсе кешегә врач чакырып йөдәтәсе дә юк та бит, югыйсә»,— дип Мәрьям апа кат-кат гафу үтенә торган иде.
Вак-төяк йомыш дигәч тә, хәзер генә шулай тоела инде ул, үз вакытында һәр йомыш зур шикелле иде. Бүген мәзәк итеп сөйләрлек, үз вакытында зур бер проблемага әйләнгән шундый бер «вак-төяк» йомышны искә алып китәсем килә. Нык алга киткән социализм илендә бәяләрне хөкүмәт үзе җайга салып торганда яшәүләре рәхәт иде, дип, коммунистик «җәннәтне» сагынып яшәгән кайбер адәмнәргә файдасы тияр, бәлкем. Берзаман, 1968 елның азагы иде бугай, миңа Мәскәүдән кунак килеп төште. Яңа елны каршылау табынына шул елларда бик затлы закуска булып киткән «Селедка в шубе» дигән закуска әзерләмәкче була бу. (Кибетләрдә сатылмый башлаганга шулай «тун киендереп» кенә ашау гадәте чыккандыр бәлки ул бичара тозлы балыкны?) Мәскәүнең ГУМ дигән магазинында өчме-дүртме сәгать чират торып, селедка белән майонезын үзе алып кайткан, чөгендерен Казан базарыннан мин барып алдым, ләкин шул закусканы әзерләү өчен кирәкле тагын бер составны — йомырканы табып булмый гына бит. «Ярар, мин әйтәм, юк белән мәшәкатьләнмә, селедка килеш кенә, тотып кына ашыйк». «Юк, тун киендереп ясыйм, тап миңа ике йомырка!» — ди кунагым үзсүзләнеп. Бернича таныш кибетчегә арт ишектән генә кереп мөрәҗәгать итеп карадым, ярдәм итә алмадылар. Шунысын да әйтим, врач булып эшләгәч, минем андый кибетчеләрем бар, башка чакта үтенечемне җиргә салмый торганнар иде. Колхоз базарында йомырка сатылмый. Базарның иң түренә фанерадан ясап зур бер игълан язып элгәннәр, шунда «Бүген безнең базарда түбәндәге бәяләр урнашты» дип, итнең килосын, йомырканың дистәсен күпмегә сату тиешлеген язып куйганнар. Язуын язганнар, тик ул игъланда күрсәтелгән арзан бәягә ит сатучы ахмак та, йомырка сатучы җүләр дә юк, сәүдә сафлары буп-буш, шар сугып уйныйсы гына калган. Мәскәү кунагы алдында Казаныбыз өчен оялып, сәмсеремне койган килеш өйгә кайтып барганда Рөстәм абый очрады. Билгеле инде, мин башыма

төшкән кайгы — Казан тиклем Казанда ике йомырка таба алмый йөрүемне сөйләргә тотындым. Рөстәм абыйларның суыткычларында Мәрьям апа чәк-чәк пешерү өчен дип саклап тоткан берничә йомырка бар икән, ияреп кереп, шуның икесен алып чыктым. Кайтарып бирә белдемме шул йомыркаларны, юкмы — хәзер инде исемдә юк. Һәрхалдә, «Бурычка алган йомыркаларны кайчан кайтарасың?» — дип сораган кеше булмады.



*Композиторның әтисе Мөхәммәтхаҗи һәм әнисе Мәрьям ханым.*

Кайчак шундый вак-төяк йомыш аркасында аралашулардан көтелмәгән матур нәтиҗә дә чыгып куя торган иде. Рөстәм абый мин белгән елларда китап укуны яратмады. «Укый алмыйм, минем башым бик тиз арый, укыганымны шунда ук оныта барам»,— дия иде. Өендә шагыйрьләр «Музыка язмасмы икән» дип өметләнеп бүләк иткән шигырь җыентыкларыннан башка китаплар күрмәдем диярлек. Шулай да кайчак укыйсы килә иде аның, укырга бирәр нәрсә биреп тор әле, дип миңа керә иде. Аңа Меримэнең «Таманго» дигән повестен укырга тәкъдим иткәнем хәтердә, бу повесть минем үземне бик тетрәндергән иде. Шул сюжетка балет язып булмыймы икән дигән фикер дә туган иде. Рөстәм абый повестьны укып чыкты, ләкин балет язмады. Бу темага балет язу өчен Африканың музыкаль фольклорын яхшы белү кирәк, аны өйрәнеп торырга минем сәламәтлегем дә, вакытым да юк, диде.

Икенче керүендә ул минем Шекспирның С. Маршак тәрҗемәсендә басылып чыккан «Сонетлар» җыентыгын карап утырган чагыма туры килде. Нәкъ шул көннәрдә Маршакка шушы тәрҗемәләре өчен Ленин премиясе бирелгән иде, бу нәрсә Рөстәм абыйның да колагына кергән булып чыкты. Җыентыкны ачкалап карады да, алып торыйм әле, дип өенә үк алып чыгып китте. (Ходай гафу итсен инде, ул бу китапны кире кайтарып бирүне онытты гына түгел, исенә төшергәч тә кайтармады, әллә саташып, әллә аңлы рәвештә «Мин бу китапны үзем сатып алдым!» — дип җавап бирде.) Күпмедер вакыт үткәч ул миңа Шекспир сонетына язылган гаҗәп матур романс уйнап-җырлап күрсәтте. «Ярар, шушы тиклем матур романс язгач, бу китап сиңа инде алайса,— дидем.— Бәлки, тагын язарсың».

Ялгышмасам, Рөстәм абый Шекспир сүзләренә тагын бер романс язган иде, ул аны миңа уйнап та күрсәтте шикелле, тик бу романсның язмышын белмим.

Рөстәм абыйлар Лесгафт урамына күчеп киткәч, безнең суына башлаган мөнәсәбәтләребезнең яңадан кызып китүенә Мәрьям апа Рахманкулова сәбәпче булды. (Укучының җырчы артистка Мәрьям Рахманкулова белән композиторның әнисе Мәрьям апаны бутамавын үтенәм.) Мин кечкенәдән Мәрьям Рахманкулованың җырлавын яратып үстем. Ул опера театрында эшләп йөргән елларда, үзем дә танылып килгән «өметле яшь драматург» булгангадыр инде, бәлкем, мин җырчыларыбызның бөтенесе белән дә диярлек танышып беттем, ләкин Мәрьям

апа белән танышырга туры килмәде. Хөрмәтем бик зур иде минем Мәрьям апага, аны музыка сәнгатебезнең бер алиһәсе кебегрәк итеп саный идем, шуңа янына үзем килеп, танышып китәргә әрсезлегем җитмәде. Ә рәсми рәвештә танышуның җае чыкмады. 1959 елда «Инде сез хәзер Карменны җырлый алмыйсыз!» — дип, үзе оештырышкан, беренче нигез ташларын үзе салган, егерме елдан артык эшләгән театрдан Мәрьям апа куалап чыгарылгач, мин бик аптыраган идем. Чөнки бу әле җырчының Няня, Графиня, Любовь, Азучена, Тугзак ана, Җиһан карчык кебек партияләрне менә дигән иттереп башкарган чагы иде. Мәрьям апа Рахманкулова белән Рөстәм абыйның якын кардәшләр икәнлеген мин белә идем, җырчының театрдан чыгарылгач булган рухи халәтен күз алдыма бик яхшы китергәнгә: «Алып бар әле мине Мәрьям апа янына, студент чакта акча булмады, бер кочак чәчәк илтеп бирим әле үзенә, күңеле күтәрелеп китәр, ичмаса!» — дип, Рөстәм абыйга мин күп ялындым, алып бармады. Әллә — вакыты булмады, әллә — теләмәде, әллә берәр башка сәбәп булды. Сәнгать — катлаулы һәм астыртын интригалар белән туды өлкә, һәммәсен дә аңлап бетерү читен.

1976 елда Татарстан радиосы 75 яшен тутырып килгән җырчының моңа тиклем беркайда, беркем җырламаган татар халык көйләреннән торган коцертын тапшырды. Ул гаҗәп үзенчәлекле концертта рояль партиясен Рөстәм Яхин алып барды. Бу концертны тыңлагач, билгеле инде, минем Мәрьям апаны күреп танышасы килүгә булган күптәнге теләгем яңадан кабынып китте, «Алып бар мине Мәрьям апа янына!» — дип, яңадан Рөстәм абыйны тыкырдата башладым.

Берничә көннән мине Рөстәм абый Мәрьям апа Рахманкулованың Патрис Лумумба урамындагы фатирына алып барды. Театрда эшләгән елларында мин янына барырга кыймый йөргән, кырыс һәм коры шикелле булып күренгән Мәрьям апа шат күңелле, зур зәвыклы һәм акыллы хатын булып чыкты. Мине иң нык гаҗәпләндергәне шул булды: 75 яшен тутырган Мәрьямападан җор сүз, шуклык, уен-көлке белән генә әйтеп куелган акыллы фикерләр бөркелеп тора иде. Анекдотлар тыңларга да ярата, аларны үзе дә оста итеп сөйли белә. Беренче булып Мәрьям ападан ишеткән, шул еллар өчен типик булган бер анекдотны искә төшереп китәсем килә.

Леонид Ильич Брежнев өендә газеталар карап утыра икән, ишектә кыңгырау шалтырый. Авызына протез тешләрен шалтыр-шылтыр иттереп тутыра-тутыра (Мәрьям апа бу хәрәкәтне искиткеч оста итеп ясап күрсәтә иде) Леонид Ильич ишек катына килә, куен кесәсеннән бер бит кәгазь чыгара һәм шунда язылганны кычкырып укып җибәрә:

— Кем бар ан-да?

Җавап бирүче булмагач, Леонид Ильич кире урынына килеп утыра, ләкин кыңгырау тагын кабатлана. Леонид Ильич тагын ишек катына килә, куен кесәсендәге язуны чыгарып, тагын укый:

— Кем бар ан-да?

Җавап тагын булмый. Шулай әллә ничә тапкыр кабатлана. Нинаять, түземе бетеп, Леонид Ильич ишекне ачып җибәрә. Ачса — каршысында Суслов басып тора.

— Ми-ха-ил Андре-ич! — ди Леонид Ильич. — Мин, кем бар ан-да, дип со-рап торам ла-баса! Ник сез җа-вап бир-ми-сез?

— Кадерле Леонид Ильич, — дип җавап бирә Суслов. — Сезнең тирән акыл белән биргән соравыгызны мин ишетеп торам, җавап бирә алмыйм, җавабымның тексты өйдә онытылып калган.

Шуны да искә төшереп үтү артык булмас: картлардан һәм картлыктан көлеп чыгарылган бу анекдотны 75 яшен тутырган Мәрьям апа Рахманкулова миңа 1977 елда, Брежнев Советлар Союзы тәхетендә әле бик нык утырган чакта сөйләгән иде.

Киләчәктә Мәрьям апа турында истәлекләр язу әллә насыйп була, әллә юк, тагын шуны әйтеп үтәсем килә. Мәрьям апа Рахманкуловада бик күбебезгә җитешмәгән сыйфат — үз кимчелекләре турында шаярып-көлеп сөйли алу бар иде. Битенә гримнәр салып күп еллар театрда эшләгәнгәдер инде, Мәрьям апаның борыны кызарып тора иде. Хатын-кыз өчен, бигрәк тә артистка булган кеше өчен, сөйләп бетергесез күңелсез хәл бит инде бу, югыйсә. Шуны истә тотып, мин Мәрьям апаның йөзенә бик текәлеп карамаска тырыша идем. Әллә шуны сизеп, үзенең кызарып торган борыныннан мәзәк ясап, тормышында булган бер эпизодны сөйләп бирде Мәрьям апа.

Куптәнге бер танышы белән врачка чират көтеп торалар икән.

— Мәрьям Маннановна,— дип сорап куйган әлеге танышы.— Сезнең бу кызыл борыныгызны күреп, өч борынга «колхоз»га керергә чакырмыйлармы әле?

Шушы эпизодны сөйләп, Мәрьям апа рәхәтләнеп көлеп алды. Үз-үзеннән менә шулай көлә алу кешенең көчле характерлы булуы турында сөйли. Мәрьям апа белән якын кардәшләр булсалар да, кызганычка каршы, Рөстәм абыйның характеры моның нәкъ киресе иде: ул үзендәге юк кына кимчелекләр өчен дә тирән кайгыга батып, ачы кичерешләр кичереп яшәде. Мәсәлән, без танышкан вакытта аның битендә бер миң бар иде. Шул миң өчен хафаланып, кистерим микән, юк микән дип, кайгырып-картаеп йөргәне хәтердә.

Мәрьям апаның Рөстәм абый белән бергәләп әзерләгән концерты әле яңгырап үткән генә көннәр булганга, аның өендә очраклы очрашкан вакытларда, табигый инде, күбрәк татар халык җырлары турында сөйләшә идек.

— Әй, бар ла бер матур борынгы көй, егетләр! — дип өзгәләнеп әйтеп салды Мәрьям апа шулай сөйләшеп утыруларыбызның берсендә.— Үтте гомерем шул көйне җырлыйсым килеп. Сүзләре юк! «Халык җырлары» дигән әнә шул китапны баштанаяк укып чыктым, менә шушы көйгә ятышлы сүзләр тапмадым.

Мәрьям апа сикереп торып, пианиносы янына килеп утырды да, уйнап җибәрде.

— Шам Шәриф көе ич бу! — диде Рөстәм абый, көйнең беренче тактын яңгырауга.

— Түгел! — дип килешмәде Мәрьям апа.— Шам Шәриф көенең мелодиясе башка булган, күрәсең, ул онытылган. Ә сүзләрен беләм мин Шам Шәриф көенең. Тик ул сүзләрне бу көйгә җырлап булмый, размерлары туры килми. Менә ул сүзләр:

Шам Шәрифкәй дигән һай калада
Кич ахшамсыз капка ябылмас,
Үткән гомер белән калган хәтер
Сатып алыйм дисәң табылмас.

Соңгы ике юлын даһи юллар дип санарлык бу җырны Мәрьям апа әлеге көйгә җырлап та карады, тик җыр көйгә сыеп бетмәде.

Бу көй турында белгәнемне мин дә кыстырып куйдым. Александр Сергеевич Ключарев «Казан татарлары көе» дип скрипка өчен эшкәрткән бу матур мелодияне элегрәк елларда радио Халидә Әхтәмова башкаруында еш тапшыра торган иде. Шушы көйнең бер гадиләштерелгән вариантын минем әнкәй гомер буе җырлап йөрде, тик аның «репертуарында» бер генә куплет бар иде:

Дөньядыр бу, дөньядыр бу,
Бик вафасыз дөньядыр бу.
Кара чәчне, энҗе тешне
Гүргә салган дөньядыр бу.

Халык җырларының «төмен» яхшы белгән Мәрьям апага бу фәлсәфи сүзләр ошады, ләкин аның фикеренчә, рәхимсез-шәфкатьсез дөнья турындагы бу дөрес фикер бераз уйнаклабрак та, боргаланып-сыргаланыбрак та торган мелодиягә ятып бетми иде.

— Әллә нинди генә кокетство бар кебек бу көйнең бормаларында,— диде Мәрьям апа.

Инструмент янына Рөстәм абый күчеп утырды.

— Кокетство гына түгел, фәлсәфи тирәнлек бар бу мелодиядә,— диде Рөстәм абый, көйгә яңадан яңа төсмерләр, гармонияләр табып уйный-уйный.— Искиткеч мелодия бу! Әгәр безнең бабаларыбыз монгол явы белән Азиядән килгән вәхшиләр булса,— белмим, шушындый нечкә хисле мелодия туар идеме икән? Шәһри Болгарлар заманыннан килгән көйдер бу. Бәлки, аның сүзләре булмагандыр да, бәлки аны берәр инструментта гына уйнаганнардыр. Мелодияне скрипка өчен эшкәрткән Александр Сергеевич аны бик яхшы аңлаган.

Берничә көн мин борынгы Шәһри Болгарны, аның урамнарын, кешеләрен күз алдыма китерергә тырышып йөрдем, күз алдыма җәйге айлы төн килде. Яраткан кызына үзенең мәхәббәтен ничегрәк итеп җиткерәсен белмәгән бер яшь егет, камыштан сорнай ясап, күл буенда әлеге гаҗәп матур көйне суза. Уйлана торгач, менә шушы шигырь килеп чыкты:

Бер яшь егет төн йокламый,
Өзелеп-өзелеп уйный сорнай,
Күңеле бер яшь кызны уйлый:
Чәчләре төн, йөзләре ай.

Йоклый алмый житкән кызлар,
Бигрәк чибәр егете, дип,
Кемне сөяр, кемне назлар,
Кемне итәр бәхетле, дип.

Йоклый алмый ята картлар,
Ай-һай, егет өзелә дә, дип.
Шулай янган-көйгән чаклар
Бар иде бит бездә дә, дип.

Тик яшь кызкай, йөзләре ай,
Тәрәзә ачмый, йөгереп чыкмый,
Гыйшык хәлен әле белми,
Гамьсез йоклый, тыныч йоклый.

Шигырь Мәрьям апага да, Рөстәм абыйга да ошады, шушы сүзләр белән алар әлеге көйне магнитофон тасмасына яздылар, жыр радио аша тапшырылды.

Сүз чыккач, шунысын да әйтим, мин язган шигырь исемсез иде, «Сорнай моңы» дигән исемне аңа Мәрьям апа тапты.

Минем өчен онытылмас көннәр булды ул Мәрьям апа Рахманкуловага 75 яшь тулган көннәр. Мин кечкенәдән табынып килгән шәхес белән танышып кына калмадым, аның күп еллардан бирле жырларга хыялланып йөргән көенә сүзләр дә язып бирә алдым, ул сүзләрне яраткан жырчым авызыннан ишеттем. Мәрьям апа исем кушкан бу шигырь бәхетле шигырь булды, күп тә үтмәде, шушы ук сүзләргә Рөстәм абый да музыка язып куйган булып чыкты. Көй миңа бик ошаса да, Мәрьям апа яраткан мелодиягә атап чыгарылган текстның бүтән музыка белән файдалануын өнәп бетермәдем. «Алайса, шушы мелодиягә тагын бер шигырь яз, синең сүзләрдән илһам алып туган музыка синең белән калсын инде»,— диде Рөстәм абый. Мин яздым. Ул шигырь «Киң аланда таң алдыннан» дип башлана. Шигырь Рөстәм абыйга ошады, ләкин ул бу текстның әлеге мелодия өчен ваграк булуын әйтте, әнә шул «Сорнай моңы»ндагы шикелле фәлсәфәсе булсын шигыреңнең, диде. Мин зуррак темага шигырь уйлап йөргәндә Рөстәм абый бу текстка романс язып куйган булып чыкты. Башка текст язып булмады, «Сорнай моңы» жырчыларның репертуарына Рөстәм абый музыкасы белән кереп китте. Бу музыканы Марсель Сәлимжанов та яраткан иде, ул аны Качалов исемендәге театрда минем «Әниемнең ак күлмәге» дигән пьеса буенча куелган спектакльдә файдаланды. Жыр Татар Дәүләт жыр һәм бию ансамбленең репертуарына керде, ансамбль белән дөньяның бик күп илләрендә булып кайтты. Минем уйлавымча, Рөстәм абый йөрәгеннән чыккан бу моң — композитор тудырган иң матур мелодияләрнең берсе.



*Рөстәм Яхин хатыны Хәлимә ханым белән.*

Гомеренең соңгы елларында больницага ятып, үзенең аһ-зарларыннан бераз арынып чыга торган гадәте бар иде Рөстәм абыйның. Кайсы елны икәне исемдә түгел, Татарстан урамындагы фатирда торып яткан чаклары, Республика больницасының неврозлар бүлегенә кереп яткач: «Яныма килеп кит әле!» — дип шалтыратты. Барсам — Рөстәм абыйны танырлык түгел. Ябыккан, чыраенда яшәү нуры беткән.

— Ни булды сиңа, Рөстәм абый, нигә болай ябыктың? — дидем. Врач булырак, башыма бик шөбһәле уй килде.

— Беттем мин, үләсе генә калды,— дип җавап кайтарды Рөстәм абый.— Тик болай озак ятып үләсем килми. Үтенәм синнән, тиз генә үлеп китү өчен яса миңа берәр укол!

Мондый үтенеч белән ул миңа берничә тапкыр мөрәҗәгать иткәләп килде, моңа тиклем мин аның мондый үтенечен шаяртуга юрап, сүзне икенчегә борып җибәрә торган идем. Бу юлы алай эшли алмадым. Шактый озак сөйләшеп утырдык без больница бакчасында. Телендә һаман бер сүз: башым эшләми, берни яза алмыйм. «Соң,— мин әйтәм,— яза алмасаң — язма, инде язганың кадәресе дә бик җиткән. Иҗат

кешеләрендә була торган хәл ул. Әнә бит Россини да 38 яшендә яза алмый башлаган, ләкин аңа карап үзен-үзе үтермәгән, тагын кырык ел яшәгән».

Берничә көннән сирень чәчәкләре күтәреп бардым мин моңа. Чәчәкләрне Рөстәм абый яратты, хуш исләрен иснәп, текәлеп-текәлеп карап утырды да, тәгәрәп чыккан күз яшьләрен йодрыгы белән сөртеп алды.

— Кара, яшь чакларны искә төшерде бит әле синең бу чәчәкләрең,— диде.— Без яшь чакта, сугышка кадәр, хәзерге кебек купшы канәферләр, лаләләр юк иде бит, бар булган чәчәк шушы сирень дә, ландыш белән шомырт иде.

Минем үземнең яшьлегемдә дә шулайрак булды. Сугыш вакытында, алтынчымы-җиденчеме класста укып йөргән чак, класста үземә ошаган бер кызның парта тартмасына күзенә күрсәтмичә генә илтеп куйыйм әле, дип, зират өстендәге сиреньне сындырган өчен әткәйнең бик каты әрләгәне истә. Шуларны уйлап төн йокламый чыккач, иртән «Сиреньнәр» дигән шигырь туды. Шигырь Рөстәм абыйның больницада яткандагы рухи халәтенә бик туры килә шикелле тоелды һәм мин аны аңа больницага илтеп бирдем. Әчемнән генә сәламәтлеге таушалып беткән композитор, соңгы куәтен җигеп, «Аккош җыры» булып калырлык берәр романс язып куймасмы дип хыялландым. Шигырьне ошатты Рөстәм абый, ул аңа больницада ятканда ук музыка да язды, ләкин бу музыка композиторның үзен дә канәгатьләндерми иде, миңа да ошамады. Өйгә чыккач та композитор бу шигырьне гел янында тотты, кат-кат әйләнеп кайтып, әллә ничә вариант музыка язды, ләкин хатыны Хәлимә ханымның әйтүенә караганда, ул музыкаларның берсе дә авторның үзенә ошамаган һәм аларны миңа Рөстәм абый күрсәтмәде дә.

Маэстроның күңеленә Ходай тәгалә сипкән энҗе бөртекләре чүпләнеп беткән булган иде инде, күрәсең.

Менә ул, Рөстәм абый үзенең соңгы көннәрендә музыкага саласы бик килсә дә, сала алмый калган шигырь:

Хуш исле нәфис сиреньнәр
Яшьлегем чәчәкләре.
Иң беренче мәхәббәтнең
Мәңге якты ядкаре.

Белəм, бусагам төбенә
Картлыгым килеп яткан.
Тик мин яшь, чөнки бакчада
Сиреньнәр чәчәк аткан.

Нигә сирень чәчәк атса,
Күңелгә шатлык тула.
Еракта калган яшьлекләр
Кире кайткан күк була?

Мин үлгәч, каберем өстендә
Сиреньнәр чәчәк атсын,
Узган-барган юлыксын да,
Кайгыларын онытсын.

* * *

Кырык елга якын аралашып яшәсәк тә, Рөстәм Яхинны мин яхшы беләидем, дип әйтә алмыйм. Катлаулы һәм шактый авыр холыклы кеше иде ул. Бер карасаң — ачык чырайлы, аралашуны, сөйләшүне ярата торган кеше, сәнгать һәм әдәбият хәлләре белән генә түгел, дөнья хәлләре, сәясәт белән дә кызыксына. Икенче карасаң — һичбер нәрсә белән кызыксынмый, һичбер нәрсәдә йомышы юк. Бер очрашканда искиткеч әдәпле һәм мөлаем кеше, вакытың булса, әйдәле, пожалуйста, безгә керик әле, бер яңа әйбер язган идем, шуны тыңларсың, дип өенә чакыра. Икенче очрашканда йөзен кара болыт баскан, телендә гел аһ-ваһ, гел үзенең кәефсезлеге, булган да, булмаган да авырулары турында сөйләп тора.

Җырның сүзен төшереп калдырып булмаган кебек, композитор Рөстәм Яхин турында сөйләгәндә дә бер нәрсәне әйтми калдыру мөмкин түгел: гомере буе аның башында бер бәйләнчек уй — idee fixe яшәп килде (һәрхәлдә, мин аны белгән еллардан башлап.) Аның күңеленә бик еш үз-үзен үтерү турындагы уй килә торган иде. Мин икеләнмим: ул үз-үзен үтермичә җитмешне узганчы яшәгән икән, моңа очрак түгел, аңарда бу эшне эшләрлек ихтыяр көче булмау сәбәп.

Парадокс шунда: миңа үләргә ярдәм ит, берәр укол када, зинһар! — дип Рөстәм абый миңа, гомерен кешеләрне дәвалауга, үлемнән алып калуга багышлаган врач кеше янына килә торган иде. Кемнәндер ишетепме, кайдандыр укыпмы,— җиңел генә үлеп китүнең юлын да тапкан. Ул — шактый зур дозада ясалган морфий инъекциясе. Башта кәефләнеп китеп, эйфориягә киләсең, аннары тирән йокыга таласың да, ансат кына үлеп китәсең. (Аның йокыга талганын күреп, якыннары Чайковский балетындагы Аврораның уянуын кул кушырып

утырып көткән шикелле көтәрләр, дип уйлый иде булса кирәк!) «Син врач, теләсәң, житәрлек кадәр дозада морфий таба аласың, пожалуйста, яса миңа шул уколны!» — дип ялвара, ялвара гына түгел, бәйләнә торган иде ул кайчакларда. Үләсе килүенең сәбәбе һәрчак бер була торган иде: минем баш миемдә склероз, башым эшләми, берни яза алмыйм.

Үзенең бетешкән-чирләшкә кеше икәнлеген расларга медицина институты студентлары өчен хан заманында басып чыгарылган, аның өстәл китабына әйләнгән бер дәреслеге бар, еш кына шул дәреслекнең билгеле битен ачып, астына сызып куелган юлларны укырга куша иде.

Баштарак мин аның мондый сүзләренә әлләни игътибар итмәдем, чөнки аның: «Башым эшләми, берни яза алмыйм!» дип уфтанулары халкыбызның музыкаль культурасына энже бөртекләре булып кергән «Моабит дәфтәре» шигырьләренә музыка язган елларда да булды. Тора-бара, бик теңкәгә тия башлагач, әйтә торган идем:

— Рөстәм абый, акылыңа кил! Ничек инде мин, врач булган кеше, андый эшкә барыйм? Шундый җинаятьне эшләрлек көч тапсам да, аның гөнаһсын кая куярмын? Вөждан газабына ничек чыдармын?

Болары турында ул бик уйламый иде шикелле.

Депрессия басып киткән полосалар кайчак берничә атнага сузыла, атна саен диярлек керер: «Укол ясап үтер мине!» — дип ялвара, үзе дә газаплана, мине дә газаплап, туйдырып бетерә иде. Әйтә идем аптырагач:

— Рөстәм абый, синең үләсең килми, син кыланасың гына. Үләсе килгән кеше үлүнең бер юлын таба инде ул, мине үтер дип врач янына килми!

Шулай әйтергә нигез дә юк түгел иде шул. Уйлап карагыз. Бүген: «Минем башым эшләми, миңа бу дөньяда кызык калмады, миңа үләргә ярдәм ит!» — дип ялына. Ә берничә көннән бу турыда онытып, үзенә нәүбәттәге мактаулы исемне бирү турындагы указның чыкмый торуына борчыла. Бүген: «Берни яза алмыйм, кешедән оят. Кеше, өч бүлмәле фатирда икәү генә яшәп яталар, бернәрсә язганы юк, дип әйтә торгандыр. Үләргә ярдәм ит миңа, зинһар!» — дип ялвара. Шуннан соң күп тә үтми, өч бүлмәле менә дигән фатирын ташлап, дүрт бүлмәлесенә күчеп китә. Кайда монда мантыйк?

Тагын шундый бер деталь. Бик теңкәгә тигәч, сынап карарга булдым мин моны. «Ярар, дидем, бу тиклем ялынгач, ясамый булдыра алмыйм. Ләкин син әйткәнчә, өеңә килеп түгел, өеңдә синең хатыныңың, синең кинәт кенә үлеп китүеңнең сәбәпләрен тикшерергә килгән сорау алучыга Хәлимә ханым «Шәриф Хөсәенов кына килеп киткән иде», диячәк. Минем әле яшәп туйганым юк, синең аркада төрмәгә кереп утырасым да килми. Әйдә, кил Куйбышев мәйданына, берәр кешесез подъездга алып кереп ясармын».

Билгеләнгән вакытта билгеләнгән урынга килдем. Рөстәм абый килмәде.

Мин шактый коры һәм каты кеше булсам кирәк. Авыр туфрагы җиңел булсын, «Үтер мине!» — дип бик аптыраткан чакларда сүгеп тә ташлый торган идем мин Рөстәм абыйны. Рәнҗи торган иде.

Шундый бер очрак хәтердә. Әле мин — Кызыл байрак, ул — Восстание урамының 38 нче йортында яшәп ятканда (1964 елның язы булырга тиеш) йокларга ятам дип кенә йөргәндә Рөстәм абый килеп керде. Аннан алдагы кичтә дә шулай соң гына кереп, аптыратып бетергән иде, депрессиядә чагы, ниләр сөйләргә кереп килүе алдан билгеле. Иртәгесен якшәмбе, поликлиникага дежур торырга барасым бар, ишек төбеннән уздырмадым мин моны. «Тагын шул бер балык башын чәйнәргә булсаң, кертмим, мин инде йокларга ятам!» — дидем. Бик рәнҗеп чыгып китте, яшь белән мөлдерәп тулган күзләре бүген дә күз алдымда.

Рәнҗи, ләкин ачу саклый белми иде.

Кирәк бит, шушы куалап чыгаруымнан соң иртән торып, дежурга чыгып китәргә йөргәндә күрше маржа телеграмма китереп тоттырды. Апалар янына кунакка киткән әнкәй Мәскәүдән кайтып килә икән, шуны каршы алуны сорап сукканнар. Минем әнкәй авыл карчыгы, бер авыз русча белми, анда-монда барганда үзен утыртып җибәрү, кайтканда каршы төшеп алу кирәк. Поезд берничә сәгатьтән килеп җитәчәк, ләкин дежурствога чыкмый калу ярамый. Шалтыратып кына әйтергә үземдә дә, туганнарда да телефон да юк чак. Нишләргә? Башка чара калмагач, күршедәге Рөстәм абый янына кердем. Кичәге хәлдән соң минем белән сөйләшеп тә тормас, ишеген генә ачып карар да, шалт иттереп ябып куяр дип курыккан идем. Алай эшләмәде, әнкәйне каршы төшеп алырга риза булды.

Дежурствомны сәгать өчтә йомгаклап, йөгереп өйгә кайтсам, өем бикле. Мәскәү поезды вакытында килгән иде, югыйсә, моны мин эштә чакта ук шал-

тыратып белдем. Нәрсә булды икән? Йөгереп Рөстәм абыйларга кердем — анда Мәрьям апа ут йотып утыра, Рөстәмнең вокзалга дип төшеп киткән җирдән әле һаман кайтып җиткәне юк, ди. Киттем вокзалга трамвайга утырып. Барсам, вокзал эчендәге утыргычларның берсендә әнкәй кайнар чәй белән сумса ашап утыра, янына посттагы солдат шикелле Рөстәм абый баскан. Күрмәгән-белмәгән кешегә ияреп китәргә — әнкәй, йодрык хәтле авыл карчыгын әллә ничә төенчеге белән вокзалда бер ялгызын калдырып китәргә — Рөстәм абый курыкканга шулай килеп чыккан икән. Рөстәм абый әнкәйгә буфеттан кайнар чәй белән сумса да алып килеп биргән.

Тәкәллефләнеп маташмыйм: аның урынында мин булсам, үземне кичә генә бусага төбеннән уздырмыйча сүгеп чыгарган кешенең әнисен сумса белән сыйлау түгел, каршыларга барып та мәшәкатьләнеп тормас идем.

* * *

Рөстәм Яхинның музыкасы турында әйтелгән фикерләр инде шактый, киләчәктә әле тагын да күбрәк әйтелер. Мин музыка белгече түгел, шуны күздә тотып булса кирәк, бу истәлекләрне язуымны сораган чакта ук миңа композиторның музыкасына кагылмаска куштылар. Консерваторияләрдә укып йөргән әфәнделәр һәм ханымнар шулайрак бит инде алар: кесәләренә консерватория дипломы салып куялар да, үзләрен күкләргә ашып, Аллаһы тәгаләнең үзе белән чәкештереп сөйләшкән кеше кебегрәк тоталар, безнең ише консерваторияләрдә укымаган бахырларга югарыдан гына карыйлар, музыка турында фикер йөртү өчен безне вәкаләтсез дип саныйлар. Хәер, үзләрен мактаганда алар безнең вәкаләтсез икәнлегебезне онытталар. Тәнкыйть сүзләре әйтә башласаң гына, консерватория бетергән булмавыбызны искә алып, музыка шикелле илаһи сәнгать турында фикер йөртергә хакыбыз юклыгын әйтәләр. Урыны җәннәттә булсын, мәрхүм Рөстәм абый Яхинда да бу гадәт юк түгел иде.

Мин мондый караш белән килешә алмыйм!

Нишләп әле безгә, тыңлаучыларга, үзебез өчен язылган, үзебез тыңлаган (еш кына хәләл акчабызны түләп!) музыка турында фикер йөртергә ярамый? Музыка — консерватория бетереп чыккан берничә бөртек музыка белгече өчен генә язылмый лабаса!

Рөстәм Яхин белән күп еллар аралашып яшәгән, ул язган музыканың күп өлешен яраткан (барысын да түгел!), үземә калса, шактый яхшы белгән тыңлаучы буларак, минем аның музыкасы турында да үз фикеремне әйтеп китәсем килә, ялгышсам — башкаларның да фикерен тыңларга әзер.

Композитор Рөстәм Яхин бик катлаулы кеше иде, ул күп еллар дәвамында үлем турында уйлап, үз-үзен үтерү турындагы бәйләнчек фикер белән газап чигеп яшәде. Мин аның башкалар шикелле, бөтен дөньясын онытып, күңел ачкан, кәеф-сафа сөргән чакларын күрмәдем. Минем күңелемә ул моңсу һәм сагышлы кеше булып кереп калды. Аның биографиясе дә шактый катлаулы. Октябрь революциясеннән соң бар байлыгын, бар булган мал-мөлкәтен ташлап качкан, илдән илгә күчеп йөри-йөри хәерчелеккә төшкән, соңгы чиктә Америка Кушма Штатларына барып егылган, шунда туган илне сагынып, кан-яшь түгеп яшәгән, шул чит-ят туфракта вафат булып калган һәм яшәп яткан якын туганнары бар иде аның. Күз алдында булып узган 1937—38 нче еллар мәхшәре дә, халыкның аннан соңгы еллардагы ачы язмышы да әсәрләнүчән художник йөрәгендә кыздырган тимер белән уеп алгандай эз калдырган булырга тиеш ләбаса. Димәк, илдәге һәм шәхси тормышындагы фаҗигаләр композиторның иҗатында теге яки бу дәрәҗәдә чагылыш табарга тиеш иде — бу күптән билгеле аксиома. Шәхси тормышлары шоп-шома гына булмаган, шактый фаҗигале булган Бетховен, Шопен, Лист һәм Чайковский кебек композиторларның әсәрләрендә бу нәрсә ярылып ята. Дөрес, яман аты чыккан социалистик реализм кысасы эчендә генә тырмашырга рөхсәт биргән тоталитар режим шартларында иҗат кешеләренең хәле башкачарак булды. Шуңа карамастан, Рөстәм Яхинның замандашлары Прокофьев һәм Шостакович үзләренең әсәрләрендә XX гасыр чумасы коммунизм кешелеккә китергән афәтне бик оста тасвирлап калдырдылар. Бәлки, ялгышамдыр, тик минемчә, Рөстәм Яхинның әсәрләрендә чынбарлыкның асылына ишарә ясаган, аның шәхси тормышындагы халәтне чагылдырган, аны үлем турында уйлап, газап эчеп яшәргә мәҗбүр иткән караңгы темалар юк дәрәҗәсендә. Композиторның иң зур әсәре булган Оркестр белән фортепиано өчен язылган концертта, шәхсән мин үзем, андый авазларны бөтенләй диярлек ишетмим.

Кечкенә күләмле инструменталь әсәрләреннән дә күбрәк оптимизм чәчрәп тора. Бу хәл мине бик гаҗәпләндерә. Нигә шулай? Республика больницасының невроз-лар бүлегендә дәваланып чыкканы булуга карамастан, фактлар һәм вакыйгалар турында төптән уйлана, аларга тирән анализ ясап, дөрес нәтиҗәгә килә белә торган кеше иде ул. Шушы уңайдан, үземнең бу язмаларның ахырында әйтәчәк фикеремне раслау рәвешендә, күп еллар дәвам иткән аралашулар вакытында булган тагын бер-ике нәрсәне искә аласым килә.

Мин үземә ошаган, үземне дулкынландырган шигырьләрне күңелдән ятлар-га яратам. Кайчак, үзем дә сизмәстән, сөйләгәнемне җупләү өчен, кайсы да булса шагыйрьдән берәр цитата китерү гадәтемә әйләнгән, шушы гадәтем белән кай-бер дус-ишне туйдырып та бетердем бугай инде. Рөстәм абый минем бу гадәтем-не яратмый, миннән көлә торган иде:

— Кайчан инде син кеше сүзе сөйләп йөрүдән туктыйсың? Кайчан үз сүз-ләрең белән сөйләргә өйрәнәсең?!

Шулай диюенә карамастан, кайчак миңа ошаган шигырь аңа да ошап куя, аны да дулкынландыра иде. Мәсәлән, Анна Ахматованың «Диңгез буе соне-ты»ндагы:

И кажется такой нетрудной,
Белея в чаще изумрудной,
Дорога, не скажу куда,—

диган үлем турындагы моңсу юлларның аны бик нык дулкынландырганы хәтер-дә. Яле-яле, язып бир әле миңа шуны, дип, бу юлларны кәгазь кисәгенә яздырып та алып чыгып китте. Берничә көн үткәч, әйләнеп керде, Ахматованың теге шигырен син баштан-аяк беләсеңме, белсәң, язып бир әле, бәлки мин бу сүзләргә музыка язармын, диде. Тик ни сәбәптәндер, язмады. Шагыйрәнең хакимият тарафыннан кыерсытылган булуы комачаулагандыр, бәлкем.

Икенче бер вакыт аны Бертольд Брехтның барабаннар кагып килгән сарык-лар турындагы җыры тетрәндерде:

Вот идут бараны,
И бьют в барабаны,
А шкуру барабанам
Дают бараны сами...

Кайсы елны икәнлеген төгәл әйтә алмыйм, минем Кызыл байрак ура-мындагы бүлмәдә яшәгән чак (мин анда 1958—66 елларда яшәдем), шушы юлларны сөйләгәч, Рөстәм абый шаркылдап көлеп җибәрде, ләкин бик тиз көлүдән туктап:

— О, потрясающе! Слушай, бу бит безнең хакта! Совет кешеләре турында әйтелгән сүзләр ич бу! Потрясающе! Күз алдына китер: Кызыл мәйдан буйлап барабанар кага-кага, юлбашчыларның рәсемнәрен күтәреп, «Яшәсен!» дә «Яшә-сен!» — дип кычкыра-кычкыра сарыклар колоннасы килә. Ничек әле ничек? А шкуру барабанам дают бараны сами — шулаймы? Потрясающе! — диде.

Брехтның бу юллары совет кешеләрен күз алдында тотып язылмаган, әлбәттә. Ләкин фашизм белән большевиклар урнаштырган тоталитар режимнар-га кул чабып, барабаннар кагып яшәгән кешеләр арасында аерма юклыгын Рөстәм абый бик вакытлы тотып алды.

Менә шушы уртаклыкны аңлый белгән кеше искиткеч гүзәл әсәрләр белән бергәттән, дистәләрчә миллион бер гонаһсыз ватандашларын һәм замандаш-ларын атып яисә концентрацион лагерьларда черетеп үтергән Сталинны мактап та, тургайларның үзләрен бөтенләй үтереп бетергән режим турында «Сайра, тургай, безнең туган илдә шат яшәргә уңай!» — дип тә җырлады. Нәни Чапайлар, коммунистик маяклар турында да, бәйсезлек өчен көрәшкә күтәрелгән үзбәк туганнарны Мәскәү алдында куштанланып кырып кайткан Татар бригадасы турында ура-патриотик җырлар да язды:

Фирганә — Бохара —
Без үткән ара,— эх!
Фрунзе безнең командарм,
Дошманнарның җиндек барын
Данлы елларда!

Еллар данлы булмаганнар шул, канлы булганнар! Бу турыда минем белән ачылып китеп сөйләшкәне булмаса да (ул чиктән тыш куркак кеше иде), Рөстәм Яхин моны аңламагандыр дип әйтсәм, телем корыр кебек.

Кайчакта мин аннан:

— Рөстәм абый, нигә син халтура җырлар язасың? — дип сорый торган идем. Яратмый иде бу хакта сөйләшүне. Бармакларын рояль клавишлары өстеннән уңлы-суллы йөртеп ала иде дә, әйтә иде:

— Халтура түгел, Шәриф. Бар — йөрәктән чыккан әйберләр. Бар — күттән чыкканнары. Йөрәктән чыккан әйберләр белән генә тамак туйдырып булмый.

— Чираттагы мактаулы исемне дә алып булмый, — дип үрти торган идем.

Хәтере кала иде Рөстәм абыйның мондый сүзләргә:

— Синең эш рәхәт, син врач булып эшлисең. Язсаң да, язмасаң да ай саен азмы-күпме алып торасың...

Рөстәм абыйларның гомер буе акчага туймаганлыкларын, гомер буе һәр тиенне санап яшәгәнлекләрен әйткән идем бугай инде.

Гомерләрен һәм талантларын җинаятьчел режимны мактауга багышлаган икәнлекләрен аңлагач, Александр Фадеев һәм Исаак Дунаевский маңгайларына пуля җибәрделәр.

Ләкин болай эшләргә һәркемнең дә көче җитми!

Үз намусын үзе сатып яшәргә мәҗбүр икәнлеген аңлаган кемдер хурлыгын аракыга батырмакчы була, үзенә кул салырга көче җитмәгән кемдер гомерен Газап диңгезенең суын эчеп уздыра.

Рөстәм Яхинның үзе дә аңлап җиткермәгән фаҗигасе аның «башы эшләмәүдә», «берни яза алмыйм» дип уфтанып яшәвендә түгел (ул аз язмады, шактый күп язды!), ә бәлки югарыда китерелгән «Татбригада җыры» кебек ура-патриотик рухтагы бравадалар яза алуында булгандыр?

Язмамның ахырында Рөстәм абыйның хатыны Хәлимә ханым турында да ике сүз әйтәсем килә. Соңгы вакытта бу хатынны сөйләп, чәйнәп йөрүчеләр күренгәләде. Шуларга җавап рәвешендә шуны гына әйтеп узам: Рөстәм абыйны яратыпмы, әллә югыйсә композитор хатыны гына буласы килепме, артыннан чапкан хатыннар шактый булды. Тик Мәрьям апа үлгәч, үзенә аш пешерү түгел, чәй генә кайнатып эчү өчен дә ярдәмсез калган маэстро янына беренче булып йөгереп килгәне, егерме елга якын аңа юлдаш булганы, кулыннан килгәнчә, булдыра алган хәтле ярдәм иткәне — берәү генә. Ул хатын — Хәлимә ханым.

Бу факт аңлатуларга мохтаҗ түгел.

*Март, 1996 ел.*

# ӘБРАР СӘГЫЙДИ

Шөһрәт вә дан эчендәге бәйге атлары, чабышкыйлар була. Андый атларны яуга-сугышларга иң беренче булып алалар. Кайнар йөрәкле бу бәйгерләр яки ярышта, яки сугышта янып үләләр. Аларны халык данга күмә, аларга кыйммәтле бүләкләр бирә.

Бар — йөк атлары. Алары, чабышкыйлар Сабан туенда узышканда, фермаларда йөк ташый, кырларга ашлама чыгара, халыкны ризык белән туендыру эшендә йөри. Ике төр ат та безнең өчен кадерле.

Әдәбиятның да бар бәйгерләре, бар эш атлары. Бар Дәрдемәндләр, Рәмиләр, Такташлар, Туфаннар; бар Ибраһимовлары, Галәүләре, Исәнбәтләре, Гыйләҗләре, Миннуллиннары.

Күп вакыт әдәбияттагы «эш атларын» күрмиләр, белмиләр. Алар торабара онытылып та куя...

Сәхипгәрәй Мортазинның 1968 елда басылган «Ялкынлы еллар поэзиясе» исемле китабы нәкъ менә шул бурычны үти кебек. Автор сөйләп-мактап бетергесез олы эш майтарган. Мондый олы күләмдәге эшне соңрак Әнвәр Шәрипов — утыз Иманы иҗатын матбугатка әзерләп, Әдхад Синугыл — Гыйззел Габбид шигырьләрен аерым китап итеп, Галимҗан Гыйльми — Бабичның бер томлыгын чыгарып башкарганнар иде. Гәрәй Рәхим төзегән шигырь антологиясендә дә без ишетмәгән, без белмәгән әллә ничә шагыйрь турында мәгълүмат бар.

С. Мортазинның әлеге китабында да моңарчы таныш булмаган, хәтта әдәбият галимнәре дә белмәгән бик күп шагыйрьләр турында мәгълүмат урнаштырылган, шигырьләре бирелгән. Фарсин, Сәнбәли, Госман, Сафи, Тулайский, Бәди... тагын әллә кемнәр, әллә нинди язмышлар, шигырьләр... Шулар арасында шигырь сөючеләр беренче тапкыр Әбрар Сәгыйди исеме белән дә танышкан иде. Бу миһербанлы вә кыйммәтле эше өчен С. Мортазинга рәхмәт әйтеп, мин Әбрар Сәгыйди исемле бер шәхесебез турында кыскача гына язарга ниятләдем.

Гасыр башында иҗат юлын башлаган шәхесләребезнең бер уртак сыйфаты бар: ул сыйфат — ат кебек җигелеп, төрле жанрларда эшләү. Багыгыз сез Такташка. Ул — шагыйрь, ул — драматург, ул — романчы. Бөтен эшен эшләп, тарихларда укып ятларлык әсәрләр калдырып, утыз яшендә китеп тә барган! Багыгыз сез Тинчуринга: ул — актер, режиссер, драматург һәм олуг хикәятче дә. Шул ук Тукай — чабышкый да, эш аты да. Егерме җиде яшендә биш томлык әсәрләрен калдырып китеп барган.

Әбрар Сәгыйди дә самай эшләр чакта, самай өлгергән чакта, каләменең иң шомарган вакытында вафат була. Ул күп төрле, күп кырлы талант иясе: шагыйрь, драматург, хикәяче, журналист. Ә төп эше — мөгаллимлек, балалар тәрбия кылу.

Бу чор кешеләренә карап, мин сокланам. Алар бер урында утыра алмаган, эшләргә, чабарга, халыкка ни дә булса калдырырга тырышканнар. Язмыш аларны аннан алып, монда куеп, куып йөреткән; алар мәҗбүрият, мөһимият коллары булганнар. Әбрар Сәгыйди дә шундый тиктормас җан булган. Бер карасаң, ул — мөгаллим. Аннан соң, 1918 елдан Революцион Хәрби Совет чакыруы буенча нәшриятта — редактор, «Эшче», «Татарстан хәбәрләре» гәзитләрендә актив язышучы журналист. 1921 елда Тәтеш кантонында «Татарстан» гәзитәсенең үз хәбәрчесе һәм гаҗәеп бер алмашынып: 1922—24 елларда Әбрар Сәгыйди Буа төбәгенең Килдураз авылында мулла булып эшли. Бу чорда Әбрар Сәгыйди Килдураз авылының идеологы, әхлакчысы, Коръән Кәримне халыкка аңлатучы имам-хатип. Нинди колач, нинди гайрәт, нинди эшкә атылганлык! Бүгенге язучыны берәр мәчеткә имам-хатип итеп куеп буламы? Бүгенге берәр шагыйрь Коръән Кәримне халыкка шәрехләп күрсәтә аламы? Дин суфыйлары белән аяк терәп бәхәсләшә аламы? Яки бүгенге динчеләребез, муллаларыбыз язучы-шагыйрь булып китәрлек дәрәҗәдә әдәбиятны, тарихны, философияне беләме? Әбрар Сәгыйдиләргә карап, сокланырга, көнләшергә, үрнәк алырга гына кала.

Муллалыктан Әбрар янә язу эшенә кайта. 1925—26 елларда Зөя Башкарма комитеты каршысында консультант һәм Татар телен гамәлгә ашыру буенча вәкил, күзәтче. Татар булмаган, татарча белмәгән кешеләргә татар телен өйрәнү шулкадәр югары сыйфатта, яхшы системага куелган була ки: бу курсларны тәмамлаган урыслар вә башка милләт вәкилләре татар телен, әдәбиятын, тарихын мөкәммәл белгәннәр. Бу олы, изге эшкә Әбрар Сәгыйди дә өлешен керткән.

Аннан соң янә мөгаллим буларак, Әбрар Сәгыйдине мәктәпләрдә күрәбез. Ул яңа буын тәрбия итә. Әбрар Сәгыйди мулла булып эшләгәндә дә, укытучы булганда да, язучы-шагыйрь, драматург сыйфатында булганда да бер генә максат белән эшли: татар балаларын, татар халкын саф намуслы, әхлаклы итеп тәрбияләү.

Әбрар Сәгыйди минем белән чагыштырганда бик яшьли үлә, ул нибары кырык дүрт ел яши, ләкин утыз пьеса, шигырьләр, поэмалар, хикәяләр, мәкаләләр калдырып китә.

Әбрар Сәгыйди Кайбыч төбәге Кече Комшан авылында Закир мулла гаиләсендә 1895 елда туган. 1913 елда иҗат юлын башлап, ул утыз ел каләмен ташламыйча эшли, ат кебек эшли! Әбрар Сәгыйди — ул эш аты. Сан саен, газит-журнал саен хикәяме, мәкаләме, шигырьме бастыра килә. Ду килеп пьесалар яза. Мәктәпкә чаба, кантон, комитет йомышларын башкара. Нинди куәт, нинди гайрәт, нинди үзмаксат кешедә!

Бернәрсә дә язмыйча, бары тик мөгаллим, бары тик мулла, бары тик Татар телен гамәлгә ашыру белән генә шөгыльләнгән булса да, без бүген Әбрар Сәгыйдине «татар халкының олуг улларының берсе», диеп искә алган булыр идек, аның рухына дога кылган булыр идек. Ләкин ул — шагыйрь. Укытучы, мулла булмыйча, шагыйрь булып үлсә дә, без аны олылар идек. Башка бер эш майтармыйча, бары тик утыз пьеса язган драматург буларак та без аның хатирәсен хөрмәтләр идек. Әбрар Сәгыйдигә мәдехләр укыган булыр идек.

Кызганыч, 1935 елда ул кичектергесез, мөһим эш белән, кышкы зәмһәрир суыкта, ил чакыруы, вөҗдан кушуы буенча утыз чакырымлык ыстансага җәйге аяк киеме белән чыгып китә һәм шунда үпкәсенә китмәс чир ала. 1939 елда шул сәбәпле гүр иясе була. Авыр туфрагы җиңел булсын, урыны Җәннәттән әйләсен!

Әдәбият тарихы шундый катлаулы язмышларны хәтерли. Ике тапкыр яшәгән шагыйрьләр бар. Шул ук Такташ — икәү. 1923 елга кадәр иҗат иткән гайрәтле, гыйсьянчы шагыйрь һәм соңыннан совет йомыркаларын мактап, мулла кыйнау белән кәпрәеп яшәүче Такташ бар. Сугышка кадәр шигырьләр язган Җәлил бар, Моабит төрмәсендә иҗат иткән шагыйрь бар. Җир белән күк аермасы! Шул ук Туфан да — икәү. Төрмәгә кадәрге бунтарь Туфан, ирекка чыккан сагышлы Туфан бар. Әгәр дә бу шагыйрьләр икенче чорларында иҗат итә алмаган булсалар, һәлак булсалар да, алар татар әдәбиятының түрендә булырлар иде. Ләкин икенче чор иҗатлары аларны — Туфанны, Җәлилне, Арсланны — бөек шагыйрьләр рәтенә куя. Беренче чор тәҗрибә туплау, осталык яулау, акыл, зиһният уяту вакыты. Ә алда чын-саф нәфисәи сәнгать юлы.

Әбрар Сәгыйди дә нәкъ менә шул, икенче чор иҗатының ишеге төбендә егылып җан бирә. Тәҗрибәсе бар, осталыгы җитәрлек, акылы уяу. Алга таба шаһәсәрләр язасы вакытта гына — ул иҗат итүдән өзелә. Кызганыч! Бу сәләтле, ат кебек җигелеп эшләүче шәхес алда әллә нинди матур әсәрләр язып, әдәбиятыбызны сөендергән булыр иде.

Әбрар Сәгыйдинең мирасы әле өйрәнелмәгән. Бүген сүзем аның иҗатына анализ ясаудан гыйбарәт түгел, чөнки мин аның иҗатын нык белмим әле. Әмма Әбрар Сәгыйдинең улы, Казан педагогия университеты укытучысы, галим Марат әфәнде атасының мирасын кадерләп саклаган һәм бер системада аның библиографиясен, әсәрләренең жанрлар буенча исемлеген төзегән, аның тәрҗемәи хәле турындагы материалларны барлаган. Әйтергә кирәк: атасы кебек, Марат әфәнде дә ат кебек эшләгән. Күпкырлы бу язучының иҗатын тәртипкә салу ул университетларда курс һәм диплом эшләреннән алып, диссертациягә кадәр башкарыла торган хезмәт.

Марат әфәнде эшләгән системалы бу исемлек әле безгә бары тик Әбрар Сәгыйди кебек уникаль шәхеснең ни дәрәҗәдә эшчән һәм күпкырлы булуы турында гына сөйли. Бу утыз пьеса арасынданиләр бар — кем дә белми. Безне могҗизалы ачышлар көтә булыр. Мине Сәгыйдинең драматургиясе тарта. Бу әсәрләрнең исемлеген генә укып чыкканда да театр кешесенең күңеле кымырҗып куя. Багыгыз: «Сәхра кызы», «Сак — Сок», «Фәрһад — Ширин», «Кызыл тау»... Нәрсәләр бар, нинди фаҗигалар ята бу әсәрләр эчендә — әлегә безгә нә-

мәгълүмдер, чөнки алар барысы да гарәп хәрефләре белән, авторның үз кулы белән язылган һәм тануы шактый кыен кулъязма хәлендәләр.

«Сәхра кызы», «Кызыл тау» әсәрләре сәхнәдә куелган һәм шул пьесалар белән атаклы Мохтар Мутин кызыксынган, сәхнәләштергән. Мохтар Мутин кебек кырыс, тәнкыйди карашлы шәхес алынган икән, димәк, әсәрләр бүген дә игътибарга лаектыр, мөгаен. «Сак — Сок», «Фәрһад — Ширин» пьесалары искерә торган темага язылмаганнар. Иншаллаһ, без бу әсәрләрне укырбыз, сәхнәдә дә күрербез әле.

1540 елда Мөхәммәдьяр әйткән: Казан тулы бар да шагыйрь, кечек, олуг, дигән. Ягъни шагыйрьләр кайнап торган Казанда шагыйрь исемен яулау шактый авыр эш. Тукайлар заманында да Казан шагыйрьләре белән шаулап торган. Бүген дә ул шулай. Тукай заманасында шагыйрь Әбрар Сәгыйдигә дә ул исемгә лаек булу җиңел булмагандыр.

...Бер мәлне — туганнары, якыннары белән урман юлыннан барганда Әбрар Сәгыйди кинәт кенә икенче дөньяга кереп киткәндәй була, дәшми. Баксаң, урман хозурлыгы, урман кырындагы басу өстендә талпынучы тургайлар, агачлардагы сайрар кошлар аның фантазиясен уяткан икән, аңа илһам килгән, ул шигырь яза башлаган. Үзенә эндәшкәч, ул:

— Илһам дигән нәрсә ул килмичә йөдәтә, бер килсә һич ычкындырмый,— дип җаваплана.

— Ни алып килгән соң бу юлы Илһам?— дигәнгә каршы Әбрар Сәгыйди шигырь сөйли башлый:

Уһ, ирек нинди бу таңда, сайрый кошлар чут та чут,
Һәр тараф нинди матур, кайгы вә михнәт һич тә юк.

Һәр тарафны нурга манчый, уһ, бу таң нинди матур.
Саф һава, уһ! Дөньяның бу вакыты Җәннәттән матур.

Зур матур кырлар, болыннар таңга саф сулышын сулый.
Зур сулар, күлләргә энҗедәй сибелгән таң нуры.

Әллә кайларда матур, моңлы авазлар ишетелә.
Күктә өзлеп сайрый тургай, моң җырын җиргә сибә.

Шагыйрь Әбрар Сәгыйди күбесенчә ике калыпта шигырьләр иҗат иткән. Унбишкә — унбиш иҗекле һәм сигез — җиде традицион шигырь шәкелен кулай күргән. Әйтик, Тукайда да бу калыплар еш очрый: «Шүрәле», «Су анасы» шигырьләре дә унбиш-унбиш калыбында язылган.

Менә тагын шул калыптагы бер шигырь. «Күкрәгем» исемле әсәре. 1919 елда язылган.

Күкрәгем дошманга каршы инде киерелде минем,
Алгы көннәрем минем тәнсез, матур, ак, төз юлым.

Миндә көч зур, мин арыслан, күкрәтәм мин күкләрен,
Көл итәр, бетерер ләгыйннәр көчләрен нык күкрәгем.

Күпме издем мин бу күкрәк берлә ләгыйньнәр көчен.
Күпме пакьләдем явызлардан кызыл, саф ил эчен.

«Игенче авызыннан» дигән әсәреннән менә бу дүрт юл диварларга шәмаил итеп эләрлек нәфис вә мәгънәле язылган.

Кырда гөлгә чорналып үскән
игеннәр таҗ миңа.
Сандугачлар тавышы
мәңгелек югалмас саз миңа.

Әбрар Сәгыйдинең лирикасы белән рәттән шигъри өндәмәләре, шигъри гыйбарә-тәгъбирләре дә игътибарны үзенә тарта.

Минем бүгенге вазифам әдәбият белгечләренә, тәнкыйтьчеләргә, татар теле һәм әдәбияты, тарих бүлекләрендә укучыларга болай дип әйтү:

— Булган, яшәгән шундый киң колачлы бер шәхес — Әбрар Сәгыйди. Аның мирасын өйрәнергә, ачарга һәм халыкка кайтарырга кирәк!

Рабит БАТУЛЛА.

Альбина Саяпова

# «КЕМГӘ ТАНСЫК БУ ЗАМАНА?»

(ДӘРДЕМӘНД ИҖАТЫНДА СИМВОЛИЗМ)

Егерменче гасыр башы, Н. Бердяев билгеләмәсе буенча, «мәдәни ренессанс» заманы — «төшенкелек чорын кичергән шигърият һәм фәлсәфәнең тернәкләнә, күтәрелә башлавы» белән үзенчәлекле. Бер үк вакытта философ күп кенә фикер ияләренең, сәнгать әһелләренең якынлашып килүче тетрәнүләрне тоемлавын билгеләп үтә:«Шагыйрьләр туачак таңнарны гына түгел, Русия һәм дөнья өстенә ябырылырга торучы дәһшәтләрне дә алдан күрделәр».[1]

Мәдәни яңарыш, шигърият һәм фәлсәфә өлкәсендәге күтәрелеш, туачак таңнарны һәм тетрәнүләрне тоемлау — XX гасыр башында Русиядәге рухи тормышның сыйфатлары менә шушы сүзләрнең эчтәлегендә гәүдәләнә. Н. Бердяев «туачак таңнарны һәм ябырылырга торучы дәһшәтләрне тоемлаучы шагыйрьләр» турында сөйләгәндә, А. Блок белән А. Белыйны күздә тоткан булса, шушы ук исемлеккә гасыр башында балкыган татар шагыйрьләре С. Рәмиев белән Дәрдемәндне дә өстәргә мөмкин. Нәфислекне үтә нечкә тоемлау хисе һәм дөньядагы тарихи вакыйгаларны фәлсәфи югарылыкта аңлату аларга якындагы уңъеллыкларда ниләр буласын фаразларга, алай гына да түгел, бөтен бер гасырның образлы сурәтен тудырырга мөмкинлек бирде. Дәрдемәнд иҗатында милләтнең тирән һәм үзенчәлекле фәлсәфи уй-фикерләре аеруча ачык чагылыш тапты.

XX гасыр сәнгате — үтәдән-үтә символик эчтәлекле яңа сәнгать. Рус әдәбиятында бу хакта беренче булып сүз әйтүче, мөгаен, А. Белый булгандыр. Гасыр сүзенең эчтәлеге турында фикер йөртеп, ул үзенең аңлау-тоемлавы нигезендә, символның иң әүвәл фәлсәфи (символның мәгънәсен ачып бирү — фикерләү эше) һәм бары тик шуннан соң гына эстетик, әдәби категория булуы турында әйтә. Европа галиме П. Рикер үзенең «Существование и герменевтика» дигән хезмәтендә: «фәлсәфә — ул герменевтика, ягъни туры мәгънә артына яшеренгән мәгънәне табу», дип раслый. Аның фикеренчә, символлар герменевтиканың төп өлешен тәшкил итә, чөнки символлар кулланганда туры, төп мәгънәне читләтеп әйтелгән икенче мәгънә аша гына җиткереп була.[2] Шулай итеп, ике мәгънәле гыйбарәләр тезмәсе — герменевтиканың асылын тәшкил итә. П. Рикер кебек үк, А. Белый да әдәби әсәрнең эчтәлеген ачуда символик образларның әһәмиятле нәрсә булуын дөрес аңлаган. Образлар куллануда алар (символистлар) Гогольдән, Дантедан, Пушкиннан, Гетедан кыйммәтлерәк өлеш кертә алмадылар, дип билгеләп үтә ул, әмма алар «сәнгатьнең үтәли символик булуын... эстетиканың бердән-бер таяну ноктасы символизм икәнлеген ахыргача аңладылар, ди. Шушылардан чыгып, ул калган яклар әһәмиятле түгел дигән нәтиҗә ясый. Ә бит әдәби әсәрләргә бәя биргәндә нәкъ менә «калган яклар» төп критерий булып саналды.[3]

Белый аңлавынча, символизм сәнгать юнәлеше, әдәби мәктәп кенә түгел, ул аны дөньяны аңлау, фикерләү рәвеше буларак кабул итә. Яңа сәнгать — үзенең символларының эчтәлеге белән дөньяга караш чагылдыручы сәнгать ул. Безнең фикеребезчә, ул — яшәеш фәлсәфәсе белән сугарылган, ягъни экзистенциаль сәнгать. «Кешелекнең яшәеше һәм үлеме турындагы мәсьәләне бөтен аяусызлык белән кузгатканда һәм аны яшәеш белән бәйле омтылышларыбызның үзәгенә куйганда, яшәү яки үлем ихтималына өздереп «әйе» дигәндә генә — бары тик шул чагында гына без яңа сәнгатьне хәрәкәткә китергән нәрсәгә якынаябыз: аның символларының эчтәлеге — яки яңарган кешелекнең үлемне тәмам җиңүе, яки төпсез караңгылык, таркалу, үлем,»[4] — дип яза А. Белый.

Дөньяны, акылга нигезләнеп түгел, ә символик ысул белән танып-белү Шопенгауэрдан башлана. Шопенгауэрда — «философиянең бетүенең башы». Аның төшенкелек фәлсәфәсеннән, яшәешнең барлык дәһшәтләрен ачыктан-ачык тануы аркылы яшәешнең өрфиялеген ачуы аша дөньяга экзистенциаль караш, төсмерләнә башлый. Ә бу сыйфат исә символизмга хас.[5] Символизм күренешнең ике ягын да күрергә мөмкинлек тудыра. Алай гына да түгел: аның яшерен мәгънәсен аңларга, моны күреп, кешене тетрәнергә мәҗбүр итә.

Чынбарлыкны экзистенциаль тоемлауның нигезе буларак, төшенкелек XX гасыр башының күренекле шагыйре булган Дәрдемәндкә дә хас. Ул — яшәешнең һәм үзенең бөек фаҗигасен аңлап, шуңа хәйран булып, сагышлы, хәсрәтле уйларга бирелгән шәхесләрнең берсе. Шагыйрьнең «Куанды ил, канат какты мәләкләр» дип башланып киткән шигъри юллары моны ачык раслый:

Куанды ил, канат какты мәләкләр,
Шашып, аң-таң булып шайтан тәкерде!..
Җитәр, җилкенмә, йолкынма, күнел син,
Кияү булсаң да, ул туйга түгел син!
Җиһан тормыш туен иткән чагында,
Синең урының — үлекләр аймагында.

Биредә Дәрдемәнд яшәеш чоңгыллары һәм «ике төрле чынбарлык яшәеш» бусагасында калган үз «мин»е турында символлар теле белән сөйли.

Төп мәгънәсе белән һәрбер символик образ дөньяны экзистенциаль аңлауга кайтып кала. А. Белый әйткәнчә, символның эчтәлеге — ул «яшәеш яки юкка чыгу кичерешләренең тулылыгы; кешелек язмышы тәкъдир сызыгында торганны төшенү һәрбер сәнгатькәр-символист өчен төп шарт булып тора...»[6]

Семантик яктан символ шулай корылган ки, ул «мәгънәне мәгънә аша тасвирлый: аңарда беренчел, асыл, еш кына очракта физик мәгънә, кинаяле, рухи, еш очракта экзистенциаль, онтологик мәгънәгә кайтып кала». Символда мәгънә ачып бирү мөһим. Символ һәрчак уйланырга мәҗбүр итә, мәгънәне ачып бирүне таләп итә.[7]

Дәрдемәнднең югарыда китерелгән шигырендә без тәкъдир котылгысызлыгы алдында торган кешелекнең тавышын ишеткәндәй булабыз. А. Белый билгеләп үткәнчә, «сәнгатькәр — яки яшәү, яки үлем хәбәрчесе: берсендә ул үлемне, икенчесендә — яшәүне күрә. Берсендә — яшәешне, икенчесендә — үлемне беткәнче сурәтләп, ул символ тудыра».[8] Яшәешне бөтен тулылыгында аңлап та, янәшәдә үлем барлыгын сизгер күңеле белән беткәнче төшенгән шагыйрь, үзенең дә бетәсен белеп, вакыт, заман фанилыгы турында яза. Дәрдемәнднең тулы канлы тормыш шавын тасвирлавы артында («куанды ил, канат какты мәләкләр...», «җиһан тормыш туен иткән чагында...») кинәт ачы хакыйкать авазы ишетелә: яшәеш өрфиясе артында кара чоңгыл ачыла — анда «үлекләр аймагы» икән.

Шигырьдәге төп образ — таң образы — ул символ. Тормыш белән үлем һәм яшәеш белән Юклык арасындагы чик сызыгы нәкъ менә шушы образ аша үтә. Мәгълүм ки, гасыр башында иҗат иткән С. Рәмиев шигъриятендә таң образы — гүзәл киләчәк, өмет һәм матурлык символы буларак кулланылган.

Таң — уяну, тормыш башлану вакыты. С. Рәмиевтә таң образы милләтнең яңа тормыш башлавы булып гәүдәләнә. Дәрдемәнд исә бу образның күнегелгән мифологик эчтәлеген җимерә. Ул таң образын яңа эпитетлар белән төрләндерә: «Шашып, аң-таң булып шайтан тәкерде!» Дәрдемәнд сурәтләгән таң — яңа тормыш хәбәрчесе түгел, ә бөтен нәрсәне көйдерүче-яндыручы, җиһанга, галәмгә шашынулы сый-туй бүләк итүче «шайтан тәкереге». Таң образын Дәрдемәнд экзистенциаль хиссият кысаларына кертеп сурәтли.

Шулай итеп, борынгы мифологик образны бер үк чорда яшәгән ике шагыйрь ике төрле аңлый һәм чагылдыра. Рәмиевтә таң — якты киләчәккә ышану символы. Дәрдемәндә — бетү, гарасат якынаюын күрсәтүче символ. Менә шуңа күрә дә Дәрдемәнднең эчке «мин»е бу дөньяга ят итеп карый, ул гомумән яшәешнең түгел, ә шәхсән үзенең, үз гомеренең чикләнгән булуын аңлап-тоеп, шуның нәтиҗәсендә «шайтан туен» кабул итә алмавын белдерә.

Дәрдемәнднең «Куанды ил...»гә кадәр үк, 1906 елда язылган дүртьюллык «Замана» дигән шигыре бар. Менә ул:

Нә алтын белгә балчык бу замана,
Белалмыйм: кемгә тансык бу замана?
Уенчак, яшь идем яшьлек кенемдә,
Бүген — карт белгә карчык бу замана!

Шигырьне йөгереп кенә укып чыкканда, тормышка аек-материалистик һәм салкынча-битараф караш сизелә, гүя автор бу юлларны читтән торып кына язган. Әмма җентекләбрәк укый башласаң, төптә, тирәндә яткан фикергә төшенәсең. Шагыйрь тормыш турында бернинди риясыз, ничек бар, шулай әйтеп биргән. Шунда Гомәр Хәйямнар, Шопенгауэрлар хәтергә килә. Дәрдемәнд кешелек тормышына, яшәешенә, аның теге ягына ничек тирән төшеп карый алган!

Дәрдемәнд иҗатын өйрәнүчеләр (Г. Ибрагимов, Ф. Кәрими, Г. Халит, С. Хәким, Н. Хисамов) аның шигырьләренең көчен фәлсәфи гомумиләштерүдә, тирәнлектә, төгәллектә, сайланган сүзләренең алыштыргысыз булуында дип билгеләп үтәләр. Без караган дүртьюллыклар да — афоризмга тартым, ә бу инде фикер һәм форманың чарланганлыгы турында сөйли.

Дәрдемәнд шигырьләренең үткенлеге — аның символлар телен куллануы белән дә аңлатыла. «Алтын — балчык», «карт — карчык»,— болар төп образлар — шагыйрьнең уй-фикере, символлары. Бу символларга нәрсә хас? Символ ул — структура, аңарда беренчел туры мәгънә бер үк вакытта бүтән, икенчел, читләтеп әйтелгән мәгънәне белдерә. Ләкин ул бары тик беренчел мәгънә аркылы гына булырга мөмкин,[9] — дигән фикере белән П. Рикер бик хаклы. Ә ул беренчел мәгънә шуннан гыйбарәт: безнең яшәешебезнең башыннан ук «фикер» дигән сүзнең мәгънәсе «миф» дигән сүзнең мәгънәсенә туры килә. Искә төшерик: «мысль» дигән рус сүзе мәгънәсе «миф» дигән грек сүзенә тигез. Фикер мифтан башлана.

Дәрдемәндәге символлар («алтын — балчык», «карт — карчык») бер үк вакытта образлар-мифологемалар да булып киләләр. Монда миф — сәнгатьчә сурәтләү — мифологик хронотопка таянып, дөнья моделен тудыра. Шулай итеп, Дәрдемәнд иҗатына яңа мифологик система хас. Символларның фәлсәфи-экзистенциаль караш аша мәгънәләрен тирәнәйтү Дәрдемәндкә формаль булмаган, гадәттән тыш мифлар кулланырга мөмкинлек бирә.

Дәрдемәнд пессимизмы — ул космик пессимизм — галәм масштабындагы төшенкелек. Аның иҗаты фани дөнья фаҗигасын аңлау белән сугарылган. Ул бүтәннәр күрә алмаганны, юклыкны күрә алды. Дәрдемәнд — бу дөньяда гамәлдәге мөмкинлекләргә таянып кына исбатлап булмаслык нәрсәләр барлыгын аңлауга күтәрелгән шәхесләрнең берсе.

Дәрдемәнднең экзистенциаль Юклыкны күрүендә, безнеңчә, суфи-мистик карашлардан килгән нәрсәләр бар кебек. Билгеле ки, суфичылык тәгълиматы, антропологик тәгълимат буларак, кешене галәм үзәге һәм бөтен яшәешнең көче дип санаган. Хакыйкатьне аңлау югарылыгына акыл ияләре генә күтәрелә алган. Суфичылык тәгълиматы дөньяны аңлауны рациональ юлга салган, әмма ләкин ул Алланы һәм шулай ук Хаклыкны, Чынлыкны аңлаганда бу юл белән барып булмаганлыкны исбатлый. Хакыйкатьне Чынлыкны аңлау юлы кешенең йөрәге аша үтә. Бу кешенең эчке казанышы, эчке яктыруы буларак кабул ителә. Мондый эчке тәҗрибәгә кеше экстаз хәлендә барлыкка килгән интуиция аша гына ирешә ала. Суфилар: «экстаз белән сугарылган хәлне аңлатып булмый, ләкин ул хәлне башка кеше йөрәгендә җавап хисе буларак тудырырга мөмкин», диләр. Дәрдемәнд күргән Юклык безне дә тетрәндергеч котылгысызлык хисләренә дучар итә. Шуны шәйләп була: суфилар аңлаган экстаз халәте тәҗрибә тышында булган (трансцендент) хәлгә якын. Ә ул тәҗрибә тышында булган халәт — дөньяны экзистенциаль тоемлау-аңлауның чагылышы.

Шагыйрь турында шагыйрьдән дә яхшырак итеп кем әйтә ала? Моңа Сибгат Хәкимнең: «Дәрдемәнд искән җилләргә колак куеп яза»,[10] дигән сүзләре дәлил булып тора. «Җил тавышы», символик образ буларак, шагыйрьнең бөтен лирикасы аша үтә, ул Дәрдемәнднең дөньяны аңлау концепциясенә төшенүгә ачкыч булып тора. Символик җил үзе белән шактый катлаулы мәгънәви йөк алып килә: бер яктан, бу — планета тормышын хәрәкәттә, чиксезлектә һәм мәңгелектә күрсәтү булса (Мәсәлән «Үлән өстенә сузылып яттым...» парчасы), икенче яктан, җирдә кеше гомеренең чикләнгәнлегенә һәм фанилыгына ишарә («Кораб», «Без»). Шунысын да билгеләп үтү гыйбрәтле: җил образы Билгесезлеккә, Юклыкка хәрәкәт итү символы да булып аңлашыла. Мисал өчен, «Без» шигыре башыннан ахырына кадәр тиз агышлы дөньяның үзгәреп торуы, фанилыгы, бөтен нәрсәнең Билгесезлеккә китеп, юкка чыгуы турындагы фикер белән сугарылган:

Исә җилләр, күчә комлар... бетә эз...
Дәрийгъ*, мәхзүн** күңел, без дә бетәбез!

---

* Дәрийгъ (дәригъ) — үкенеч
** Мәхзүн — аянычлы, кайгылы

Бу шигырьдәге икенче бер символик образ — «без» — шулай ук авторның фәлсәфи кыйбласының нигез ташын тәшкил итә. Әлеге образның герменевтикасы түбәндәге экзистенциаль гыйбарәгә кайтып кала: фани дөньяда без — тузан бөртеге, вакыт безнең өметләребезне дә, безнең үзебезне дә келгә әверелдерәчәк:

Өеп чергән өмидне... төртте утны—
Йотып утларны китте... яна-яна...

Шунысын да әйтү урынлы булыр: экзистециаль төсмер Дәрдемәнднең социаль проблемалар контекстында үз урынын билгеләүче лирик героена да хас:

Зәгыйфь кырмыскамын мин юлда яткан,
Түгел бал корты мин — чагып елаткан.
Ни зур дәүләт, кем, шөкер итәм чук,—
Минем беркемгә җәбер көчем юк.

Һәм тагын. Әгәр «Без» шигырендә җил образын Юклыкка хәрәкәт итү, бөтен нәрсәнең шушы Юклык белән тәмамлануы символы булса, «Исәрме җил тугай буйлап» шигырендә эчке тынычлану һәм канәгатьләнү чагылышы буларак тоелган шул ук образ, асылда Юклык алдында кешелек өчен яшәү һәм яшәмәү кебек мәңгелек табышмак алдында катып калу, өнсез калу халәтен күрсәтә:

Исәрме җил тугай буйлап,
Җырлармы кыз моңын сөйләп,
Күләрме шатланып, көйләп,—
Агач, таш эчләре шаңрап,
Киләдер бер нида* яңырап!...

Символик җил образы Дәрдемәнд лирикасында яшәешкә мөнәсәбәттә Юклыкны күрү-күрсәтү мәгънәсендә генә түгел, ә бәлки якты сагыш чагылышы буларак та күренә:

**Күләнкәдә буй аткан талчыбыкларны — ярымның зифа буенча, агым суларның гөрләүләрен моңлы көенә бицзәтә идем; көрпә чәчәкләрнең күркәм килешен матуркаемның матур килешенә охшата идем.**

Бу — ниндидер бөек шатлык һәм тирән сагыш хисләренең берьюлы, бер булып чагылуы; һәм тегесенә, һәм монысына нисбәттә сызлану-сагыш уята торган хисләр:

**Агым суларның гөрләп агышында гизле сагышлар бары, җиләс җил белән шаулап тибрәнгән агачларның моңлы зары күңлемә әсәр итте. («Җылы һава тынык...»).**

Дәрдемәнднең проза белән язылган «Үлән өстендә сузылып яттым» әсәрендә җил образы тагын тирән мәгънә салынган символик төс ала: биредә вакыт — яшәешнең, яшәеш агышының төп факторы булып, шулай ук чорларны берберсенә бәйләүче булып гәүдәләнә:

**Бу искән җилләрдә кичкән елларның моңлы агышы белевә, үткән гомерләрнең хәсрәтле сагышы тоела иде. Алда киләчәк адәмнәрнең тупалашып баскан аяк тавышлары ишетелгәндәй була иде.**

Шушы ук символик образ ярдәмендә шагыйрь якты сагыш хисе, каядыр хәрәкәт итүче яшәешнең мәңге аңлап булмаслык серенә колак салганда барлыкка килгән әсәрләнү хисе тудыра.

Милли үзаңда җил образының элек-электән килгән мифологик, фәлсәфи мәгънәсе бар. Дәрдемәнд шушы милли карашка таянып, үз мифологемасын тудыра: җил — үткән чорлар, бүгенге көннәр, киләчәк заманнарны вакыт кысасында берләштерүче экзистенциаль символ.

## Искәрмәләр


1. Бердяев Н. А. Самопознание.— М., 1991.—164 б.
2. Рикер П. Существование и герменевтика // Феномен человека.— М., 1993.—324 б.
3. Белый А. Символизм как миропонимание.— М., 1994.—340 б.
4. Шунда ук.—256 б.
5. Шунда ук.—244 б.
6. Шунда ук.—258 б.
7. Рикер П. Существование и герменевтика.—327 б.
8. Белый А. Символизм как миропонимание.—256 б.
9. Рикер П. Существование и герменевтика.—315 б.
10. Хәким С. Шагыйрьнең осталыгы // Дәрдемәнд. Исә җилләр.— Казан. 1980.—7 б.


* Нида — зар-ыңгырашу

# КАРГЫШЛЫ ЕЛЛАР...

(БЕР КИТАП БАСЫЛЫП ЧЫГУ УҢАЕННАН УЙЛАНУ)




...1974 елда язучы Рәфкать Кәраминең «Капитан Хәкимов» дигән повесте аерым китап булып басылып чыккан иде. Ул вакытта үземнең дә офицер киеме киеп Ерак Көнчыгышта хезмәт итеп яткан чагым, шуңа күрә ялга диеп Казанга кайткач, кибеттә күрү белән сатып алдым мин бу китапны. Белми-күрми дигәндәй генә алсам да, күңелем дөрес сизенгән икән: ул миңа бик күп яктан якын китап булып чыкты. Хәтта андагы вакыйгалар сурәтләнгән урын да мин армиядә хезмәт итеп яткан җирдән ерак түгел иде. Капитан Хәкимов белән без фәкыйрегез лейтенант Вәлиевне бары тик Татар бугазы гына аерып тора иде! Ягъни, язучы үзенең әлеге повестенда Сахалин утравында хезмәт итеп ятучы татар офицерының тормышын сурәтли.

Менә хәзер, ул китапны укыганнан соң инде 22 ел гомер үткәч, яңадан искә төшереп, хәтерне яңартып карыйм. Совет офицеры тормышын күрсәткән әлеге повестьның эчтәлеге ни дәрәҗәдә «искерде» икән? Ул үзенең кызыклыгын, актуальлеген күпмегә югалтты икән? Әле бит язучы үзенең бу китабын ул чакта бик тә модадагы социаль заказ буенча да язган булырга мөмкин! «Армия тормышыннан әдәби әсәрләр бик аз» дип Татарстан китап нәшрияты әдипләргә заказларны биргәләде бит — бер дә сер түгел.

Әсәрдәге бөтен каһарманнарны, вакыйгаларны кабат-кабат искә төшергәннән соң (ә алар минем хәтергә бик яхшы уелып калган, чөнки повестьны ашыкмыйча, тәмләп, хәтта берничә мәртәбә дә укып чыккан идем бугай әле — мәкалә язарга да бик исәбем бар иде дә, вакыт тимәү аркасында гына бу ниятем чынга ашмый калды) менә хәзер нык ышанып шуны әйтә алам: «Капитан Хәкимов»ны бүгенге укучы да яратып кабул итәчәк. Ни өчен? дигәндә җавап бер булыр: чөнки бу әсәр кеше турында! Анда чын кешеләр яши, реаль вакыйгалар һәм конфликтлар күрсәтелә. Хәтта Ерак Көнчыгышның ул чагында без яшәгән искиткеч табигате: юлбарыслар йөри, йөземнәр, карбызлар үсә торган табигате дә бик матур итеп һәм шактый тулы тасвирлана ул повестьта. Укучы үзе барып күргәндәй була.

Казанга кайтып яши башлагач тагын шуны да белдем: язучы Рәфкать Кәрами иҗаты турында матбугатта шактый әйбәт кенә фикерләр дә әйтелгәләгән икән. Бигрәк тә Фәрваз Миңнуллинның «Кичке уйлар» дигән мәкаләсе (Р. Кәраминең шул исемдәге китабы турында) һәм Барлас Камалов язмалары истә калган. Әлбәттә, Ерак Көнчыгышта ук күңелдә туган кызыксыну белән Р. Кәраминең ул вакытка хәтле чыккан башка китапларын да табып укыдым. «Дүрт кешелек каюта»ны, «Кичке уйлар»ны... Боларны укып чыккач язучы турындагы фикерләрем тагын да тулыланды, тәэсирләр дә тагын да яхшырды.

«Социаль заказ» дигән нәрсә турында сүз кузгатып алган идек, менә шуңа яңадан әйләнеп кайтмыйча булмый әле. Эш шунда: Рәфкать Кәрами җитмешенче еллар ахырында, сиксәненче еллар башында «Очар кошлар белән янәшә» исемле трилогия бастырды. Язучылар берлешмәсендә бу әсәр хакында: «химкомбинат коручы төзелеш оешмаларының берсе турында сүз бара» диелә.

Әйе, 1978 елда «Казан утлары» журналында басылгач ул трилогиянең беренче кисәген мин дә укыган идем. Дөресен әйтим: һич кенә дә яхшы тәэсир калмаган иде! Чөнки анда үзенчәлекле каһарманнар да, зур вакыйгалар да, мөһим проблемалар да юк иде. Соң уйлап кына карыйк инде. Михаил Шолохов казак егете Мелеховның революция чорындагы олы трагедиясен язды... Алексей Толстой урыс зыялылары фаҗигасен күрсәтеп «Михнәтле заман» трилогиясен тудырды... Аларда зур вакыйгалар, олы каршылыклар, сыйныфлар, социаль агымнар, көчле шәхесләр бәрелеше! Ә безнең язучыбыз исә... химкомбинат тормышыннан алып трилогия иҗат итмәкче! Менә бу очракта инде без «социаль заказ» дигән нәрсәнең чын асылы белән очраштык. Бу инде, үзебезчә тупас итеп әйтмәсәк тә, китапча әйткәндә — бармактан суыру! Билгеле, Рәфкать Кәраминең бу җимгә эләгүе дә гаҗәп түгел. Ул озак еллар буе төзелеш оешмаларында эшләгән, аны бик яхшы белә.

Бу күренеш хәзер безгә нәрсә турында сөйли? Минемчә, ул шул хакта искәртә: шәхес буларак, гражданин буларак язучының буыны ныгып җитмәгән булса — аның сәләте вакыт-вакыт ялгышрак тыкрыкларга да кереп китәргә мөмкин икән. «Эшче темасы» дигән нәрсәнең торгынлык чорында безнең татар әдәбиятында гаять киң таралуын бары тик әнә шуның белән генә аңлатырга була. Ә бит Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах, Салих Баттал бу «җим»гә алданмады. Чөнки шәхес һәм гражданин буларак буыннары нык иде аларның!

Тагын кызык: торгынлык елларында шул ук Рәфкать Кәраминең «Сагышлы кояш» дигән бик уңышлы, чын әдәби әсәре дә басылып чыкты! Аның бу китабын без сокланып укыдык, сәләте өчен сөендек. «Аттан ала да туа, кола да туа», дигән сүз шушы була микәнни инде? — дип эчтән уйландык та...

Менә илдә үзгәртеп кору еллары башланды. Исеме мәгълүм байтак кына әдипләрнең иҗаты тукталып, сөрлегеп калды. Ләкин ул чакта «Кичке уйлар», «Дүрт кешелек каюта», «Сагышлы кояш» сыман кызыклы һәм мәгънәле китаплар чыгарган язучы Рәфкать Кәрами өчен тынлык, тукталыш булырга тиеш түгел сыман иде. Әмма соңгы ун елда аның иҗаты да шактый гына салмакланды кебек тәэсир кала. Дөрес матбугатта аның хикәяләре күренгәләде. Мисал өчен, 1995 елда «Казан утлары»ның 11 санында басылган «Авылдаш» исемле нечкә психологик хикәясен әйтергә мөмкин. Шулай ук Рәфкать әфәнде матбугат битләрендә милләтебез һәм аның мәдәнияте мәнфагатен кайгыртып мөһим эчтәлекле мәкаләләр бастырды. Авылларда күп йөрүче әдип буларак ул инде, әлбәттә, халыкның ничек сулаганын бик яхшы белә.

Шулай итеп, «үзгәртеп кору башлангач Рәфкать Кәрами дә әдәби иҗатта сүрелә төште» диеп йөри идек, «Казан утлары» журналы үзенең 1992 елгы 1 һәм 2 саннарында аның «Каргышлы юллар» исемле романын урнаштырды. Ә әсәр ахырында исә язылу вакыты итеп 1989 ел күрсәтелгән. Тукта әле, бу зур гына күләмле роман өчен кирәкле бик күп материал туплауны һәм аны озаклап, җентекләп иҗат итүне дә уйласаң — әдип һич тә тукталып тормаган булып чыга түгелме соң?! Шулайдыр: Сарман ягында туып, бала чактан ук авыл, крестиян тәрбиясен үзенә сеңдереп үскән егет биредә дә авыл кешесенең әйбәт холкына тугры булып калгандыр — гомерен бушка, әрәмгә уздырмагандыр. 1989 елда язылып беткән роман әнә шуңа бер саллы дәлил. Үткән елны исә бу роман Татарстан китап нәшриятында 6 мең генә тираж белән булса да (шушындый кызыклы һәм тәрбияви әһәмияткә ия әсәр өчен бу бик тә аз тираж билгеле) аерым китап булып басылып чыкты.

Бу әсәр язучының үзе өчен дә һәм шулай ук безнең бүгенге прозага да хас булган мөһим генә сыйфатларны чагылдыра. Шуңа күрә, әйдәгез, кечкенә пыяла савытка салып диңгез суын тикшергән сыман — шушы бер роман аша үзебезнең бүгенге әдәбиятны, һәм анда уңышлы гына иҗат итеп килүче бер әдибебез дөньясын аңларга тырышыйк.

Әсәрнең эчтәлеген кыскача гына әйтеп бирергә уйласак, Сталинның шәхес культы елларында бер гаепсезгә төрмәгә утыртылган намуслы кешеләр турында, диярбез. Әйе, мондый әсәрләр бездә булды. Ибраһим Салаховның «Тайгак кичү»е, Гурий Тавлинның «Афәт»е... Аяз Гыйләҗев истәлекләре... Болар — үзләре Сталин төрмәсен «татыган» кешеләр. Аларның язганы да документаль әсәр дип кабул ителә, әдипләр үз күзләре белән күргәнне, үз тәннәре һәм җаннары белән кичергән газапны безгә җиткерделәр.

Китап булып басылып чыккан бу әсәрнең жанры «роман» диеп куелган. Журнал варианты белән чагыштырганда исеме дә үзгәргән: тегендә «Каргышлы юллар» булса, монда инде — «Каргышлы этаплар». Авторның роман исемен ни өчен үзгәртүе турында уйланабыз да, мондыйрак фикергә киләбез. «Этаплар»

дигән сүз үзе татарча булмаса да, ике мәгънәне белдерүе белән роман исемен шактый тирәнәйтә бугай. Чыннан да, «этап» дигәндә тоткыннарның сөргенгә баруы да күзаллана һәм, шул ук вакытта, икенче мәгънә катламы буларак, тулаем безнең ил үткән тормыш, вакыт этаплары да уйланыла бит.

Романның тышкы төзелеше дә уй-фикернең менә шушындый агышын хасил итә, шуңа юл бирә. Байтак кына бүлекләр алдыннан ил күләмендә барган репрессияләр турында документаль мәгълүматлар, саннар бирелеп бару әнә шундый тәэсир калдыра. Роман үзе Мотаһир Фарукшин исемле гади бер авыл кешесенең ул еллардагы фаҗигалы язмышын тасвирлый, ә әлеге җан тетрәткеч, миллионлаган кешеләр фаҗигасен аңлатучы саннар СССР дигән бөтен илнең коточкыч бер төрмәгә әверелгән булуын раслап бара.

Ләкин нинди генә кырыс еллар булмасын, җирдә яшәү дәвам иткәндә кешеләр үзләренә хас булган сөенү, өметләнү хисләреннән дә мәхрүм булмыйлар шул. Әле алай гына да түгел: биологик дәрәҗәдә һәр җан иясендә була торган әнә шул иң эчкәре, иң нигез тойгылар социаль тормыш авырлашкан чакларда адәм балалары өчен төп терәккә, бердәнбер таянычка әверелеп кала. Караңгы, кара, салкын еллар полосасында аларның җаннарын саклап кала...

«Каргышлы этаплар» романының беренче битләре дә авыл тормышының җанга тынычлык, рәхәтлек бирүче күренешләрен тасвирлый.

«Уртага яткан өч яшьлек Әгъдәсне уятмаска тырышып, Мотаһир шыпырт кына хатынына дәште:

— Мөсәмирә, торасыңмы әле?!

Хатыны уяу икән. Ак яулык бәйләгән башын чак кына калкытып иренә яратып карады.

— Торыйммы соң?»

Бер караганда бу инде гап-гади бер күренеш, дөньяның табигый агышы. Әмма... Әмма... Әйдәгез әле, менә шушы күренешнең чын эчтәлегенә керик, аны тулы мәгънәсендә аңлап бетерик. Сау-сәламәт ир белән хатын... Алар бер-берсен нык, ышанычлы ярату белән ярата... Урталарында мәхәббәт җимеше — малай да мышнап йоклый. Аларның өе җылы, дөньялары тыныч. Тамаклары да тук...

Әле генә без санап киткән менә шушы нәрсәләр, менә шушы хасиятләр — адәм баласы өчен иң зур бәхет, иң олы мәртәбә түгелме соң инде?! Бүген дә: көн вә төн дөнья куганнан соң, әллә никадәр этлекләр эшләгәннән соң һәм кешеләр башына баса-баса күпмедер югары күтәрелгәннән соң да, кайбер адәмнәр өчен әнә шул бәхет ирешелмәгән ерак хыял гына булып кала түгелме?

Язучы Рәфкать Кәрами иҗатының бу әсәрдә дә нык чагылган һәм алдарак без искә алган әдипләр, тәнкыйтьчеләр дә билгеләп үткән иң матур сыйфаты да әнә шул: әдип кешеләр яшәешендәге әнә шундый иң нигез, иң мөһим, иң кадерле рухи-әхлакый хәзинәләрне үз әсәрләрендә тирән итеп, тәэсирле итеп сурәтләп бирә белә. Кешелек тормышының үзәген тәшкил иткән нигез хасиятләр, иң төп юлның баганалары гаять тә ачык һәм дөрес тасвирлана аның әсәрләрендә.

Шул уңайдан тагын бер мөһим нәрсәне онытмыйк әле. Әсәр персонажларының исемнәре турында дип әйтүем. Иң үзәктә — Мотаһир, Мөсәмирә. Аларның малайлары Әгъдәс... Менә шушы исемнәрне ишеткәч сезнең күңелдә ниндирәк уй-тойгылар туа? Ә минемчә, болар, мондый исемнәр — чынлык, ныклык, ышанычлык символлары булып ишетелә. Ул исемнәр үзләре үк гади, әмма нык үзәкле һәм ышанычлы кешеләр турында сөйли.

Гап-гади татар авылында беркемне дә җәберсетмичә генә көн күреп яткан менә шушы ихлас, эчкерсез кешеләр дөньясына һич тә котмагәндә бәла килеп керә. Бу бәланең чыганагын да, аның тормыштагы чып-чын җирлеген дә Р. Кәрами дөрес күрсәтә. Мотаһирны Мәскәүдәге олы җитәкчеләр кушуы буенча түгел, ә шул ук авылда яшәп яткан бер хөсет адәм «чакканга кырә» алалар.

Романның менә бу урыны шулай ук татар тормышы турында тирән уйларга тарта. Гадел һәм ихлас яшәүче кешеләр ни өчен кайберәүләргә ошамый? Бу — ак белән кара төснең бер-берсен фаш итүе кебек күренешме? Үз янәшәсендәге Аклыкны алып атса, үзенең каралыгы күренмәс дип уйлыймы әллә тормыштагы Кара төс? Ә конкрет бу әсәрне алсак, Мотаһир — авылның ревкомиссия рәисе икән. Ул кайберәүләргә урлашырга комачаулый икән!

Татар авылында яшәп яткан бер кешене кулга алу күренеше шулай ук киң гомумиләштерү көченә ия. Биредә Мотаһир гүяки — СССР дигән империянең барлык намуслы, гаепсез кешеләрен гәүдәләндерә. Алдашуга, сатуга һәм икейөзлелеккә нигезләнгән бу җәмгыять ул чакта үзенең иң гадел һәм иң фидакарь җаннарын төрмәләргә тыгып бетерде бит! Халык өчен диеп җан атып йөргән иң саф күңелле затларны төрмәләрдә юк итте бу җәмгыять! Империя урнаштырган

менә шушы канун хәзер дә тәмам үлгән дип кем әйтә ала?! Хәзер дә югарыда күпчелек икейөзлеләр һәм мәкерлеләр генә утыра түгелме?! Иң сафлар һәм иң фидакарьләр бүген дә күпләп кырыла түгелме?!! Сталин хәйләкәрлегенә, Сталин мәкерлелегенә ия шома кешеләр бүген дә фидакарь затларны теге дөньяга матур-матур сүзләр сөйли-сөйли рәхәтләнеп озата түгелме?!!

Романның беренче өлеше укучы күңелендә әнә шундый гасабилы уйлар уята. Төп каһарман Мотаһир язмышыннан килеп чыгып, бүгенге көн кешеләре яшәешенә килеп ялгана торган мондый уйлар, әлбәттә, әсәрнең бәһасен дә күтәрә, аның тәэсир көчен дә арттыра.

Автор файдасына тагын шуны әйтергә кирәк: ул шомлы утызынчы еллар тормышын бик нык өйрәнгән. Китапны укып барганда чынлыгына шик туардай, ышанмастай эш-гамәлләр күренми. Ә менә психологик яктан нечкә тотып алынган һәм шул чор тормышын, шул чор кешесенең күңел халәтен төгәл ачып бирә торган ситуацияләр күп. Менә берсе.

«Ул, туңмас өчен, төрмә каршында әрле-бирле йөренә башлады. Капка төбеннән урам чатына хәтле бара да кире китә. Туктап тора, тагын китә... Ашыйсы-эчәсе килсә дә, туңса да түзде Мотаһир, читкә китмәде, кешеләр белән дә сөйләшмәде. Шулай да бер мәртәбә аңа сүз катучы булды. Күрәсең, болар төрмәдәге туганнары янына килүчеләр иде. Берсе яшь, икенчесе олырак ике хатын аның янында туктады.

Яшьрәге пышылдап кына:

— Абый, сезнеке ничәнче камерада утыра? — дип сорады.

Ләкин Мотаһир аңа ни дип әйтергә дә белмәде, ярдәме тимәде.

— Юк шул, үскәнем, мин кеше янына килмәдем.

...Конвойчылар район белән элемтәгә кергәннән соң мәсьәлә көчкә ачыкланды: дүрт-биш сәгать үткәч, караңгы төшкәндә, Мотаһирны кабул иттеләр».

Менә хәзер, туксанынчы елларда — егерменче гасыр инде тәмамланып килгәндә — төрмә капкасы төбендә сәгатьләр буе таптанып, үзен төрмәгә алып кереп китүләрен көтеп йөрүче кешене күз алдына китерүе, башка сыйдыруы да кыен. Әмма илдә Сталин төзегән чынлык нәкъ әнә шундый була шул: кешегә кол психологиясе тәмам сеңдерелә. Бу вакытта инде илдәге бөтен юллар Римгә түгел, ә төрмәгә илтә. Романда Мотаһир болай дип уйлый: «Аны барыбер эзләп табачаклар. Ул җир читенә китеп олага алмый бит, китсә дә, килгән юлына кире төшәр — өенә кайтыр. Тагын борчу, тагын шул ук каталажка, этап... Монысыннан да яманрак булыр»...

Әйе, болар — тәмам куркытылган кешенең уйлары. Империядә яшәүче һәр кешене биләгән, богаулаган тойгылар алар. Ләкин романны укыганда без татар кешесенә хас булган сыйфатларны байтак кына табабыз. Димәк, язучы Р. Кәрами үз каһарманнарының милли һәм индивидуаль үзенчәлекләрен дә ача алган дигән сүз бу.

Мотаһирның төрмәдәге беренче төнендә үк ачыла башлый андый хасият. Үзенә бик тә кыен була башлагач ул күңеленнән генә өйдәгеләрне исенә төшерә дә, йөрәгенә бераз җиңеллек тоя һәм шуннан соң болай уйлый: «Бәлки шушы уй аны чатнама суыкларда җылытып, өметсезлеккә бирелгән чакларда күңелен күтәреп, ач вакытларда җан азыгы булып торыр, гел озата йөрер. Бәлки Мотаһир бары шушы уйлары аркасында гына исән калыр — кирәк-кирәкмәс адым ясаудан тыелып калыр. Бик күп ялгышлар бигесезлектән, сине көтеп, кылган гамәлләреңне хөкем итеп торучы булмаудан ясала. Әгәр ата-ана, кардәш-ыру, авыл халкы алдында җаваплылык тою, бурычлы икәнеңне аңлау хисе булса, бик күп җинаятьләр эшләнми калыр иде. Кече яшьтән канына сеңгән тәүфыйк, әдәп кагыйдәләрен бозмаска тырышу — безнең халыкны һәркайда күркәм итеп күрсәтүче асыл сыйфатлар түгелме соң?»

Тоткынлыктагы беренче төнендә Мотаһир кичергән менә бу уйлар бик тә тәэсирле! Утызынчы еллар кешесе күңелендә туган ул фикерләр романны укыган чагында сине бер мәлгә туктатып калдыра, бүгенге кешеләр, хәзерге күренешләр турында тирән уйларга чумдыра. «Бүгенге кешеләрнең тәүфыйксызлыгы каян килә?» дигән үткен сорау тирәсендә бөтерелүче уй-фикерләр алар.

Әйе, безнең татар әдәбияты бу олы сорауга җавапны инде озак еллар буена эзли. Иң җитди иҗат көчләребез әнә шул өлкәдә тырыша. Чөнки бездәге әдәбият ул — Көнбатыш илләрендәге кебек мавыгу, күңел ачу чарасы гына түгел. Бездә әдәбият — тормышының иң җитди яклары, аеруча кешенең рухи-әхлакый яшәеше турында ихластан һәм газаплы уйлану, эзләнү ул.

Менә хәзер, безнең көннәрдә, әдәбият өчен шактый зур ирек килде. Ирек ул, әлбәттә, үзең теләгәнчә эшли алу дигән сүз. Ләкин дөрес рухи-әхлакый кыйбласы

булмаган кешенең иреге ул нинди була соң? Ул — теләнә ни килде шуны сөйләү, алдын-артын уйлап тормыйча нәрсә эләгә шуны язу, кешене көлдерү өчен теләсәң ничек кылану-кылтаюмы?

Әйе, әле татарлыгы бетмәгән чын авыл тормышында туып үскән өлкән һәм урта буын әдипләр, безне зур рухи кыйммәткә ия әдәби әсәрләр белән куандыралар, милләтне эстетик һәм рухи яктан тәрбияләрләр. Ләкин, шуның белән бергә, яшь буын иҗатчыларда әхлакый юнәлеше анык булмаган, бары тик кызыкка яисә тупас натурализмга гына корылган язмалар да шактый күренә башлады. Иҗат кешесенә карата мондый фикер әйткәндә совет чоры тормышыннан калган — КПССның өлкә комитеты карарлары да искә төшә, билгеле. Алар да бит язучыларга һәм башка төр иҗат кешеләренә карата әнә шундый: «халык массаларын тәрбияләүгә хезмәт итми» дигән авыр сүзләрне куллана иделәр. Әмма чагыштырып карыйк.

Инде менә без хәзер ун еллап шактый ирекле хәлдә яшибез. Теләгән фикерләрне шактый ук күләмдә яза алабыз. Хәтта теләгән һәр нәрсәне диярлек яза алабыз. Ләкин... Ләкин ныклап уйлап карыйк әле: тормыш куйган мәсьәләдән, үз милләтең көткән проблемадан «ирекле» булган иҗатчының бәһасе нинди? Иҗатчының шәхси иреге белән чагыштырганда үз милләтең, дөрес рухи тормыш, гуманизм хакына ирексезлек ничегрәк күренә икән?!

Бервакыт ирексездән студент чакта философия фәненнән укыган шундый сүзләр искә төшә: «чын ирек — ул аңланган зарурият» (подлинная свобода — эта осознанная необходимость!) Татар әдәбиятының бүген иҗат итүче иң җитди көчләре дә, минемчә, үзләрен ирекле рәвештә милләткә хезмәт итүче дип саныйлар. Милләт белән шәхеснең иң гармоник берлеге дә әнә шулай барлыкка киләдер ул.

Бу роман каһарманы Мотаһирга авыр чакта ныклык бирүче уйлар безнең дә фикерләрне милләт һәм аның өчен көрәш идеясенә китереп чыгара. Әдипләр, зыялылар өчен генә түгел, ә һәр татар кешесе өчен үтә дә мөһим булган идеягә!

Романдагы икенче мөһим персонаж — Мөсәмирә, тоткын Мотаһирның кеч-кенә малае белән һәм әле тагын бер баласын табарга җыенып, авырлы килеш авылда калган хатыны. Аның образын иҗат итүгә язучы бөтен күңел җылысын салган һәм илһамын да иң тулы көченә эшкә җиккән. Нәтиҗәдә Мөсәмирә укучы күңелендә истә кала торган, үзенчәлекле, җанлы образ булып чыккан. Ирен кулга алып, өйдән алып чыгып барганда Мөсәмирә әйткән сүзләрне карыйк.

— Мотаһир, чәй өлгерде бит!

Гади авыл хатынының үзенә иң авыр вакытта әйткән әлеге сүзләренә автор мондый аңлатма бирә: «Кияүгә чыкканнан алып, кара гүргә кергәнчә гомерен ихатада кош-корт тирәсендә, кече якта аш-су белән әвәрә килеп үткәрүче татар хатыннарының иң кирәкле һәм урынлы дип санаган сүзе иде бу. Чөнки беркем дә аштан олы була алмый: мулламы ул, колхоз яисә авыл советы рәисеме, Казаннан яки районнан килгән түрәме, туган-тумача яисә бала-чагамы, хәтта наган таккан милиционер да...»

Әнә шулай итеп, үз әсәренең иң киеренке, иң истә кала торган урыннарында язучы безнең күңелгә милләтнең асыл сыйфатларын салып куя. Ә инде бүгенге яшь буын укучылар өчен менә моның ише нечкә алымнар белән әхлакый тәрбия бирү бигрәк тә мөһим бит.

Әсәр бер яктан салкын төньяктагы төрмәгә озатылган Мотаһирның газаплы язмышын сурәтләсә, икенче яктан үз авылында калган Мөсәмирәнең башыннан кичкәннәрне тасвирлый. Ә ике арада күзгә күренмәс, ләкин нык җепләр сузылган... Менә тоткын Мотаһир тал чыбыкларыннан кәрзин үрә: «Әнә бит тоткасын ничек җайлы итәргә тырышты ул аның, хатын-кыз кулына эләгәсен белгәнгә шулай пөхтә итеп үрде. Билгеле, ул хатын моның кайда ясалуын, кем үрүен белмәс тә, шулай да, миннән булсын яхшылык дигәндәй, Мотаһир йөрәк җылысын салып эшләде».

Сугыш чорында авылда калган татар хатыннарының героик хезмәте турында безнең матбугатта күп һәм тәэсирле итеп язылды. Рәфкать Кәрами дә үз әсәрендә алар батырлыгын тасвирлауның үзенчәлекле күренешләрен таба.

«Бервакыт Мөсәмирә кычкырып җибәрде:

— Зәһлүл, тәгәрмәч таптым!

— Нинди тәгәрмәч тагын? — диде Зәһлүл аптырап.

— Сабан тәгәрмәче, — дип, Мөсәмирә җиргә төртеп күрсәтте.

Зәһлүл шикләнебрәк әле ана, әле сабанга карап:

— Үзеңнеке бармы соң? — дип сорады.

Мөсәмирә караса — аптырап китте: үз сабанының бер тәгәрмәче юк икән. Тәгәрмәчсез ничек әйләнгәндер ул?»

Кычкырып көләрсең дә, утырып еларсың да монда! Бу бит инде көн-төн басуда эшләүче хатын-кызның тәмам ару билгесе. Һәм, шул ук вакытта, ир-ат эшенә хатын-кызның кулы да, күңеле дә ятмавын күрсәтә ул. Менә моның ише күренешләр әсәр идеясенә бик нәтиҗәле «эшли», эчтәлекне тирәнәйтә. Ә инде романда язучының турыдан-туры болай дип мөрәҗәгать итүен карагыз: — Аналар, апалар, сеңелләр! Мин, шушы китапны язучы, хәсрәтле көннәрегезне йөрәгем белән тоючы, барча авырлыкларыгызны йөрәгем аша үткәрүче, еллар аша сезгә карасам — күзләрем дымлана, күңелләрем тула, җәбер-җәфа кичергән чорлар өчен, кешеләрнең шәфкатьсезлеге өчен сездән гафу сорыйм. Күпләрегезгә, авыр туфрагыгыз җиңел булсын, дип телим. Җиңү көннәрендә олылап сезне искә алырга тырышам, иртә-кич намаз вакытларында картлар сезгә багышлап дога кылсыннар иде, дип телим».

Әйе, шик юк, роман салкын акыл кушуы буенча гына түгел, ә йөрәк кушуы буенча һәм бөтен күңелне биреп, ихластан тырышып, изге җаннарның язмышы өчен тетрәнеп һәм рухланып язылган. Төньякның кырыс табигате дә, тоткынлыкта Мотаһир очраткан яңа шәхесләр дә сәнгать чаралары аша тәэсирле итеп бирелгән. «Әрекмән белән кычыткан үскән һәр җирдә татар бар», дип язу да; урыс милләте кешесен күздә тотып «мин сине аркылы таккан дип торам» дип әйтү дә; хатын кешенең ирен уйлап «алтын бусагам юк шул» диюе дә; «йомыркадан җөй эзләп йөрмә, яме» дигән кызыклы гыйбәрәләр дә һәм уңышлы кулланылган төбәк сүзләре дә әсәрнең кызыклылыгын, үзенчәлеген арттыралар.

Әмма шундый матур-матур тезмәләр үрә белгән әдипнең 171 нче биттә: «Кайчагында бик соң гына да минем арттан киләләр. Ә мин авыруны ташлап китәргә мәҗбүрмен», — дип куюы гаҗәпләндерә. Татарча сөйләшкән кеше: «алмага киләләр», «чакырырга киләләр» ди бит инде ул... «минем арттан» диме.

Әйе, бу романның күзгә ташланган кимчелекләре турында сүз кузгаттык. Минемчә, алар күп түгел. Ләкин китапның беренче битендә үк: «...Унсигезенче декабрь — якшәмбе иде. Ял көне икәнен белгәндәй... бүген кояш та иртәрәк чыкты...» дип тәгәлсезлек җибәрү дә килешми. Чөнки көн озынлыгы егермеләреннән соң арта башласа да, кояшның чыгуы әле яңа ел җиткәндә генә иртәрәк була. Монда инде бәлки автор башта «28 декабрь» дип дөрес язгандыр да, соңрак вакыйганы яңа елдан ерагайту өчен җиңел кулдан гына «18 декабрь»гә үзгәрткәндер дип уйларга да мөмкин.

Бүлекләр алдыннан документаль хәбәрләр, төгәл саннар бирелеп бару илдәге фаҗигаларның зурлыгын, колачын билдерә дигән идек. Әмма ул белешмәләр урыны-урыны белән озынгарак китә дә, аларның тәэсир көче кими башлый. Әдәби текст арасында урнаштырылган булгач, аларның озынлыгы бигрәк тә сизелә. Минемчә, ул белешмәләр бик тә кыска һәм тәэсирле булырга тиеш иде. Әдәби җөмләләр дәрәҗәсендә булырга тиеш иде алар! Саннары, мәгънәләре белән!

Һәм тагын бер мөһим нәрсә. Романның ахыры болай тәгәлләнә: «...Мотаһир онытылып укып утыра... Ләкин шулчак кемдер кинәт ишек шакый калса, Мотаһир сискәнеп китә, чөнки тагын аны алып китәргә килгәннәрдер төсле тоела...»

Әйе, роман каһарманы Мотаһир әнә шулай бүген дә, безнең көннәрдә дә куркып яши. Авторның үз әсәрен безне тәмам тынычландырып, бөтен кайгыларны юлдан алып ташламыйча бетерүе — әйбәт. Чөнки бит әле бүген дә фашистик һәм шовинистик карашлы кешеләр югары хакимияткә үрелә. Мотаһирныкы ише курку әле бүген бик күпләрдә, миллионнарда яши. Һәм ул куркуны бөтенләй җирлексез, сәбәпсез курку дип әйтергә дә ярамый. Нәкъ менә шуңа күрә дә бирeдә язучыга бер тәкъдим, теләк белдерәсе килә. Бу роман тарихта булганны гына язып калмаган булса, әсәр тагын да яхшырак чыгар иде. Чөнки үзләре төрмәдә утырып кайткан кешеләр документаль жанрда язды — аларныкы чын тарихи-документаль әсәр буларак кабул ителде. Шулай дөрес иде, шулай аңлашылды да. Ләкин бирeдә «Каргышлы этаплар»ның жанры, «роман» дип билгеләнгәч, тарихи һәм документаль чынлык бераз чикләнсә дә, яисә үзгәрсә дә ярар иде. Авторның хыялы бәлки андагы вакыйгаларны бүгенге тормыш белән дә бәйли алган булыр иде. Ягъни әсәрнең вакыт ягыннан колачын киңәйтү,

перспективада сурәтләү, әдәби әсәр буларак романның идея-эстетик җегәрен арттыру турында сүз бара. Билгеле, бу очракта инде язучы кешедән тирән фикерләү, талант зурлыгы һәм фәлсәфи көч тә таләп ителә. Ләкин күңел биреп һәм ныклап уйланганда чын язучы таланты боларның байтагына ирешә алган булыр иде. Бары тик әнә шундый олы максатны алга кую гына кирәк иде.

Билгеле, безнең бу тәкъдимне бәлки урынсызрак дип тә санарга буладыр. «Роман ничек бар — шулай кабул итегез»,— дияр бәлки автор. Әмма, шулай да, икенче як фикерен дә бераз уйлап карагыз әле, җегетләр. Чөнки безнең татар прозасы вакыты-вакыты белән бигрәк тә «җиргә төшеп» бетә бит! Әлбәттә, бу әсәрләргә реализм көчен бирә, ышандыруны арттыра. Ләкин без биредә әдәбият турында, образлы фикерләү турында сүз барганын да истән чыгармасак иде!

Әсәрләребезгә алынган каһарманнар моңа кадәр әдәбиятта яктыртылмаган рухи һәм фәлбсәфи мәсьәләләр турында уйланып яшәсәләр, аларның ул яшәүләре безнең өчен укырга кызыклы да һәм мәгънәле дә булса, китаплар укыгач без үзебезгә өр-яңа дөнья ачкандай сөенсәк — милләтебез тормышы тагын да матураеп, баеп китәр иде бит.

Әйе, аңлыйбыз: соңгы елларда проза жанрының хәлләре җиңел түгел. Заманы да утырып, басылып эшләүгә, иҗат итүгә дәртләндереп тормый. Хөкүмәтебез дә милләтнең иҗат көчләренә тиешле игътибар бирми. Шуларның барысы өстенә, прозада иҗат итүче көчләр дә хәзер бик-бик сыекланды: өлкән буыныбыз бик тә нәтиҗәле эшләгәннән соң хәзер табигый рәвештә сүлпәнләндә — аларга инде болай да зур рәхмәт әйтергә кирәк! Ә урта буыннан җигелеп эшләүчеләр шулай ук бик тә әз — бер кулның бармаклары җитәрлек санда гына... Яшьрәкләр исә тагын да сирәк. Монда инде әсәрләрнең сыйфат ягы да бүтәнчәрәк: шәһәр җирендә туып үскән татарларныкы төслерәк...

Менә шушындый хәвефле диярлек бер вакытта басылып чыккан Рәфкать Кәрами романы безне, әлбәттә, нигездә сөендерде. Аны чын әдәбият әсәре буларак онытылып, бирелеп укыйсың. Заман шаукымына бирелеп авторның әсәр сыйфатына игътибарны киметмәве дә — мактауга лаек. Алга таба бәлки әле үз чорыбыз тормышыннан да менә шушындый әйбәт роман иҗат итәр безнең бу язучыбыз?

**Мансур ВӘЛИ.**



# ШАГЫЙРЬ ГОМЕРЕ

(Халисә Мөдәрисованың «Былтыргы көз» исемле китабын укыгач)




Халисә Мөдәрисова шигырьләрен укып чыккач, ирексездән бөек шагыйрьнең: «Что без страданий жизнь поэта? Что без бури океан?» — дигән үзәккә үтәрлек сүзләре искә төшә. Шагыйрь гомере, чын шагыйрь гомере — ул давыллы да, утлы да, шаулы да, тын да, бер сүз белән әйткәндә, газаплы гомер һәм аның газаплары шагыйрь йөрәгә аша үтә.

Өстә китерелгән бөек Лермонтовның шигырь юлларын вакытында Хәсән Туфанга багышланган шигыремдә кулланган идем. Лермонтов... Хәсән Туфан... Халисә Мөдәрисова... Кайсы берәүләргә бу параллель фәстерү булып та тоелыр, әмма Халисә Мөдәрисова шигърияткә утлы һәм давыллы йөрәгә белән килде. Аның әле иң тәүге иҗади алымында ук, унтугыз яшьлек кызның: «Түзәр хәлләрем калмады — бирегез сөйгәнемне», — дип әрнүле тавышы шагыйрәнең нинди йөрәкле булачагын сизү авыр түгел иде. Бу әрнү сөю газабы гына булса да (ә бит сөю газабы — иң көчле, иң тирән газап) шагыйрәнең киләчәк иҗат гомере нинди кылларда яңгыраячагын билгеләгән сыйфат иде.

Әйе, газаплар да төрлечә, төрле дәрәҗәдә булалар: шагыйрьләр жирләреннән сөреләләр, йә булмаса үзләре үз-үзләрен сөрәләр, төрмәләргә дә ябылалар, концлагерьларда да башлары чери — болар, билгеле булуынча, төрле-төрле законнарга, хакимлек итүләргә бәйле, әмма шагыйрьнең үзенә генә хас, үзенең йөрәк тибешенә, күңел агышының үзенчәлегенә хас, кара-каршылыклы уйларына хас, шул ук вакытта, башкаларның күңеле белән уртаклык тапкан, шул ук вакытта аларныкыннан тирәнрәк, хисләрәк газаплары була.

Халисә Мөдәрисованың тормыш юлы һич тә катлаулы түгел: Башкортстанның Нуриман районы, Бәйгелде авылы мәктәбе, университет, укытучы, хезмәткәр — ә күпләргә хас гади иҗат биографиясе бик ук такыр да түгел. Шагыйрәнең шигырьләре, чын шагыйрьләргә хас булганча, эчке каршылыклар белән тулы, ә бу каршылыклар бик тә саллы һәм оригиналь поэтик образлар аша гәүдәләнә.

Бик күпләргә гадәти булган күренешләрдән, әйберләрдән дә ул шигырь таба белә һәм һәр шигырендә теге яки бу вакыйгага, әйберләргә карата үз карашы, үзенең эчке мөнәсәбәте, дулкынлануы бар. Менә тормышның бер гади детале — балдак, җитмәсә алтын балдак.

Сары күзле алтын балдагым,
Бармагымнан бер дә салмадым,
Син түгелсең ирек сынжыры,
Алтын кыршау — никах чылбыры.

Никах чылбыры... күрәсез, алтын балдак ирексездән ирексезлек образына әйләнә. Алтын ирексезлек... Кыйммәтле ирексезлек... Бай ирексезлек... Күрәсез, ул күпме ассоциатив фикерләүләргә алып килә. Ә бит матур, бай, кыйммәтле ирексезлектән дә яманрак бәхетсезлек бар микән дөньяда?

Халисә Мөдәрисова шигъри фикерләүләрендә бөтен яклап та, — тормыш турындамы ул, мәхәббәт турындамы ул, гаилә-көнкүреш турындамы ул — ихлас һәм ирекле. Бу ирклелек хатын-кыз күзлегеннән, хатын-кыз күңеленнән чагылуы белән үзенчәлекле (җәя эчендә шуны да әйтеп китмәкче булам: тормышта Шагыйрьнең хатыны, Шагыйрәнең ире булу җиңел түгел. Төрле көнчел-мөнчел хатын Шагыйрьнең, көнчел-мөнчел ир Шагыйрәнең җәмәгате була алмый. Бу очракта һәркайсына әхлакый югарылыкта булу таләп ителә). Бу үзенчәлек кайсыбер ир-атка азмы-күпме ятрак булып та күренергә мөмкин. Бездә хәзер хатын-кызлардан шигырь язучылар бихисап. Аларның барысында да диярлек, әлбәттә, нечкә күңеллелек бар, әмма алардагы нечкәлектә өф итеп торган мәмәйлек юк түгел, аларның күбесендә шигырь язу кул эшенә — тегү, чигүгә охшаш (хәтта бер шагыйрә ачыктан-ачык: «Шигырь язам — чигү чигәм» — дип язды. Мәсәлән, Ев-

тушенко булса кирәк, хәтта Анна Ахматованың шигырьләрен кул эше, дип атап, язып чыгарга базнат итте. Вакытында урыс язучылары арасында Антонина Коптяеваның «Иван Иванович» исемле романы хакында «рукоделье» дигән сүз йөрде, әмма шигырь язу — чигү чигү түгел һәм аның шулай түгел икәнлеген, шигырь язу — яну, йөрәк газабы икәнлеген Халисә Мөдәрисованың һәр шигырендә, дип әйтерлек чатнап күренеп тора. Аның шигырьләрендә хатын-кыз назлылыгы белән ирлек чаялыгы беркаилы булып килеп кушыла һәм бу чаялык үз тойгыларыңны яшерү куркынычыннан азат итә. Мәсәлән, шагыйрә үзенә кырык яшь тулганын да (ә хатын-кызлар яшьләрен яшерүчәннәр бит), җанының, тәненең ни халәттә булганын да яшерми.

Пәйгамбәр яры яшендә —
Минем иң пешкән чагым,
Үзем теләп учларына
Өзелеп төшкән чагым.

Әгәр тарихка кереп, Мөхәммәт пәйгамбәрнең беренче хатыны Хәдичәнең иреннән унбиш яшькә өлкән булуын, аңа алты бала табып бирүен дә искә алганда, шигырьдәге ихласлык тагын да тирәнәя төшә.

Билгеле булуынча, тарихта хатын-кызлар затыннан пәйгамбәрләр булмаган, ә Халисә Мөдәрисова ир-ат сыйфатына кереп, бер шигырендә бик тә ачынып, бик тә әрнеп:

Үз илендә пәйгамбәрләр булмый,
Булалмадым мин дә пәйгамбәр.
Булды алар, булды, тик мин түгел —
Өлешенә көмеш тигәннәр,—

ди дә, илгә туган җиренә мөрәҗәгать итеп:

Сөйкемле зат булалмадым синдә,
Ни кылсам да күңел кителде,
Үз өендә үги ана белән
Үсеп килгән бала шикелле,—

дип шигырен тәмамлый.

Мондый ачыну һәм әрнү өчен нигез дә бар. Бу очракта башкорт сәнгатенең кабатланмас шәхесе Ишмулла Дилмөхәмәтовның бер сүзе тагын искә төшә. Аның яңа гына Академия театрына эшкә кергән чагы иде. Очрашкан бервакытта ул миңа ачынып: «Кадер юк, агай!» — дигән иде. Бу сүзләрне әйтер өчен, димәк, аның хакы булган, ул, димәк, үзендәге талантны тойган, үзенең үтә сәләтле кеше икәнлеген белгән. Әгәр Халисә Мөдәрисова үзен үз өендә үги бала итеп хис итә икән, димәк, моңа нигез бар. Шигърияттә ул егерме елдан артык хезмәт итә, шигырьләре һәркемне сокландыра, ә нәтиҗәдә? Хәтта шушы китабын да үз хезмәте өчен дәүләттән бер тиен дә әҗер алмый (ә хезмәте нинди әле!) чыгарырга мәҗбүр һәм ирексездән безнең телдә «кадер» сүзе белән «кабер» сүзенең рифмалашуында бик зур мәгънә ятканы башка килә һәм тән чымырдап куя. Тормышка, илгә булган үпкә һәм ачыну бик урынлы һәм тирән булса да, ул кинә кумый, зур йөрәкле кешеләргә хас булган уй һәм тойгылар белән фикерен очлый, чөнки:

Бала кеткән ана кебек дөнья
Үз алдына үзе елмая.

Мондый тойгы тик хатын-кыз табигатенә хас икәнлеге ярылып ята. Ул барысын да гафу итәргә әзер — аңа күп тә кирәкми.

Мин — хатын-кыз, бары яратыгыз,
Минем вакыт кыска таң кебек.

Шушы ике шигъри юл белән шигырьләрдән мисал алуны туктатам. Халисә Мөдәрисованың нинди шагыйрә икәнлеген аның һәр шигыре сөйли — димәк, аларны үзенә укырга кирәк.

Халисә Мөдәрисова китабын «Былтыргы көз» дип атаган. Былтыргы көз... Исеме серле, әмма шулай атавы юкка түгел. Китапта көз мизгеле төрле-төрле

поэтик образлар аша шигырьләренә керә. Китапта көз турында шигырьләр күп, урыны-урыны белән алар бер-берсен кабатлап та алалар. Әгәр көз мизгелләре шагыйрәне уйландыра, илһамландыра икән, шигырьләрдә тирән һәм фәлсәфи фикерләр әйтергә ярдәм итә икән, монда бернинди хилафлык юк. Шулай да кабатланулардан азат булу нур гына өстәр иде.

«Былтыргы көз»...— ул өстә әйткәнемчә, егерме елдан артык иҗат җимеше, ул, ничектер, шагыйрә үзенең ниндидер дәверенә йомгак ясау кебек тә күренә. Бу гаҗәп түгел, узган заманнарда язучыларның егерме еллык иҗат бәйрәмен дә үткәрүчән булганнар. Хәзер андый бәйрәмнәрне түгел, юбилейларны үткәрергә дә житешер хәл юк. Күп без. Бик күп без! Алар арасында танылганнарын да, исемнәре бик билгеле булганнарын да очратырга мөмкин. Халисә Мөдәрисова билгелеме соң?

Мәсәлән, аның «Балан» җыры радио аша, кешеләрнең сораулары буенча, еш кабатлана, ә ул җырның авторы кем икәнлеген беләләрме икән соң? Икеле. Аның тагын «Сагындым сөйгәнемне» дигән шигыре җырлана. Алар, һичшиксез, әйбәт җырлар, әмма Халисә Мөдәрисованың йөрәге, иңе — бар булмышы җырларында түгел (җыр язар өчен шагыйрь булу да бик кирәкми. Татар композиторы әйтмешли, аны эте дә бете дә яза хәзер), ә ул менә шушы китапка кергән шигырьләрендә. Җырны тыңлау өчен күп нәрсә таләп ителми, ә шигырьне уку һәм аңлау өчен һич югында туган телеңдә укый-яза белергә һәм шигъри йөрәкле кеше булырга кирәк.

**Нажар НӘҖМИ.**

---

## «ШӘҺРИ КАЗАН» ЧАКЫРА

**Соңгы елларда чыга башлаган иң кызыклы басмаларның берсе — «Шәһри Казан» газетасы дисәк, шөт, ялгышмабыздыр. Чыннан да, бу газета халыкны борчыган иң үткен мәсьәләләрне актив күтәрә, кайнар бәхәсләрне дә еш оештыра, төрле һәм яңа фикерләргә урын бирә, зыялыларыбыз язган саллы мәкаләләргә юлны киң ача. Аның битләрендә шулай ук кызыклы әдәби әсәрләр еш басыла, сәнгать дөньясы яхшы яктыртыла, күренекле шәхесләр турында язмалар да дөнья күрә.**

**Кыскасы, «Шәһри Казан» — һәр татар кешесенең ышанычлы күңел юлдашы!**

**Газетага язылу дәвам итә. Бергә булыйк, дуслар!**

**Каталогтагы индексыбыз — 54126.**

***Редакция.***

# ТАТАР ШӘҖӘРӘЛӘРЕ




Шәҗәрә — нәсел агачы, бабайларыңның әллә ничә буыннарга кадәр исемнәрен, дөньядан үтү тәртипләрен, нәселе тармаклануларын белү дигән сүз. Ул безнең халык яшәешендә, теге яки бу ихтыяҗ таләбе буенча, һәрчак кулланышта булган. Күктән төшкән нәрсә дә түгел, эшләп табып мәйданга китерелгән нәрсә дә түгел.

1995 елда Тел, әдәбият һәм тарих институты гыйльми хезмәткәре Марсель Әхмәтҗановның «Татар шәҗәрәләре» исемле фәнни хезмәте басылып чыкты. Автор археографик (иске кульязма китаплар эзләп) экспедицияләрдә йөргәндә авылларда аерым нәселләрдә сакланган «нәсел чылбыры» — «нәсел агачлары» (шәҗәрәләр) белән дә кызыксынган, аларны барлаган, җыйган икән. Авторның язуына караганда, аның кулында 500 дән артык нәсел шәҗәрәсе тупланган. Шул җыелган материаллар нигезендә, ул 1981 елда кандидатлык диссертациясе яклый. Бу диссертация 1991 елда «Татарские шеджере» исеме белән рус телендә аерым китап булып басылып чыга. Инде менә 126 битле китап рәвешендә автор туплаган шәҗәрәләрдән алтмыштан артык текст, сайлабрак, бүгенге көннең мөмкинлегеннән чыгып, искәрмәләр характерындагы кайбер аңлатмалар белән татар укучысына да тәкъдим ителә.

Татар шәҗәрәләрен фәнни әйләнешкә кертү элек тә булган. Мәсәлән, Ш. Мәрҗанинең «Мостафад...»ында, Риза Фәхретдиннең мәшһүр «Асар»ендә аларның кызыклы үрнәкләрен байтак табып була. Безнең заманда да аларга әйләнеп кайтулар булды. 1972 елда басылып чыккан «Татарские исторические источники XVII—XVIII вв.» китабында М. Усманов җәмәгатьчелек игътибарын шуңа юнәлткән иде. 1960 елда Уфада да Р. Кузеевның «Башкирские шеджере» дигән китабында шәҗәрәчелек монументаль фәнни хезмәт рәвешендә җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителгән иде. М. Әхмәтҗанов анда кайбер татар шәҗәрәләре дә кертелгәнлеген искәртә. Һәм, гомумән, авыр тарих юлын кулга-кул тотынып үткән бу ике кардәш халык арасында мәдәни уртаклыклар бүгенге көннәргә кадәр дәвам итә.

Әйе, шәҗәрәләр турында сөйләшү әлләни яңалык та түгел кебек. Шулай да, мәсәлән киләчәктә, татар шәҗәрәләренең тарих белеме буларак формалашуы турында сүз чыкса, М. Әхмәтҗанов исеме бу юнәлешнең бездә фәнни белем булып формалашуына нигез салучы, аны фәнни юнәлешкә, тарих фәне тармагына әйләндерүче буларак телгә алыначак. Әйе, бу эштә Марсель иптәш докторларыбызга, академикларыбызга да насыйп булмаган, күпләрне сокландырырлык уңышка ирешкән. Кирәкле, мөһим, зур эш башкарган. «Татар шәҗәрәләре» — мәдәниятебез тарихында олы казанышыбыз булган әһәмиятле хезмәт. Бу уңышы белән авторны котларга, тәбрикләргә генә мөмкин. Әмма бу хезмәт яңа фәнебезнең киләчәге, яшәүчәнлеге, чын камиллеге турындагы беренче казанышлардан хисләнеп, «бозау куанычына» («телячий восторгка») бирелмәскә, шул билгеләнгән юнәлешне киңәйтү, ныгытуга игътибар бирү мәсьәләсен дә көн тәртибенә куя.

Ә уйланыр урын бар. Мәсәлән, башкорт кардәшләрнең моннан утыз биш ел элек үк инде бу хакта кирпеч калынлыгында китап чыгаруларын искә төшерсәк, республикабыз «мөмкинлекләре»нең шушындый гына булганы өчен хурлану, халкыбыз өчен әрнү хисе дә күңелне били. Хәер, моңа үртәлергә түгел, бу китапчык ничек дөнья күрә алды икән әле, дип гаҗәпләнергә тиешбездер. Чөнки һәммәбез шул җирдә, шул атмосферада яшибез, мөнәсәбәтне күреп торабыз.

Эчне пошырган бер нәрсә бар: алынма сүзләрне уку, тәрҗемә итүләрдәге шапшаклыклар өчен җаваплылык, безнең шартларда, күбрәк нәшрият ягына карый кебек. Автор М. Әхмәтҗанов эшнең үзенә кагылышлы өлешен, тапкырлыктәвәккәллек күрсәтеп башкарган. Аның иске сүзләрне уку, аңлау дәрәҗәсе күптән һәммә кешегә билгеле. Китапта алынма сүзле текстлар аз булса да, уку-аңлату һәм тәрҗемәдә җибәрелгән хаталар күзгә ташлана. Аларны төзәтү мотлак зарур булганга, күземә чалынган кадәрен биредә теркәп үтүне кирәк дип таптым.

**10-б.** Мөрәүвәҗ (әйләү) — җәелү, хөкемен (протекторат) урнаштыру сүзе мәрүҗ дип укылган һәм текстка ярашмый торган рәвештә — «үтенеп сорый» дип тәрҗемә ителгән.

**20-б.** Галәйһи сүзе галия дип укылган.

**21-б.** (Әмерен) иҗрайә (килтерү) үтәү — эчрәя дип укылган. Истилаг-басып алу сүзе — истилаҗ дип, тәсрыйфына сүзе — тәгърифына дип бирелгән.

**22-б.** (Әмере) бизрәк түгел, бозруг (олы әмир). Тәбакыя түгел, тәбакаи; рәбыйгы мәскүн — язлыкта кеше яши торган урын түгел, дөньяның дүрт ягы.

**35-б.** Нәзарән сүзе — назыйре дип укылган. Ике урында да буйлә сүзе — бу илә дип укылган.

**39-б.** Йотар сүзе — ятар, дип укылган.

**49-б.** (Разыйаллаһе) Гайна түгел, ганһе. Шам — Иерусалим түгел, Дамаск, Сурия.

**50-б.** (Пәйгамбәр) Салиуллаһ түгел, саллаллаһе.

**53-б.** Иле түгел, илә. Юксик түгел, юксәк. Зирзәбир түгел, зирзибәр. Калисәсе-стенасы түгел, чиркәве. Уза түгел, үзә.

**54-б.** «Р» хәрефе кыршылган күрәсең, рөгъяте сүзе гаяте дип укылган. Саллаллаһи сүзе инде саллиулла дип укылган.

**55.** «Иман каласы» шәҗәрәдә Уфа дип күрсәтелгән дә, автор да шуны кабатлый. «Яман кала» — Орски Уфага күчерелгән.

**74.** Вәладәт тарихы — нәсел тарихы түгел, туган елы.

**84.** Шаһи Озынның кулы түгел, шаһи изеннең — рөхсәтнең; кауле — сүзе.

**88.** (Тау иле) «ягында» сүзе янында дип басылган.

**98.** Мөзәйин (бизәүле) сүзе мөзин укылып, кечкенә дип тәрҗемә ителә.

**120-б.** Бабаларының сүзе балаларының дип басылган.

Китапта бәхәсле урыннар да аз түгел. Менә кайберләре:

**3-б.** Татар халкы бүген дә Дәшти Кыпчакта яши ди (Татарстанның географик урыны күз алдында тотыла).

**4-б.** Нагайбәк сүзен нигә нагайбак дип язарга?

**5-б.** Пыран булды. Заран тагылмасыннан башка бу сүз кулланыла микән?

**57, 60-б.** Сәйрам (шәһәре исеме) Сирам дип бирелә.

**58.** Мәшруг — ысул түгел, яраклы, шәригатькә лаек.

**74, 76-б.** Зәбидә, Әнүр исемнәре шул ук Зөбәйдә, Әнвәр ич.

**91-б.** Җонис-Җунус, Җуныс (Юныс ич).

Тарихка бәйләнешле материалларда да кайбер шундый бәхәсле урыннар бар:

**15-б.** Болгар төбәген сакларга дип Алтын Урдадан йөз мең татар күчерү. XVI йөздә, «кара ваба»дан соң, Алтын Урданың үзен сакларлык та көче калмый. Кара бик шәҗәрәсенең Рычков вариантында, Нугай эпосындагы дастан каһарманнары генеологиясе нигезендә, XIV-йөз түгел, XVII йөздә каранугайларның Кырым белән Идел арасында урыс белән Кырым арасында куылып йөреп, Җаекта тупләнүе чагыла, күрәсең.

**24-б.** Борынгы чорда бабаларны Нух пәйгамбәргә, Адәм атагача илтеп тоташтыруны Алтын Урда «сәяси доктринасына» кайтарып калдыру дөрес түгел. Бу хакта фәндә инде урнашкан караш бар. Шул юл белән барлык халыклар үзләренең яшәү хокукына һәм гомум кешелек тарихында игътибарга, хөрмәткә лаек урыны барлыгын раслаган. Ул Алтын Урдадан читтә, Иранда, Гарәбтә, Африкада, Европа илләрендә дә таралган күренеш. Алтын Урдага кадәр дә булган. Угыз хан шәҗәрәсен «Иранлыларга ияру»гә әйләндерү дә, нәкъ шул сәбәпләрдән туган нәрсә булганы өчен, чынлыкка туры килми.

**38-б.** Шәйбаниләр шәҗәрәсендә Исмәгыйль дигән исем очратып, Идегәй оныгы Исмәгыйль мирзаны Шәйбаниләргә ябыштыру белән дә килешеп булмый. Тексттагы «Аеры Калбак» аталмасы Шәҗәрәдәге Шәйбанины Мөхәммәд Шәйбанига кайтарып калдыруны да шик астына куя. «Калбак» сүзе — калмак, калмык (монгол). Аеры Калбак — Җужи улы (калмык) Шәйбаниның Алтын Урдадан «аеры» улусын атау түгелме соң?

**40-б.** «Ата» терминын угыз мирасы дип билгеләү дә бәхәсле. Хуҗа Әхмәт Ясәви мөридләреннән һәм үз нәсәбеннән чыккан суфи шәехләре дә «ата» исемен йөрткән (Хаким ата, Зәнги ата, Садыр ата, Исмәгыйль ата һ. б.) «Ата» — угыз термины түгел, суфилык тарикать аталмасы...

Хезмәт басылып таралды. Китап мәйданында урын алды. Ул эшкәрткән мәйданда «чирәм җир» күтәрелде, эшкәртеләчәк җирнең мәйданы, киңлекләре, чикләре билгеләнде дигән сүз. Әмма «чирәм күтәрелү» — аның әйләндереп капланулы гына әле. Ул тагын шул ук чирәм җиргә әйләнеп калмасын өчен, аны

эшкәртергә, уңыш китерерлек йомшартырга, тамыр, гордалардан (кантарлардан) тазартырга-арындырырга кирәк. Аның эшкәртәсе яклары — очсыз-кырыйсыз. Бу хезмәт — диңгездән бер тамчы гына әле.

Китапта урыны-урыны белән тәнкыйди-аналитик караш һәм күзәтүләр җитенкерәми. Нәтиҗәдә, шәҗәрәләрдәге төрле ясалмалыкларны да автор чынга ала кебек тәэсир кала.

Дәлилләүләр, анализлар җитәрлек булмаганга, күп кенә урыннарда авторның материалны ярату-сокланулары чамадан чыгу, эмоциягә бирелү булып сизелә башлый. Фәндә исә эмоция генә чын бәя була алмый.

Шул ук факторлар тәэсирендә, сәяси-этник төсмерле полемик репликалары да материалны алдан уйланылган ниндидер идеологик максатка көчләп тартуга охшый. Бик ихлас, изге максатларда әйтелгән фикерләрне дә мондый тәэсир төссезләндерә, аларга бөтенләй башка караш төсмере йөгертә.

Шәҗәрәләрдә тарихи риваятьләр килеп чыккан урыннарда материал ничек чын алмазга әйләнеп китә! Тарихи офыклар киңәя, бөтенләй, башка, яңа бер дөнья ачылып киткәндәй була. Һәр шәҗәрәдә сизелеп киткән яңа үзенчәлекләр нигезендә жанр үзенчәлекләре, бу конкрет шәҗәрәнең аерымлыклары, үзлекләре, тенденцияләре турында сөхбәтләшүләр — аңлатма мәкаләләр — алып барылса, эчтәлек бермә-бер баер, тирәнәер иде. Безнең карашка беренче нәүбәттә укучыга аңлатырга тиешле темалар мондый: «Чыңгызнамә»ләр, Әбелгазый «Шәҗәрәи төрек», Ш. Мәрҗани («Мостафад» һ. б.) хезмәтләренең татар шәҗәрәчелегендә урыны. Боларга хәтта аерым бүлекчәләр биреп буладыр. Икенчесе: шәҗәрәләрнең функциональ төркемләнүләре: 1) Суфи силсиләләре (буын чылбырлары), 2) Дастан (эпос) традицияләре, 3) Аксөякләр (Морзалар) «нәсел агачы», 4) Морзалык яки җир биләмәләренә хокук дәгъваларны нигезләү өчен ясалган шәҗәрәләр (материалларга караганда болар бездә иң зур күпчелекне тәшкил итә), 5) Укымышлылар династияләре мәйданга китергән шәҗәрәләр, 6) Капитализм чорында, яңа «өске катлау» — бай, сәүдәгәрләрнең үз нәселләрен саклауга каратып әзерләткән язмалары.

Башка тагын ниндиләр? Шәҗәрәләрдә боларның кайсыларының нинди элементлары катнашуын билгеләү, кайсы тенденция өстенлек алганын күрсәтү. Менә шулай эшкәрткәндә генә безнең шәҗәрәләр мирасыбыз чын фәнни нигезгә утырыр һәм кызыклы бай тарихи чыганак булып китә алыр. Автор М. Әхмәтҗанов шул мөһим эшкә алынган. Шактый материал һәм тәҗрибә тупланган. Аңа киләчәктә бу эшен камиллеккә китерүдә зур уңышлар теләп калабыз.

Мәсгуд **ГАЙНЕТДИН.**

## Ибраһим Сәлаховка — 85 яшь




Тугандаш Казагыстанның Күкчәтау өлкәсендәге Кызыл-Яр авылында яшә-
үче күренекле татар язучысы — Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге
Дәүләт бүләге лауреаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Иб-
раһим Низами улы Сәлаховка шушы елның 30 августында 85 яшь тула. Аның
олуг юбилее Татарстан Җөмһүриятенең Бәйсезлек турында Декларация кабул
итүенең алты еллык бәйрәменә туры килүе белән икеләтә истәлекле! Без мөх-
тәрәм юбилярны — әдәбиятыбыз аксакалын — әдәбиятыбызны «Күкчәтау дала-
ларында», «Имәннәр тамыр җәйгәндә», «Тайгак кичү» романнары, повестьлар
һәм хикәяләр, пьесалар һәм шигырьләр белән баеткан, Татарстаннан еракта
яшәсә дә, милли һәм рухи тормышыбызга дәрт-дәрман өстәп яшәү әмәлен
тапкан кадерле затны күп санлы укучыларыбыз исеменнән, Туган көне белән
ихлас күңелдән кайнар котлыйбыз, аңа сәламәтлек, иҗади уңышлар, күңел
бәйрәмнәре телибез!

Ибраһим аганың гыйбрәтле язмышы — аның әсәрләрендә. Тормышның үтә
катлаулы, сикәлтәле юлларын үтеп тә күңел көрлеген, иҗади активлыгын югалт-
маган бу әдип бигрәк тә яшь каләм әһелләре өчен үрнәк шәхес.



Ә бу рәсемдә сез Ибраһим аганы 1991 елның 25 октябрендә Күкчәтау шәһәрендә мәдәният сараенда 80 яшьлек бәйрәмен билгеләп үткән вакытта күрәсез. Аны котларга Казандагы якын дуслары — Татарстанның халык язучылары, Г. Тукай бүләге лауреатлары Аяз Гыйләҗев белән Мөхәммәт Мәһдиев тә килгән иде...

*Әлеге фоторәсемнәр язучы Шаһинур МОСТАФИН тупланмасыннан алынды.*



# Шамил Маннап (Шаман)

## Фермерда эшләү җиңелме?

Ачык күңелле, алчак кеше булганга, шагыйрь Нәби абый Дәүлинең дуслары күп иде. Шундый дусларының берсе — танылган диктор Эльс Гадел белән кафеда сыйланып утыра болар. Нәби абый үзенең немец әсирлегендә күргән җәфалары турында искә алгач, Эльс саксыз сүз ычкындыра:

— Концлагерьда авыр булгандыр анысы, ә менә немес фермерында эшләү алай ук кыен түгелдер инде ул?

Нәби абый, битендәге тирән җыерчыклар пәрәвезен алып ташларга теләгәндәй, зур учы белән сыпырып куя:

— Андагы хәлләрне аңлау өчен үзең күреп, үзең кичерергә кирәк, канишны...— ди ул һәм сүзне икенчегә бора:— Слушай, Гадел, иртәгә мин дачага барам. Син дә кил, язгы матур көнне өйдә утырып әрәм итмә. Анда башларны да «төзәтербез»,—ди.

Эльс иртүк торып, күзен тырнап ачуга, Нәби Дәүлинең Аккош күлендәге дачасына ашыга. Ул килеп җиткәндә, Нәби абый ак күлмәктән, биленә таянып бакчасында басып тора.

— Ә-ә, килдеңме, зимагур!— ди ул, алтын тешләре белән балкып елмая.— Килсәң, әнә ал көрәкне и сөрә башла!

— Әүвәл аз гына башны «төзәтеп» аласы иде бит,— ди Эльс, чыраен чытып.

— Ха-ха-ха! Өлгерерсең,— ди Нәби Дәүли.— Башта эшләп күрсәт әле! Фрештейн зи?

Эльс нишләсен, тиз-тиз казый башлый. Нәби абый үзе тәмәке тартып, биленә таянган килеш, ара-тирә күрсәтмәләр бирә:

— Тирәнрәк ал, тирәнрәк! Бураэнаңны тигез тот, чокыр-чакыр калдырма! Кантарларыңны ваткала, тырмалаганда үзеңә җиңелрәк булыр... Акрын кыймылдыйсың, шнель-шнель, русиш швайн!

Шулай, тирги-тирги, төшкә кадәр җанын ала эшләтеп Эльсның.

Ниһаять, Эльс бакчаны казып бетерә дә, көрәген җиргә ташлый.

— Уфф! Хәл бетте! Хет чәй булса да бир, эксплуататор!— ди ул, көйгән иреннәрен чак-чак кыймылдатып.

Нәби абый тагын бакчаны яңгыратып хахылдый.

— Йә, аңладыңмы инде фермерда эшләүнең «кыен түгеллеген»? Фрештейн зи?

— Аңладым-аңладым, фрештейн!— ди Эльс, маңгай тирен учына сыпырып.— Гафу ит, Нәби абый...

— Аңласаң, бик яхшы. Әйдә, өйгә рәхим ит. Анда чәе дә, мәе дә булыр...— ди Нәби абый.

## «Кирәкмәс шул!..»

Түгәрәк юбилеенда Сибгат Хәкимгә Казан мехчылары бик әйбәт, бик затлы бүрек бүләк итәләр. Башына ук кигереп куялар.

Юбилей кичәсенең концерт өлеше башлана. Җырчылар, шагыйрьнең үзе әйтмешли, «үз җыры белән сыйлый» башлыйлар. Алып баручы чираттагы җырның исемен әйтә: «Башка берни дә кирәкми...» Шул вакыт залдан Нәби Дәүлинең карлыгулы-томат тавышы яңгырап ишетелә:

— Кирәкмәс шул! Шундый шәп бүрек бирсәләр, минем дә башыма берни дә кирәкмәс иде!..

## Тик тормаган телдә бәла бар

Алтмышынчы еллар. Партиянең Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Фикрәт Табиев язучылар алдында чыгыш ясый. Сүз экология мәсьәләләре, әйләнә-тирәбезнең чисталыгы турында бара.

— Мин сезнең бөтен соравыгызга җавап бирергә әзермен!— дип, залга мөрәҗәгать итә Табиев.

Урта рәтләрдән Нәби Дәүли тавышы ишетелә:

— Казанның Үзәк ял паркында тәртип юк, чисталык юк. Кичен анда яшьләр җыела, аракы эчәләр, тәмәке тарталар, кызлар кочалар. Артларыннан буш шешәләр, тәмәке төпчекләре, кәгазь чүбе өелеп кала. Менә сез, иптәш Табиев, нишләп һаман шунда тәртип урнаштырырга ярдәм итә алмыйсыз?

Фикрәт Әхмәтҗановичның чыннан да җавабы әзер икән.

— Ә сез, Нәби Дәүли, кичләрен паркта йөрмәгез, өегездә хатыныгыз белән чәй эчеп кенә утырыгыз! Вот так!— ди ул.

Залда көлеш, Нәби абый үзе дә көлә.

— Мына шылай инде ул, тик тормаган телдә бәла бар...— дип куя ул.

## Тотылган да котылган

Бервакыт Шамил абый Бикчурин кайдадыр «кунак булганнан» соң, таң алдыннан гына өенә кайтып килә икән. Җәмәгать транспорты күптән тукталган, ә кайтасы юл шактый ерак. Шул вакыт (менә бәхет!) ут уйнатып, милиция машинасы килеп чыга. Шамил абый кул күтәреп, туктата моны.

— Мине таныйсызмы, сез, диваналар?— ди ул милиционерларга.

— Танымаска?! Язучы Бикчуринны танымаска?!— ди тегеләр.

— Танысагыз, диваналар, илтегез мине өемә чаклы.

— Була ул! Утыр әйдә!— ди милиционерлар көлеп.

Машина выжылдап, айныткыч ишек алдына килеп кергәч, эшнең нидәлеген сизеп ала Шамил абый. Әмма, милиционерларның гаҗәпләнүенә каршы, ачуланмый, тавыш күтәрми, киресенчә, сөенеп болай сөйләнә:

— Диваналар, әйбәт егетләр икәнсез! Болай булгач, кайда булуым турында хатын алдында җавап тотудан котылдым бит. Сездә «кунакта булуым» турында дакумит бирергә онытмагыз түлке...— ди.

## Герман җиреннән кайткан кебек

Мәшһүр җырчы Фән Вәлиәхмәтовның «Герман көе»нә җырлавын кем генә мөкиббән булып тыңламый! Арча районы хакимияте башлыгы Вагыйз Минһаҗев та бик ярата ул җырны. Җырны гына түгел, гомумән, Фән Вәлиәхмәтов җырлавына гашыйк ул. Бервакыт алар Питрәч районы сабан туенда очрашалар. Бәйрәмнән соң, Вагыйз Минһаҗев җырчыны, ай-ваена карамый, машинасына утыртып, үз районына кунакка алып китә. Юл буе Фәнне «Герман көе»нә җырлата ул. Аның үтенүе буенча җырчы Арча культура йортында чыгыш ясый. Анда да «Герман көе»нә кат-кат сорап җырлаталар. Концерттан соң, хакимият башлыгы Фән Вәлиәхмәтовны үзенең туган авылы — Хәсәншәехкә алып китә. Юлда янә — «Герман көе»... Инде авылда мунча кереп, бераз ял итим дисә, Вагыйз Минһаҗев яңа идея уйлап чыгара:

— Әйдә, Фән дус, иртән иртүк гармун уйнап, «Герман көе»н җырлый-җырлый урам әйләнәбез! Әти, абыйларның Герман сугышына чыгып киткәннәрен хәтерләтерлек булсын...— ди.

Фән авыр сулап, болай җавап бирә:

— Инде, Вагыйз Василович, болай да Герман сугышына чыгып киту генә түгел, Герман җиреннән әйләнеп кайткан кебек булды, бу кадәр җырлауга!

Шулай да алар икенче көнне таң белән гармун тартып, җырлый-җырлый урам әйләнәләр...

## Хәбәрче көпчәк

Башкортстанның Туймазы район үзәгеннән Илчебай авылында җинел машина чаба. Март ае. Юл шактый бозлавык, урыны-урыны белән машина көпчәкләре шуып кына уза. Машина эчендә икәү: җырчы Фән Вәлиәхмәтов белән шагыйрь Әнгам Атнабаев, Илчебай авылына концерт куярга баралар.

— Син «Герман көе»н җырларсың, мин шул темага язылган шигырьләремне укырмын...— дип, хыялланып бара Әнгам Атнабаев.

— Күрше авылларга да хәбәр иткән булсалар ярый, алар да концерт карап китәрләр иде...— ди Фән Вәлиәхмәтов.

— Карале, машинаң синең якка бераз янтаеп барган шикелле,— ди бервакыт Әнгам абый.

— Мин синнән авыррак бит,— шуңадыр,— дип елмая Фән.

— Без тәгәрәп түгел, шуып кына барабыз түгелме соң?— дип, кабат борчыла Әнгам Атнабай.

— Юл бозлавык бит,— дип, аны тынычландыра Фән.

— Карале, теге нинди тәгәрмәч ул, машинаны узып тәгәри!— дип кычкырып җибәрә Әнгам абый.

— Белмим шул. Шулай да ала китик без аны, кирәге чыгар.

Машинаны туктатып, төшеп теге көпчәкне куып тоталар да багажникка салмакчы булалар. Шул вакыт үз машиналарының алгы көпчәге юклыкны күреп ала болар.

— Бәй, машинаны узып, кая бармакчы булган бу тәгәрмәч?— ди Фән гаҗәпләнеп.

Бу юлы инде Әнгам Атнабай җавап бирә:

— Алдан барып, безнең концерт белән килүебезне күрше авылларга хәбәр итмәкче булгандыр ул,— ди.

## Шәйхи ага «рәхмәте»

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе әдипләрнең түгәрәк туган көннәрен нинди дә булса бүләк белән билгеләп үтә.

Менә бервакыт Шәйхи Маннурга 75 яшь тула. Идарә рәисе Гариф Ахунов әдәби фонд директоры Лирон Хәмидуллин янына киңәшкә керә.

— Шәйхи абзый — зур язучы, ниндирәк бүләк алыйк икән?— ди ул.

Лирон, башын кашып, уйланып торганнан соң:

— Чыннан да, аңа транзистор гына бирү килешмәс,— ди.— Әйдә, без аңа шәп бер телевизор бүләк итик! Рәхмәт әйтсен әле безгә.

Шулай килешәләр. Лирон, җиңел машинага утырып, кибеттән кибеткә чаба, ниһаять, телевизорны табып ала һәм Шәйхи аганың фатирына илтеп үк бирергә була. «Әйдә, сөендерим әле үзен!»— дип уйлый ул.

Бирнә сандыгы зурлыгындагы телевизорны көч-хәлгә күтәреп, Шәйхи аганың дүртенче каттагы фатирына менә, коридор идәненә куеп, бер кулы белән маңгаендагы тирен сөртә, икенчесе белән ишек кыңгыравын баса. Җиңел пижамадан Шәйхи Маннур килеп чыга. Эшнең нидәлеген аңлап алганнан соң, ул рәхмәт ишетергә өметләнеп торган Әдәби фонд директорына әйтә:

— Ну, чуртыма дип алып килдегез бу шайтан әрҗәсен? Шуңа багынып утырмасам, минем башка эшләрем беткән дип белдегезме әллә, пнимаешь?

Әдәби фонд директоры, юбилярны көч-хәл юмалап, телевизорны «таможня» аша уздыра, фатирга кертеп куя һәм, бүләкне алып калганы өчен Шәйхи абзыйга рәхмәт әйтә-әйтә, ычкыну ягын карый.

## Котылу чарасы

Заманында Шәйхи Маннурның шахмат җене кагылган кеше булганлыгы күпләргә мәгълүмдер. Ул бервакыт Тукай клубында узган әдәби кичәдән соң, клуб мөдире Маннур Саттар белән шахмат уйнап кала. Арган булгандырмы, бу кичтәге уен аның өчен уңыш китерми. Оттыра гына бит, әттәгенәсе! Оттырган саен тагын да үҗәтләнебрәк уйнавын дәвам итә. Инде ярты төн дә уза, таң сызыла башлый. Маннур Саттар:

— Җитәр инде, Шәйхи абый, кайтып йокларга кирәктер,— дип караса да, өлкән Маннурның кузгалырга исәбе юк.

— Тагын бер партия генә...— ди ул.

Маннур Саттар аңлап ала: оттырмый торып, котылу юк моңардан. Һәм ул юри җиңелә. Ләкин әле бер мәртәбә отуга гына да канәгать түгел икән Шәйхи абзаң. Өч партия откannan соң гына, ул ниһаять, кайтырга кузгала.

— Менә шулай уйныйлар аны, энекәш!— ди ул саубуллашканда, канәгать елмаеп.

## Өлгергәнен көтсәң...

Займищедагы дачасында Аяз Гыйләҗев төрле-төрле җимеш агачлары үстерә. Бигрәк тә алмагачларын яратып тәрбияли ул. Әмма алмаларының өлгереп җиткәнен көтми, яшел килеш кимерә башлый.

— Нишләп өлгергәнен көтмисең, Аяз абый?— дип сорый аңардан узганбарганнар.

— Өлгергәнен көтсәң, миңа тәтеми ул, парин. Караклардан артмый,— дип җавап бирә Аяз Гыйләҗев.

## Бер авызга — ике тел

Мансур Вәли матбугат йорты ашханәсендә аш бүлеп торучы кызга дәшә:

— Миңа бәрәңге белән тел бирсәгез иде.

— Бер телме, икенеме салыйк?— ди Гөлфия атлысы.

— Берсе җитәр,— ди Мансур.— Бер авызга ике тел сыймый ул. Кайбер сәясәтчеләр генә Татарстан авызына ике тел куярга маташалар...

## «Сафбаш» булу өчен — гариза

«Татарстан яшьләре» газетасы редакциясендә эшли башлаган яшь хәбәрче Нәсимә Садыйкованы чираттагы санны чыгару өчен «сафбаш», ягъни, дежур итеп билгелиләр.

— Ә син «сафбаш» булырга рөхсәт сорап, мөхәррир исеменә гариза яздыңмы соң әле?— дип сорый аңардан бер бүлмәдә утырып эшләүче шаян Илдус Сафин.

— Юк,— ди Нәсимә.

— Алайса, сеңелем, яз тизрәк. Башкалар өлгергәләгәнче ашык. Монда «сафбаш» булырга теләүчеләр уйма.

Нәсимә тиз генә гариза язып, мөхәррир Харис Әшрафҗанов бүлмәсенә кереп китә. Бераздан әйләнеп тә чыга.

— Булды, Илдус абый!— ди ул шатланып.

— Ничегрәк булды соң?— дип төпченә Илдус, җитди булырга тырышып.

— Ни... мөхәррир башта мондый гаризаны язарга кем кушты, дип кызыксынды. Әйткәч, елмайды да: «Илдус абыең рөхсәт итсә, мин риза»,— диде. Син ризадыр бит, Илдус абый?

— Ярый инде, бүлмәдәшләр бит. Риза булмыйча нишлим... Теләсәң, минем өчен дә «сафбаш» булырсың.

— Рәхмәт инде. Яхшылыгыңны онытмам, Илдус абый,— ди кызый, ихлас ышанып.

Хәзерге вакытта Чаллыда чыга торган балалар һәм яшүсмерләр газетасы — «Көмеш кыңгырау»ның мөхәррире Нәсимә Садыйкованың журналистикада «беренче чирканчык» алуы әнә шулай була.

## Кызыллар яклы булгач, ярый!

«Узган заман»да була бу хәл. Тәнкыйтьче Мансур Вәлине партиягә әгъза итеп алу өчен партбюро утырышы бара. Яшь иптәшне төрле яклап тикшерәләр, тәфтишлиләр, «капшап карыйлар».

— Эчү ягы ничегрәк соң синең?— дип сорый беркетмә язып утыручы Венера Ихсанова, нәзакатьле елмаеп.

Мансурның кыйгач кашлары күзлек өстендә бер күтәрелеп, бер төшеп уйнаклап ала. Ул әлеге четерекле сорауга ни дип җавап бирергә дә белми, аптырабрак кала. Бүлмәдә тынлык. Шул вакыт, сирәк сөйли вә сүзләрен сайлап-сайлап кына чыгара торган Сибгат абый Хәким әйтеп куя:

— Ә без... Мансур белән... Аккош күлендә... вермут салабыз!

Бюро әгъзалары көлешеп алалар да:

— Ә-ә, кызыл шәраб кына икән. Аклар белән дус булмагач, ярыйдыр шәт. Коммунист кызыллар яклы булырга тиеш тә...— дип, Мансур Вәлине партиягә әгъзалыкка кабул итәләр.

## Тун киməүнең сәбәбе

Кышкы зәмһәрир суык көннәрнең берсендә «Казан утлары» редакциясенә Туфан Миңнуллин килеп керә. Өстендә — яңа кайры тун, башында — шәп ондатра бүрек.

— Хәлләр ничек, егетләр?— дип сәлам бирә ул, көр тавышы белән бүлмәне тутырып.— Шәп яшисезме?

— Бигүк шәп түгел шул, туңабыз,— ди Мансур Вәли, күшеккән кулларын уыштырып.

Туфан елмая.

— Ник тун киеп утырмыйсыз соң?— ди ул, төрттереп.

Сүзгә Мәннәф кушыла:

— Бик кияр идек тә, тун белән пардан киярлек бүрегебез юк әлегә...— ди ул.

## «Кай арада... өлгердең?»

Туфан Миңнуллин редакция әһелләре белән гәп куертып торганда ишекне тибеп ачып, даһи шагыйрь Роберт Әхмәтҗан килеп керә. Арыслан тотарлык кына «кәефләнгән» үзе.

— Син, яшьти, кай арада... өлгердең әле?— дип сорый Туфан, сүзләренә астыртын мәгънә салып.

Робертның бу «шырпыдан» сырт йоннары кабара:

— Ничек инде ул: кай а-ра-да?!— ди ул, тавышын бөереннән чыгарып.

Туфан көлә:

— Син әллә ни уйладың, бугай. Мин бит бөтенләй башка нәрсә турында сорыйм: кай арада... поэма язып өлгердең әле?— дим.

Роберт:

— Ә-ә, аны әйтәсең икән. Ха-ха-ха!

## ЖУРНАЛИСТЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ

22 июльдә Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев Казан Кремлендә Германия, Австрия, Швейцариядән һәм Россиянең төрле төбәкләреннән килгән журналистлар белән очрашты. «Матбугат һәм регионализм» дигән 1 Халыкара гамәли семинарда катнашучыларны Җөмһүриятебез Илбашы Татарстанның иҗтимагый-сәяси-социаль хәле, икътисады, мәдәнияты белән якыннан таныштырды, милләтара һәм халыкара бәйләнешләр турында сөйләде. Соңыннан ул журналистларның күп санлы сорауларына тулы җаваплар бирде.

## ҖИҢҮЧЕЛӘР БИЛГЕЛЕ

Казан Кремлендә күп манаралы Кол Шәриф мәчетен төзү-тергезү буенча иң яхшы проектка игълан ителгән бәйге, ниһаять, тәгәлләнде. Республикабызның күренекле архитекторлары, реставраторлары һәм тарихчыларыннан торган мәртәбәле жюри җиңүчеләрне ачыклады. Беренче бүләккә Казан дәүләт архитектура-төзелеш академиясе укытучылары Айвар Саттаров, Михаил Сафронов, Искәндәр Сәйфуллин, «Татаргражданпроект»ның әйдәп баручы инженеры Шамил Латыйпов һәм академия студенты Радик Сафин эшләгән проект лаек булды.

## ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ — ТЕАТРЛАР

Татарстан Республикасы Премьер-министры Ф. Мөхәммәтшин, вице-премьер И. Хәйруллин, Мәдәният министры М. Таишев, Казан мэры К. Исхаков мәркәзебездәге Качалов исемендәге Зур драма академия театрында, Казанның Яшьләр, Татар яшьләре театрларында булып, төзү һәм яңарту эшләренең барышы белән таныштылар. Хөкүмәт комиссиясе әлеге театрларны тизрәк сафка бастыру өчен реконструкциялəү эшләрен финанслауның төп юнәлешләрен билгеләде.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ

Һәртөрле кызыклы материалларга бай булган, төсле рәсемнәр белән бизәлгән «Бизнес в Татарстане» журналының (баш мөхәррире — Хөсәен Вәлиәхмәтов) чираттагы яңа саны дөнья күрде. Бу юлы анда «Казан утлары» журналына багышланган махсус сәхифә дә урын алган. Журналыбызның баш мөхәррире Равил Фәйзуллин шул уңайдан «Казан утлары»ның данлы-гыйбрәтле үткән юлы турында рус, инглиз телләрендә чыгыш ясый. Сәхифәдә шулай ук аның һәм журналның төрле елларда чыккан саннарының төсле рәсемнәре дә урнаштырылган.

## «ТАТАР КИТАБЫ» НӘШРИЯТЫ

5 июльдә Татарстан Язучылар берлеге каршында оешкан «Татар китабы» нәшриятын тәгъдир итү тантанасы булды. Нәшрият үзенең беренче эше итеп Татарстанның халык язучысы, Тукай бүләге лауреаты Мөхәммәт Мәһдиевка багышланган «Кеше китә — җыры кала» дигән китап бастырып чыгарды. Анда әлеге язучы-галим турында мавыктыргыч истәлекләр, аның шәхси архивыннан алынган кызыклы хатлар, фотолар, төрле гуаһнамәләр (документлар) тупланган, авторның ике повесте урын алган.

Нәшриятне ачу тантанасында Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, ТР Дәүләт Советы Рәисенең беренче урынбасары, шагыйрь Р. Харис, Дәүләт Советының даими комиссия рәисе, шагыйрь Р. Миңнуллин, ТР Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Әхмәтҗанов, Татарстанның халык язучысы А. Гыйләҗев, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Р. Фәйзуллин, «Төрек дөньясын саклау фонды» башлыгы, профессор Туран Язган (Төркия) һ. б. килгән кунаклар, язучылар чыгыш ясады.

## АБДУЛЛА АЛИШ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯ

Татарстан Язучылар берлегенең идарә утырышында күренекле шагыйрь, балалар язучысы, М. Җәлилнең якын дусты һәм көрәштәше Абдулла Алиш исемендәге премия булдыру турында карар кабул ителде, бирү тәртибе тәгаенләнде. Әлеге бүләк балалар әдәбияты өлкәсендәге күренекле хезмәтләре өчен (проза, поэзия, драматургия, тәнкыйть һәм публицистика өлкәсендәге әсәрләргә), шулай ук балалар әдәбиятын пропагандалау һәм үстерүдәге эшчәнлеге өчен аерым оешмаларга, шәхесләргә биреләчәк. Премиянең күләме — 600 доллар (Бүләкнең матди ягын «Тимер» ширкәте күтәрә.) Яңа лауреатларның исемнәре һәр елны 15 сентябрьдә — Алиш туган көндә игълан ителәчәк.

## ХАЛЫК ШАГЫЙРЕНӘ БАГЫШЛАП

27 июньдә Тукай музееның күргәзмәләр залында танылган рәссам-график, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Э. Зариповның үз авылдашы — Татарстанның халык шагыйре, Тукай бүләге лауреаты И. Юзеевка багышланган шәхси күргәзмәсе ачылды. Тантанада Татарстан Рәссамнәр берлеге идарәсе рәисе А. Абзгильдин, рес-

публикабыз Язучылар оешмасы житәкчесе Р. Мөхәммәдиев, Татарстанның халык шагыйре Ш. Галиев, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Р. Фәйзуллин, Тукай музее директоры, язучы Ф. Яхин һ. б. чыгыш ясады.

## ЖЫРГА БАЙ ГОМЕР

Күренекле шагыйрь, күп кенә популяр жыр сүзләре авторы — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Исхакый исемендәге премия лауреаты Әхмәт Рәшитовның тууына 60 ел тулуга багышлап, К. Тинчурин театрында әдәби-музыкаль тамаша үткәрелде. Юбилярны ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, Татарстанның халык язучылары Г. Ахунов, А. Гыйләжев, Татарстан Мәгариф министры В. Гайфуллин, ТР Мәдәният министры урынбасары М. Низамиев, Буа районы хакимияте башлыгы урынбасары Х. Асьянов, Казандагы «Буа якташлыгы җәмгыяте» рәисе И. Закиров, күп кенә газета-журнал редакцияләре, киң җәмәгатьчелек вәкилләре, якын дуслары кайнар котладылар, бүләкләр тапшырдылар.

Кичәдә халкыбызның яраткан артистларыннан З. Сөнгатуллина, К. Хәйретдинова, Л. Әхмәтова, Р. Маликов, Ф. Сәләхов, Татар жыр һәм бию ансамбле коллективы, шулай ук «Татарстан» теле-радио компаниясе оркестры (җитәкчеләре — Л. Кустабаева, Р. Үтәй) чыгыш ясады.

15 июньдә исә Ә. Рәшитовны туган ягына — Буа районының Яңа Чәчкаб авылына чакырып, аның иҗат кичәсен шулай ук зурлап уздырдылар. Юбиляр адресына «Үзәк» күмәк хуҗалыгы рәисе Ә. Сибгатуллин, урта мәктәп директоры Р. Солтанов, мөгаллимәләрдән Р. Бариева, Н. Садыйкова һ. б. үзләренең җылы сүзләрен җиткерделәр. Авыл үзешчәннәре һәм мәктәп балалары Ә. Рәшитов сүзләренә язылган җырлардан зур концерт хәзерләгәннәр иде.

## ӘДИПЛӘРНЕ ИСКӘ АЛУ

28 июньдә бер төркем язучылар һәм матбугат эшлеклеләре (Г. Ахунов, Р. Мостафин, Х. Әюпов, Г. Шәрәфетдинов, Х. Әшрәфҗанов, А. Миңһаҗева, И. Ихсанова, Р. Даутов һ. б.) Арча районының Ишнарат авылына барып, күренекле тәнкыйтьче һәм матбугат эшлеклесе Фәрваз Миңнуллинның каберенә зиярәт кылып, чәчәкләр куеп кайттылар. Язучылар белән бергә Казанның Җәмигъ мәчетеннән килгән Гыйлмулла хәзрәт кабер янында Коръән укыды, калган иптәшләр мәрхүм турында истәлекләре белән чыгыш ясадылар. Юл уңаеннан әлеге төркем Гөберчәк авылындагы Мөхәммәт Мәһдиев кабере янында да булды, анда да Коръән укылды һәм истәлекләр сөйләнде. Сәяхәттә М. Мәһдиевнең хатыны Лилия Мәһдиева һәм мәрхүмнәрнең гаилә дусларыннан Диләрә Даутова һ. б. бар иде.

## ОЧА ТОРГАН ТАТАРГА ҺӘЙКӘЛ

Атаклы милләттәшебез — дөньякүләм танылган биюче Рудольф Нуриевның Париж янындагы Сен-Женевьев-де-Буа бистәсендәге каберенә һәйкәл куелды. Һәйкәлнең авторы — итальян рәссамы Эццо Фиджерио. Ул заманында Р. Нуриевка, сценограф сыйфатында, берничә балет куешырга ярдәм иткән булган.

## «ТАҢБАТЫР»ГА — ГРАН-ПРИ

Яшь кинематографчыларның Ашхабад шәһәрендә үткәрелгән халыкара фестивалендә Татарстанда эшләнгән «Таңбатыр» мультфильмы (фильмның режиссеры — Гарик Сәйфетдинов) Гран-прига лаек булды.

## «ТАТАР БАЯНЧЫЛАРЫ»

Үз эшчәнлеген көннән-көн яхшырта-камилләштерә баручы «Мәгариф» нәшрияты (директоры — язучы Мөдәррис Вәлиев) сәнгать сөючеләр өчен матур бүләк хәзерләде — татар халкының иң оста баянчыларының иҗат һәм тормыш юлларын яктыртучы публицистик язмаларны берләштергән китап бастырып чыгарды. «Татар баянчылары» дип исемләнгән әлеге сувенир китапның төзүче-авторлары — Татарстанның атказанган артисты, баянчы Кирам Сатиев һәм язучы Нияз Акмалов.

## БАЛАЛАР ӨЧЕН БЕРЕНЧЕ АУДИОКАССЕТА

Казанның «Магнит тасмалар һәм техник пленкалар» акционерлык җәмгыяте мәктәпкәчә яшьтәге нәниләр һәм укучылар өчен «Сабыйга» дип исемләнгән беренче аудиокассета эшләп чыгарды. Аңа сөекле язучыбыз Г. Тукайның иҗат мирасы үрнәкләре — балалар өчен шигырьләре, әкиятләре яздырылган. Шунда ук танылган композиторларыбыздан Ф. Яруллин, Ә. Бакиров, Н. Җиһанов, М. Мозаффаров әсәрләре дә урын алган...

Әлеге язманың сценарий авторы, баш каручысы һәм продюссеры — артистка Рузалия Зәкиева, музыкаль җитәкчесе — Сагыйт Хәбибуллин, музыкаль редакторы — Мөнирә Хәбибуллина.

## ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ ҮЗӘГЕ

Ут күршебез Марий-Элнең Бәрәңге районында Республика Татар мәдәнияте үзәге ачылды. Әлеге үзәкнең директоры — Казанда махсус югары уку йортын тәмамлап кайткан Нурислам Мөхәммәтовның тынгысыз эшчәнлеге нәтиҗәсендә, милләттәшләребезгә мәдәни хезмәт күрсәтү сизелерлек җанланды. Бию, җыр, театр түгәрәкләре, «Алтын Ай» дип исемләнгән эстрада ансамбле оештырылды.

Татар Мәдәнияте үзәге үзенең филиалларын Йошкар-Олада һәм татарлар күпләп яши торган авылларда ачарга да нияттә.

# ХАНСӘВӘР ИШАН ШӘМАИЛЕ

Сембер өлкәсе Иске Кулатка районы Зимница авылына мине бер төркем Казан галимнәре арасында йөргән «көзгеле шәмаил» яисә «ишан шәмаиле» турындагы риваять китерде. Чыннан да, бу гали ядкарьне күргән-белгәннәр аның кабатланмас гүзәллеге, идәннән-түшәмгә кадәр биеклеге, затлылыгы һәм, гомумән, аны гадәти шәмаилләрдән өстен иткән гаҗәеп сыйфатлары хакында ничектер серле итеп сөйлиләр иде. Шәмаилнең бүгенге хуҗасы — авылдашлары арасында белемлелеге, хәбәрдарлеге белән аерылып торган, кайчандыр Урта Азияләрдә, Ташкентларда яшәп, 1948 елда кире туган ягына кайтып егылган, серле ишанның шәкерте — гарәп, фарсы сүзләрен катыштырудан туган әллә нинди «галәмәт» телдә сөйләшүче Кәшафетдин абзый безне күрүгә кырт кисте: «Доганы Казанга бирәсем юк... Казанлылар дин тотмыйлар... Алланы бар дип белмиләр. Коммунистлар сез...» Бу вакыйга 1987 елда, җәй булып үтте. Данлыклы шәмаил Кәшаф абзыйның йортында калды. Без аны рәсемгә төшереп алу бәхетенә генә ирештек.

Шәмаилнең «көзгеле» дип аталуы әлеге аның буена, көзгесыман дәү һәм затлы өслегенә караганлыгы аңлашыла. Ә ни өчен соң ул тагын ишан шәмаиле дип йөртелә?

Теге гасыр ахыры — егерменче йөз башында Зимницада яшәгән Хәбибулла ибне Хансәвәр тирә-якта атаклы кеше булган. Мәдрәсә салдырган, дәрес биргән; дин гыйлемен тирән белгәнгә, аны ишан дип йөрткәннәр. Ул хаҗга барган; Төркиягә сәяхәт иткән. Шәрекъ телләрен су кебек эчкәнгә, дини бәхәсләрдә җиңгән. Иң әһәмиятлесе — 700 дән артык мөрите-варисы булган. Шәмаил шул Хансәвәр ишан йортыннан икән. 1920 елда Хансәвәр ишанның мәдрәсәсен ябып, үзен сөргәннәр. Ә шәмаил исә, аның хезмәтчесе һәм шәкерте булган Кәшәфетдин абзый тарафыннан саклап алып калынган. Әйе, шәмаил, чын мәгънәсендә, олугъ вә хикмәтле... Зәңгәр-алтын төсләр, сыгылмалы матур хәрефләр яшькелт-күк пыяла яссылыгында, әйтерсең лә, чынлап тора! Аның хакында, Төркиядән килгән, дигән версия дә бар. Тәгаен шулай булуы мәгълүм түгел. Аны Төркиядән алып кайткан мәчет рәсемнәре буенча җирле рәссамнең яки берәр Казаннан чакырулы нәккашның башкаруы да ихтимал.

Метр ярым чамасындагы вертикаль композициянең фоны, гадәткә кергәнчә, кара түгел, зәңгәрсу-фирәзә. Рәсемнең өске зур өлешен күктә салават күпере кебек ярылып яткан, «аятелкөрси» догасы язылган дуга рәсеме алып тора. Бу сурәтнең нигезендә — Ходай Тәгаләдән пәйгамбәребезгә ниндидер шигъри аваз — сигналлар, космик информация формасында ирештерелгән коръән аятьләре. Аста: яшькелт-зәңгәр-соры су — диңгез образы (Босфор!) Уңнан-сулга, кабатланып килгән бизәксыман, түгәрәкләп, гомумиләштереп сурәтләнгән мәчет биналары, манаралар: Суфия, Солтан Әхмәт, Сөләймания силуэтлары. Гарәп язуы сыман бер-беренә тоташтырып, «керештереп» язылган мәчетләр тәсбихы уңдагы алтын утлы капка рәсеме ярдәмендә дини концепциягә теркәлә: аятьләр сафлыгын, мәчетләр пакълеген, Хак тәгаләнең хикмәтле сүзләрен йөрәкләрдә саклаган һәм бары тик изгелек кылган адәмнәр генә шушы алтын капкаларны кичеп, җәннәт бакчаларына тап булырлар... Югары почмактагы, кош сайравыдай гүзәл, асыл чигүләр дә җәннәт образын ассызыклыйлар. Дуга астындагы ай-кояш бизәгенә әйләндерелгән «Әгүзе билләһи...» композициянең гади ноктасы, космик үзәк — Аллаһы тәгаләнең иҗади кодрәтенә мәдхия.

Татар сынлы сәнгатенең формалашу юлларында — каллиграфия ысуллары белән — туып килүче пейзаж чалымнарын берләштерү нәтиҗәсендә туган бу шәмаил — без күнеккән, һәвәскәр оста тарафыннан башкарылган примитив түгел. Ул, чын мәгънәсендә, синкретик сәнгать һәм аның авторы да тиңдәшсез профессионал...

**Розалина ШАҺИЕВА,**
сәнгать белгече.

**Тышлыкның беренче битендә:** Хансәвәр шәмаиле. Билгесез автор эше.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы Лирон Хәмидуллин.

# ӘДӘБИЯТ СӨЮЧЕ ДУСЛАРЫБЫЗ!

Тагын Сезнең исегезгә төшерәбез: шушы елның сентябреннән 1997 ел өчен татар халкының төп журналы «Казан утлары»на язылу башлана.

Журналыбызны алдырырга теләүчеләр өчен әзер әбүнә кәгазен тәкъдим итәбез. Аны журнал битеннән пөхтә генә итеп кисеп алырга һәм тәртип белән генә кирәкле графа-бүлемтәләрне тутырырга, аннары элемтә (почта) бүлекчәсенә тапшырырга кирәк.

Әбүнәчеләребез өчен «Казан утлары»ның ярты еллык бәһасе: республикабызда яшәүчеләр өчен — 15 мең сум (димәк, бер еллыкка — 30 мең сум!), Татарстаннан читтәгеләр өчен — 13 мең 200 сум (соңгыларына, транспорт чыгымнары да өстәлү сәбәпле, журналга язылу бәһасе бераз киметелде). Республикабызда чыга торган башка басмалар белән чагыштырганда, иң арзан бәя бу!

Ф. СП-1

Министерство связи СССР
«Союзпечать»

**АБОНЕМЕНТ** на газету / журнал **73210** (индекс издания)

„Казан утлары" (наименование издания) | Количество комплектов

на 19 97 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда (почтовый индекс) (адрес)

Кому (фамилия, инициалы)

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

ПВ | место | литер | на газету / журнал **73210** (индекс издания)

„Казан утлары" (наименование издания)

| Стоимость | подписки | ___руб. ___коп. | Количество комплектов |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ___руб. ___коп. | |

на 19 97 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда (почтовый индекс) (адрес)

Кому (фамилия, инициалы)

Билгеле булганча, киләсе елның маенда «Казанда утлары»ның чыга башлавына 75 ел тула. Шул уңайдан, журналыбыз үзенең битләрендә берсеннән-берсе мавыктыргыч роман-повестьлар, хикәя-парчалар, шигырь-поэмалар, халкыбыз тарихына һәм мәдәниятенә караган, күренекле шәхесләребезнең эшчәнлеген һәм тормышын яктырткан кызыклы язмалар бирәчәк, иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздагы яңалыклар, яңа китаплар, рәссамнарыбызның иҗат үрнәкләре белән даими таныштырачак.

**Журналыбызның индексы — 73210.** Ул Татарстан һәм Россия күләмендә чыгарылган каталогларга кертелгән (Россиянеке — зәңгәр төстә).

Киләчәктә дә бергә булыйк, кадерле дуслар!

## ПРОВЕРЬТЕ ПРАВИЛЬНОСТЬ ОФОРМЛЕНИЯ АБОНЕМЕНТА!

На абонементе должен быть проставлен оттиск кассовой машины.

При оформлении подписки (переадресовки) без кассовой машины на абонементе проставляется оттиск календарного штемпеля отделения связи. В этом случае абонемент выдается с квитанцией об оплате стоимости подписки (переадресовки).

---

Для оформления подписки на газету или журнал, а также для переадресования издания бланк абонемента с доставочной карточкой заполняется подписчиком чернилами, разборчиво, без сокращений, в соответствии с условиями, изложенными в каталогах Союзпечати.

Заполнение месячных клеток при переадресовании издания, а также клетки "ПВ-МЕСТО" производится работниками предприятий связи и Союзпечати.

Татарское отделение "Росбланкиздат". 1/24/112/. 02.95 г. т. 350000 Асбест. тип. 3. 641.

# ЯҢА КИТАПЛАР




**Арча төбәге тарихы.** Төзүчеләр — К. Низаметдинов, И. Хәлиуллин. Казан: Татарстан китап нәшрияты. 1996 ел. 256 бит. Тиражы — 3000 данә.


Арча — Татарстанның иң зур районнарының берсе, үзенең хезмәт сөючән халкы белән шөһрәт казанган төбәк. Аның бай тарихы, шул җирлектә туган һәм буыннан-буынга туплана килгән рухи мирасы бар.

«Һәр төбәкнең үзенә генә хас йөзе, тарихи традицияләре бар... Районыбыз татарның атаклы шәхесләрен күпләп биргән. Без моның белән горурланабыз. «Уңдырышлы Арча туфрагы». Туры һәм күчерелмә мәгънәдә без шулай әйтәбез», — дип яза Арча районы хакимияте башлыгы Вәгыйз Минһаҗев. Әйе, ул бик хаклы. Мәдәни тарихыбыз һәм әдәбиятыбыз дөньясында тирән эз калдырган кайбер шәхесләрне генә искә төшерик: Г. Курсави, Ш. Мәрҗани, Г. Тукай, М. Галәү, Г. Бәширов, М. Мәһдиев, Г. Ахунов, Р. Төхфәтуллин...

Китап өч бүлектән (I. Чал тарих авазы; II. Авыллар тарихы; III. Тарих һәм шәхес) тора. М. Мәһдиев, М. Әхмәтҗанов, Р. Галләмов, Р. Салихов, Р. Хәйретдинов, К. Низаметдиновлар составындагы авторлар коллективы Арча төбәге тарихын шактый киң яктырта алганнар.

Татар һәм рус телләрендә чыккан бу китапта, шулай ук, академик И. Таһировның укучыларга адресланган кереш сүз — юлламасы да урнаштырылган. Гомумән, республиканың башка төбәк җитәкчеләре өчен дә үрнәк алырлык башлангыч бу китап.

Индекс 73210



ЗАН УТЛАРЫ
I UTLARЫ
КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)